Вахит Имамов

КАЗАН ДАСТАНЫ

Тарихи роман

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2005

УДК 820/89 (470)
ББК 84 (2Рос=Тат)-44
И 48

Имамов Вахит

И 48 Казан дастаны: Тарихи роман. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. — 239 б.

Танылган язучының әлеге китабында Казан каласына нигез салынган чорлардагы вакыйгалар зур осталык белән сурәтләнә.

ISBN 5-298-04137-X

© Татарстан китап нәшрияты, 2005
© Вахит Имамов, 2005

КАЗАН ДАСТАНЫ

(*Тарихи роман*)

Казанның 1000
еллыгына багышлана

1

Алмыш ханның онығы Габдулла таждар бүген ау-сунарга чыга. Иртәдән бирле Биләр өстендә дәртле аһәң йөзә:

— Габдулла хан савыгып аягына баскан!

— Габдулла хан бүген яраннары белән күңел ача!

Бар тарафтан пайтәхет капкаларына ак күбеккә баткан чапкыннар чабып-очып кына кереп тора. Иреннәрдә гел шатлыклы хәбәр:

— Ашлы әмире Сәлман илле мәргәне белән килеп җитә!

— Болгар олугбәге Хаммат кырнакларына чаклы үзе белән алган!

— Кашан олугбәге килеп җитәргә ике фәрсах кына ара калды!

Габдулла ханның күңелендә дә бәйрәм. Узган көздә аны Сарытау яныннан чатырлы арбада, киез өстенә салып кына алып кайтканнар иде. Кыш буе имчеләр өшкерде, табиблар биеде һәм, Ходайга мең шөкер, Габдулла хан янә ияр өстенә менәргә, кулына гөрзи-җәя алырга да әзер. Хәбәр китми калмас, дошман белеп торсын. Габдулла хан бүген сунарлыкка гына чыкмый. Габдулла ханның бүген-иртәгә яуга чыгуы бар!

Яңа хәбәр килеп кергән саен, Габдулла хан күңелендә сөенеч арта бара. Төп калалардагы олугбәкләр килеп җитә икән, димәк, алар кул астында булып исәпләнгән барсил, искил, бәрәнҗәр кабиләләре дә Габдулла хан данын зурлый, яклый. Эшләр болай уңай тора икән, алар инде ауга-сунарга гына түгел, хәтта Габдулла хан әләме астына басып ерак яуларга чыгарга да әзер дигән сүз бу... Тик Нур-Суар каласының олугбәге Талиб Шәмсидән хәбәр юк бит әле менә. Юлда гына тоткарлануымы, әллә килмәвеме? Әллә... әллә һаман киреләнә, санга санамыймы? Суар кабиләсенекеләр гомер буе шулай. Алмыш хан аларны көч-хәл белән генә

ипкә-сапка кертә алган иде. Әле ярый, суарлар Алмыш хан җиде диңгез, җитмеш дәрья аръягындагы Баһдад хәлифе юллаган илчелекне кабул иткән чакта сынатмады. Чит-ят кунаклар алдында үзләрен пырдымсыз, киребеткән аеры кавем итеп танытмадылар, бер гаилә балалары булып күренделәр. Шул илчеләр бар Болгарга ислам динен кабул иттереп китте. Әмма... Алмыштан соң Биләр тәхетенә аның улы — Габдулланың әтисе Микаил менүгә үк, Суардагы әмир Шәмси тагын тәртәгә тибә башлады. Йә йөз хәйлә табып Микаил чакырган яуда катнашмый калды, йә хан белән бертигез кыйланып үзенең Суарында акча сугып ятты. Инде менә Шәмсинең улы Талибны да үз белдеге белән акча суга, диләр. Узган ел бортаслар өстенә яу белән барганда да олугбәкләр арасыннан Талиб үз алайлары белән гаскәргә иң соңыннан гына килеп кушылды. Иртәгә нинди мөгез чыгарыр — моны шайтан үзе генә белә...

Дөрес, максат итсәң, бер Талибны гына тез астына бөтереп салып була инде ул анысы. Әнә бит, бәрәнҗәрләр, барсилләр, искилләр, алардан тыш әле сабакүллеләр, тәмте, чалмат, башкорт ырулары — барысы да Болгар ханы ягында. Ачуың кузгалдымы, хәбәр сал, сызгыр гына. Һәммәсе дә алайлары[1], нөгәрләре[2], чирүләре[3] белән килеп җитәчәкләр. Ә аннары җир өстеннән хуш бул, тәкәббер һәм киребеткән Суар! Гомумгаскәр, көлеңне дә калдырмыйча, ярты көн эчендә тетеп ата сине!..

Ләкин... алай кыйланырга һич тә ярамый бит. Көтүдәге ике үгез сөзешә башладымы, аларның һәр икесе бүре тешенә эләгә. Дошманнар болай да хәттин ашкан. Ука елгасы аръягыннан ел да урыс ушкуйлары янап тора. Җаек аръягыннан кара аймыклар белән бәҗәнәкләр, кыпчаклар, угызлар тынгы бирми. Сарытау ягында, борын төбендә генә бортаслар чәбәләнә. Һәм иң яманы — Хәзәр каганлыгы ашый Болгар башын, шул чак кына да тездән күтәрелергә, тураеп басарга чама бирми...

Ah, онытып торырга кирәк боларны, уйламаска кирәк! Иң мөһиме: Габдулла ханның башы исән-сау бит! Ул савыгып аягына басты һәм ул да ау чыгарга, күңел ачарга лаек ласа!..

Янда Хәдичә бөтерелеп йөри. Яу сәфәренә әзерләнгән диярсең, ул нәкъ ирләрчә итеп, сугыш киемнәре киеп алган. Толымнарын, бөтереп, көмеш очлым астына яшергәндер инде, бөтенләй күренмиләр. Тәненнән-сыныннан ялкын бөркелеп тора. Һич кенә дә бишенче дистәсен ваклаган баш хатын димәссең син моны. И-их, бик сусаган, өзлеккән юл-

[1] Алай — полк.
[2] Нөгәр — отряд.
[3] Чирү — гаскәр.

чылар килеп җитүгә үк тилмереп төбәлә торган тирән кое төбендәге су шикелле талымлы һәм назлы күзләрендә моң һәм сагыш чалымнары да булмасамы?! Тик юк бит, юк, күзләрендә сагыш сүнми аның. Шул Хәзәр каганы Манас кулындагы кызы Бәнат турында кайгыру галәмәте бу. Бәнат, Бәнат... Каган ятагына аманат итеп озатылган, мәмләкәт иминлеге хакына сатылган кәнизәк кыз. Сыер, елкы, сарык урынына Манас хәрамханәсенә кертеп ябылган колчура хан кызы... Их, онытырга иде, бүгенгә генә булса да уйламаска иде бу турыда!..

Сарай ишегеннән Борак килеп керде. Борак әле яшь, авыз колакта. Сәрдәр сәрдәр инде. Ауга түгел, яуга бара диярсең, иңнәренә-биленә бар коралын аскан. Җәя, садак, ятаган кылыч, хәнҗәр, гөрзи... Ике яклап иягенә салынып төшкән мыек чылгыйларын сыйпаштырган була, ә табак кебек җәелеп киткән иреннәрен барыбер җыя алмый.

— Тәмтедән Шөгер бәк килеп җитте. Сабакүл, Жүкәтау бәкләре дә монда. Һәммәсе җыелдылар. Юлга чыга башласак та була.

Ханның карашында капылт очкын кабынып китте, әйтерсең лә эчендә шайтан учак якты.

— Ә Нур-Суардан Талиб?

— Әттә... әттә... генәсе, — дип сакауланып торды-торды да Борак, борчак сипкән шикелле, тиз-тиз тезеп салды: — Аларның нөгәре бишбылтыр ук килеп җитте бит инде. Кушкүл буендагы яланда аш пешереп ята.

— Нишләп миңа кереп әйтүче юк? — дип, Габдулла хан, әүвәл йодрык болгый-болгый, Борак өстенә килә башлаган иде дә, кибәндәй олы гәүдәле сәрдәрнең кыл да кыймылдатмыйча, өстәвенә элеккечә авыз ерып торуын күргәч, үзе дә пырхылдап җибәрмичә булдыра алмады.

— Әллә кайчан кереп әйтәләр аны, и, тавык баш!..

Биләрдән сорнайлар кычкыртып, ат уйнатып чыгып киттеләр. Кәрван озын елга чаклы сузылган. Алда хан һәм аның яраннары. Уртада һәркайсы иртәгә үк тәхеткә менәргә хокуклы Суар, Кашан, Ашлы, Болгар калаларының әмирләре. Алар артына үз дәрәҗәләрен белеп кенә зур-зур олысларның мөхтәрәм бәкләре тезелешкән. Артта кубызчылар, пешекчеләр, ат караучылар, сакчы торгаклар, кәнизәкләр; шоңкар, лачын, бөркет ияләре.

Габдулла ханның күзе күбрәк улы Мөхәммәттә. Озын буйлы, киң җилкәле, түгәрәк сакал-мыектан. Сарайдагыларның барчасы да аны коры холыклы, каты куллы, диләр. Утызын тутырып килә инде, ә аның кул астына вилаять, бәйлек түгел, хәтта кала яки олысның да эләккәне юк әле. Әтисеннән көн саен ук булмаса да, атна саен сорый:

— Берәр олыс йә кечерәк вилаятькә гади бәк итеп булса да җибәр инде, әткәй? Синең итәктән төшәргә вакыт җитте миңа.

Габдулла хан дәшми. Аның үз исәбе. Бәклек качмый, игенче-сабанчылар белән һөнәрчеләрдән җыйган салым хисабына типтереп яшәү өчен алланың кашка тәкәсе булу кирәк түгел. Вакыты җиткәч, Мөхәммәтнең дә тәхет дигән «җен»гә утырасы бар. Болгар мәмләкәтендәге бәкләр генә түгел, читтәге ханнар, кенәзләр, барча таҗдарлар белән эш йөртә белгән хаким итеп үстерәсе иде бу малаен. Кайсыдыр ханны алдап-юмалап тота, икенчеләре белән солых, берлек төзи белә торган хаким булып җитешсен иде аның улы! Бу Хәзәр каганының тырнагы астыннан ычкынырга, беркемгә дә буйсынмаган, бәйсез Болгар мәмләкәте төзергә иде бит инде!..

Их, тагын уйлар читкә кереп китте!..

Габдулла хан үзе белән кырнак кызлар — җарияләр дә алды. Фани дөньяга бер генә киләсең бит, типтереп, рәхәтен белеп калырга кирәк! Түшәк өстендә кан косып яткан вакытта, әнә беркемгә дә аның һәм аңа да һичкемнең кирәге юк иде. Бөтен теләк — исән калу булды. Ә хәзер ул исән, ул яңаданияр өстендә! Тәндә — дәрте, күңелдә дәрманы бар. Талиб, Хаммат, Сәлман ише әмирләр мыскыллап, шикләнеп карарлык булмасын. Аллага шөкер, иллегә җитеп килгән Габдулла ханның мәчесе дә тычканны шәп тота! Күрегез, белегез, минем сезнең борыныгызга чиертерлек кенә дәрманым бар әле!

2

Ау барып чыкмады. Кораса елгасы аръягындагы Меңказ дигән күл буена матур гына барып урнашканнар иде югыйсә. Колчуралар, сакчы, мәргәннәр зирек, шомырт, балан куаклары ышыгына киез чатырлар кордылар. Бәкләр белән әмирләр күлнең вак-вак таллыклар белән капланган почмагында, Хәдичә ханәш җитәкчелегендәге байбичәләр, кызлар, кәнизәкләр — һәммәсе берьюлы төнбоеклар яткан уйсулыкта су коенып чыктылар. Аннары күл буеннан унбишегерме адымда әллә ничә учак яктылар да, шулар тирәсендәге уен-көлке, җыр-биюләр, аркан тартыш, көрәш, чыр-чу килгән авазлар ярты төнгә чаклы дәвам итте. Габдулла хан күңеленең һәр почмагы түм-түгәрәк иде, һәммәсен дә елмаеп кына күздән кичереп утырды. Канәгать калырлык, җаны тыныч, ваемсыз булырлык нигезе дә бар иде шул. Чөнки тәхеткә куркыныч янардай әмирләрнең дүртесе дә монда. Талиб, Хаммат, Сәлман, Кашан бәге Ялкын. Болардан башка бәрәнҗәрләр, барсил, искил, суарларның бер генә нөгәре дә

Биләр капкаларын бәреп керә алмый. Бүтән төрле, көтелмәгән дошман табылса да, пайтәхетнең диварлары бик-йозаксыз түгел. Сәет Хәсәншәех шунда калды. Баш вәзир Миңлебакир анда. Иң мөһиме: бер меңкешелек алпарлары[1], газиләре[2], угъланнары[3] белән Габдулланың уртанчы малае Галделвәһап шунда.

Габдулла хан болай да кыска җәйге төннең калган ярты-сын хатыны Хәдичә ханәш куенында гына үткәрмәкче иде, таң атып килгәндә үк ашына таракан төште.

— Биләрдән, Габделвәһап әмирдән чапкын килде. Яшерен хәбәре бар, — дип, сәрдәр Борак куйган җансакчылар кереп уяттылар.

Чатырлар киездән булса да, алар меңколаклы. Габдуллага, киенеп, күл буендагы яланга чыгарга туры килде. Әле җимешләре ямь-яшел көенчә утырган зур шомырт агачы төбендә ак күбеккә баткан бер ат тора. Янда — йөзе тиргә, тузанга буялып беткән чапкын. Шулай да таныды хан. Узган көздә үк әллә кайдагы Үзи елгасы[4] буена, Кияү каласына[5] шымчы итеп озатылган Даян мәргән бит бу.

Габдулла хан өлгер, җитез атларга тырышып, якындагы калкулык өстенә төбәп китте. Даян — түрә сарайлары тирәсендә буталып шомарган таш — күләгә кебек тавышсыз-тынсыз гына аңа тагылырга мәҗбүр булды. Калкулык түбәсенә менеп, әйләнә-тирәгә күз йөгерткәч, Габдулла хан, гыжлавын басып, кыска гына дәште:

— Нинди утлы хәбәрләр төяп кайттың? Сөйлә, мәргән.

Даян калкулык өстенә ашыгып менүдән бигрәк, ерак юллар үтә-үтә талчыккан иде, ахры. Кылыч кынына таянып, бөгелә төшебрәк сүз башлады:

— Утлы дип әйтәсең дә, Габдулла хан, юк, безнең өчен хәвефле яңалыклар юк шикелле. Шулай да чапкын өчен алтмыш көнлек араны кырык көндә үтеп кайттым әле менә.

Габдулла хан мыскыллы елмаеп бүләргә мәҗбүр булды:

— Алай артыңа ут капкандай чапкач, сәбәбе бардыр инде.

Даян җитдиләнде.

— Игорь кенәзне үтереп ташладылар анда. Древляннар. Ике каен агачына бәйләп урталай аерганнар.

Габдулла ханның ияге олы бияләй шикелле салынып төште, борын өстенә җыелган куе кашлары астында ике күзе ялык-йолык килде.

---

[1] Алпар — тоташ тимер көбәгә төренгән сугышчы, рыцарь.
[2] Гази — сугышчы.
[3] Угълан — ныклы коралланган җайдак.
[4] Үзи елгасы — Днепр.
[5] Кияү каласы — Киев.

— Ке-нәз-не-е? Игорь кенәзне-е-ме-е? Нич-чек инде үтереп? Ул якын-тирәдәге ничәмә-ничә кенәзне үзенә буйсындырды. Безнеңчә әйтсәң, Игорь аларның ханы лабаса ул.

Габдулла калтыранды, ә Даян мәргән бу өшәнү-шомнарны юлда кайтканда ук коеп калдырган, күрәсең, кабак төше ярган шикелле генә, җиңел дәвам итте:

— Ханын хан, мәгәр менә аның да башын тотып ашаганнар бит әле. Дөресен әйткәндә, үз башына үзе җиткән инде. Нәфес, нәфес, бүтән берни түгел.

Габдулла кырысланды, тешләре шак-шок килде.

— Дилбегәңне кыскарт. Кайда, нигә үтергәннәр аны?

— Игорь салым җыярга чыккан. Дружинасы белән. Нигә шәхсән үзе җыярга алынгандыр инде, анысын Ходай Тәгалә үзе генә белә. Бәлки, боярларына ышанып җитмәгәндер... — Даян мәргән каш астыннан гына ханга күз ташлады, тегесенең йөзе үзгәрешсез иде. — ...Древляннар дип аталган кабиләгә барган. Тегеләр карышмыйча, күпме тиеш, шулкадәрле салым биреп озатканнар моны. Күрәчәктер инде, кайтыр юлның яртысына җиткәч тукталган бит Игорь. «Болар салымны бик тиз җыеп бирде, мин болардан аз алганмын икән», — дип хафага ук төшкән. Аннары ярты дружинасын салым төягән олаулар белән Киевка озаткан да, үзе кире киткән. Древляннар Коростень дигән кала эченә кереп бикләнгәннәр. Кенәзләре котырта башлаган: «Бүре көтүгә бер ияләшсә, барча сарыкларны талап бетермичә тынмаячак», — дигән. Шуннан соң древляннар Киев дружинасы өстенә ташланганнар да барча газиләрне кырып бетергәннәр. Ә Игорьның үзен ике яшь каенга бәйләп урталай аерганнар*.

Даян сөйләүдән туктады, ә Габдулла ханның йөзе балавыз шикелле катып калган иде. Авызына вак таш капканмыни, бер сүз дәшми. Аның йөзеннән-кыяфәтеннән һични аңларлык түгел. Ул бу җиһаннан бөтенләй аерылган, чоңгыл эченә кереп чумган сыман. Зиһенендә, күңел түрендә генә буран кайный.

«Ә мин салымны болгарлардан бик күп талыйм микән? Сабанчылар белән һөнәрчеләр еллык табышларының уннан бер өлешен миңа биреп бара. Сәүдә юлын таптаучылар белән аеры хисап. Тагын... мөселманнар мәчетләргә гошер сәдакасы түли. Шул ук сабанчы белән һөнәрчеләрне яңа кала, яңа кирмәннәр төзелешенә куалыйлар. Яуны-фәләнне искә алмасаң, башка төрле талау юк та бугай. Шул безнең дингә күчмәгән кара чирмешләргә генә икеләтә салым түлә-

---

* 945 елда булган вакыйга.

тәм мин. Кыз-зык, кара чирмешләр мине дә шулай каен ботагына тотып асар иде микән?»

Габдулла хан җиһанга әйләнеп кайтты шикелле, таш чәйнәгәндәге сыман чытырдавык тавышы яңгырады:

— Ә син миңа моны хәбәр итәр өчен генә кайтмагансыңдыр ла инде. Җан-фәрман чабулап. Алтмыш көнлек юлны кырык көндә үтеп. Йә, ачып сал, сандыгыңда нинди еланнар бар тагын?

— Аның калганнары да безнең өчен зыянга түгел бугай, — диде Даян үпкә белдермичә. — Әгәр үгезләр үзара сөзешә башлый икән, сыерлар ял итә. Киев тәхетенә утырырга тиешле Святослав бик яшь, хәзер аның урынына дилбегәне мәрхүм Игорьның хатыны Ольга үз кулына алган. Аңа башка каладагы кенәзләрнең күндәмлек күрсәтеп, бил бөгеп яшәүләре бик икеле. Бүген булмаса, иртәгә баш күтәрә, үзара сугеша башлаулары мөмкин.

Габдулла хан калкулыктан бөтенләй читкә, Меңказ күле буендагы чатырларга карап тора иде. Янә кырыс тавышы ишетелде:

— Кияү каласындагы байлар, баярлар ул Үлгәгә бер дә терәк-мазар булырлык түгелмени? Ахыр чиктә, дыружинасы дидең бит әле, газиләре инде, шулар ни кылмакчы була?

— Бөтен галәмәт тә шунда. Киевтагы байлар да, дружина да тоташы белән Ольга ягында. Дөрес, хак булса, дружинаның сәрдәре Свенельд инде күптән Ольга белән ятак бүлешә, диләр. Очкынсыз гына төтен булмый калмас, Свенельд хәзер Киевтагы иң бай бояр. Ничек кенә булмасын, мәгәр Ольга ире Игорь җыеп калдырган бар салымны төяп, хәзәрләр пайтәхетенә озаттырган, диләр.

— Һе-һе! Оста хатын бу. Манас каганны сатып алырга җыенадыр инде.

Габдулланың тавышы бу юлы коры ботак-санак сынган сыман чытырдап һәм зәһәр яңгыраса да, Даян дәртен кузгатмыйча гына янә тезде:

— Юк, бер дә Манасий каганны сатып алырга җыенмый ул хатын. Миңа Ольга дружинасына ялланган ике угыз сатты. Әтилдә кенәзләрдән качып киткән урыслар бик күп икән. Алар хәзер пайтәхеттә меңәр-меңәр исәпләнә, диләр. Әтилне үземнең барып күргәнем юк бит. Анда урыслар аерым бистә корып урнашкан, ди. Ольга Киевта тупланган салымны менә шушы качак урысларны сатып алыр өчен озаттырган. Алар Әтилдә фетнә күтәрсен һәм яһүди Манасий каганны алып атсын өчен.

— Әт-тәт-тәт-тә! — дип сузып торды Габдулла хан, үз колакларына үзе ышанмыйча. — Оста гына түгел, елан бит бу!.. Әмма... әмма...

Габдулла хан бер мәлгә тукталып калды. Чигәләрен, маңгаен бармаклары белән угалады. Даян ягына борылып баскан чакта, йөзе инде җитди, уйчан иде.

— Әле кырык көнлек юлдан кайткан гына булсаң да, тагын иярге менәргә туры килә сиңа, ачуланма, мәргән. Син салырга өлгергән сукмакларны, син үтеп керә алган куышарыкларны беркем белми. Таныш-белешләреңдә инде җитәрлектер. Синең яңадан пәйда булуың да беркемдә шик уятмый. Шуңа күрә, бар, вәзир янына кереп, үзеңә җитәрлек алтын-көмеш ал да яңабаштан Кияү каласына, ул елан хатын янына кит инде син. Кирәк икән, көләш тап үзеңә, гаилә кор. Ләкин ятла. Урыс пайтәхетенең үзәгендә яткан чакта сине бер йөз, бер мең газиләр дә алыштыра алмый. Бөтен Болгар мәмләкәтенең күзе-колагы син.

Даян җавап итеп бер сүз эндәшмәде. Күренеп тора, тагын ерак юлга, чит-ят җиргә чыгып китәргә күңеленде дәрт-дәрман юк иде. Габдулла хан шуны сизеп алды, күрәсең, калкулык түбәсенә менеп, Даян мәргәнне кочагына кысты.

— Мәмләкәтебез иминлеге өчен, Болгар өчен шулай кирәк, мәргән, үпкәләмә миңа. Вакыт җитәр, кайтарырбыз сине. Ышан, кайтарырбыз…

Даян атлый-юырта дигәндәй аска томырылды. Бераздан аның армас аргамагы янә Биләр юлы буйлап тузан болыты туздырып чаба иде. Габдулла хан аны тәмам агачлар, ерымнар эченә кереп югалганчы күзәтеп торды да калкулык түбәсенә чүгәләп уйга калды.

Кияү каласының ханбикәсе Әтилдәге урысларны фетнәгә күтәрергә әзерләнә, диген. Димәк, Манас каган тырнагы астыннан чыгарга, салым түләүдән туктарга, аңа баш иеп яшәүдән котылырга җыена инде бу. Каганнан бәйсез булырга җыена, азат дәүләт төзергә хыяллана. Хатын башы белән. Хатын башы белән! Ә соң Габдулла хан бәйсез булырга хыялланмыймыни? Салым түләп, газизләрдән-газиз кызын кырнаклыкка биреп, тез өстенә чүгеп яшәү аңа рәхәтмени? Бу коллыктан, бу хурлыктан ничек котылырга соң?

Менә урыс ханбикәсе үз кенәзләреннән качкан илдәшләренә таянмакчы була. Ә Хәзәр җирендә болгарлар урысларга караганда биш мәртәбә, ун мәртәбә күбрәк. Андагы пайтәхет Әтил үзе генә дә ярты лашы белән болгарлардан тора. Манас каган — Әтилнең уңъяк ярында, ә болгарлар — сулда. Каган үзенең сараен гына ак кирпечтән төзеткән. Ул уңъяк ярда башка бер генә байга да, чит-ят кавемгә дә андый кирмән-йортлар төзергә рөхсәт итми. Аның каравы сулъяк ярда болгарлар рәхәтләнә. Габдулланың аманат илтергә, каганга ант китерергә дип пайтәхеткә кат-кат барганы бар. Берочтан дип, бөтен Әтил урамнарын айкап чыкканы бар.

Хәзәр башкаласы, яһүдиләр үзәге булып саналса да, Әтилдәге мәчетләр утызга җитеп килә. Өстәвенә сулъяк ярдагы каланың нәкъ үзәк өлешендә дүрт манаралы Җәмигъ мәчет тә бар. Хак булса, хәзер Әтилдәге болгарларның саны егерме меңләп исәпләнә, диләр. Тукта, нигә шушы хәтле көчне Болгар файдасына, ислам файдасына кулланмаска әле? Урыс ханбикәсе анда үз качакларын фетнә күтәрергә әзерли икән, нигә әле аңа кушылмаска? Чит каземме, түгелме, без икебез дә бер як ярга, азатлыкка таба йөзәбез бит!..

Әйе, әйе, сак булырга кирәк. Яһүдләр бик мәкерле. Габдулла ханның авызы былтыр яман пеште инде. Ничек итеп төп башына утырттылар, бакчы? Габдулла барча кабиләләрдән бердәм курсыбай[1] оештыра башлагач, бәрәнҗәрләрнеке дигән булып, яһүдигә күчкән Балак атлы газине озатканнар. Карап торышка гап-гади бер бәрәнҗәр инде, аның асыл динен-фигылен кем казыган? Иллә мәгәр гади генә кеше булып чыкмады бу. Мәргәннәр бәйгесе-фәлән оештырдыңмы, бу гел алда. Ат чабышы кузгатасың икән, янә барча бүләк-санак аңа. Өстәвенә юха. Икмәк белән әвеш-тәвеш сатып ятканга Борак сәрдәр өстенә баскан иде, акланып йә карышып бер сүз әйтми. Шуңа аны Габдулла үзе йөзбаш итеп куйды. Кеше үз гаебен таный, өмете бар, янәсе. Шул, тагын да ышанычны акласын дип, Габдулла аны бортасларның иң олы каласы Бәнҗәгә юл җибәрде.

— Бар, Бәнҗәнең сакланышын тикшер. Бортаслар корсак киптереп ятсалар, кулга төшерәбез.

Ә Балак атна-ун көннән әйләнеп кайтты да сайрапмысайрый! Теле телгә йокмый юха еланның.

— Бәнҗәдә бер генә йөз дә сугышчы калмаган. Барысы да Җаек аръягында, кара аймыкларга каршы яуда йөри…

Габдулла хан өстәмә иравыл да озатып маташмады, ике меңләп кенә гази туплады да шундук юлга чыкты. Артларына ут капкандай, алны-ялны белми чаптырдылар. «Каудар эшкә шайтан катыша» диләр, хак, күрәсең.

Бәнҗә диварлары аларны унбиш-егермеләп тоткавыллар[2] белән генә каршы алды. Шәһәрне үләт давылы кырып чыккан диярсең: эчке якта һичбер тавыш, һичбер хәрәкәт юк. Габдулла хан майлы калҗа өмет итеп исерде, күрәсең, алдын-артын карап тормый-нитми бар нөгәрен диварга ташлаттырды. Ялтыравык тәтәй күргән бала-чагамыни, хәтта үзе дә читтә калмады бит, сантый. Ә бортаслар шуны гына көтеп торган икән. Болгарлар кырмыска күче шикелле булып имән диварларны сырып алу-

[1] Курсыбай — шәхси гвардия.

[2] Тоткавыл — тышкы сакчы, капка сакчысы.

га ук капкалар ачылды да, Бәнҗә эченнән буар еланнан да гайрәтлерәк ташкын бәреп чыкты. Болгарлар башына күсәк белән сугып миңгерәтелгән мал сыман өерелеп артка таба ташланганнар иде, ерымнар эченнән тагын бүре көтүенә охшаган чылбыр калыкты. Бортаслар нәфселәрен тыя белмәгән болгарларны, уртага алып, чүпрәк карачкы урынына дөмбәсләп һәм изеп кинәнделәр генә!

Габдулла ханның күзләре юха елан Балакта гына иде. Шәһәр капкаларыннан буар елан килеп чыгуга ук алар ягына таярга омтылды ул. Алданган хан күрде: карашында, ирен читләрендә зәһәр мәкерле тантана, бетмәс-төкәнмәс нәфрәт һәм үч чагыла иде сатлык җанның.

— Качма, җасус соран![1] — дип кычкырып, Габдулла хан аның артыннан томырылган иде, кемдер аның муенына арттан күсәк белән орды...

Хан аңына килгәннән соң гына сораштырып белде. Аны чолганыштан Борак сәрдәр ияренә аркылы салып кына алып чыккан икән...

3

Өченче көнне таңда Кораса аръягындагы Кырыкнарат урманына төбәп юл тоттылар. Камышлы күлләре, көмештәй ак сулы чишмәләре белән танылган як. Монда ат тоягы баткан һәр түмгәк астыннан яңа чишмә тибеп чыга, диләр.

Габдулла хан юлга кузгалгач та, әмирләрне үз янына чакырып күңел серен ачты:

— Әтил каласында урыс качаклары олы фетнә куптарырга әзерләнә икән. Чит кабилә, чит-ят халык вәкилләре булсалар да, фетнәләре безнең файдага. Мәгәр алар бик аз, Манас каганны чәнчелдереп төшерә алулары бик икеле. Аларга Әтилдәге безнең болгарларны да кушсак, начар булмас иде. Анда болгарларны авызына каратып тора торган Мөкътәсир бәгебез бар. Аллага шөкер, андагы Асаф сәет тә, яшерен хөтбәләрен Болгар иленә багышлап, безгә азат тормыш тели-тели укый. Алардан кала Әтилдә тагын һөнәркияннарны, сәүдә кәрванын йөртүчеләрне үз учларында тота торган Гали бәк, Рәшит бәк, Күчем бәкләребез дә бар бит әле. Алар янына үгетчеләр җибәрсәк, бәкләргә ияреп, Әтилдәге барча болгар кузгалыр дип уйлыйм. Ә сез ниндирәк фикердә? Безгә дә каганның туймас корсагына көтү-көтү мал озатып ятудан туктарга вакыттыр бит?

Гаҗәп, шаккатмалы! Хаммат белән Сәлман әмир — ике-

[1] Җасус соран — шымчы, хамелеон.

се тиң Талиб тарафына күз ташлады. Ә Ялкын әмир сорауларны бөтенләй дә ишетмәгән сыман ияренә текәлеп бара бирде. Таждар күңелендә шом кузгалды, Талиб җавап тотты:

— Вакыт, күптән вакыт инде, Габдулла... хан. Син үз кызың Бәнатны каган хәрәменә аманат итеп озаттың, минем Сажидә шунда. Әнә Хаммат, Ялкын, Сәлман әмирләрнең — һәммәсенең балалары шунда. Шуларны уйлаган саен, йөрәктән кан тама... Янә килеп, көз җитте исә, көтү-көтү итеп мал куабыз. Салым җыя башлаган саен, кара гавам елый. Җитәр, мондый хурлыкларга тагын күпме түзмәк кирәк? Бәләкәй буйлы эт гомер буе көчек хисабында йөри, диләр. Тешләп күрсәтмәсә, аның эт икәнен кем белсен ди? Бәйдән ычкынырга вакыт инде безгә, вакыт, вакыт...

Габдулла хан һәрбер төге белән тоеп барды. Талиб Шәмси суар гына түгел, барча кабиләләр исеменнән җебегәнлектә, күндәмлектә гаепләргә маташа бит аны. Имеш, син аумакай, Манас каганга азау тешеңне күрсәтерлек тә егәрең юк. Имеш, син кузгаткан яулар гел уңышсыз чыга. Былтыр Бәнҗәдә борын канатып кайтуың шуңа ачык мисал. Имеш, үз илеңне талый-талый, син Манас каган алдында һаман тәлинкә тотачаксың әле. Чөнки сиңа, ярты-йортымы ул, черекме ул, тәхет кенә кирәк... Шулай уйлый, шул рәвешчә кыздырасы килә, әйтеп кенә бетерми бит Талиб. Ә бәлки... Бәлки әле, башкалар да аны хуплыйлардыр. Авызларына су капкандай дәшми барулары шуны раслый сыман. Габдулла хан, ачуын эченә йотып, сүзне тәмамларга мәҗбүр булды...

Баткак яландагы Дөя күзе дигән күл буена җиткәч, икегә бүленделәр.

— Монда кабан, җәйран мыжгып тора, — дип шапырынды Борак. Ул, чыннан да, бала чактан бирле урман белән ау юлында аунап үскән кеше. — Авыз ачып йөрсәң, әле барс өстенә дә килеп чыгуың бар, вах-ха-ха-ха!

Борак күгәрчен боты чаклы эре тешләрен ыржайтып, башын дөя сыман югарыга чөеп шулай шаркылдады. И-и, беркатлы алабай да инде!

Сакчыларны, ук атарга кыҗрап килгән ат караучыларны күлнең таллар, гөлҗимеш, балан, карлыган куаклары каплаган башына җибәрделәр.

— Сез шул яктан чаң сугып килерсез, без камышлар арасына кереп утырабыз.

Габдулла хан күңелендә әллә шик уянды, әллә беркем дә күз алдына китерә алмастай хәйлә-ният корды, ул талгын гына тавыш белән улы Мөхәммәткә әмер бирде:

— Боларның елгырлыгына ышануы кыен. Әйдә, син шул нөгәргә баш бул әле, улым...

Бәла бер дә көтелмәгән яктан килеп чыкты. Берзаманны Габдулла ханның тулпары Борындык әллә нигә генә кәҗәли башлады да уйнаклый-уйнаклый камышлык эченә очып барып керде. Аның артыннан фәкать Борак кына берьялгызы элдереп килеп җитте. Ә бәкләр-әмирләр төркеме алты-җиде дилбегә буена артта калган иде.

Менә шул мизгелдә суга ятып торган камышлар арасыннан тана хәтле иләмсез зур гәүдәле кабан килеп чыкты. Әллә балалары белән шунда качып яткан инде, әллә сөяркәсе белән шаярган чак булган — аны кемнәр белсен? Әмма күренеп тора, үзен бимазалап йөргәнгә ярсыган бу. Күзләрен кан баскан, аяклары белән чирәмне бияләй чаклы итеп умырып, күккә алып чөя. Ә авыз читеннән ике якка чыгып тырпайган казык тешләре үткен хәнҗәр кебек!

Габдулла хан төртеп уяткан шикелле кабаланып Борындыкның касыгына тибеп карады, теге талпына-чәбәләнә, ләкин арткы аякларын тартып ала алмый. Баткак төшкә туры килгән икән, инде тубыкка чаклы саз эченә баткан. Габдулла хан кабан күзләренә текәлде дә катты. Кабан да, җайлы, очсыз корбан таптым, диебрәк сөенгәндер инде, канлы, усал карашы белән гел Габдулланың йөзен генә мөшкәдә тотып тора. Күз алышы башлангач та, таҗдарның зиһенен фәкать бер генә уй яшен шикелле яндырып-телеп узды: «Тәкъдир дигәннәре шушы микәнни соң?»

Борак бәлагә тарган ханның хәлен аңлап-чамалап өлгергәндер инде, камчысы белән кизәнеп-котырынып Борындыкның арт санына сукты.

— На-а, муеның асты өскә килгере җан!

Борындык җәйран шикелле капылт сикерде дә сазлык тырнагыннан котылып чыкты. Коры җиргә баскач бик гайрәтләнеп урыннан купкан иде, качып өлгермәде. Бүредән дә әшәкерәк булып котырынган кабан хәнҗәр төсле казыклары белән Борындыкның корсагын ярып узды. Габдулла хан капылт алгы сыйракларына тезләнгән ат өстеннән чирәмлеккә очты. Ул, аякларына күтәрелеп, кылычын кулына алып өлгергәнче, кабан аны да сытып узган иде инде…

Кул сузымында гына калган бәк һәм әмирләр һәммәсен дә күреп тордылар. Алар ярдәмгә ташланган минутта Борак сәрдәр кабанны да икегә ярып салган һәм хәзер инде Габдулла ханның җансыз гәүдәсе каршына тезләнеп баскан иде. Әмир Талиб ияренда утырган көе менә шул мизгелдә аның муенына чукмар белән орды. Өшәнеп калган бәкләр аңа төбәлгән чакта, әмирнең усал кысылган иреннәре арасыннан санаулы гына мыскыллы зәһәр сүзләр сытылып чыкты:

— Ат хәтле атка кул күтәрде, игелексез бәндә!..

4

Талибны шушында, Дөя күзе күле буенда ук, ак киез өстенә күтәрделәр. Ушсыз-аңсыз калган Мөхәммәт тә аңа ант китерде:

— Сине искил, бәрәнҗәр, суар кабиләләренең әмирләре Болгар мәмләкәтенең ханы итеп таный. Мин дә барсил кабиләсе исеменнән сиңа ант китерәм.

— Ә биләрләр? — диде, ярсып, канат җибәргән хан.

— Биләр — энекәшем Bahап кулында бит. Мәркәзгә кайтуга ук, дивар тышына чакырып аны үзем үгетләрмен. Үзара кан коеп дошманнарны сөендереп булмас…

Талиб сарайга әнә шулай итеп, тавыш-тынсыз гына үтеп керде. Боракны, кулларына-аякларына богау кидереп, кол рәвешендә алып кайтканнар иде. Ансат җиңүдән акылын җуйган Талиб мондый гына түбәнсетүләрне дә азсынды, күрәсең. Борак бөтенләй сынсын, урамга чыгып күренерлеге калмасын, дигәндер инде, яңа әмер бирде:

— Борак ат хәтле атны әрәм итте бит. Борындыкның йөгәне белән ияре хуҗасыз көе калды. Хәзер кая куйыйк? Әйдә, аларны Боракның үзенә кидереп, урамнарны әйләнегез әле.

Шул минутта ук кичәге сәрдәргә йөгән белән ияр кидерделәр дә, камчы белән яра-яра, урам буйлап куалап йөрттеләр. Аннары, шул ияре белән йөгәнен дә салдырып тормыйча, кое шикелле зинданга ыргыттылар. Һаман да шул сарай тарафыннан әмер булды микән, пәһлевандай гәүдәле Боракка сыңар телем икмәк тә кертеп бирүче кеше табылмады. Аның каравы зиндан авызыннан кочак-кочак печән ташладылар. Талиб Шәмси Суар каласыннан китерткән шыгавыллар[1] ихахайлап көлде:

— Син хәзер Борак түгел, тулпар Борындык бит. Ияр тагып йөри белгәнсең икән, печәнен дә аша…

Кичә бөтен мәмләкәтне үз кулында тоткан гаярь сәрдәр зинданның балчык идәнендә коры сөяккә калып, кибеп вафат булды. Ул җан биргәнне ишеткәч кенә чышан-пышан килеп хәбәр кузгаттылар:

— Талиб Дөя күзе дигән күл буенда әле Габдулла хан әрәм булганчы ук түнтәреш әзерләгән. Шуннан алдагы төндә, Талиб башка әмирләрне чакырып сөйләшкән чакта, Борак сәрдәр берүзе генә бу явызга каршы төшкән икән…

Тәхетне эләктереп алган Талиб исә кайчандыр ил терәге булып торган Борак турында баш ватудан бөтенләй туктаган, ул хәзер күл буенда чакта әле исән көе Габдулла хан әйтеп калдырган уй-фикерләр эчендә яна иде. «Әтилдә урыс

[1] Шыгавыл — эчке сакчы, сарай сакчылары.

качаклары фетнә әзерлиләр. Чапкын җибәреп, Манас каганны кисәтергә кирәк. Үзенә тугры булган этне барча хуҗа сөя. Мин тугрылык күрсәтсәм, Манас каган бәһаләми калмас».

Ләкин Талиб ханны эчтән һаман да шул яхшысынмау, умырткасызлык, икеләнү, шөбһәләнү дигән кортлар талады да, ул бу ниятен ай буена сузды. «Болгарларга, хәтта суарларның берәрсенә әйтсәм дә, моның соңыннан тишелеп чыгуы бар. Йә ул чапкынны мәкер белән юк итәсе була. Кул астында гына андый катыйль дә юк. Йә тегесенә, йә монысына кемне табасы соң?»

Яңа хан, ниһаять, тәвәккәлләп, үз янына ил сатлыгы булып танылган Балакны чакырттырып алды. Балак — майга буяп ташласаң эт яламастай шакшы бәндә, ләкин ул, ни генә әйтсәң дә, мәрхүм Габдулла хан дошманы. Ә дошманыңның дошманы, гадәттә, сиңа дус була ул.

Балак — кыйбат, затлы умырткалы кеше түгел, бик тиз ризалашты. Талиб чапкыны булып ияргә бик тиз сикереп менсә дә, Әтилгә барып җиткәнче ул соңарган, Хәзәр каганлыгында Болгар ханыннан башка сатлыклар да табылган иде инде. Чапкын булып барган Балак Әтилгә керүгә үк өстенә кайнар су койгандай куырылып калды. Болгарлар бистәсендәге байтак йортлар өстендә янгын уйный, җитмәсә, урам буйлап каган сараена таба бер-берсенә бау-арканнар белән бәйләп тагылган мәхбүсләрне сыер көтүе урынына куалыйлар иде.

— Манасий каган яшерен фирка ачкан. Әтилдә, каганның борын төбендә, йөзәрләгән хыянәтче бәндә елан сыман качып яткан икән. Болгарлардагы Мөкътәсир бәк белән урыс Демьян Манасий каганга каршы фетнә әзерләгән. Бүген кичен аларның икесен тиң сарай мәйданында дарга асалар, ди.

Чапкын Балак кичкә хәтле көтте. Чынында да, Мөкътәсир бәк белән Демьянның икесен дә асып үтерделәр. Мәхбүс итеп алынган башка болгарлар һәм урыслар Үргәнеч базарына сатарга озатылды.

Балак өчен боларны манзара кылу гына берни бирмәс иде. Сарай тирәсендәге сакчылар арасында иснәнеп йөргән чакта җанын җылытырлык сүз ишетте.

— Мөкътәсир бәкнең ундүртме-унбишме яшьлек Айсылу атлы бик тә чибәр кызы булган икән. Каган Мөкътәсиргә «шул кызыңны хатынлыкка бирсәң, гафу итәм» дип әйтеп тә караган, бәк сынмаган. Мөкътәсирнең кызы хәзер юкка чыккан, ә каган аны бик нык юллата, ди. Кем дә кем табып китерә, каган шуңа бер мең динар кадәресе алтын бирә икән…

Биләргә әйләнеп кайткач, Балак бер меңне биш меңгә чаклы камыр сыман күпертеп караса да, Талиб хан тәхетеннән тәгәрәп төшмәде шул. Аны хәзер яңа кайгы баскан, Зөя

буенда утырган Тигәнәш кирмәнен бортас чирүе җимереп киткән икән.

«Шулай, тәхетне эләктереп алу — әзергә бәзер җигелгән арбага сикереп менү генә түгел ул, — дип уйлады сатлык Балак, эченнән генә kahkahә белән көлеп. — Хуҗа камытын караклык белән каптыргансың икән, келәсез өй эчендәге шикелле, теләсә кайсы почмакта шылт иткән тавышка да колак салып яшисең бар әле».

Ләкин сыңар кирмәнсез калу Талиб өчен корт чагу кебек тә булмагандыр инде. Бер дә кара кайгыга батарга җыенмады бит бу. Киресенчә, мәмләкәттәге хәятны ал да гөл итеп күрсәтергә маташуыдыр инде, ай үттеме, яңа төрле бәйрәм уйлап таба. Тәүге кар ятуга, бар Чирмешән ярын тутырып, каз өмәсе оештырган иде, салкыннар зәһәрләнә башлауга бөтен Биләр өчен бердәм фәрман игълан иттеләр:

— Талиб хан дошманнарга каршы яу әзерли. Шуңа күрә Алтын капка каршындагы кырда боздан ясап чып-чын кирмән-кала торгызырга! Чирүне икегә бүлеп, ханиябез шунда хәрби күнекмәләр, бәрелеш үткәрәчәк.

Ярты шәһәр халкы, алмаш-тилмәш килеп, ялан кырда икеөч атна буена «кала» төзеп ятты. Ханның «бәрелеше» бик тә яман булачактыр инде, гаскәриләр биреп, Кашан тарафына салымчы-казанчыларның яңа нөгәрләрен чыгарып җибәрделәр. «Озынколак» бу гамәлнең асылын да бик тиз гөман кылды:

— Дөя күзе дигән күл буенда Талибны Кашан әмире Ялкын бик үк якламаган. Талибны киезгә күтәргән чагында да, ул берүзе читтә калган икән. Шуның өчен Талиб хәзер Кашанны талап үч кайтара, диләр.

Гөманлаулар дөреслеккә чыкты. Талиб Ялкын бәкне алып ташлаган да аның урынына Нур-Суардан чакырткан Нуретдинне әмир итеп утыртып та куйган. Яңа хуҗа каршы килмәгәндер, хуплагандыр инде, казанчылар пайтәхеткә олау-олау салым төяп кайтты. Ул байлык-зиннәтләрне һаман да шул бозлы кала төзүгә ялланган яһүдиләргә, бортасларга чыгарып җилгәрделәр. Халык тагын астан гына сыкрап җавап бирде:

— Ah, ул боз алачыкларына сине дә бикләп катырырга иде, ялкау мордар[1]!..

Талиб ыжлап та бирмәде, бозлы кала калкып чыгуга яңа фәрман корды:

— Боз кирмәнен кырык кыздан торган нөгәр саклаячак. Болар өстенә каланың аерым ханбикәсе дә була. Бәкләр вә морзалар! Олыслардан иң-иң чибәр кызларыгызны сайлап китерегез! Каланы иң якын яраннарым белән үзем яулап алам!

Тышта салкын көннәр дәвам итә иде, бозлы калага бер

[1] Мордар — юып булмас гөнаһ кылган, гадәттә үз-үзенә кул салган кеше.

зыян да килмәде. Ә атна дигәндә Биләргә йомшак туннар өстеннән көмеш шайманнарга[1] төренгән сылу кызларны китереп җиткерделәр. Шуннан соң адәм ышанмаслык кәмит канат җәйде.

Боларны, кулларына чып-чын кылыч-җәя тоттырып, боз кирмән диварлары артына кертеп бастырдылар. Ханбикә киемнәренә төренгән япь-яшь кызый өчен келәмнәр түшәлгән, кайнар чәйнекләр тезелгән зур бүлмәдә чып-чын тәхетләргә кадәр әзерләнгән иде. Әмма бу яшь кызыйны әллә сөҗү, әллә бал белән сыйлап өлгергәннәр инде, ул тәхеткә утырып та карамыйча кирмән буйлап әмер бирә йөрде:

— Диварга якынайган кемнең кем булуына карап тормыйча, нәкъ яудагыча шикелле сугышасыз! Яудан ярасыз чыккан кызларны олугбәкләр хатынлыкка ала!

Сылу кызлар, алда көткән мондый олы бүләкләр хакында ишеткәч, акылларыннан ук ычкындылар, шашындылар, ахры. Талиб чакыруы буенча Суар каласыннан килеп курсыбай хәтле курсыбайда гази булып йөргән әзмәвердәй ир-егетләрне дә күз чалымына китереп тормадылар алар. Газиләрнең беренче дистәсе боз диварларга килеп җиткәнче үк сәрпи уктан[2] ауды. Аннары бер-бер артлы яңа дистәләр һөҗүмгә ябырылды. Артта Талиб ханның, әмирләрнең газиләрне кыздырып кычкырган авазлары кат-кат яңгырады:

— Кем ханбикәне беренче булып үбә, шуңа алтын очлым!

— Ханбикә бүлмәсенә үтеп керә алган газиләргә йөзәр динар алтын!

Уйнап башланган һөҗүмнәр чын сугышка күчте. Алапа[3] хакына ялланган газиләр арасында да сантыйлар җитәрлек бит. Шулар кызган баштан җиде-сигез кызны турап ташладылар. Томан кебек чип-чиста, үтә күренмәле булып утырган диварлар кызыл канга батты. Кан исе һәм гарьләнү ачысы кызларны ярсытты, күрәсең, болар кылычлары белән уңнысулны күрми айкый башладылар. Диварлардан эре-эре боз кантарлары кубарылып очты. Кайсыдыр газинең сыңар кулын чабып төшерделәр, икенчесе йөзен тотып ауды. Кылыч, сөңге очы тиеп җәрәхәтләнгән өчме-дүртме кызый, чырыйлап кычкырып, боз диварлар арасында адашып чабып йөрде. Күренеп тора: тагын ике-өч чыра янып бетәрдәй арадан соң боз кирмән эчендәге орыш тукталачак иде. Шул вакытта кирмән каршына Талиб таҗдар үзе сикереп чыкты.

— Ханбикә үземә! Ханбикәне үзем тотып үбәм!

Уеннан уймак чыга күрмәсен тагын, дигәннәрдер инде,

---

[1] Шайман — сугыш киемнәре.

[2] Сәрпи ук — тигез колаклы ераккa оча торган ук.

[3] Алапа — хәрбиләргә түләнә торган хезмәт хакы.

Талибның ян-ягына сукса үгезне егардай сакчылар тезелеп басты. Талиб әллә күрде боларны, әллә күз чалымына да китереп маташмады, болан сыман сикергәләп диварга ябырылды. Өсләренә кем килүен сизенделәр, ахры. Бер-ике кыз чырыйлап кычкырган булып читкә йөгереште. Икесе-өчесе сизмәгәндә сикереп Талиб ханны кочагына алды. Ләкин юк, ханның сайлаган корбаны болар гына түгел иде инде. Әле бер, әле икенче боз дивар артына сузылганда аның котырган үгез мөгрәвен хәтерләткән котсыз, усал тавышы яңгырап торды:

— Ханбикә кайда? Ханбикәне кая яшердегез? Ул кызыйны үзем тотып үбәм!

Нинаять, Талибны чәйнекләр пар бөркеп утырган бүлмәгә этәрделәр. Хан тун изүләрен аера-аера килеп керде дә, тәхеттә утырган чибәр кызны йолкып келәмнәр өстенә сузып салды. Әүвәл талпан сыман кадалып кызның иреннәренә генә ябышкан иде дә, кыргыйлыгы кузгалып китте бугай. Икенче минутта ул инде янда дистәләгән сакчылары барлыгын да онытып, «ханбикә»нең итәкләрен ачып салган иде...

5

Март аендагы Нәүрүз бәйрәменнән соң Каргатуй, икенче ай ахырында ук сабантуй үткәргән иде дә, чәчү беткәнен, җыен тантанасын көтеп җиткерергә түземлеге калмады. Шомыртлар, чия, алмагачлар шау чәчәккә күмелүгә үк, Талиб колак ишетмәгән «Кызлар туе» дигән бәйрәм уйлап тапты. Монысында күренекле байларның кияүгә бирердәй булып җитлеккән кызлары гына түгел, бәкләр, морзалар, кибет тотучылар, кәрван йөртүчеләр, алачыкка хуҗа һөнәрчеләр үзләре да катнашырга тиеш була икән. Байлар сыкрый-сыкрый олаулар төяделәр, «озынколак» үзенчә фаш итте:

— Бу бәйрәмнең дә гайре кыргый бернинди мөгезе юк. Ялкау Талиб үзенең ятагына яңа җарияләр сайлый, шуңа өстәп байлык җыя инде.

Талиб билгеләгән көндә Биләрдән егерме чакрымдагы Коръүзәнгә чатырлар, тирмәләр куя-куя килеп урнаштылар. Миңлебакир читкә тибелгәннән соң, вәзир булып йөргән Һашим беренче мәҗлескә җыелуга ук игълан итте:

— Туй кадәр туйга әзерләнгән чакта, пайтәхет казнасына өлеш чыгармау бер дә савап түгел. Моннан ары җиткән кызларыгыз өчен дә, башка чыгарга җыенган уллырыгыз өчен дә салым түләячәксез.

— Имәндә икән чикләвек! — диде һәркайсы эчтән генә. — Болай барса, Талиб-бирән озакламый бездән тәһарәт алган өчен дә салым-ясак түләтәчәк икән.

Телен тыя белмәүчеләр, беркатлылар умарта оясына бикләнгән корт күче шикелле бызылдаган булды, авыз эченнән генә быж-быж килде. Ә асылда исә Корүзәнгә төшкән һичбер кеше халык алдына чыгып гауга күтәрмәде. Һашим аваз салгач, һәммәсе дә олау тутырып килгән зиннәтләрен аның чатырына шыпан-шыпан гына илтеп аудардылар.

Кичен Корүзәнне йөзәрләгән учаклар каплап алды, күктә тулган ай елмайды. Барча халыкны яланга эндәштеләр. Боландай булып җитлеккән кызлар арасында су тулы чиләкләрне күтәреп узыш оештырылды.

— Беренче булып килгән кызга — саф көмештән очлым! — дип кычкырды япь-яшь кызлар күргәч ярсып купкан Талиб.

Үз байлыгы белән сату итә диярсең, Һашим өстәп куйды:

— Икенче булып килгән сылукайга көянтәсен алтын кайма белән үзем бизәп бирәм!

Бәйгедә катнашучыларның әтиләре-әниләре еракка, Корүзәннең Киндер күле буена тезелешеп утырганнар, ә якында гына аңга килергә чакыручы, тыючы-нитүче юк. Япь-яшь кызлар шашындылар инде. Көянтәләренә чиләкләр элделәр дә ак-караны күрми чабышалар. Чаяраклары кеше күп дип тормый, кычкырыша хәтта.

— Син көянтәңне иңбашыңа куймый йөгерәсең!

— Синең суың артылаш түгелеп бетте, хәрәмләшмә алай!

Ахырда Җүкәтаудан килгән сәүдәгәр Мирасның чем-кара чәчле кызы Сания җиңеп чыкты. Икенче урын Ашлы кибетчесе Нурисламның кызы Мәһитапка булды. Кызларның үзләреннән бигрәк, әти-әниләре хан кулыннан бүләк көтә иде. Хыяллары белән җиде кат болыт өстенә менеп киткән бичараларны утлы хәбәр салып җиргә төшерделәр:

— Хан кызларыгызга бүләкләрне үзенең чатырына чакырып өләшәчәк. Ханның алар белән әле манзара-гәп корып утырасы да бар. Комачаулап йөрмәгез, сез кайтыгыз...

Хан бу төндә берьюлы ике яшь кыз белән истирахәт кичте...

Таңда чатыр-тирмәләргә Талиб ханның яңа «мөгезен» илтеп җиткерделәр:

— Барча кызлар өчен ат чабышы була. Бәйгедә хан үзе дә катнашачак. Ханны узган чаптар иясенә — саф алтыннан көбә!

Янә барча кызлар котырынып купты. Ханга ничек тәлинкә ялап ярарга белми йөдәгән әллә ничаклы ир көмеш аелларын, көбәләрен, чатырларын сатып яңа чаптар алды. Зиһен шөрепләре бушаган дистәләгән ана мич пумаласы да куркып качардай ямьсез кызларының чәчләрен кырыкмаса кырык толым итеп үрде, иреннәрен, йөзләрен, кашларын иннек, сөрмә, кершәннәргә төрде.

Киндер күле тирәли узачак бәйге сызыгына йөзәрләгән чапкын тезелеште. Болгар кызлары ат күрмәгән кыргый бәндә түгел, вәзир Һашим кызыл яулык болгап хәбәр салуга ук җитез элдерделәр. Сүз дә юк, Талиб хан иярләп алган байтал сәрпи ук та куып җитә алмаслык гаярь тулпар иде. Шуны белгәнгә күрә Талиб әүвәл былагайланып, юри атын тыя-тыя барды. Иң беренче булып алга чыккан кыздан ярты күл чамасы артка калгач кына байталның касыкларын искә төшерде ул. Ирек куйгач, байталга да канат чыкты бугай, лачын сыман бөгәрләнеп алга томырылды. Менә беренче төркемне узып китте Талиб. Менә бүре көтүе шикелле өерелеп чапкан икенче төркем арасына килеп керде. Байтал тагын бер ыргылса, боларны да куып узачак һәм иң алдагы тулпар эзеннән элдерәчәк иде.

Талиб яңа төркем эчендә очып барган чакта, гайре табигый бер хәл килеп туды. Күзләрен генә ачык калдырып, йөзен-кашын яулыкка төргән бер кыз әүвәл ханның үз янәшәсенә килеп басуын көтеп-шәйләп барды. Ә Талиб аңа кул сузымы ара якынлашуга, кыз кизәнеп торып камчысы белән ярсыган байталның маңгаена сукты. Байтал, көтелмәгән чокырга килеп эләккән сыман, шундук алгы аякларына тезләнде, Талиб аның башы аша җир өстенә очты. Икенче мизгелдә җайдак кызый аргамагын дала ягына борды. Һавада ул ачыргаланып-ярсып кычкырган тавыш яңгырап калды:

— Менә сиңа көмеш очлым өчен! Менә сиңа бүгенге төн өчен!..

Талиб ханның умырткасы сынган булып чыкты. Интегә-интегә, газапланып кына җан бирде ул. Соңгы сүзен аны тирәләп баскан күпләр ишеттеләр:

— Саниядән берүк үч алмагыз. Аның гаебе юк...

6

Әмир Мөхәммәт бу минутта Корүзәннән бөтенләй бик еракта, Кәлтә елгасы буендагы биек тау башында басып тора иде. Бүген ул монда зур сынау үткәрә.

Аста үзән. Мөхәммәт әүвәл шуның түмгәк булып утырган бер җиренә хәнҗәр көйләп куйды. Үткен йөзен күккә таба каратты, сабын җиргә күмде. Хәзер менә шуңа тау башыннан текәлеп карап торды-торды да янәшә баскан унике яшьлек улы Тимер-Мөэминнең муенына сукты.

— Җан-фәрманга йөгер! Шул хәнҗәргә күкрәгеңне ач та капланып ят!

Беренче кат кына интектерүе түгел иде инде бу. Тимер-Мөэмин хәзер дә бизгәк тоткан шикелле калтырана башла-

ды, ләкин әтисенең йөзенә күтәрелеп бөтенләй карамады. Аның уе-ихтыяры бу минутта аста — үлем дәһшәте бөркеп торган хәнҗәрдә генә иде. Менә ул ярдан сикерергә җыенган кеше сыман кисәк этенде дә кулларын канат шикелле итеп болгый-болгый аска томырылды. Алда — аннан каһкаһә белән көлеп торган, мәңге җиңелү белмәс, котсыз, явыз хәнҗәр. Юк, хәнҗәр генә түгел, әтисенә тиешле тәхетне оятсыз рәвештә, нахак юл белән эләктергән Талиб дошман бит бу! Чәнчелдереп төшерергә кирәк аны, чыраена барып ябышырга кирәк! Аңа хәтле унбиш адым чамасы ара калды, ун адым, биш...

Тимер-Мөэмин түмгәк өстеннән сикереп узып китте. Баш түбәсенә китереп суккандай, өстә әтисенең котырынып кычкырган тавышы яңгырады:

— Имгәк! Җебегән! Куркак! Мондый юаш бозау булып үссәң, синнән тәхет яуларлык хан чыгачакмыни? Тәхетне калтырап торган, җебегән куллар белән яуламыйлар аны. Әнә шул корыч хәнҗәрләрне сындырырдай кансыз булу кирәк. Мин сиңа юкка гына Тимер дигән исем кушканмыни?!

— Юк, мин хан булам, булам, булам! — дип, Тимер-Мөэмин әүвәл аста ачыргаланып елый башлады да, аннары ярсый-ярсый янә өскә йөгереп менде.

— Юк, мин курыкмыйм! Бар, куй хәнҗәреңне. Бу юлы капланам. Мин берзаманны барыбер хан булам! — дип тәкрарлады ул, әтисеннән бигрәк үзенең җанын-ихтыярын ышандырыр өчен. Һәм әтисе янына менеп басуга ук, ярсу колын сыман сикергәләп, янә тау башыннан аска томырылды.

Унбиш адым ара калып бара, унау, бишәү, өчәү... Тимер-Мөэмин чебеш алырга ташланган карчыга шикелле кулларын ике якка җәеп хәнҗәр өстенә сикерде. Ләкин... ләкин нинди галәмәт соң бу? Нишләп очы гына Тимер-Мөэминнең тиресен тырнады да хәнҗәр йөзе сап эченә кереп юкка чыкты? Әтисе аны нинди ялган хәнҗәр белән алдый? Нигә мәсхәрәли?

Тимер-Мөэмин гарьләнүдән әүвәл ярсый-ярсый хәнҗәр кереп чумган түмгәкне төя башлады, аннары сикереп торып әтисенә карап чәрелдәде:

— Мин курыкмадым. Мин хәнҗәр өстенә капланып яткан идем. Син алдадың гына. Ә мин барыбер хан булам. Барыбер булам! Син алдадың гына. Син... син...

Тимер-Мөэмин гарьләнү ачысыннан тыела алмый үкси үк башлады. Аска төшеп җиткән Мөхәммәт аны күкрәгенә кысты.

— Булды. Ниһаять, син дә чын ир булып үсеп җиттең, улым. Шулай кирәк. Тәхет хәтле тәхетне өмет иткәч, менә шундый ихтыяр, көч кирәк. Син расладың. Болай барса, валлаһидыр, син чын хан булачаксың...

Иярләрне иярләргә терәп кайтыр юлга борылганнар гы-

на иде, Биләр тарафында тузан болыты куптарып чапкан җайдак пәйда булды.

— Берәр нинди бәла килеп чыкмады микән? Юкка гына болай котырып чапмас. Болгарга берәр яктан дошман бәреп кермәгән булса ярый инде тагын.

Әтисенең шулай хәвефкә төшеп сөйләнүе тәэсир итте бугай, Тимер-Мөэмин, атын тыя төшеп, кыныннан нәни кылычын ук суырып алды. Юкка булган икән, чапкын килә-килешкә үк, ияреннән төшеп тормыйча да яңалык чыгарып салды:

— Талиб вафат. Ат өстеннән егылып әрәм булды. Болгар иле хансыз. Әмирләр, Изге чишмә янына җыелып, сине көтә.

Мөхәммәт бер генә сүз белән дә җавап-мазар кайтарып маташмады, аргамагының касыгына типте.

7

Даян мәргән ничәнче ай инде Киев буйлап киләп сарып йөри. Җаны ятардай шөгыль тапмый җәфалангач, Евсей атлы бер боярга сакчы булып ялланырга туры килде аңа. Бояр башта ук ошатты бугай үзен. Ошатмаслык түгел. Түшәмгә җиткән пәһлевандай буй-сын. Үзенә тартып торган, эчкерсез җылылык бөркегән күз карашы. Түгәрәк, пөхтә итеп кискән сакал-мыек. Һәркайсына дәү-дәү ирләр утыртып йөртердәй мәһабәт иңбашлары. Шуңа карамастан егет пешекчеләр янына минут саен ризык сорап керми. Көмеш җепләр белән бизәлгән йөгән-иярле бик шәп тулпары бар. Бүтәннәрдән бер тиенгә артык та түләү таләп итми. Хуҗа кеше моннан да кулайрак хезмәтчене кайдан гына, ничек кенә эзләп тапсын инде?

Очсыз ялчы отышлы, шулай да шикләндерә. Евсей бояр беренче ай узып барганда ук кызыксынып сорап куйган иде:

— Элек бер дә күзгә чалынганың юк иде. Син Киевка каян гына килеп чыктың соң? Атың, дирбияләреңбик кыйммәтле. Аларын каян таптың? Байчура нәселеннәнме син, әллә юлбасармы?

Егет, хуҗаның күзләренә текәлеп, бөтен соравына берьюлы җавап бирде:

— Ярәшкән кызым бар иде. Бер бай тартып алды. Аны тотып суйдым. Шуннан бирле монда.

Егетнең үз күңелен уч төбедәй ачып салуы телсез итте бугай, ике арадагы аңлашулар шундук тәмамланды. Ә хәзер бояр кай тарафка гына юнәлмәсен, Даян һәр урында колак салып йөри. Кенәз сарае эченнән хәтәр яман хәбәрләр дә саркып чыга тора.

— Хәзәр каганы Манасий Ольга янына Әкбәр атлы илче җибәргән. Әкбәр мөселман булса да, боярларның һәрбер киңәшмәсенә кереп утыра, ди. Ул илчелектән бигрәк әллә шымчы, әллә толбикәнең күңелен күреп торучы нәсел айгыры итеп озатылган инде? Икесенең тиң тәкатьләре коргаксыган бугай. Киңәшмәгә-нигә карап тормыйча күрше бүлмәгә йөгереп чыгалар да, ух-вах килеп акыра-бакыра эсселәрен басып керәләр, ди бит. Шушы хәтле оятсызлык буламыни инде, кит, атакай!..

Сарайдагы мондый әкәмәтләр гомер-гомергә Киевта яшәгән байтак боярларның үзәгенә үтте, күрәсең. Даян бер кичтә, инде тәмам караңгылык төшкәч, Евсей боярның сәер юлга җыенуын шәйләп сискәнде. Евсей тезгә җиткән озын киндер күлмәк астыннан җиңел көбә киде. Әле күккә, әле мич авызына карап ниләрдер укынды. Боярның нинди юл сайлавын, ниләр ниятләвен чамалау читен иде.

Читтән генә күзәтчелек итеп йөрү кирәкмәгән икән. Озын кара җилән астына кылычын, хәнҗәрләрен дә таккач, Евсей аны үзе дәшеп алды:

— Синең безгә кирәк булуың бар. Коралларыңны яшеребрәк так та, әйдә, ияр әле.

Бояр «безгә» диде. Ничәү алар, кемнәр? Итәк астына яшергән кораллар белән нәрсә кылмакчылар? Берәрсеннән үч алырга җыенамы болар, саклык чарасымы? Даян юл буена менә шулар турында гөман корып барды, әмма авыз ачып бер сүз эндәшмәде. Барыр, күрер. Ни генә булмасын, Даян мәргән бер чүкүдә сугып ала торган аңгыра карга түгел.

Мыштым дигән инеш аша салынган тәбәнәк күпер янында аларны бер төркем боярлар көтеп алды.

— Мин белештем, — дип телгә килде берсе. — Ольга Свенельд йортында кәеф-сафа корып утыра. Әкбәр сарайның беренче катында котыра-котыра су җылытып йөри. Үзенчә, гөнаһларын юып алырга исәбе бардыр инде.

— Бик хуп, — диде Евсей. — Су коена икән, коралы янда булмаячак. Безнең өчен аерата кулай. Әйдә, киттек.

Кенәз сарае янына барып җиткәч, Даян мәргәнне капка төбендә үк калдырдылар. Даян аптырады. Ихата эчендә булмасын, урам якта булмасын, бер сакчы юк. Гаҗәп! Йә акчага сатып алганнар инде боларны, йә Ольга белән Әкбәрнең уйнашлары, чынлап торып, сакчы ирләрнең дә үзәгенә үткән. Болай булса, яраннарыңа таянып яшәрдәй өметеңышанычың бер дә юк икән бит синең, кенәзбикә!..

Боярлар сарайдан берсен-берсе уза-уза, йөгерешеп чыктылар. Кайсылары кылычын үлән белән сөртә, кайсылары чаптар аттай гыж-гыж килеп сулый. Капка төбендә берсе генә шапырынып-очынып телгә килде:

— Гаурәтен дә чабып өздем әле теге пакыч җанның. Ольга, кәнтәй, муенына тагып йөрсен шуны!..

Өенә кайтып кергәч тә Евсей җылы бишмәтләрен, зур-зур биштәрләрен барлый, җыештыра башлады. Дәшми йөрүне артыксынды бугай, Даян мәргәнгә дә әмер бирде:

— Безнең өчен бер мәлгә читтә югалып йөрү хәерлерәк булыр. Ут белән кат-кат шаяра башласаң, сакалсыз калуың бар. Суздаль ягында үзара кан коюлар, суеш юк, ахрысы. Шул тарафка киттек.

Берәр айдан адәм ышанмаслык хәбәр куып җитте.

— Ольга биш мең кешелек гаскәр туплаган да древляннар өстенә үч алырга барган. Древляннар башта «менә безнең Ямал дигән кенәзебез буйдак, мәрхүм Игорең урынына шуны ирлеккә ал» дип ялынып караганнар. Толбикә боларның үтенечләрен җиргә салмаган, Ямал белән бер сарайга кереп бикләнгән, ди. Аннан йөгереп чыккан дә әйткән: «Сезнең кенәзегезнең исеменнән бигрәк җисеме бик бәләкәй, минем көймәдә андый калак белән ишеп ерак китеп булмый». Шуннан соң Ольга яраннары древляннарның иң мөхтәрәм кешеләрен сарай эченә чакырып керткәннәр дә тышкы яктан бикләп ут төрткәннәр. Коростеньдагы йөзәрләгән бүтән кешеләрне Ольга, кәнтәй, тере көе җиргә күмдерткән. Аннары сугышчылар, котырган эт көтүе шикелле, якындагы авылларны турап чыкканнар, ди. Ольга ире Игорь җәсәде яткан урынга гына да биш мең древлянны суеп салган...

Евсей боярның чәче үрә торды. Каткан кар өстенә капланып, җирне төя-төя шашынды ул:

— Биш мең ирне тураган, биш мең ирне! Үзенең туганнарын. Тырнак очына да тормас Игорь өчен. Имгәк! Иблис! Кәнтәй!..

Качакларны сыендырган Аю бистәсендәгеләр әллә кайда, җиде җир артында, һәлак булган билгесез кардәшләрен шул көнне үк юа башладылар. Әче бал, көмешкә, төнәтмә ише агулар атна буена елга булып акты. Агач чүмечләрне бер-бер артлы күтәреп эчәләр дә елашалар болар. Исерешеп алгач, йә түшәм сайгаклары арасыннан туфракса коелырлык итеп биешәләр, йә бер савыт-сабаны, бер өстәл-урындыкны исән калдырмыйча үзара сугышалар.

Даян мәргән беренче төн кергәч, бәладән башаяк дип, мич өстенә менеп яткан иде. Таң сызыла башлагач, сәке ягыннан килгән ухылдау-гыжлау авазларын ишетеп ияк калкытырга мәҗбүр булды. Текәлебрәк караса, йорт хуҗасы Аким үзенең килене Варвараны көйләштереп ята.

— Әй, минем Ефим артына ут төртсәң дә, берни сизми лә ул. Карт алаша буразнаны бозмый, дигән сүзне тикшереп

бак менә. Биатайның күңелен күреп алу савап кына булыр, каршы торма, килен.

Болар эшләрен төгәлләгәч, йомышларын йомышларга дип ихатага чыгып югалганнар гына иде, сәке буенда, идәндә Ефим карман-сәрмән килә башлады. Бер-берсенә ябышып каткан керфекләрен ачардай куәте юк, әмма барыбер дә сыңар кулы белән таныш итәк эзли. Кармалана торгач, хатынының әнисе Лукерьяның ботларына барып төртелде бу. Ни галәмәт, әби кешенең тәнендә ике кат итәктән башка тоткарлык юк икән. Ефим тегене аю сыман сытып ятканнан соң, астан канәгать ухылдаган авазлары гына ишетелеп торды. Кияү идәнгә шуып төшкәч түгел, ишектә Варвара күренгәч кенә айныдылар болар. Ефим теш арасыннан челт итеп төкереп нәтиҗәсен әйтте:

— Аерма юк икән…

Даян мәргән шуннан соңгы төннәрен толып бөркәнеп сәндерәдә кунды. Таң аткан саен, Евсей боярның колагына бер үк сүз тукыды:

— Бу мәхшәрдә безнең эткә дә кирәгебез юк. Киевтагы йортың җимерелеп беткәнче, әйдә, кайтыйк.

Ниһаять, чираттагы таңда Евсей авызына төнәтмә дә ала алмас булды. Чыгара да коса, чыгара да коса. Куллары салам да күтәрә алмаслык булып дер-дер килә, йөзе ап-ак.

— Баста! — диде ул Даян мәргәннән бигрәк үз-үзенә. — Тагын эчәм икән, кәкрәям дә үләм.

Аннан итәк очы сыман яргаланып-сыпылып беткән иреннәрен ачып, гыж-гыж килеп, йортның хуҗабикәсенә әмер бирде:

— Мичеңә як! Шунда юынып чыгам.

Даян күптән игътибар итеп килә. Бу йорт эченә җыелып эчүчеләрнең бик күбесе су коенып юынуны белми. Су белән танышрак булган кешеләрнең дә гадәтләре сәер. Мондагы хуҗаларның, кунакларның барчасы да мич буена куелган бердәнбер ләгән эченә тыгылып юыналар. Кайсы тамак чайкап төкеренә шунда, кайсысы култык асларын гына түгел, борынын да юа. Әле шул суны алыштыруны да ике-өч көн буена оныталар.

— Их, шәрекъ мунчасына куалап кертергә иде сине! Каен миллек белән ике-өч кат чабынсаң, өр-яңадан туып чыгар идең! — дип, Даян көчкә тын алып утырган Евсейның хәленә керергә мәҗбүр булды.

— Ишеткән бар. Юк, андый мунчалар безгә төс булмастыр. Без, үзебезчә, мичкә генә кереп юынабыз.

— Ничек инде мичкә?

— Шулай, мич эченә. Теләгең бар икән, кара да тор.

Даянны инде болай да кызыксыну комары биләп алган иде. Күзәтә башлагач гел шаккатты. Сәер икән болардагы гадәт.

Олы мич эчендә дугаланып тезелгән ташлар кызара башлагач та, хуҗабикә участкагы күмерләрне алды. Ут очкыннары уйнаклап торган көл өстенә икеме-өчме такта ташладылар. Анадан тума чишенеп өлгергән Евсей бояр балык шикелле шуып шулар өстенә чумды. Аннары хуҗабикә кызыл ташлар ягына олы бер тустаган җылы су тондырды да, шул мизгелдә үк мич авызын капкач белән япты. Эчке яктан Евсейның дию, җен-пәриләр шикелле үкереп аваз салган тавышы ишетелде:

— Ачыгыз, чыгарыгыз мине! Юкса янып үләм!

— Пычагым булсынмы сиңа, дөмекмәссең! — дип кенә җавап кайтарды да, хуҗабикә хатын мич капкачын ачып янә су тондырды.

Мичне йортның бер почмагыннан икенчесенә күчереп йөртердәй дулап-сикергәләп, эчтән кабат-кабат Евсей аваз бирде:

— Коткарыгыз, коткарыгыз, үләм!..

Кызган ташлар чыжлаудан туктаганнан соң гына, Евсейны идән өстенә тартып чыгардылар. Даян инде боярның җиде кат тиресе кәбестә катламнары сыман салынып төшкәндер дип хафаланган иде, хуҗабикә әйтмешли, пычагым да булмаган бит моңа. Кул-аяклары да шул көенчә, тәне дә сау. Ләкин Евсей бөрлегән шикелле кызарып-янып чыккан, өстеннән кушучлап су ага.

— Менә хәзер Киевка кайтсак та була инде, — дип телгә килде ул, ниһаять, икеме-өчме чүмеч куас эчеп куйганнан соң.

Даян да шат иде. Ирләр шул көнне үк иярләргә менде.

8

Кенәзбикә Ольга, Киевка әйләнеп кайткач та, һаман котыруын дәвам итте. Тагын бер кат гафу үтенмәкче, тугрылыкка ант итмәкче булып, древляннар инде пайтәхеткә дә илче ирләр юллап карадылар. Башлык булып килгән сәүдәгәр Никита зал түренә әллә никадәрле алтын-көмеш савытлар тезеп чыкты, кенәзбикә каршына якынаеп тезен чүкте, ләкин җылы караш белән хәер хаһлык дигәннәрен сатып ала алмады.

— Дарга, дарга! Агач ботагына! — дип чәрелдәде Ольга, төкерекләрен чәчеп. — Олег бабам әйтеп калдырган васыять — һәр кабилә өчен тайпылышсыз канун. Киев — барча шәһәрләрнең анасы, бар кабилә — безнең өчен коллар! Кем буйсынмый, шуңа үлем, үлем, үлем!

Кенәзбикәнең куллары-аяклары тартыша башлады, күзләре акайды, ирен читләреннән селәгәй агып чыкты. Сакчыларның аны башкача газаплыйсы килмәде, ахрысы, Никитаны залдан сөйрәп чыгып киттеләр дә сарай каршындагы

беренче өянке ботагында гомерен очладылар. Гәүдәсе әле өч-дүрт көн буена дәһшәт бөркеп торды, аннары югалды. Дөньяда Никита атлы сәүдәгәр булганлыгын сарайдагылар гына түгел, шәһәрдәге кара халык та оныткан иде инде. Аның исемен көтмәгәндә-нитмәгәндә нәп-нәни кыз уятты.

Ул көнне дә кенәзбикә коллар базарын әйләнеп кайтырга ният иткән иде. Базарга үзенең сак башлыгы Ермолай белән янәшәдә барып керде ул. Тол хатынның соңгы айларда хасил булган яңа гадәте бар. Тән сакчылары сайлыйм, дигән булып, Ольга ялкын чәчеп торган тол хатын эссесен басардай махсус ирләр эзли. Кибән чаклы олы гәүдәләләр дә, карчыга борынлы, уйнаш карашлы чибәрләр дә кирәк түгел аңа. Ольга баганага бәйләп куелган ирләрне... чишендереп сайлый...

Тол хатын булса да, ачыктан-ачык күренеп йөрергә кыенсына бугай. Ольга базарга чыккан чакта яулыгын күзләренә чаклы төшереп бәйли, аны гына да азсынгач, борын өстенә челтәр киеп куя. Барыбер таныйлар, кенәзбикәгә сиздермиләр генә.

Менә бүген дә, ак-караны күрмичә, коллар сатыла торган инеш буендагы рәткә атылды ул. Ольганың аты да гаярь, аннары ул бикәсенең сукмагын да яттан белә инде, элдертерә генә. Ермолай, аның артыннан җитешергә дип, үз атының касыкларын төяргә мәҗбүр булды.

Ольга, корбан тапкан карчыга шикелле томырылып, кысык күзле, киң яңаклы, биленә чаклы шәрә бер дала ире бәйләнгән баганага төбәп бара иде, сәләмә киемле кол кызлар арасыннан чәрелдәгән тавыш сискәндерде:

— Кенәзбикә, кенәзбикә! Зинһар, безне жәллә! Яраннарыңа әйт, мине энекәшемнән аерып сатмасыннар!

Ольга чытырманлык ерып барганда сынган ботакка килеп төртелгәндәй куырылып калды. Нинди хәерсез кыз бу? Коллар арасыннан кайсы мәхлук аны яулык, челтәр бөркәнгән көе дә яхшы таный? Саф урыс телендә эндәште бит, ничек итеп колга әверелгән?

Ихтыярсыздан, кенәзбикә тезгеннәрен тартып атын тыйды. Челтәр арасыннан аермачык күренеп бетмәсә дә, коллар рәтен ялт-йолт айкап чыкты. Әнә, кайсылары аякларын сузып, кайсылары бөкләп, йөзгә якын кыз бала тезелеп утыра. Бишалтысында гына яулык күренә, күбесе яланбаш. Чәчләре тузгыган, киемнәре теткәләнеп беткән. Берничәсенең ертык сәләмәләре арасыннан имчәк очларына тикле тырпаеп тора, капларга дип ымсыну да ясап карамыйлар. Аякларындагы, кулларындагы богаулар астында өр-яңа җәрәхәт эзләре. Димәк, болар әле ерак юллар үтеп күнекмәгән, кичә-бүген генә Киев базарына куып китерелгән коллар. Мөгаен, древляннардыр. Днепр өстендәге дулкыннарда кораблар уйнаклап тора, озак-

ламый шуларда бу кызлар да хәзәрләр, юнаннар[1], гөрҗиләр[2] кулына кәнизәкләр булып китәр инде...

Баягы бичара кыз тавышы янә ишетелде:

— Кенәзбикә, мине энекәшемнән аерып сатма инде!

Ольга очкынлы күз карашын шул тарафка атты. Тезләренә күтәрелгән, ике кулын алга сузган бер кыз ялвара. Яше әллә ни түгел, күп булса ун-унбердер. Чәче җитен сыман сап-сары, төскә-биткә чибәр. Ә күзләре... Күзләре чишмә суында чайкап алган фирүзәләр сыман. Эчкерсезләр, саф-лар, аларга күпме генә төбәлсәң дә, төбен күреп булмый. Моның ише нарасый сабыйны өстәләнә аш-су китереп йөргәндә очратып та сөенерлек кенә. Җитмәсә, сарайда пешекче, тукучы, җыручы кызлар әледән-әле сакчылардан, кунаклардан буйга узып тора, яңа алмаш атна саен кирәк.

— Моны богауларыннан азат ит, үзем белән алам! — дип кычкырды башта Ольга коллар кәрванбашына, аннан янә кызыйга күз атты. — Кайсысы синең энекәшең, әйдә, күрсәт!

Күз ачып йомганчы богаулардан азат ителгән кыз парпар итеп баганаларга бәйләп куелган малайлар тарафына ияк какты.

— Әнә дүртенче багана янындагы җирән — минем энем. Исеме Добрыня. Үзе юаш булганга гына тагылган кушаматмазар түгел. Бу аның чын исеме.

Мондый тәфсилле аңлатмадан елмаеп куйса да, малай тарафына күз ташлау кенәзбикә кешене шундук сискәнергә мәҗбүр итте. Малай куркыныч түгел, җиде-сигез яшьтә. Әмма моның бөтен төсе-кыяфәте уч төбе шикелле таныш бит. Кайда очратты мондый кешене Ольга? Кемнең туганы бу?

Кенәзбикә яшь кызыйга төбәлеп сорау бирде:

— Сине ничек дип йөртәләр?

— М-м-малуша.

— Сез кайсы яктан монда килеп эләктегез? Әтиегез кайда?

— Коростеньнан без, кенәзбикә, Коростеньнан, — диде Малуша, иңнәренә таш салгандай янә авыр сулап. — Әтиебез Никита синнән гафу үтенмәкче, бүләкләр бирмәкче булып чыгып киткән иде дә, аны сакчыларың дарга тотып аскан. Яклаучысыз калгач, колларга әверелдек тә куйдык инде менә.

Малуша сөйләменнән соң кенәзбикә елан өстенә баскандай куырылып калды. Менә сиңа махмырдан соң тозлы кәбестә! Сарайда берсе пешекче, икенчесе сакчы булырга ярамасмы дип, Ольга ике колны азат иткән иде, алары да кичәге дошманының балалары икән. Бу минутта базардагы йөзәрләгән күз аңа төбәлеп тора, ничек хәл итәсе?

---

[1] Юнаннар — византияләләр.

[2] Гөрҗиләр — грузиннар.

Шул чагында сабыйлар самимилеге белән телгә килгән Малуша базарны ду китерде:

— Сез курыкмагыз, изге кенәзбикә. Без сезгә тырнак очы хәтле дә этлек эшләмәбез, гомер буе тугры хезмәт итәрбез. Сез мине энекәшемнән аермагыз гына.

Дистәләгән ирләр ихахайлап көлде. Алар тынгач, Ольга һәркайсына ишетелерлек итеп, җитди төстә дәште:

— Этлек эшләргә чос түгелсең икән, моннан ары минем түшәк сакчым булырсың, Малушакай…

Шулай итеп, ятимә кыз бала кенәзбикә сараенда үз кешегә әверелде дә куйды. Ә ике-өч ел үткәч, кенәзбикә кочагыннан аерылган чакта, сак башлыгы Ермолай аны сәер яңалык белән кисәткәндәй итте:

— Синең улың Святослав Малушаны ала да гел урманяланнарга чыгып олага. Беркөн аларны Гордей сәүдәгәр Янгантау буенда шәп-шәрә көенә күреп кайткан. Син Святославны һаман бала-чага, малай-шалай, дисең, кенәзбикә. Уеннан уймак чыкмаса ярый да бит.

Ольга ике кулын селти-селти көлде:

— Уйдырма! Уйдырма! Аңамы соң?.. Хәер, хак булса да, зыян түгел. Шәрә кызлар янында күбрәк йөри икән, тизрәк чын ир булып җитлегер…

Шулай да кенәзбикә ул кичне караңгы төшүгә үк үз янына Асмуд атлы боярны чакырттырып алды. Төсе-кыяфәте тол калган еллардагы шикелле нурсыз, кара иде. Асмуд бусаганы атлап кергәч, Ольга карчыга шикелле аңа ябырылды:

— Яу сәфәренә-мазар йөргәнең юк, Киевтан чыкканың юк. Инде шул көе дә күз-колак була алмагач, ни пычагыма дип кенә мин сине Святославка аталык бояр итеп билгеләдем? Минем малай кәнизәкләр белән өегә башлаган, ә син ни карыйсың?

Асмуд күзгә күренмичә бызылдаган чебен-черкидән арынган шикелле генә итеп кулларын чәбәләде:

— Читкә йөрү ир-атларга осталык кына өсти, нигә кайгырасың, кенәзбикә? Кәләш әзер. Святославка унбиш кенә тулсын. Аннары муенына камыт кидерәбез дә, ипкә утыра ул.

— Юк, юк, унбишен дә көтеп тормыйбыз, хәзер үк өйләндерәбез, — дип, янә теге еллардагы шикелле төкерекләрен чәчә-чәчә кычкырды кенәзбикә. — Ялчы кызыйның итәккә бала салып кайтканын көтеп ятып булмас…

Өйләнү турындагы сүзне ишетүгә үк Святослав хәзәрләр ягындагы далага чыгып качты. Арканнарга урап кире алып кайттылар. Ашык-пошык итеп туй ясалды. Аннары берничә айдан соң сарайдагылар төн йокыларын калдырып бала көтте. Сарай, әлбәттә, иң беренче чиратта, кенәз дәвам-

чысына өмет баглый иде. Ләкин Святославка тәүге угылны барыбер дә Малуша бүләк итте.

— Малайга атны Владимир дип куш. Мин аннан берчакта да баш тартачак түгел, — дип пышылдаган булды яшь ата, бәхетсез Малуша янына качып кереп кенә.

Ә кенәзбикә Ольга үзенчә хәл итте.

— Безгә синең уйнаштан тапкан балаңның кирәге юк. Коростеныңа олак!..

Котырынган Святослав, биш йөз кешелек кенә дружинасын алып, әнисенең шәхси утары булып исәпләнгән Вышегород каласы өстенә ябырылды. Агач кирмәнне өч мең яугир саклый, ләкин аларда Святославтагы шикелле ярсу юк иде шул. Яшь кенәз әнисенең утарыннан көл калдырып узды.

— Әй, сабыйлыгы чыгып бетмәгәндер әле. Тузыныр да тынар, — дип кул селтәде Ольга.

Чынлап баксаң, кенәзбикәнең күңелен башка кайгы басты. Соңгы айларда аны кендегеннән астарак ниндидер чир газаплый, шуннан котылу өчен Ольга хәзер юл чыгарга ниятләп йөри иде. Берничә атнадан соң гына калалардан калаларга яңа хәбәр күчте:

— Ольга юнаннар янына Кайсаркалага[1] киткән. Гөнаһларын юарга җыенадыр инде. Аны чукынырга ният иткән, диләр…

9

Мөхәммәт ханның кәефе юк заман. Шәрекъ яктан, Җаек аша, Болгар җирләренә кара аймыклар бәреп кергән, диләр. Исәпкә-санга алырлык кала-кирмәннәрне җимерү-кырулары турында хәбәрләр юк югын. Ләкин Идел, Кондырча, Сакмар буенда утырган дистәләгән авылларны талаганнар, яндырганнар инде. Анда — бортаслар белән чиктәш, ерак төбәк. Пайтәхетнең үзенә дә, мәмләкәтнең сеңерләре булган олысларга да һичбер куркыныч юк. Әмма менә аймык җайдаклары аерым ханлык корырга маташкан бортас кабиләсен энәсеннән җебенә чаклы айкап-актарып талаганнар икән. Хәтта ике дистә мең кешеле Бәнҗәне дә умарталыкка төшкән аю сыман пыран-заран китереп чыкканнар, ди. Шул кирәк ул умыртка сыз аумакай бортасларга! Йомшак иренле бозаудай кыланып, тагын күпме еллар буе ике сыерны — болгарларны да, хәзәрләрне дә имеп яшәргә, икейөзлеләнергә була инде?

Иң әүвәл әле Алмыш хан ук үз әләме, үз тирмәсе янына чакырып караган боларны, баш тартканнар. Имеш, Алмыш-

[1] Кайсаркала — Царьград, Константинополь.

тан да куәтлерәк хакимнәр бар әле җир йөзендә, Хәзәр каганы бар. Аннары Микаил бабасы үз ягына аударырга тырышып карады бортасларны, монысына Мөхәммәт тә шаһит. Һаман бер үк төрле җавап ишеттеләр:

— Сез безнең шикелле үк мөселман мөселманын. Икебез бергә кушылсак, яңа мәмләкәт симертергә япкан үгез сыман көрәеп, гайрәтләнеп китәчәк, моны без аңлыйбыз. Иллә мәгәр... ни бит... болайрак бит... Безгә үз ханыбыз белән аерым тирмә корып яшәү кулайрак. Аннан... каган да бар. Сез җиде дәрья, кырык катлы урман артына кереп качкан кавем, Әтилдән бик ерак. Ә без кул сузымында гына. Үгез эзләгән сыерлар шикелле сезгә ияреп китсәк, каганның безнең көтүне кырып чыгуы бар...

Шул каганнан өркеп Бәнҗәдә туплаган аманат, салымнарын Әтил каласына елга буйлап, сал белән генә озатып ятканнар иде дә, менә бит, ерактагы дошман бәреп кергәч, якламаган Манас. Бортасларга ярдәмгә хәтта бер генә йөз дә гази бирмәгән, ди. Алай гынамы соң? Бортасларның тоташ таланганын күз чалымына да китереп тормыйча, еллык яңа салым, сараена яшь егетләр таләп итә ди бит, нинди хәлдер? Соңгы елларда каган үзенең хәрәмханәләрендәге җария кызларны яңартып торуны ташлады, аның каравы сараена һаман-һаман яшь малайлар даулый. «Каган хәзер малайларны мунчасында кызтәкәгә әйләндерә икән» дигән сәер хәбәр йөри. Ләкин аманат итеп озатылган угылларның берсенең дә кабат әйләнеп кайтканы юк. Алар җир тишегенә убылган шикелле гел югалып тора. Ә дөресен генә, тәгаен итеп кенә һичбер тарафта һичкем белми.

Мөхәммәт үзе тәхеткә менүгә үк Миңлебакир бәкне янә вәзир итеп күтәреп куйган иде. Кичә кичен әнә шул вәзир кереп әйтте:

— Ошбу Манас кайсы кыйблага төбәлеп, нинди сәясәт алып барадыр, аңламыйм. Сәмәндәрдән Ахияр бәк кайтып төшкән иде. Әтил аша, әйләнеч юлдан кайткан. Шул сөйләде. Манас каган Әтил илә Сәмәндәр арасындагы чик сызыгын ачкан да Тын дәрья[1] белән Көбә үзән[2] ягына бәҗәнәкләр чирүен үткәреп җибәргән, ди. Бәҗәнәкләр, Тын дәрья эргәсенә барып җитүгә үк, Саркел атлы каланы кулга төшергәннәр. Хәзер шул куна тактасы шикелле шыр ачык далада да әллә каян бүрәнәләр илә ак таш табып, кирмән диварларын ныгыталар икән. Ул бәҗәнәкләр алдында тәлинкә тоту Манас каганга ник кирәккән инде? Артык көрәеп алсалар, шул ук бәҗәнәкләр Манасның үз сыртына пычак китереп батырачак ласа.

---

[1] Тын дәрья — Дон.
[2] Көбә үзән — Кубань.

Мөхәммәт каршы төште:

— Менә бәҗәнәкләрне Манас ник үз җирләре аша үткәреп җибәргән инде дип баш ватасың икән, Бакир агай. Бер дә кырык карта шикелле катлы-катлы сере юк бит моның. Манас Кияү каласының көчәеп китүеннән, аннан ары юнаннарның һөҗүменнән курка. Ул якта тагын безнең туганнарыбыз — кара болгарлар да бар бит әле. Янә килеп, янәшәдә алан илә чиркәс кабиләләре яшәп ята. Таулар арасында ингуш, чәчән, ләкс дигән кабиләләр гомер сөрәләр, ди. Каган бәҗәнәкләрне Тын дәрья буена үткәреп, әнә шул кабиләләрнең һәммәсенә берьюлы җим ыргыткан. Нәфсегез бик кыҗраса, бәҗәнәкләрне тотып ашагыз, миңа гына тимәгез, янәсе.

— Бу — Кияү каланыкылар, юнаннар, кара болгарлар илә ике арага калкан корган дигән сүз була бит, — дип әләктереп алды вәзир. — Акылы кот икән.

Мөхәммәт ни чарадан бичара кыяфәттә өстәп куйды:

— Каганда мәкер бетмәс-төкәнмәс. Шушы чаклы этлек аңа каян гына килеп бетә икән?..

Бүген Мөхәммәтне таң атканда кереп уяттылар.

— Бәнҗәдән чапкын бар. Башка берәүгә дә бер сүз әйтми, сине генә сорый.

Тәхеткә менгәннән бирле Мөхәммәтнең күз алдыннан Балак дигән сатлык китми тора. Нинди шома еландыр инде бу, һич тоттырмый. Бәнҗә диварлары янында Габдулла ханның кулыннан чыгып качкан иде, Мөхәммәт Изге чишмә буеннан пайтәхеткә хан булып кайтып кергәнче Биләрдән дә табан ялтыраткан. Тагын кай яктан килеп чыгар да, кайчан чагып алыр, бар, чамалап кара.

Мөхәммәт хәнҗәрен кыныннан алып җиң эченә яшерергә мәҗбүр булды, аннан гына ишек сакчысына дәште:

— Чакыр, керсен.

Көтелмәгән кунак кайнар мичкә тыгып киптерелгән сыман какча, ябык гәүдәле, каратут йөзле бәндә булып чыкты. Әллә шул ябык булганга инде, буе да, муены, куллары да галәмәт озын шикелле тоелалар моның. Сузылса, ул дәү өстәлнең икенче башында утырган дошманын да җиңел генә буа алыр кебек. Аллага шөкер, җилән канатлары ике якка ачык, билбавында һичбер коралы юк.

— Мин хан чапкыны да, Бәнҗә әмире дә түгел, — дип, тиз-тиз башлады ул. Үзе Мөхәммәт хан каршында тезгә чүгеп яки бил бөгеп вакланмады, бүреген генә баш түбәсеннән йолкып култык астына тыкты. — Мин гап-гади бер бәк. Атым Шоңкар. Бәнҗәдә азат, тигез хәят булдыру яклы гавамның атап озаткан бер илчесе булам.

Мөхәммәт борын очына олы шөпшә килеп кунган сыман нык сагаеп калды. Тукта, ошбу илче Бәнҗәдә түнтәреш әзер-

ләргә йөри түгелме соң? Мөхәммәтнең хыялы — Бәнҗә каласын үзенеке итү. Әлеге бәндә дә шул сәясәт яклы. Алай булса, моннан йөз чөерү килешеп бетмәс. Су тегермәнендәге куласага инеш-ерганаклар кайсы яктан гына килеп өстәлмәсен, һәммәсе дә хуҗа файдасына бит.

— Гавам үшән сыер хәлендә яшәүдән тәмам гарык. Бәҗәнәкләр талап үтеп китә, Манас каган бертуктаусыз сава. Инде менә аймык чирүе дә талап чыкты. Ә яклап калучы, сакка басучы юк. Калабызда Минай хан бар, тик ул бертуктаусыз йоклый. Аңа үгез үлсә — ит, арба ватылса — утын. Тәхете генә исән булсын да, аңа җил тимәсен. Без бүре өере уртасында калган көтү сымак, таланудан туйдык. Әйдә, чирү җыеп бар да изелүдән коткар. Без син корган тирмә каршында баш иярга әзер.

Мөхәммәт хан вәзир Миңлебакирны чакыртты. Кашандагы әмирлектән алып курсыбайга сәрдәр итеп куйган Нуретдинне дәште. Аннан гына бер-бер артлы сорауларын тезде:

— Минай кул астында бүген күпме гази?

— Даими чирүдә йөргәне алты меңләп бардыр. Арттырам дисә, шул, авыллардагы сабанчыларны гына кыйнап җыйса инде.

— Аймыклар кая китте?

— Икегә бүленделәр. Бер нөгәре Каф тау ягында гөржиләргә каршы яуда йөри. Икенче яртысы Кондырча буенда угызларга очрадылар бугай, әлегә тик торалар.

— Син үзең кара гавам арасыннан никадәрле чирү җыя аласың?

— Санап караган бар, ныклап котыртсаң, дүрт-биш меңгә җитә. Вәләкин безнең күбебездә көбә, очлым юк бит. Коралы да шул, колгага таккан балта, чалгыдан ясаган сөңгеләр генә инде. Дөрес, кылычлар бар. Хәнҗәрне әйткән дә юк.

— Сез үзегез башлап фетнә куптарырга җыенасызмы, безне көтәсезме?

— Башлап сез килсәгез, кулайрак булыр сыман. Ялгыз көе кузгалсак, хан чирүе безне печән чүмәләсе урынына тетеп кенә ата…

— Йә, нишлибез?

Шулай диде дә Мөхәммәт хан Миңлебакир вәзирне, Нуретдин сәрдәрне күз карашы белән көйдереп чыкты, тегеләр дәшмәделәр. Бүлмә буйлап әрле-бирле йөри-йөри хан үзе сүз башлады:

— Нуретдин бәк! Кашандагы энекәшең Елкыга үзең чапкын җибәр. Алайлары белән безне Зөя тамагында көтеп торсын. Аннан ким дигәндә өч мең газиле чирү, колагыңа кертлә… Аннары син төп Суар кешесе, туган калаңа да син бара-

сың. Мин сине юкка гына сәрдәр итеп күтәреп куймагандыр, әйдә, расла. Нур-Суардан янә өч мең газилек чирү. Очрашу урыны шул ук.

Нуретдин ишеккә таба кузгала башлаган иде, Мөхәммәтнең кырыс тавышы кадаклап куйгандай итте:

— Ашыкма, көт, әле сүз бетмәде.

Мөхәммәт хан вәзир тарафына борылып басты.

— Олуг вәзир, сиңа Ашлы каласына төбәп чыгарга туры килә. Искил кабиләсен кузгату синең өстә. Аларга бертуктаусыз Урыс елгасы буендагы вятич ушкуйлары янап тора, ул хәтлесен беләм... Йллә мәгәр Җаек ягыннан кергән аймыклар да һәммәбезгә, шул исәптән Ашлыга да дошман. Гел үз тирмәсе, үз тиресе өчен генә калтырап яшәмәсен, Сәлман да башка әмирләрдән калышмыйча өч мең җайдак бирсен. Син аларны Идел буйлап алып төшәрсең. Сәлман тимер калкан япкан зур каеклар биреп җибәрсә дә начар булмас иде. Синең белән Зөя тамагында кавышабызмы, беркадәр түбәнрәкме, анысын күз күрер.

Ниһаять, Мөхәммәт хан үзе турында да сүз кузгатты:

— Ә миңа Биләр, Жүкәтау белән Болгар яугирләрен җыештырып барырга туры килә. Мәгәр...

Мөхәммәт хан авызына су капкан шикелле капылт туктап калды. Тешләре шыгырдады, яңак сөякләре уйнаклады. Сизелеп тора, аны эчтән яман бер корт кимерә, талый иде. Кабат телгә килгәч тә, тавышы сынып, калтыранып чыкты:

— Мин... беренче тапкыр яуга... хан буларак барам... Миңа җиңелергә ярамый... Җиңелеп кайтсам, Болгар халкы йөз чөерә миннән. Аннары бер генә юл — тәхетне ташла да кит... Шуңа күрә мин болай хәл иттем. Нуретдин бәк, яуны син әйдисең! Мин чирүдә меңбаш булып барам. Исемем Әхәт булыр. Яуда миңа ил хакиме итеп эндәшү юк!

10

Болгарлар Бәнҗә каласына барып җиткән чакта, җир өстенә тәүге ак кар төшкән иде инде. Тышта салкын, ачы җил исә. Иярдәгеләр дә, каектагылар да эчләре китеп җәфаланган шикелле бөгәрләнеп бара. Ләкин җил-салкыннар каладагылар өчен дә бер үк бит ул. Бәнҗә янына тәүге иравыл нөгәрләре озатуга ук ачыкланды. Кала тулысынча мәрткә киткәнмени, диварларында бер йөз чамасы да тоткавыл юк.

Сәрдәр Нуретдин утлы таба өстендә, ни кылырга белми. Аптырагач, шыпан-шыпан гына Мөхәммәт янына килеп җитте.

— Диварда җүнле сак күренми. Ни кылабыз хәзер, меңбаш Әхәт?

Мөхәммәт Нуретдин йөзенә карап елмайгандай итә, әмма үзенең эчендә тоташ ут яна.

— Монда минем атайның авызы пеште инде. Ул күргәннә кабатлыйсым килми. Кул астында унбиш мең гази бар лабаса, яңа иравыл җибәр. — Бераз баргач янә өстәп куйды: — Чирүне икегә бүл. Берсен хәзәр даласын ышыкларга җибәр. Алла сакласын, Манас этләренең килеп төшүе бар. Икенче нөгәрең төн ягыннан килеп каланы тулысынча камалышка алсын. Ул-бу килеп чыкмасын дип тозак алайлары калдырсак ярар иде дә инде, мәгәр көне салкын. Кала диварларына ташлансак, алар барыбер түзеп тормаячак.

— Ә каеклар? Каектагылар, дим. Аларны нишләтәбез?

Нуретдин шушы сорауларны тезеп салгач кына, Мөхәммәт иләслөнеп маңгаена сукты:

— И-и, том-мана! Каекка утырып яу йөргән бармыни? Бөтенләй онытканмын. Аларның бурычлары күптән билгеле инде. Җайдаклар каланы урап алуга ук елга яклап диварга ташланалар. Арабызда каекчылар булу безнең өчен аеры отышлырак. Мондый кара көз көнендә яр ягыннан һөҗүм итүне һичкем көтми...

Мөхәммәт белән Нуретдин юкка гына бу кадәрле тәфсилләп әзерләнде. Чынында исә болгарлар Бәнҗәне яусыз-нисез диярлек кулга төшерделәр. Бортаслар әле яңа гына аймыклар тарафыннан таланган да булгач, кичке эңгер-меңгер төшеп барган чакта әллә каян гына янә утыз алайлы дошман килеп чыгар дип каладагы һичбер түрә уйламаган, ахры. Сакка куйган тоткавыллар мәрт йокысыннан айнып оран сала башлаган чакта, болгар җайдаклары эреле-ваклы калкулыклар арасындагы уйсулыклар, тирән ерымнар эченнән атылып чыгып, кала диварларын буар елан сыман чолгап алган иде инде. Тимер белән тышланган капкаларын да янда әзер торган ком-таш тулы арбалар белән терәтергә өлгерә алмадылар. Болгарларның алты-җиде дөя өстенә салып алып килгән очлы бүрәнәләре имән капкаларны атланмайга кадалган хәнҗәр шикелле генә урталай ярып узды. Ә Бәнҗә урамнарына бәреп кергәч, болгарларга кылыч айкарга, ук очырырга язмады да бугай. Монда Минай газиләре өстенә Шоңкар кул астындагы кара гавам нөгәрләре очып кунган, алар ярсыган әтәчләр шикелле үзара кыйнашалар, чукышалар иде. Болгарларга шул Минай хан сарае янында гына җансакчылар белән әүмәкләшеп алырга туры килде. Берзаманны киемнәре бүре талаган сарык тиресе кебек умырылган, теткәләнгән ханның үзен дә сарай ишегеннән сөйрәп чыгардылар.

— Хатыннары ягына кереп качкан. Яшь кәҗәсе яткан сәке астыннан көчкә сөйрәп алдык! — дип кaһкaһәләп һәм олы бүләк өмет итеп кычкырды бер гази.

Нуретдин сәрдәр инде сарай баскычы өстенә сикереп менгән, Мөхәммәт исә иярендә утырган килеш мәйдан почмагында гына тора иде. Корбаннарсыз гына җиңү яулау Нуретдин сәрдәрнең күзен томалаган, күрәсең, ул мәйдандагылардан киңәш сорагандай кыланып, тизрәк хөкем карары чыгарырга ашыкты:

— Яр башыннан этләргә ыргытабызмы моны, дарга асабызмы?

Гади сугышчылар арасында ике башлы булган ачыгавыз юк бит. Меңбаш Әхәт булып йөргән сыбайның[1] асылда кем икәнен һәркем яхшы белә, аннан узып кем сүз әйтсен инде?

Мөхәммәтнең авазы ишетелде:

— Син тавык лапасына кергән көзән сымак, сәрдәр. Гел кан исенә кыжрап торасың. Хан суярга сузып салган мескен тавык түгел, ашыкмале алай. Кирәк тапсак, аның гомерен соңыннан да кыярга өлгерербез. Ханнар саугатлыкка[2] көн дә эләгеп тормый. Аны колчура ясап Биләргә алып китү үзе бер дан.

— Ю-у-ук! Саугат булырга да, колчура булырга да теләмим! Андый хурлыкка төшкәнче, ичмаса, үтерегез! — дип, Минай янда торган бер-ике газинең сөңгеләренә сикереп караса да, тоткын ханны бик тиз эләктереп, тез астына бөкләп салдылар.

— Зынҗырларга утыртыгыз моны! — дип кычкырды «меңбаш Әхәт». — Аннары сак куегыз! Минай ханның сыңар гына чәче коелса да, башың белән җавап бирәчәксең!

Нуретдинне тоташ тир каплады. Ярсуыннан кием астында бала йоннары кабаргандай булды. «Исемне дә әйтеп мәшәкатьләнми бу. Сәрдәр дип исәпләнеп йөргән булам тагын».

«Меңбаш Әхәт» янә телгә килде:

— Миңа сатлык Балакны табып китерегез! Тере көе, анысының да чәчен йолыкмыйча. Менә мин аны, ичмаса, рәхәтләнеп асам!

Ирләр Бәнҗә урамнары буйлап таралганда, Мөхәммәтнең соңгы әмере дә куып җитте:

— Йортларны, кибетләрне талауны тыям! Хәзер инде Бәнҗә — безнең шәһәр. Җинаять өстендә каптырсам, асачакмын!

Моны гына да азсынды, күрәсең, Мөхәммәт Нуретдин тарафына борылып өстәп куйды:

— Һәммә урам буйлап йөзбашларны җибәр. Талау яки көчләү оештырган бәндәләрне кызгану юк!..

Мөхәммәт үзе Идел буендагы урамнарга таба төшеп китте. Артта яна-кабалана җансакчылар йөзе тезелеште. Бәла-

---

[1] С ы б а й — гаскәр, отряд башлыгы. Офицер мәгънәсендә.

[2] С а у г а т — әсир, сугыш тоткыны.

дән башаяк, кыйналудан качкан дошман сугышчыларының килеп чыгуы бар.

Монда күбесенчә салчылар, балыкчылар гомер сөрәдер инде, урамнар тын. Ихаталарда, сарай артларында сумалалары коелып беткән көймәләр аунап ята. Кайбер сарай түбәләрендә кышкы ялга кайткан җәтмә, сөзгеч өемнәре күренештерә. Лапас-келәтләр тирәсенә ярым сынык ишкәкләр бастырып куйганнар, күрше белән ике арага тезгән коймамыни!

Мөхәммәт сунарчы елгырлыгы белән күзәтеп бара иде, ярым ачык бер йорт ишегеннән үзенә төбәлгән карашны тотып алды. Яулыгын иягенә төшереп бәйләсә дә, гүзәллеген яшереп булмас сылу, яшь йөз, очкын бөркеп торган карлыгандай күзләр!

Угрылык өстендә тотылгандай булды, ахрысы, чибәр кызый тиен сыман сикереп юкка чыкты. Мөхәммәт тә үзенең комарлы уенга кереп чумганын тоймый-сизми калды, ияреннән капылт сикереп төште. Аның артыннан ук тагын ике-өч җансакчы да коелып төшкән иде, Мөхәммәт усал әмер белән шып туктатты:

— Йярәсе булмагыз, артка!..

Ишекне ачып керсә, кызый берьялгызы. Өстенә тагын бер шәл, иске җилән ябынып өлгергән, битенә корым сөркән. Ул йә шушы йорттагы ир хатыны, йә сазаган кыз, янәсе. Ah, хәйләкәр!

— Ару гына яшисеңме, әбекәй? — дип эндәште Мөхәммәт, авыз ерып җибәрүдән көч-хәл белән тыелып. — Су эчереп чыгармассың микән?

Мич буенда дәшми генә басып торды-торды да, ахыр чиктә кызый чүмеч белән әйләнеп килергә мәҗбүр булды. Үзе йөзен шәл астына яшерә, ә куллары елгадан гына йөзеп чыккан каз канаты шикелле ап-ак.

Мөхәммәт аны әүвәл әнә шул ап-ак кулларыннан эләктереп тартты, аннары инде кочагына состы. Юк, каптырмады кызый. Мөхәммәтнең кочагыннан балык кебек кенә шуып чыкты, янә тиен сыман сикергәләп бер почмакка качты. Әмма, ниһаять, телгә килде бит, наян!

— Битләреңне тырнап бетерәм, якынаясы булма!

Менә шул чагында гына Мөхәммәт рәхәтләнеп, туарылып көлеп җибәрде:

— Минем өйләнәсе бар әле. Юк, син миңа тимә.

Җаны утка очкан күбәләктәй уйнаклаган кызый тел очыннан нинди сорау ычкынганын бөтенләй сизмәде дә:

— Кемгә?

Гыйшык хисләре җәйге челлә сыман кызган Мөхәммәт тагын-тагын рәхәтләнеп көлде:

— Кемгә булсын, сиңа инде, сиңа.

— Абау, норсыз!

Мөхәммәт мич буендагы утыргычка барып утырды. Кызый каш астыннан гына күз ташлады. Башында көмеш очлым, билендә алтын аеллы каеш. Үзен дистәләгән җайдак саклап йөри. Кем булыр бу?

Мөхәммәтне дә байтак сорау утлы күмер сыман көйдерә иде. Инде җитдиләнеп сүз башлады:

— Уен беренче тапкырында гына күңелле ул. Шаярдык, көлдек, булды. Хәзер яшермә әйт. Син кем кызы буласың, атың нинди?

Кызый янә азау тешен күрсәтеп җавап бирде:

— Син Газраилме әллә, нигә сораштырасың? Әүвәл үзең сөйлә. Син үзең кем?

— Мин меңбашы, — дип, Мөхәммәткә ялган белән капларга туры килде. — Биләр каласыннан. Әхәт булам.

— Сез Бәнҗәне бөтенләйгә алдыгызмы инде? Әллә талыйсыз да кайтып китәсезме?

— Юк, таламыйбыз да, китмибез дә. Бәнҗә — безнең шәһәр. Ләкин синең кебек чибәр кызлар өчен аермасы юктыр. Кай якка кияүгә чыгасыз, сезгә Ватан шулдыр.

Кызый оялды шикелле, йөзенә алсулык йөгерде. Мөхәммәт элекке сорауларын янә кабатлады:

— Йә, син дә әйт. Атаң нинди кеше? Үзеңнең атың нинди?

— Атам юк инде минем, — диде, ниһаять, кызый, моңсулана калып. — Мөкътәсир бәк иде минем атам. Әтилдә яшәдек без. Былтыр аны каган шымчылары эләктереп дарга асты. Мине каган хатынлыкка алмакчы иде, мин качып котылдым. Бер ел була инде монда килгәнемә. Урамга да чыгып күренгән юк. Куркам.

Мөхәммәт башын чайкый-чайкый уйга талып утырды, аратирә йодрыгы белән тез капкачларына да суккалап-суккалап куйды. Бераздан гына ятимә кызга тутырып күз атты ул.

— Исемеңне ничек дидең әле?

— Айсылу ла.

— Ярар, — диде Мөхәммәт, аягына кубып. — Әйдә, җыен. Мин сине үзем белән Биләргә алып китәм.

— Ә син өйләнгәнме соң?

— Миңа биш мәртәбә өйләнсәм дә ярый.

Янә сүз әйткәнче, Айсылуның ияге дерелдәп торды.

— Хажга бардыңмыни?

— Юк, бармадым... Мин хан булам, сылу.

— Нинди хан ул тагын?

— Мин бая сиңа ялганладым гына. Мин меңбашы түгел, ә Мөхәммәт хан булам...

Айсылу шул минутта артка авып китте. Мөхәммәт аны нечкә биленнән эләктереп алырга чак өлгерде.

11

Ул Айсылуны ияренә утыртып кабат хан сарае янына әйләнеп кайткан чакта, хыянәтче Балакны да тотып китергәннәр иде инде. Мөхәммәт күренүгә, сарай баскычына тезелешкән төркем эченнән күптәнге танышы Шоңкар алга чыкты.

— Синең сүзне көтәбез, меңбаш Әхәт. Баулар әзер. Бу сатлыкны ә-әнә теге каеннарны бөгеп икегә аерыбызмы, атларга тагабызмы?

— Син дә Нуретдин шикелле канга сусадыңмыни? — дип кычкырды Мөхәммәт көтмәгәндә, кайнар суга салган кысла кебек кызарып. — Сиңа да шул кан кою, баш кисү, кеше турау гына кирәкмени? Адәм рәтле генә, ипле генә яши белмисеңме?

Мөхәммәтнең яшелле-зәңгәрле тавышыннан шомга калды, күрәсең, азат хәят сакчысы Шоңкар акланырга ашыкты:

— Соң... соң, әле бая гына үзең, бу сатлыкны дарга асам, дидең ләбаса. Үзең шулай дигәч, без ни... без ни...

— Мин ни әйтмәм. Үз башыгыз кайда?

Һәммәсе тын калдылар. Мөхәммәт хан кулларын бауларга чорнап бер чаптар ияренә тагылган Балакка текәлде. Каз талаган сыман тишкәләнгән чалбар, җәрәхәткә батырып тукмалган йөз. Күзләре каш астында ялык-йолык килә, берәүнең дә карашын күтәрә алмый. Селтәнеп суксаң түгел, битенә төкерсәң дә авачак бу. И-и, шушы хөрәсән дә кайчандыр аның әтисе Габдулланың башын ашамакчы иде ләбаса. Тф-ф-фү, нәҗес! Шушы хөрәсән канына ничек кул буйыйсың? Моның ише маймыч белән ваклансаң, хурлыгы ни тора!

Мөхәммәт карашын Шоңкарга күчерде. Монысы җиңү яулады, тантана итә инде. Шоңкар дигән исем йөрткән була, ә үзе үләксә чукыган козгын төсле. Тапкан корбан! Әле Минай хәтле Минай ханны әйләндереп төшерергә үрелә бу, әле Балак кебек эт-бетне дә кабып йотарга әзер. Мондый сайлап тормас, туймас тамаклы козгын аламасы булса, иртәгә Мөхәммәтнең башын да чукыячак бит бу. Юк, сабак бирергә кирәк мондый мәнсезләргә. Боларга гына түгел, Мөхәммәт хан ни кылыр дип көткән менә бу меңнәргә дә. Сабак алсыннар, гыйбрәт алсыннар, ә хәбәре мәмләкәтләр, олыслар, бәйлекләр буйлап китсен...

Мөхәммәт авызын ачты:

— Гали, Әкрәм! — дип кычкырды ул үзенең йөзбашларына. — Шоңкарны да кулга алыгыз! Аннары икесен дә кала читенә алып чыгыгыз да далага җибәрегез.

Бөтенесе күзләрен шакмак итте. Телләрен кайнар эскәк белән көйдергәннәрмени, көрмәкләнә-көрмәкләнә сүзләрен чак әйттеләр:

— Нич-чек, Бал-лакны иреккәме? Ш-шул с-сатлыкны далага җ-җибәрикме?

— Ә Шоңкарны нигә? Нинди гаебе бар?

Мөхәммәт ятлап куйган сыман, тукталышсыз тезде:

— Үч алу ул — кеше җанын ялт итеп кыеп ташлау гына түгел. Бу Балакны тотып астың икән, ул күз ачып йомарлык ара эчендә генә интегә дә котыла. Ю-у-ук, аны гомер буе газап чигеп яшәрлек иттерергә кирәк. Барып сыенырга куыш тапмасын ул. Батса, килеп таянырга яр тапмасын. Йорты, хатыны, балалары булмасын. Һәрбер кабым ашамлыкны үзе эзләп тапсын. Ахырда, инде дөмеккәч, хәтта кабергә индерерлек тә якыннары, туганнары булмасын аның. Гәүдәсен-башын этләр ашап китсен. Менә шул чагында катыйльлегенә, хыянәтенә җәза алачак ул!

— Ә Шоңкарны, ә Шоңкарны нигә куасың соң? — дип, акылга килергә чакырып карадылар, Мөхәммәт тайпылмады.

— Хуҗасын бер мәртәбә сөзгән сыер иртәгә дә сөзә. Аның мөгезен сындырып кына яман гадәтеннән биздереп булмый. Ә бәйгә утыртылган этне әйткән дә юк. Бүген бер хуҗасын таласа, иртәгә яңасына да килеп ябыша ул. Эт котырса, меңәр төрле гөман корып тору артык. Димәк, бүре теше тигән аңа, зәхмәт йоккан. Атай, мәрхүм, хикмәтле бер сүз әйтеп калдырган иде. «Бүре теше тигәнне бүрегә бирү фарыз». Шуңа күрә менә мин Шоңкарны бәйдән ычкындырам. Әйдә, иреккә очып карасын. Теше сынгач кире кайтыр әле…

Балак, җайдаклар кала читенә куалый башлагач ук, күз яшенә батты. Шоңкарның гына йөзендә төк тә селкенмәде. Ул мәйданнан тәмам чыгып югалганчы фәкать ханны гына усал, нәфрәтле карашы белән бораулап-ашап барды. Хушлашкандай, тыкрыктан кычкырган сүзләре ишетелде:

— Тугры этне кугач, өйгә угры керә торган була.

Кешеләр теге якка да, бу якка да карап шаккаттылар. Бу көнне Мөхәммәт бик сәер, аның һичбер хөкемен аңлап булмый иде.

Шул ук Идел буендагы бер урамга күз-колак булырга җибәрелгән йөзбашлары Суардан килгән үзләренең үк туганын эләктереп кайтты.

— Унике яшьлек кызны егып тапалаган, — дип бәян итте ирләр. — Сабый өстеннән моны көчкә сөйрәп алдык.

Җинаятьче дер калтырап елый, ә үзенең гәүдәсе — кысып тотсаң җаны чыгардай ябык. Шушы өтекнең ишкәгенә дә көймә кирәккән бит!

— Ике каен ботагына моны! — дип үкереп җибәрде хан. — Моның ише ыштан бетләренең нәселе корысын!

Өтек ирне җиргә кадәр бөгелгән каеннарга бәйләп икегә аердылар…

Бәнҗәдән чыгып китәр алдыннан бортасларны мәйдан уртасына җыйнап, Мөхәммәт хан аңлаешлы, усал итеп әйтте:

— Минаегызны саугат ясап Болгарга алып китәм. Яңаны утыртсагыз, тагын киләм. Моннан ары сездә таждар ханнар мәңге булмаячак. Сезгә ике генә юл. Йә Болгар тирмәсе янына килеп баш иясез дә гомерлек вә ышанычлы терәк табачаксыз. Йә... Манас каган пычагы астына ятачак сугым маллары сез... Манас яклар, ул коткарыр дип уйлап алданмагыз. Ул яһүди, аның сезнең белән уртак казан асып яшисе юк. Ә без мөселманнар. Манас ике авызлы түгел. Иңгә-иң кушылсак, кабып йота алмас.

12

Нуретдин сәрдәр әле Бәнҗә каласыннан чыгып киткәнче үк Мөхәммәтнең колак итен ашый башлаган иде:

— Яулап алынган каланы җиңелеп хур булган халык кулына кабат ташламыйлар бит ул, бер әмир утыртып калдыр.

Кайтыр юлга чыккач, ялга тукталган саен, ханның яшь хатыны өчен корылган чатыр авызына килеп, Нуретдин чебен сыман һаман безелдәде:

— Дилбегәсе бушатылган ат йөкне читкә сөйри. Бәнҗәгә әмир китереп утыртырга кирәк.

Мөхәммәт хан яшь хатын кайнарлыгыннан исереп өлгергән иде, берзаманны сынды:

— Ярар, син дигәнчә булсын. Минем малайлар бәләкәйрәк әле. Кемне утыртабыз?

Менә шул вакытта гына битлеген салды сәрдәр:

— Минем Рахманга егерме биш яшь тулып килә инде, әле һаман үзенә аеры сояк кимереп караганы юк. Бүгенгәчә минем учактан калган күмер эчендә генә актарынып ята. Малай кешене вакытында тездән төшермәсәң, атасының сакалын йолка, диләр. Минем Рахманга да үз казанын асарга вакыттыр бит инде:

— Соң, сине сәрдәр итеп куйгач, болай да энекәшең Елкыны Кашан каласына утыртып калдырдым ла инде. Бәнҗәне Рахманның авызына каптырып, сезнең нәселгә ярты ханлыкны бүлеп бириммени? — дип, Мөхәммәт әүвәл каршы чыккан иде, Нуретдин пычакны икенче кабырга арасына китереп тыкты:

— Син Кашанга хәйлә белән чакырып Нур-Суардан кори калдырганчы, мин дәүләтнең иң бай әмире булып утыра идем. Биләр, Биләр, дисәң дә, пайтәхеттәге казнаның байлык-зурлык ягыннан Суар казанын узганы юк әле. Аннары Рахманга да, барыбер, гел минем табактан ашап, миннән кал-

ган киемнәрне киеп яшәргә димәгән бит. Алма ашыйсы килде дип кенә аның агачын җимеше яшел көе селкетмиләр бит ул. Пайтәхеткә киләчәктә хезмәт итәрдәй угылларны, агачкагөлгә су сипкән шикелле, бүгеннән үк сыный-сыный үстерү хәерлерәк. Биләрдәме, Бәнҗәдәме, ул барыбер синең табаның астында олтан булачак кеше. Мин картаеп барам. Ходайныкын белмәссең, иртәгә аның минем урынга вәзир булуы бар.

— Әй, ник чукынып китмисез! Чапкын җибәр. Аллага шөкер, яусыз-нисез көенчә бортасларны куштык. Болай барса, мин Биләрдә озак утырам әле, — дип, Мөхәммәт хан һаваланып-юмартланып кул изәде. Шушы беркатлылыгы белән үз башына никадәрле афәт чакырганын ул, әлбәттә, күзалламый иде.

…Инде тәмам ир булганнан соң гына әтисенең куеныннан чыккан Рахман Бәнҗәгә башта ук бер мең газилек нөгәр белән килде. Аерым вилаять хуҗасы булып алгач, беренче эше итеп, тирә-юньдә йөргән угызлардан, бәҗәнәкләрдән, кыпчаклардан янә ике мең газиле чирү туплап куйды. Моның чаклы гаскәрне, билгеле ки, коралландырырга, ашатырга, йоклатырга кирәк. Рахман озак-озак итеп баш ватмады, үзенең вилаятенә буйсынган барча кала-олысларга өстәмә салым җиткерде:

— Ике моржа саен берәр елкы йә дүрт сарык! Зөлхиҗҗә ае кергәнче фәрман үтәлмәсә, олысларны үзем айкап чыгам!..

Акбүләк калачыгы вилаять чигендә, аның хуҗасы Арыслан бәк күбесенчә, карт каен кәүсәләре астына поскан җиләк үсентеләре, абагалар кебек, йә хәзәр яубашларына, йә аймык тарханнарына ышыкланыбрак яшәргә тырыша иде. Бәнҗәдә хасил булган яңа әмир фәрманын ишеткәч, һич тә тәгәрәп төшәргә ашыкмады. Ә ул арада инде зөлхиҗҗә ае аяк атлады да, аяз көнне суккан яшен сыман, Акбүләк олысына Бәнҗә газиләре килеп керде. Чирү башында әмир Рахман үзе килгән икән, Арыслан бәк, меңәрләгән елкылар көтүен куалый-куалый, яраннары белән шома гына итеп далага чыгып качты. Юк, Сакмар, Җаек елгалары буендагы бәләкәй урманнар артына кереп яшеренергә ирек бирмәделәр. Җәенке яңаклы, кысык күзле бәҗәнәк йөзләре куып җитте дә, Арыслан бәк белән аның яраннарын мал көтүе урынына чыбыркы белән куалап, янә Акбүләк урамнарына алып кайтты.

— Әмир Рахман Бөтерчек Таш чишмәсе янына чатыр корган, синең баш иеп килгәнне шунда көтә, — диделәр.

Арыслан бәк тәгаен чамалады: яңа әмиргә качак бәк кирәк түгел, ул Акбүләк хуҗасыннан икеләтә бүләк көтә инде. Бәйләнчек Саз буена күмгән алтын-мәрҗәннәр моңа харам булыр, Акбүләктәге иң сылу кызларны җыеп илтсәң дә өне тыгылмас микән?

Олыс бәге әзерләткән кәрван атларына илле кызны тезеп

утырттылар. Кызкайларның күлмәкләре-җиләннәре ука җепләр белән чигелгән, чәчләрен кырыкмаса кырык төрле вак-вак толымнарга аерып үргәннәр. Кыйгач кашларына, озын керфекләренә сөрмә тартканнар, битләрендә иннек. Берсеннән-берсе чибәррәк шушы кызлар да ярамаса инде!..

Әмир Рахман аны ап-ак киез чатыр алдында, ак бәз япкан артлы кәнәфигә утырып каршылады. Алдан ук сөҗү әзерләп салганнардыр инде, ул әледән-әле керәч чәйнек борынын имеп-имеп куя. Күзе тонган, изүләре ачык, күкрәген йон баскан. Арыслан бәк тезеп куйган кызлар ягына караш та ташламады:

— Алар болай да минеке, соңрак өлгерермен, — ди. Ә аннары инде Арыслан бәкнең бөтенләй ис-акылын алды: — Синең яшь хатының бик чибәр икән бит, шуны апкил. Шәхсән үзең, үз кулларың белән китереп бир, аңладыңмы мине?..

«Бәйләнчек Саз буена күмгән алтын-мәрҗән әрәм». Арыслан бәк вәлидә хатынын әмир Рахман чатырына кертергә мәҗбүр булды. Ләкин азгын белән убырның нәфесен бер йотым су белән генә басып буламы соң? Кайсы сатлыгы ничек итеп җиткергәндер инде, чатырдан чыгуга Рахман иярге сикерде дә Актүбәгә Арыслан бәкнең унбиш яшьлек кызы Ләйләне эзләп китте.

Гайшә исемле хезмәтче кыз мунча яккан икән. Ләйлә белән Гайшә икесе дә мунчада булганнар. Рахман шуларның өстенә барып кергән. Әүвәл, ләүкә өстенә салып, Ләйләне көчләгән ул, Гайшә ачыргаланып елый-елый читтән карап торган. Аннары: «Ә-ә, кызыгасыңмыни?» — дип кычкырган да, сикереп торып Гайшә өстенә күчкән...

Чатыр янына кире әйләнеп кайткач, ат шикелле кешнәп көлә-көлә, Арыслан бәккә боларны үзе сөйләде ул. Шушы килеш кенә калган булса, Арыслан бәк әле ычкынмас та иде. Ахырда әмир Рахман бармак башы чаклы тешләрен ыржайтып әйтеп салды:

— Яшь хатының да, Ләйләң дә, ай-яй, кайнар икән! Син мунча ягып, бал китереп торырсың, ә мин аларны, икесен берьюлы, берәр атна чамасы тагын кытыклармын.

Менә шул чагында, йодрыкларын төйнәп әмир өстенә ташлангач, Рахман сакчылары кылыч белән сыңар кулын чабып өзде аның... Арыслан бәк беркадәр савыгып аягына басуга ук, ат атланып, далага чыгып китте. Әүвәл аны Бәйләнчек Саз буенда күреп калганнар, аннары кара аймыклар җәйләве ягында...

Биләргә хәбәр кайтты. Әле шул Акбүләк олысында чагында ук әмир Рахман белән ул үзенең баскын гаскәренә сәрдәр итеп куйган Булат арасында бик тә каты җәнҗал

күпкан икән. Сабанчыларның, елкы, дөя, сарык көтүе тотучыларның үкереп елавына түзә алмыйча, сәрдәр Булат үзе башлап тавыш кузгаткан, ди:

— Өстәмә салым түләү турындагы фәрманыңны кире ал, болай булмый. Иртәгә бөтен гавам сине сөңге очына күтәрә бит.

— Юк, байгуралар бер фәрманны ике кабат кабатлар өчен дә, кире алыр өчен дә тумыйлар ул, — дип җавап тотты нык кәпрәйгән Рахман.

— Син әнә үз артыңнан биш йөз җарияле хәрамханә сөйрәп йөртәсең. Гавамнан талап җыйган бөтен байлык шул җарияләр илә газиләргә китә. Дошман пәйда булса, чирү хәстәрләргә казнада бер динар юк. Сиңа ил кайгысына караганда, хәрамханә ятаклары кадерлерәк икән алайса, бар инде, җарияләреңнең итәк-чабуына каплан да ят.

Булат шулай тузынган-тузынган да, үзенең йөзен иртеп, Бәнҗәгә кайтып киткән. Акылга утыртмакчы булып, Рахман аның артыннан өч йөз җайдаклы нөгәр юллаган, ди. Әмма тегеләре Булат әләме астына барып кушылганнар. Хәзер Булат Бәнҗәдә утыра, Рахман олыслар буенча типтереп йөри. Ни белән бетәр бу?..

Яз җитүгә, шәрекъ ягыннан болыттай тузан күптарып, Болгар җиренә аймыклар чирүе бәреп керде. Юл йөртүчесен сыңар куллы качак болгар карты, диделәр. Бу, чыннан да, Болгар илен яхшы белә бугай, аймыкларны иң яшерен иңкүлекләр, үзәннәр арасыннан Биләргә таба алып килә башлады. Мөхәммәт янә тиз арада унбиш меңлек чирү туплады да җайдакларны дошманнарга каршы алып китте. Тук Елга буендагы таулы-чокырлырак урында очраштылар.

Мөхәммәт хан алдан ук бер иңкүлеккә кайсы ефәк, кайсы киез чатырлардан ыстан корып куйды. Ышанычлырак булсын дип, дистәләгән казан астылар, учак тергезделәр. Янда ике-өч йөз генә шәп тулпарлар белән сакчылар калдырдылар. Имеш, бу хәрби ыстан түгел, ә азык-төлек, корал, шайман, ганимәт[1] җыйналган олау һәм аны саклап йөрүче нөгәр генә.

Аймыклар шул кармакка эләкте. Меңбашлары, йөзбашлары камчы белән яра-яра тыюга карамастан, гади җайдаклар берсен-берсе сыта-сыта, меңәрләп-меңәрләп чатырлар эченә ябырылды. Үзара ызгыш-талаш, сугыш күпты. Мөхәммәт нәкъ менә шул минутта тозакка куелган меңнәре белән аймыклар өстенә ташланды.

Болгар җиренә керергә җөрьәт иткән кадерсез кунакларны аяусыз турадылар. Аймык меңбашлары калдык-пос-

[1] Ганимәт — трофей.

тык йөзләрен алып качарга мәҗбүр булды. Мөхәммәт каршына сыңар куллы дәрвишне тотып китерделәр.

— Кем буласың? — дип кенә сорады тимер битлек киеп алган сыман кырыс йөзле хан.

Дәрвиш һич тә коелып төшмичә җавап тотты:

— Элек Арыслан бәк идем, хәзер колчурамын. Синең җәлладларың йортсыз калдырдылар.

— Кем рәнҗетте сине?

— Синең язгы боздай ышанычсыз вәзиреңнең улы.

Мөхәммәт хан бераз вакыт кына ияр өстендә уртларын уйнаклатып утырды да уттай көйдерерлек карашын янә Арыслан бәк йөзенә күчерде.

— Мин хата җибәргәнмен, мәгәр ул төзәтердәй. Ә синең гаебеңне, менә шушы чулак кулың кабат үсалмаган шикелле үк, төзәтә торган түгел, Арыслан... бәк. Син сыңар кулыңны дәүләт тикле дәүләткә алыштыргансың. Сиңа үлем җәзасы тиеш, гафу кылу көтмә...

Бераздан чатырлар артында кисәк кычкырып җибәргән тавыш ишетелде дә бер мизгелдән тынды. Мөхәммәт җансакчыларына борылып әмер бирде:

— Бәнҗә илә Кияү каласына чапкыннар җибәрегез. Булат сәрдәрне Бәнҗәгә әмир итеп куям. Ә атам юллаган Даян мәргәнне алыштырырга вакыт. Чит мәмләкәт йөрәгенә үтеп, аларның бар серен аңлый белә торган сәйяхчыларыбыз бик күп түгел безнең. Нуретдин вәзир әнә бер улын да йөгәндә тота алмый, ник картайды. Бәлки, Даян мәргән аның дилбегәсен үз кулына алыр. Тизрәк кайтарыгыз...

Болгар гаскәре һаман бер урында таптанды, ә аймыклар далаларына кайтышлый чик буендагы авылларны кырып узган икән. Җаек ягыннан килгән ул хәбәрләр бер дә сөенечле түгел иде.

— Сиксән авылны яндырып юк иткәннәр. Кыр-яланда карт-корылар гына утырып калган. Яшьрәкләрнең барчасын да Хорасан базарына колчура итеп сатарга алып киткәннәр, ди.

13

Шәрекътан искән ачы җилгә каршы кәрван бара. Кол итеп алынган болгарларны Хорасанга илтүче аймыклар кәрваны ул. Болгарларның кулларында зынҗыр, муеннарына озын бау тагылган. Көчле җил, дала буйлап куып, әллә нинди тозлы ком алып килә. Ул күзләргә, борынга, колакларга тула. Ышыкланырлык әмәл табып булмый. Бер-берең ар-

тына елыша башладыңмы, кәрванбашка сакчы булып ялланган угызлар сыртыңа камчы белән сыдыра йә сөңге очы белән китереп кадый. Сакчыларның һәммәсе дә ат яки дөя сыртына атланган, аларга тубык тиңелтен ком сазлыгын ерып җәяү атлыйсы түгел. Рәхәтләнеп йокымсырап баралар-баралар да, күзләрен ачтылармы, җен алыштырып куйган шикелле акырып, алга куалыйлар. Һәммә колның сыртында камчы эзе, сөңге яралары. Киемнәре телгәләнеп беткән, умырылып төшкән. Мондый мохтаҗлык, җәфа, кимсетелүләргә түзәрләр иде әле. Иң яманы — эчләре сыртка береккән, тамак төпләре ут яккандай корыган. Һәммәсенең су эчәсе килә. Бер генә йотым булса да су бирсеннәр иде. Су кирәк аларга, су, су, су…

Байдар инде ничә көннәр буе аяк астына карамаска тырыша, янәшәдә ятып калган тауларны, чокырларны, үзәннәрне күзли. Аяк астына төбәлсәң, баш әйләнә, егылуың мөмкин. Егылдыңмы, сакчылар сояк күргән ач эт көтүе шикелле котырынып өстеңә ташлана. Җаек, Иләк, Үр елгалары буенда инде ничәмә-ничә дистә болгар ятып калды. Кәрванбашка Хорасан базарында сатарга таза ирләр, чибәр кызлар кирәк. Чирлеләр, ябыклар, гарибрәкләр аңа берни түгел. Сакчылар аяктан егылган хәлсезләрне кыйный-кыйный куалап карыйлар да, өмет булмадымы, үләксә урынына ташлап калдыралар. Ярамый моның ише юлда егылырга, ярамый, ярамый.

Ә тирә-юньне ятлап, хәтер сандыгына салып калдырырга кирәк. Кол итеп базарда сатылуга кадәр барып җитмәс Байдар, барыбер качар. Кол хәленә калып, тез өстендә йөреп, адәм хуры булып яшәү өчен туып үсмәде ул. Ул гаиләдә бердәнбер бала иде. Әтисен әле Байдар сабый чакта ук хәзәрләр белән яуда үтерделәр. Әнисенең күзе чалыш иде, аны яңадан кияүгә сорап килүче адәм табылмады. Шул әнисенең йөзендәге кыек өчен малайлар бәләкәй чактан бирле үртәп йөргәннәр иде дә, Байдар алар арасында иң эре гәүдәле, усал йодрыклы малай булып үсте. Бер-икесен егып чирәм ашаткач шундук туктадылар. Байдар әле аннан соң да гел сугыш чукмары булды, ташбаш булды. Ауга чыккач, берәр авыл егетләре белән туры килделәрме, кадрәклеләр аларны дөмбәсләргә гел Байдарны алга чыгардылар. Олыскүләм кубып уздырылган бәйрәмнәрдә аркан тартыш, көрәш, баганага менү, таш ыргыту буенча бәйгеге оештырдылармы — күп очракта Байдар җиңеп чыкты. Арттан баш түбәсенә күсәк белән китереп ормасалар, аймыклар кулына да төшми иде ул, унын-егермесен тал чыбыгы урынына турап ата иде. Хәер, базарга юл ерак, аңа хәтле барыбер качачак ул…

Тугыз коймак дигән тәбәнәк кенә таулар ышыгына килеп егылгач, торгаклар[1]-кушчылар[2] саксыз-күзәтүсез калдырдылар аны. Шушы урынга җитәрәк кенә ике җәйран атып алганнар иде, ялга тукталгач, шуларның тиреләрен тунаганны, казан асканны аю биеткәндәй кararга җыелдылар. Берәве ит турый, икенчесе корыган карама, чаган, зелпе ботакларын сындырып ташый. Гел җәйләүдә, гел елкы көтүе көтеп үскән бер яшь аймык кубыз чиртергә дә тотынды бит хәтта. Чирәмгә тезелешеп утырган колларда гамьнәре бөтенләй юк.

Тыныч, ямьле урын бу. Бер якта түбәтәй шикелле бәләкәй генә, йомры гына таулар. Икенче якта өстен яртылаш рәвештә төнбоеклар каплаган озынча күл. Исемен Акборын диделәр, туры килә. Әнә бит, очлаеп торган бер башы тоташ ак ташлардан гына хасил ярымтүгәрәк ярга килеп төртелә. Җитмәсә, яр өстендә тагын ялтыравыклы укалар белән катнашкан ап-ак ташлы озын калкулык бар. Валлаһи, Акборын бу.

Торгаклар болгарларның бауларын-зынҗырларын төнгелеккә дә салдырмаган иде. Байдар баудан ычкыну җаен күптән уйлап тапты. Яныңдагы ике колны алмаш-тилмәш итеп култыкларың астыннан үткәрәсең дә, үзең ычкынасың. Дөрес, алай иткәч теге ике күршеңнең муен тирәсендәге төеннәре тагын да тыгызланыбрак, өелеп кала. Ләкин аларны да яндагы янә күрше белән әвеш-тәвеш китереп ычкындырып була. Чылбыр буенча шул рәвешчә китсәң, барлык әсирләрне дә «муенчак»тан азат итү мөмкин. Тик һәммәсе дә риза булалармы әле әсирләрнең, куркып калалармы? Уенмуен түгел, эләксәң, кылыч астына ятуың да бар бит…

Төнлә чышан-пышан килеп уяткач, ике яктагы ир дә Байдар тәкъдименнән куркып баш тарттылар. Берсе сүгенүдән дә тыелып тормый:

— Ычкынып, анаңның итәк астына кереп качасыңмыни? Ул да юк, ичмаса. Ә монда бөтен тирә-якта дала. Уч төбе шикелле, ун чакрым ара аермачык көе күренеп тора. Куып җитәләр дә тураклыйлар. Аннары гәүдәңне йә чүл бүресе, йә козгыннар талый. Пычагыма кирәк. Харәземдәме, Бохарадамы, кем генә сатып алмасын, кайда да барыбер мич салам мин. Бохарада салдың ни дә, минем кечтеки Сарсазда салдың ни, миңа аерма юк, шул ук кирпеч. Син теләсә нишлә, ә мин качмыйм.

Икенчесе егетнең бала башы кадәр булып кысылган йодрыкларыннан шөлләп калды, ахры, анысы сугым малы сыман бөтенләй дәшми ятты. Байдар берүзе купты. Төнге торгаклар божрасыннан шуышып чыккач, ерак качмады ул.

---

[1] Торгак — сакчы.

[2] Кушчы — кәрвандагы хезмәтче яки кол.

Акборын ярыннан әүвәл сөяк төсле каты булып кипкән көпшә сындырып алды, аннары чупылдатмый-селкетмичә су төбенә чумды.

Иртән, иң беренче булып, әлбәттә инде, төнге торгаклар оран салып гауга кузгаттылар:

— Болгар пәһлеваны качкан! Бер кол качкан!

Тирмәдән сикереп чыккан кәрванбашы кул астына эләккән бер-ике торгакны тотып ярды.

— Ул пәһлеван — дөя бәясе торырдай кол иде. Тапмасагыз, мин сезнең үзегезне базарга чыгарып сатам!

Торгаклар күл тирәли йөгерешә башлагач, шул ук кәрванбашы дөя шикелле үкерә-үкерә әмер бирде:

— Иярге менегез дә әнә Карагач үзәненә таба элдерегез! Бу якта адәм качып калырдай башка иңкүлек юк. Качса, шул якка гына китә. Тапмый кайтсагыз, асам!..

Әлбәттә, чапкыннар Байдарның эзен дә тапмый кайтты. Кәрванбашы күңелен бушатыр өчен генә тагын икеме-өчме торгакның сыртына камчы белән сыдырды-тамызды да алга кузгалырга әмер бирде. Шулай да, киткәндә үкенеп, ярымсыкрап дәшкән сүзләре күл өстендә яңгырап торды әле:

— Дөя бәһасе байлыкны кулдан ычкындырды, кадалгыры сукбай!..

Байдар төнбоек яфраклары астыннан чыккач та байтак вакыт буе дала өстен, офыкны күзәтеп утырды. Бер якта да тузан күренмәгәч кенә тәвәккәлләп яр өстенә чыкты. Ярты төн буена су эчендә утыру нык туңдырган иде. Башта керпе сыман йомарланып барырга мәҗбүр булса да, ул бераздан җылыну өчен йөгерүгә күчте. Ничә тәүлек буе юньле ризык күргәне юк, җеп өзәрлек тә хәле калмаган шикелле, ә барыбер ашыгырга кирәк. Дала-дала дисәң дә, сәүдә юллары бу. Әллә нинди этләр-сыртланнарның иснәнеп йөрүе мөмкин. Кулларына килеп каптыңмы, беттең. Янә зынҗыр синең кулларыңа, янә камчы.

Ике тәүлек чамасы алпан-тилпән килеп атлый торгач, ул тоташ вак ташлардан гына хасил ике тау арасына качып урнашкан бер бәләкәй алачык өстенә барып чыкты. Киртә-казыкларны элде-ялды гына бәйләп ясалган ихатада иярләнгән ике чаптар әллә солы, әллә арпа чемчи, шулардан кала алачык тирәсендә бер җан иясе дә күренми. Нинди сәер ыстан бу, хуҗалары кайда? Ачыгавыз сукбайларны коллыкка эләктерергә йөрүче кушчылармы болар, әллә аймык, угыз, кыпчак яубашларының шымчы чапкыннарымы? Болгар өстенә яңа каза чакыручы саескаңнар булмаса ярый тагын.

Байдар чокыр-чакырлар эченә кача-поса киртә ихатага таба якынлашты. Көтмәгәндә борынына кыздырган ит исе

килеп бәрелде аның, башы әйләнеп китте. Их, бер генә кисәген булса да эләктерәсе иде шуның, тик кайда ул?

Киртәләр артында гына калкып чыккач, ике чаптар да өркенеп ялгаш аламасыннан читкә сикерделәр. Өзәңге-авызлыклары чыңлап куйды, Байдар янә бер таш артына посты. Юк, алачык эченнән һичбер төрле аваз ишетелми, үләт кыргынмыни?

Байдар ихата эченә сикереп керде. Алачык нигезе янында урталай чабып ташланган эт гәүдәсе ауный, янда ит белән дөге боткасы салынган агач җамаяк тора. Нишләп ризыгын да ашарга өлгермәгән бу мескен, нигә юк иткәннәр? Дүрт аяклы хайваннар беркатлы һәм эчкерсез сантыйлар бит. Ике аяклы җанвар бер кабым ризык күрсәтсә дә, шуңа алданып, койрыкларын болгый-болгый чабып килергә генә торалар. Бу бичараның да шул нәфсе, тәгам дигәннәре башына җитте микән?

Уйланып, баш ватып торырдай ара юк иде. Капылт сикерде дә Байдар әүвәл җамаякны эләктереп алды. Икенче мизгелдә ул инде өзәңгеләргә дә басып тормыйча бер чаптарның ияренә менеп алган иде. Киртәләр аша сикереп кузгалырга җыенгач, яшен төсле уй көйдереп узды: «Икенче чаптарны да ияртмәсәм, болар куып җитә».

«Нигә әле мине сайламадың?» дигән сыман үзенә томырылып карап торучы икенче чаптар йөгәненә үрелгән генә иде, артта кырыс дәшкән аваз яңгырады:

— Нәфесең тишек капчык кебек икән синең, угры. Ә миңа ни кала?

Өшәнеп артына борылса, кызлар кебек нечкә билле бер ир басып тора. Өстендә күлмәк тә юк, ә кулында угын корган җәя. Әлеге юлчы берәр чишмәгә йә якындагы күлгә барып юынгандыр инде.

— Төш, җаныңны орыйм! — диде ул усал итеп. — Адым саен ат өләшеп йөрергә син мине хан дип белдеңме әллә?

Сөйләндереп уяулыгын йоклатырга кирәк, дип уйланды Байдар. Сыңар аягын өзәңгедән ычкындыруга ук телгә килде:

— Көмешләнгән иярле икешәр ат тоткач, бик үк хәерче дә түгелсеңдер инде. Син минем сымак бер җамаяк эт ашына калган мескен сукбайга охшамаган алай.

— Ха-ха-ха! — дип көлде күңеле булган җайдак.

Икенче мизгелдә ни булганын ул аңламый да калды. Әүвәл аның чыраена ботка тулы җамаяк килеп бәрелде, аннан угры сукбай, аю сыман сытып, өстенә менеп ятты.

— Син кияүгә бирәсе кыз түгел лә, юха телгә нигә алданасың? — дип сөйләнде өстә аны тез астына бөгеп салган Байдар. Әллә каян гына бау кисәге тартып чыгарды, атлар иясенең кулларын чорнап куйды. Җәяне иңбашына киеп

алган Байдар бераздан инде янә ияр өстендә утыра, баягы хужа тузан эчендә аунап ята иде.

— Үпкәләмә, — диде Байдар хушлашкандай. — Бер атыңны алам. Мин син уйлаганча ук убыр түгел. Берсе сиңа кала... Куа чыкма. Ханны озаткан сымак ияреп йөрүләрен җенем сөйми.

14

Җаек елгасын кичеп, Болгар чигенә кергәндә, таудагы куакларга ышыкланып барган җайдакны шәйләде ул. Ара шактый ерак, шулай да җайдак япа-ялгыз, моңа шик юк. Ашыкканы-көйгәне сизелми, аты кунактан кайтып килгән шикелле юыртып кына бара. Җайдак үзе зур гәүдәле түгел, өзәңгеләр ат корсагы астына асылынып тормый. Иңбашына җәя генә элеп алган сыман, һәрхәлдә, сөңге очы, чукмар ише корал күренми. Нинди пошмас сукбай бу? Нишләп бер аягын атлаганчы икенчесен эт ашардай үшән?

Байдар да чаптарын күләгә яткан иңкүлек эченә төшерде һәм, җеп белән тагылгандай, сәер җайдакның эзенә басып бара башлады. Чаптарын аз гына кыздырып алган иде, ара якынайды. Бу кеше белән уртак казан асасы юк әле, дип уйлап, атын тыя төште. Карашын аермыйча гел күзәтте. Әллә нинди сәер, әкәмәт кеше бу. Тау итәгендә түтәлдәй укмашып утырган миләүшәләр, кыңгыраулар, кызалаклар янына килеп җиткән иде, ияреннән сузылып, алты-җиде чәчәк өзеп алды. Шуларны әүвәл исни-исни иләсләнеп барды, аннары юргасының ялына үреп куйды. Әллә хатын-кыз инде бу, кәһәр суккан?! Гәүдәсе дә кечкенә, коралы юк. Алай дисәң, нигә ирләр киеменнән? Ни өчен ялык-йолык килеп торган көмеш очлым кигән? Ул кәрваныннан адашып калган берәр байчура кызымы соң әллә?..

Үзәнлекләр эченнән сузылып бара-бара, көзге сыман ялтырап яткан күл буена җиттеләр. Тирә-юненә эреле-ваклы балан, чикләвек, чаган куаклары тезелеп киткән. Яр буенда камыш, сарут, кыяк. Әз генә җил истеме, күлнең өсте су анасы астан кытыклаган сыман шадраланып китә. Ә суы күк йөзе шикелле зәп-зәңгәр, чип-чиста, үтә күренмәле. Ара-тирә балыклар да сикерешеп куя. Җәннәт бакчасы дигәннәре менә кайда икән!

Сәер җайдак яр буена килеп җитүгә үк, як-ягына караныпта тормыйча, өстен салып атты. Чит көтүгә иярген бәрән сыман тагылып килгән Байдар чаптарын зирек агачлары ышыгына кертеп яшерергә өлгергән иде инде, үз күзләренә үзе ышанмыйча, авыз ачып калды. Менә хикмәт!

Алты-җиде дилбегә арасы ераклыкта бер кыз басып тора. Өстендә тасма да юк. Толымнарын иңбашыннан төшереп күкрәгенә салган. Алма шикелле түм-түгәрәк, нәни күкрәкләре кар көртләре сыман тырпайган. Ике учка сыеп бетәрдәй бил. Җәйраннарныкына биргесез озын, матур ботлар. Уртада йөрәгеңне күкрәгеңнән суырып алырдай булып ымсындырып торган гөлҗәннәт... И-их, сылулык! И-и, бетмәс-төкәнмәс әкияти зиннәт!..

Кыз бишектәге сабый баланың күз яшьләредәй керсез, чиста сулы күл төбенә чумды. Балыкмыни, ничек оста йөзә! Су өстендә әле ап-ак мендәрләре ялтырап ала, әле нәни алмалары калкып чыга. Байдар тешен кысып, учын кысып ята. Алгысынма, түз, егеткәй, түз! Син юлбасар түгел. Шулай да, и-их, тагын бер мәртәбә су өстенә калыксын иде бит инде! Ah, бу kahәр!..

Яр өстендә аның киемнәрен кочаклап торган чит-ят ирне күргәч, сылу кызый чирәм өстенә чүгәләде дә чәр кычкырып җибәрде:

— Әй-яй-я-ә-әй!

Бер мизгелдән кызый яңа төрле кубыз җыры кушты:

— Аб-бау, аб-бау!

Байдарның авыз ера башлавын күргәч, кешечә сүз катты:

— Әллә коралы юк дип, тотып көчләргә җыенасыңмы, норсыз? Килеп кенә кара, менә сиңа!

Кызның кулында нәни генә хәнҗәр пәйда булды, Байдарның күзләре маңгаена менде. Кайдан суырып чыгарды, кая яшергән ул?

— Курыкма, мин сиңа кагылмыйм, — дип, Байдар үз тавышын белдерде. — Сине кызык итмәкче идем, киемнәреңне шуңа гына алдым.

Кызга да җан керде, тавышы юньсез кияү эләккән каенаналар мырлавына охшап, хәтәр усал чыкты:

— Нигә үзеңнеке сыман кочаклап торасың соң? Бир алайса.

Киемнәрне алга сузып килгән егетнең ерык авызына карап алданды кыз. Күңеле су өстендәге балык шикелле уйнаклаган Байдар аны болан баласы урынына каптырды да күкрәгенә кысты. Карашында бернинди этлек, явызлык, мәкер юк иде бу егетнең. Тик эчкерсез, самими хисләр генә дә назга сусау. Шуны тыя алмыйча, гөлгә кунган бал корты шикелле, аның сусыл иреннәренә капланды егеткәй. Җир чайкалып китте...

Айныгач, чирәм өстенә сузылып яткан көенчә таныштылар алар.

— Сания, — диде сылу үз исемен. — Жүкәтау каласыннан. Шундагы Мирас атлы кешенең кызы булам. Әткәй-

әнкәй янына гына кайтып булмый. Әллә ничә айлар буе качып йөрим инде. Гел-гел берьялгызым. Син минем яныма сиздерми якынайган тәүге кеше. Нигә качам? Анысын син сорашма. Мин би-и-ик хәтәр кеше. Сиңа минем белән янәшәдә йөрү ярамый. Тоттылар исә, сиңа да, миңа да йә дар агачы, йә дөм караңгы зиндан.

Байдар кычкырып көлде:

— У-hy-hy! Алай бик куркыныч булгач, мин синнән калмыйм да калмыйм инде. Синең ише хәтәр кеше белән бергә яшәү үзе бер юаныч, үзе зур дан. Аннары, мин синең мондый татлы иреннәреңнән ничек аерылыйм ди?

Күләгәдә үскән гөл шикелле җылылыкка һәм назга сусаган иреннәр тагын-тагын бергә кушылдылар. Күл буендагы мамыктай чирәмнәр дә яшь кияү белән киленнең тән җылысын, назларын таратмаска, сакларга тырыша иде сыман. Хәтфә үлән сабаклары әле байтак вакыт буе бер дә тураеп басарга ашыкмыйча ятты…

Бауга бәйләнгән шикелле һәрчак бергә йөргән бу ике җайдакны соңыннан йөзәрләген чапкыннар, дәрвишләр, сәйяхчылар күрде. Ләкин берчакта да алар янына якын килә алмадылар. Болар офыктагы өрәк сыман иде. Сәер риваять туды.

Имеш, бер явыз хан ниндидер сылуга очраган да аның фирүзәдәй зәп-зәңгәр күзләрен күреп сихерләнгән, кулын сораган, ди. Кызның читтә сөйгән егете булган, ул баш тарткан. Шуннан хан бу чибәрнең күзләрен чокып алырга боерган, ди. Җәлладлар кызның кулына ябышып өлгергәнче, күк йөзеннән канатлы атка атланган егете килеп төшкән. Кызны алган да янә күккә, ак болытлар өстенә менеп киткән. Хан сихерләп өлгергәндер инде. Кызга чит-ят кешеләр якынаеп йөзенә текәлсәләр, сылуның күзләрендәге фирүзәдәй гүзәл зәңгәрлек юкка чыгачак та, бу кәләш шул минутта сукыр әбигә әйләнәчәк икән. Менә шуңа күрә бер дә кешеләргә якын килми, ди, алар. Хәвеф-мазар туса, егет кызны канатлы атына утырта да күк йөзенә күтәрелә икән. Шулай да бик бәхетле булып яшиләр, ди бит, икесе дә, амин.

15

Көннәр, сау-сәламәт кеше сулыш алган төсле, сизелми дә узып кына тора. Тау сыртларын каплап алган имән-өрәңгеләр, сирәк күрешүчән кодагыйлар кебек чөкердәшеп утырган яфракларын да койгач, кылыч-сөңгеләрен тырпайтып дошман чирүен каршыларга әзерләнгән яугирләр төркеменә охшап калды. Ерактан күзәткәндә, яугир-агачларның кыяфәте хәтәр. Аларның һәммәсе дә хәзер йөзәр куллы, мең бармаклы сыман.

Җиһанга көз керә. Ул фәлән еллар буе сәйяхлыкта йөргәннән соң гына кәләш изүенә борынын төртү бәхетенә ирешкән яшь кияү шикелле бөтенләй акылдан ычкынды, күрәсең. Әнә бүген дә җил әле әнисенең күкрәгенә ябышкан сабый бала сыман җиргә ятып исә, әле тәртә арасына тәүге тапкыр җигелгәч арт аякларына күтәрелеп чыгымлаган ярсу тайдай өермә ясап дулый. Шәрекъ яктан, Җаек дәрьясы буеннан күпкан пырдымсыз җил инде бу. Ә җил-давыл мондый чакта кояш чыгышы тарафыннан истеме, бетте диген. Болай булса, көз бик озакка сузылачак икән. Шундый сынамыш бар, картлар шулай диләр.

Байдар бөтен тәнен борча талаган шикелле кыбырсына, бер урында утырып тора алмый. Әле быелгы җәй уртасында гына бастырып куйган алачык тирәли ничәмә-ничә кабат урап чыкты инде. Бу — алачык кына түгел түгелен, Кадрәктәге байтак кешенең борынына төртерлек өй инде ул, ләкин Байдарның алай олыдан кубып сөйләнергә бер дә теле бармый. Шуның карындык тарткан тәрәзә аламасына ябык ишекләрне тырный-тырный җылы эзләп йөргән мәче балалары шикелле бара да төртелә, бара да төртелә. Әмма алачык-өй ишеген ачып эчкә уза алмый. Аны бүген казан тирәсендә комачаулап йөргән ялкау килен урынына сыпырып чыгардылар. Хәзер дә әле рөхсәт бирүче юк. Аннары... иң мөһиме... эчке яктан тилмереп көткән сабый тавышы да ишетелми һаман. Байдарның хатыны бала таба бүген. Сания бәгырькәе аңа бүген сабый бүләк итәчәк!

Яландагы җил-давылга төкерми дә Байдар. Аның үзенең күңелендә ут давылы, үз эчендә туфан. Мичкә ташлаган әрдәнәләр инде күптән янып беткәннәрдер. Күбесенчә усак утыннарын ыргытып чыкты бугай. Ә усак — айлар буе киптерсәң дә мәңге чи инде ул. Ирдән уңмаган хатын шикелле яшереп кенә, чыш-пыш килеп кенә елый-елый, күз яшьләрен агызаагызза, әллә кайчан юкка чыкканнардыр. Җитмәсә, әнә җиле дә бик усал, саламнан япкан түбәнең итәкләрен кыз-кыркын янында бөтерелгән шук малайлар шикелле күтәреп-йолкып исә. Сания салкын сәкедә аунап интекмәсә ярый әле тагын.

Байдарның хәтер сандыгы бала бишеге шикелле уйнаклап-биеп ала. Өй эчендә башка төрле китек-җитешсезлек юк та сыман. Елан-чаян үтеп кермәсен дип, Байдар әле җәй уртасында ук нигез тирәли ат кылыннан үргән аркан сузып чыкты. Сәке өстенә, мич башына печән түшәгәнче, ямь-яшел көенчә кычыткан чабып салды. Болай иткәч, печән астына тычканнар гына түгел, таракан-кондыз да үтми. Карындык тәрәзә, ишек ярыклары бәрән тиреләре белән томаланган. Җылы сулар, зур җамаяк әзер. Кендек бәйлим дисә, кыл өстәлдә... Күз алдыннан кичергәндә ямалмыйча калган ер-

тык бетте бугай инде. Мәгәр Саниягә тагын кайсы яклап җайдан торырга кирәген ничек белмәк кирәк?

Болай да иртәдән бирле сытык чырай белән генә йөзгән кояш катлы-катлы болытлар арасына кереп качкач, яңгыр җир өстеннән әүвәл имче карчыклар шикелле төкеренгәләп кенә үтеп киткән иде. Ә аннары шәрекъ яклап ялтыраган яшен кылычы күктәге күлнең төбен урталай ярды бугай, дуамалланып-шашып, тоташ су дәрьясы коярга тотынды. Яңгыр, валлаһи да, керәле-чыгалырак акылга ия пырдымсыз сукбай сыман икән. Әле тилемсә йә шук малайлар шикелле иләсләнеп биеп ала ул, әле биленә җиткән сакалын өстерәгән бөкре карт шикелле урманнар, болыннар өстенә ятып шуыша. Ә күк йөзе белән җир арасында уйнаклаган яшен шул чал чәчле карт таянган шома таяк шикелле ялт-йолт килеп куя.

Байдар бүген дә шул җил-яңгырдан качып, тәүге айларда үзләре яшеренеп яткан тау куышына кереп поскан иде. Шуның авызыннан галәм күзәтә-күзәтә онытылган, ахры. Аяклары бер оя кырмыска ябышып талагандай кымырҗый башлагач кына, оеган тәнен яза-яза урыныннан купты. Аһ, син, җансыз бүкән! Ә Сания анда ярдәмгә чакырып ятса?

Үзе алачык дип мыскыл иткән тәбәнәк өй каршына йөгереп килүгә үк тайгак боз өстенә барып менгән нәни бозау сыман коелып төште Байдар. Ярабби Ходаем! Тәрәз аша дөньяга менә мин дә тудым дип аваз салып яткан сабый бала тавышы ишетелә. Елавы да «ник кермисең, ник күрмисең, атай?» дип, шелтә белдереп чакырудыр сыман.

Бусага аша шөлләп кенә узса, Сания күптән аягына баскан, агач җамаяк өстендә бала юып йөри. Үзе чиксез өзлекләндер, талчыккандыр инде, ә йөзе тәүге кар каплаган җир өсте шикелле тик елмаеп тора.

— Безнең улыбыз бар, — диде Сания, күз карашы белән наз һәм бәхет сибеп. — Беренче булып, сиңа иш булырга тугандыр инде ул.

Байдар әле һаман телен йоткан сыман, зәхмәт суккан сыман кымшана алмый басып тора иде. Баш түбәсендә әйтерсең ут кайный, кайнарлыгы бөтен тәнне көйдерә. Яланга йөгереп чыгып, яшь тай, ярсу ат урынына тузынасы, иләсләнеп-илереп кычкырасы, сикерәсе килә. Ә аның, ни гажәп, кыл кыймылдатырлык та куәте-җегәре юк.

Янә Саниянең ипләп әйткән тавышы ишетелде:

— Йә, улыңны тотып кара, кулыңа ал инде.

Байдар, гомер буе балчык чүлмәк ясаучылар янында йөреп, хәзер менә бәллүр касә, алтын каурыйлы кош тотарга әзерләнгән өйрәнчек малай сыман, уч төпләрен күлмәк итәкләренә тиз-тиз ышкып алды. Аннары соңга калудан курыккандай ашыга-ашыга, кулларын алга сузды.

— Авыр ул, — диде Сания, мактангандай итеп. — Валлаһи, баһадир бу, үзеңә охшаган инде.

Көзге шомырт яки чия яфраклары шикелле кып-кызыл, йоп-йомры тәнле нинди матур сабый! Үзенең җир бәһасе, галәм бәһасе икәнен белеп торамыни, әле дымы да кипмәгән нәп-нәни иреннәре арасыннан телен чыгарып елый. Ата кулын, ата кайнарлыгын сизгәч кенә җиһандагы бу мизгелнең никадәрле мөһим, никадәр җаваплы булуын аңлап өлгерде диярсең, беравык ара гына авызын йомып, Байдар күкрәгенә таба борынын төртеп алды. Аннары «йә, артык сикеренмә, җитеп торыр сиңа» дигән сыман, түшәм күтәрердәй итеп элекке җырын сузды. Ләкин тилмереп көтеп алган газиз балаңның елавы мич артында сайрашкан чикерткәләр тавышы гына түгел, ул күпме тыңласаң да туйдырмый икән бит, и-и, әкәмәт!

— Ун кадак чамасы бардыр, валлаһи, авыр бит бу, — дип, ниһаять, Байдар да авыз ачты.

— Соң, син баһадирдан баһадир тумый инде, — дип, Сания дә форсат чыгудан файдаланып ирен үсендерердәй сүзләр табып алды. Аннан кулын сузды. — Йә, җитте, бир. Малаеңны имезергә вакыт.

Сабый әнисенең күкрәгенә чәчәк тажына кунган корт шикелле ябышып байтак чупылдады. Күңеле булгач, белеп торыгыз, мин менә болай да итә беләм әле дигән сыман, әнисенең итәгенә сытык күз яшьләредәй чишмә челтерәтте дә, икенче минутта ук бер якка янтаеп йокыга да талды. Байдарның инде дә түземлеге коргаксыган иде. Ялан уртасына колын шикелле уйнаклый-уйнаклый, кушаяклап чабып чыкты да, бар җиһанны уятырдай итеп, иләсләнеп-янып кычкырды ул:

— Минем ма-ла-ем ба-а-ар! Минем улым туды-ы-ы! Бүгеннән башлап мин дә атай хәзе-е-рр!..

Кич җиткәч, өй нигезенә салган корыган зирек бүрәнәсе өстенә инде Сания белән җитәкләшеп чыгып утырдылар. Яңгыр-давыл үткән, бөтен ялан тып-тын. Гөнаһларын-керен юган чирәмлек өстеннән яңа сауган сөткә охшаш бу-пар күтәрелә. Һава тиешле барча кунакларын озаткан мунча эчедәй җылы. Күк йөзенә шау чәчәккә чумган алан дагы шикелле эреле-ваклы йолдыз түтәлләре сибелешкән. Арада су төбеннән калыккандай чекрәеп торганнары, йә яшь егетләр утырмага килүгә үк шаяруга күчкән мут кызлар шикелле үзара күз кысышып уйнаганнары да байтак кына. Ком белән ышкып чистарткан җиз табак шикелле яп-якты, түм-түгәрәк ай да бүген үзенең ярын җуйган аккош сыман гомер буе япа-ялгыз интегүен онытып торган, ахры. Әнә ул да хәзер елгыр чишмә кебек ашыга-ашыга аккан вак болытлар

буйлап агачтан-агачка очынган тиен сыман, күл өстендә уйнаклаган чабак сыман сикергәләп йөзә. И-и, дөньяның илаһи һәм камил минутлары!..

— Улыбызга Зәбир исемен кушарбыз инде, — ди Сания, иренең болай да кысып тоткан кочагына сеңеп. — Шундый бер бәхетсез көтүче турында ишеткән бар. Ул күрше кабиләдәге Зөбәрҗәт атлы сылуга гашыйк булган, тик теге кызның абыйлары моңа каршы төшкән икән. Егет Зөбәрҗәтне көн саен күрер өчен аларның авылына килеп яллангач та риза булмаган аның абыйлары. Зәбирне әүвәл чыбыркы белән тотып ярганнар, ди. Егет ниятеннән кайтып ант итмәгәч, далага чыгарып, ялгыз чаган агачына бәйләп куйганнар, ди. Өстән кояш кыздыра, һәр яктан җил талый, ә моңа бер йотым да су бирмичә озын көннәр буе җәфалаганнар, тилмерткәннәр икән. Ул гынамы әле? Берзаманны, һәр кич саен, әллә нинди гриф дигән явыз кошлар килеп, моның күкрәген тишкәли, йөрәген кисәккисәк итеп чукый башлаганнар. Зөбәрҗәт бу хакта ишетеп килеп җиткән чакта, Зәбир инде соңгы сулышларын алып яткан булган. Барыбер дә, соңгы сүзе итеп, сине генә сөям, сине күктә көтәм, дип әйтергә өлгергән, ди әле, бичаракай. Бәхетсез Зөбәрҗәт шуннан соң киек казга, апак кыр казына әверелгән дә күк йөзенә ашкан. Ә-ә-ән-нә, күрәсеңме, чишмә суындагы чуерташлар кебек бер-бер артлы тезелешеп киткән йолдызлык бар. Әнә башкалары арасында алар яп-яктылар. Киек Каз Юлы, ди, аларның исемнәре. Зәбирнең җаны аны эзләп менсә, адашмасын, таба алсын өчен, Зөбәрҗәт үз каурыйларын күз яшьләре белән сөртә-сөртә шул рәвешчә чәчеп барган икән. Бер-берсен эзләп табып кавыша алмаган бәхетсез ярлар әле хәзер дә шул Киек Каз Юлына карап табыналар икән...

Пәһлеван гәүдәле Байдар да көтелмәгән риваятьтән ару гына тәэсирләнде бугай, сүз кайтара алмыйча озак тын утырды. Ә авыз ачканда ир-атның шул, үз кырыгы кырык иде инде:

— Юк, Зәбир турындагы хикәят безгә ябышмый, хатын. Зәбир белән Зөбәрҗәт кавыша, кушыла алмаган мескен ярлар бит ул. Ә без елдан артык гомер бергә көн күрәбез. Артабан, безнең уртак малаебыз да бар бит әле тагын. Юк, без улыбызга бәхетсез Зәбирнең атын кушалмыйбыз инде. Безнең малайның авырлыгы гына да бер пот. Юк, безнең малай бөтен Болгарыңны дер селкетә торган ир булырга тиеш. Аңа тояклары белән лас-лос атлап йөри торган яу атыныкы сыман исем кирәк. Бәйләнергә, сорашып йөдәтергә монда кешеләр юк бит. Син ашыкма, уйлашырбыз әле.

16

Чәчкә төшкән чал шикелле, кыш айлары да сиздерми генә килеп җитте. Бер таңда ишек ачсалар, ялан өстен, агачларны-тауларны ап-ак кар каплаган. Дөрес, эреле-ваклы ерымнар, чокырлар, чишмәләр белән ергаланган тау итәкләренә, агачлар арасына ярлы-ябагай юрганы шикелле тишекле-тошыклы булып түшәлгән ул. Ә тигез иңкүлекләр, кырлар өстендә, яңа гына сауган сөт түгелгән шикелле, гел тоташтан ап-ак булып ята. Юылган кердәй чистарып калган иңкүлекләрдә, тау битләрендә җимешләрен коеп бетермәгән куаклар аеруча ыспай һәм юмарт бай шикелле кукраеп утыралар. Ботак очларында тәлгәш-тәлгәш булып тезелешкән баланнарга ут кабынганмыни!

Үз өстенә яткан тәүге кар япмасы күргәч, күк йөзе дә, җиһан да бәхетле яшь ана кебек үк елмаеп туймый сыман. Чөнки кар катламы юмарт килен тәбикмәге калынлыгы гына булып түшәлсә дә, аның әле яңа туган бала сыман керсез һәм гөнаһсыз чагы бит. Аңа сокланмыйча һәм ят күз белән карап буламыни?!

Байдар белән Сания дә яңа дөньяны тын алырга куркып, таң калып күзәттеләр.

— Менә яңа кышка да аяк бастык бит, әтисе, — диде Сания, иренең тәртәләргә биргесез беләкләренә кайнар йөзен терәп. — Аллага шөкер, быел үзебезнең йортта үткәрәбез аны.

— Сез өйдә калырсыз, ә мин ауга китәм, — диде Байдар, үзенчә уй сөреп. — Куяннар, көртлекләр яңа карга ияләнмәде әле. Аларны каптыру авыр булмаячак.

Һәм вакытны җилем сыман тартып-сузып тормый җыенды да, Байдар шул сәгатьтә ауга чыгып китте. Ләкин үзен нинди хәтәр капкын сагалавын ул күз алдына да китерә алмый иде.

Карашар белән Йомрытау дигән ике биек, түгәрәк калкулыклар арасыннан үтеп барган чакта ачыгавызлы бала-чага урынына эләктерделәр аны. Байдар, пошмас сантый, менә шушы калкулыкларның исемнәре турында уйлап бара иде.

Каян гына, кайсы халыклардан үтеп кергән риваять-хикәяттер. Имеш, элеккерәк заманнарда Алтын дигән бер хан яшәгән, ди. Монда булмаган, ди, аның пайтәхете. Тулпар менеп чапсаң, утыз-кырык көнлек ераклыкта, җиде катлы таулар, җитмеш дала аръягындагы олы дәрья буенда булган аның иле. Берзаманны Алтын хан картайган да үлем түшәгенә менеп яткан. Үз янына ике җиткән улын чакыртып китергән бу. Тегеләре Дансыз белән Сансыз дигән гаҗәп сәер исемлеләр икән. Мөгаен, алар андый сәер атлы булмаганнардыр да инде, ләкин халык хәтере аларны шулай саклап калган.

Алтын хан боларның кулына ике алма тоттырган:

— Менә шуларны пычак белән урталай кисегез әле, — дигән.

Тегеләр кискәч, яңа әмер биргән:

— Хәзер яртышар алмагызны үзара алышыгыз да янә бербөтен итеп кушып карагыз, — дигән.

Уллары ике алманың ике яртысын ябыштырырга тырышып караса да, әлбәттә, тегеләр зурлыклары белән бер-берсенә тиң килмәгән инде. Шуннан малайлар олырак кисәкләрне пычак белән юна, кыра башлаганнар. Берсен кечерәйтсәләр, икенчесе зуррак булып кала, инде аларын да кискәләргә туры килә икән. Ахыр чиктә ике малайның кулындагы алмалар да кечерәеп, кырылып юкка чыккан.

— Бер-берегездән аерылсагыз, мин төзегән илне үзара бүлешсәгез, сезнең икегезне дә менә шундый язмыш көтә, балакайлар, — дип кисәткән дә җан биргән, ди, боларның әтиләре.

Ләкин әлеге сүзләрне колакларына киртләмәгән шул аның малайлары. Аерым-аерым хан булырга маташып, бер илдән ике кабилә ясап бүлешкәннәр. Боларның көчсезләнеп калуыннан файдаланып, дошман ябырылган. Менә шушы урында әүвәл өлкәне, Дансыз атлысын дошман чолгап алган. Җиңеп чыга алмасын алдан ук сизенгәндер инде, энекәше Сансыз янына чапкын юллаган ул.

— Тәңре шулай каргагандыр инде, атай васыятен үтәми ялгыштык без. Мин синең колың булырга да риза. Тик ярдәмгә килеп җит тә, әйдә, илне генә коткар, — дигән Дансыз.

Ә кечесе Сансыз «синең башыңа җитсәләр, мин ике кабиләгә дә берьюлы хан булам» дип сөенеп ята икән. Ярдәмгә килмәгән ул. Баскын дошман Дансызны үтергән, ди. Җиләк кебек сылу кызларын, япь-яшь егетләрне коллыкка алып киткәннәр. Кабилә урынында ап-ак чәчле карт-карчыклар гына торып калган.

Аннары явыз эчле Сансыз угылга да чират җиткән. Дошманнар анысының кабиләсен җиде күчеш артындагы Туксу дигән инеш буена барып туздырганнар. Сансыз хан ике-өч яраны белән генә качып котыла алган. Менә шул чагында үзен ярдәмгә чакырган мәрхүм абыйсын исенә төшергән ул. Гөнаһысын юмакчы, сәждә кылмакчы булып, Дансызның кабере янына килгән. Ул җиргә тезләнгәч, моның алтын очлымына кызыккан яраннары «син барыбер илсез калдың инде, сиңа кирәге юк» дип, кече Сансызның да башын кыеп төшергәннәр.

Ахырда ак сакаллы картлар, яшь-кыркыннар җыелып, итәкләре, учлары белән ташый-ташый ике туган кабере өстенә курган төзегәннәр. «Илне бүләргә ярамаганлыкка, бердәмлеккә чакырган һәйкәл булып торсын», — дип әйткәннәр, ди, картлар. Дансыз белән Сансызның исемнәре тора-бара

онытылган инде. Узгынчылар аларның курганнарын хәзер Караташ белән Йомрытау дип кенә, үзләренә яраклаштырып йөртә. Ә Алтын ханның ике башбаштак, ике бәхетсез улы турындагы риваятьне барыбер онытмыйлар. Менә бит ул язмыш!..

Һавада әрләп сызгыруына охшаш тавыш ишетелүгә үк чаптарының муенына сеңгән иде Байдар. Йә сәрпи ук тавышы инде бу, йә биек тау түбәсеннән айкап ыргытылган кыл-аркан очкандагы аваз. Кай тарафта сагалап торган иде микән инде аны дошман? Нишләп сабый бала сыман исәңгерәп барган?

Сызгырып очкан әйбер ат кылыннан үргән җәтмә булып чыкты. Байдар кыныннан кылычын алып өлгергәнче, аның өстенә икеме-өчме аюдай ир сузылып яткан иде инде. Кымшанырга да ирек бирмичә, баһадирны яңа туган сабый сыман кыл «биләү»гә төреп, көмешләнгән иярләрдә утырган җайдаклар төркеме алдына китереп ташладылар. Байдар кыл җәтмә челтәрләре арасыннан гына карап ятты. Бай, тәкәббер һәм бик гайрәтле иде ап-ак тулпар өстендә утырган иң баш хуҗа. Агачтан ясалган битлек кигән сыман хәрәкәтсез-хиссез йөзе белән Байдарга таба иелеп, бик аз гына вакыт карап торды. Тоткынга эндәшкән чагында да иреннәре, ияге селкенмәде. Әйтерсең лә сүзләр аның түгәрәк, пөхтә итеп киселгән сакал-мыеклары арасыннан сытылып чыкты:

— Атың нинди? Кем буласың, сукбай?

Байдар ап-ак тулпар тояклары каршында эт шикелле аунамаска теләп урыныннан калкынган иде дә, янга баскан сакчы касыгына типте:

— Хан үзе сиңа сүз кушарга түбәнчелек итте. Тик кенә ят, эт җан!

Хан, хан? Кайсы хан икән бу, Мөхәммәт ханмыни? Угыз, кыпчак яки аймык кабиләләренең башлыклары монда, Болгар җәйләүләренә килеп, үз биләмәләрендәге шикелле иллеалтмыш җайдак озатуында гына йөрмәсләр бит инде? Мондый нөгәр озатуында, җитмәсә, аткы җәя белән ук садагы гына асып йөри икән, димәк, Байдар шикелле ауга гына чыккан Мөхәммәт хандыр инде бу.

— Атым Байдар минем, — дип, ниһаять, телгә килергә булды тоткын пәһлеван. — Ягъфәр бәк олысындагы Кадрәк авылыннан.

— Байдар, Байдар, аңлашылды миңа. — Мөхәммәт хан сәер рәвештә ирен читләре белән көлемсерәп куйды. — Ягъфәр бәк мәңгелеккә күчкәнгә ике җәй, ике кыш узып бара бит инде. Бу хәтле гомер буена өнгә чумып, әллә аю белән бергә йокладыңмы, сукбай?

Хан җавап та көтеп маташмады, тулпарының касыгына

типте. Җәтмәдән арындырсалар да, кулларын бау очына чорнап, Байдарны ияр аелына тагып йөгерттеләр. Хан ыстаны Эре Колмак яланы дигән иңкүлектә икән. Монда чатырлар, тирмәләр чиксез. Тыз-быз килеп пешекче яшь кызлар, йөзәрләгән сакчылар йөгерешә. Ыстан уртасында дистәләгән учак яна, казаннар быгырдап кайный. Таганнарда тимер таякларга кидертелгән бәрән, куян, җәйран түшкәләре утлы күмер өстендә бөтерелә.

Хан гап-гади кушчы сыман кыланып бер учак янына барып утырды да, күмер шикелле кызган, майлары тамып торган түшкәдән иң шәп калҗаны кисеп, хәнҗәр очына алды. Аны тегеләй, болай иттереп боргалады, иреннәренә китереп өф-өф өргән булды. Шул чагында гына телгә килде хаким:

— Азат итегез әле бу тоткынны.

Сакчылар кыл-арканнарны кискәннәр генә иде, ханның һичбер кол яки гади яугир акылына кереп тә карамаслык әмере яңгырады:

— Әй, сукбай! Менә монда кил дә минем каршыма утыр.

Байдар оеган кулларын ышкый-ышкый аның каршына килеп чүгәләүгә, Мөхәммәт хан очына кызарып пешкән калҗа кадалган беләк буе хәнҗәрен пәһлеванның иреннәре арасына китереп тыкты.

— Миңа дигән итне агуламадылар микән? Әүвәл син ашап кара әле, әйдә.

Байдар бер мизгел эчендә шабыр тиргә батты. Бөтен тәне, беләкләре буйлап борча-кырмыскалар көтүе чабышкандай булды. Каз тәне чыкты, бала йоннары да кабардылар бугай. Зиһене аша казандагы кайнар су шикелле уйлар кайнап узды.

«Нинди мөгез чыгарырга тели, ниләр кыйлана бу? Агу хакында сүз кузгатуы төтен генә инде. Ханның кайсы түшкәгә килеп ябышасын хыянәтче яран ничек белеп торсын? Ни өчен нәкъ мине сайлап алуы да аңлашыла сыман. Мин элмәккә килеп эләккән кол, мин тулысынча моның карамагындагы тоткын. Мине эт урынына куеп сынасаң да була. Ләкин беләк буе хәнҗәрне минем авызга терәп куюы бер дә уен, сынау гына түгел инде. Авызны ачтыммы, моның хәнҗәрне минем бугазга китереп кадавы бар. Сабына бер сукса, үпкәгә, йөрәккә хәтле телеп төшәчәк бу хәнҗәр. Ни эшләргә, нәрсәне ачыкларга тели соң бу Мөхәммәт? Мине болай эт хәленә кую аңа нигә кирәк? Исән калырга язды микән миңа, әллә... әллә инде соңгы сулышыммы?..»

Мөхәммәт ханның эчендә дә тоташ ут ялкыны.

«Ыстандагы барча пешекчеләр, сакчы ирләр, ауга ияреп килгән бәкләр текәлеп каткан. Тоткын Байдар нишләр? Тың-

лармы ул тиле хан әмерен, әллә куркуыннан елан кебек тез астына төшеп сарылырмы? Бүре күргән сарык бәрәне шикелле бәлтерәп төшсә, ышаныч юк моңа. Ул чагында иң яхшысы, йә хәнҗәрне бугазына батыр, йә кылычтан чаптыр. Әгәр инде курыкмыйча, шикләнмичә хәнҗәр очындагы калҗаны каба икән, моңа киләчәктә дә гомер буе таянып һәм ышанып була. Кирәк булса, сине яклап, утка да керәчәк бу. Ләкин... ләкин моның кыяфәтендә, карашында кирелек, үҗәтлек тә учактагы ут шикелле дөрләп кабынган бит. Көч-гайрәте сыңар ханны гына түгел, бер дистә җансакчыңны ботарлап атарлык бар. Ә көтмәгәндә, буар елан сыман сикереп, өстеңә ыргылсамы? Җансакчыларың моның башын-кулларын чабып ташлаганчы, ул синең билеңне-умырткаңны җиде тапкыр сындырып өлгерәчәк. Һаман авызын ачмый. Йөзләгән күз көтә. Йә, нишләргә инде?..»

Байдар сөекле хатынын, газиз нарасыен үбәргә омтылган сыман иреннәрен очлайтты һәм хәнҗәр очын авызына капты. Икенче мизгелдә ул инде җылы калҗа чәйни, ә Мөхәммәт хан иңбашыннан авыр йөк төшкән шикелле уфылдап янә кайнар түшкәне каезлап утыра иде. Таш багана шикелле катып калган җансакчылар, бәкләр бүтән учаклар, казаннар тирәсенә ябырылгач кына, Мөхәммәт хан сер әйткәндәй пышылдап кына дәште:

— Ә синең хатының белән малаең минем чатырда бит. Без аларны синең эзеңә басканчы ук эләктергән идек инде. Әгәр хәнҗәрне капмасаң, мин аларның да гомерен кыя идем.

17

Мөхәммәт ханның кәефе чамалы чак. Вәзир Даян кереп сәер бер сер чиште:

— Синең Тимер-Мөэмин нишләптер гел яшь ханәш бүлмәсе янында буталып йөри. Узган атнада да икесе генә Сеңертау буена елан әйләнергә чыгып киткәннәр иде. Син ул көнне Жүкәтауда кунып калдың, ә алар таң атканда гына кайтып керде. Ярый әле Айкапуда[1] торган тоткавыллар тавыш куптармаган...

Мөхәммәт хан вәзир барында йөрәген көйдереп алган утны сиздермәде. Ә ул чыгып китүгә, әйтерсең лә бөтен эченҗанын елан талый иде, әллә ничә урындыкларны, комганнарны, гөл савытларын әйләндереп атты.

— Соран, кабих, җәллад! — дип сүгенде ул, йодрыклары

[1] Айкапу — Алтын капка. Өсте алтын белән бизәлгән өчен шулай атаганнар.

белән диварларны, ишекләрне ярсып кыйный-кыйный. — Төпчек анасына килеп ябышмаса, хатын беткәнмени?

Аннан уйга калды. Тимер-Мөэмингә егерме яшь тулды. Югыйсә Мөхәммәт аны өйләндерде дә инде. Әмма үз казанын асарга аерым кала, вилаять бирмәде. Чөнки аның бу өлкән малаен гадәләтсез, кансыз, вәхши, диләр. Бала атасы булырга җыена бугай, ә үзе һаман Биләр буйлап этләр-мәчеләрне үтереп йөри. Урамда бер җан иясе калмаган, качак мәче-фәләк күренде исә, Тимер-Мөэмин аны шундук тураклый, ди. Моңа ышаныч бик аз. Шул уртанчы малае Ибраһим белән төпчек Габбасына таянса гына инде. Габбасы бераз аумакайрак сыман, ә Ибраһим һәрнәрсәне бизмәнгә салгандай эш итә, уйчан, салмак, төпле. Шуңа күрә унсигез яшьтә генә дип тормады, хәтәр калкып, ыспайланып килгән Болгар каласына озатты аны Мөхәммәт хан. Дөрес, ялгызын гына түгел, таянып эш йөртергә вәзир Даянның малае Насыйрны да бирде. Тегесе дә бик яшь, әмма урыс мәмләкәтендә канат ярган, әллә ничә милләт күргән егет. Йөкне бергә-бергә җигелеп тартсалар, зуррак эшләр майтарырга да өйрәнерләр әле. Төпчеге Габбас та күз ачар. Мөхәммәт хан аны Җүкәтаудагы Илбуга бәк канаты астына илтеп куйды. Илбуга — заманында Микаил хан гаскәрләрен яуга йөрткән сәрдәр. Мең кат сыналган. Акыл казанындагы хәйлә-тәҗрибәне чүмечләп ташысаң да коргаксымас. Габбас белән Ибраһим хәзер әтиләреңнән тирмәләреннән читтә, абына-сөртенә, тирли-тирли акыл җыйсыннар. Ә Тимер-Мөэмин?.. Ah, ул сатлык затны! Мөхәммәт аны кортлаган тәкә урынына тотып печмәсәме?!

Хан яшь хатыны Айсылу янына төнлә белән генә, ажгырып барып керде. Нык тузынып тавыш куптарып атлагандыр, ахры. Мөхәммәт ишеккә типкәндә, бүлмә эчендә ниләрдер шак-шок килә, ә ул бусагадан узганда, урам яктагы тәрәз шыр ачык, чиккән пәрдәләр генә җилдә җилфердәп дулкынлана иде.

Айсылу ярым шәрә. Мунча ләүкәсеннән сикереп төшкән шикелле кызарынып чыккан. Чем-кара толымнары тузгып беткән, ботлар ачык. Этлек өстендә тотыла язгач курыккандыр инде, ике якка салынып төшкән тыгыз күкрәкләре дер-дер килә.

— Фәхеш оештырып ятасыңмы минем йортта? Ыштыр җиреңә мунча ташы сыман кызып җиттемени, кәнтәй елан? — дип үкереп Мөхәммәт хан камчы белән ярырга тотынгач, вәлидә Айсылу ефәк тасма сыман бөтерелеп, аның аяклары астына шуышып төште.

— Минем гаебем юк. Ул үзе мине көчләргә азапланды. Мыскыл итмә мине, газиз ирем!..

Ah, хатын-кызда шул тимерне дә эретердәй юха тел булмасамы! Газиз, ди бит, ирем, дип тора бит, ничек алданмыйсың? Мөхәммәт тә сынды. Берничә минуттан соң ул инде бөтен тәне буйлап шуышкан иреннәр кайнарлыгыннан онытылган иде…

Тимер-Мөэминне икенче көнне дә, бер атнадан соң да таба алмадылар. Аннары гына хәбәр кайтып җитте. Җүкәтауга, Габбас ышыгына, энекәше куышына кереп качкан. Берьюлы ике малаеңа каршы кузгалып, ил көлдереп булмый бит инде. Мөхәммәт бөтенләй, язгы ташкыннан котылгач үз ярларына кайткан елга сыман тынды. Ә ул арада Ашлы ягыннан давыл:

— Идел буйлап вятич ушкуйлары бәреп керде! — дигән хәбәр җиткерде.

Нигә кирәккәндер, Биләрдәге бар гаскәрен җыеп, Мөхәммәт хан ашлыларга ярдәмгә үзе чыгып китте. Ә азгын Тимер-Мөэмин биләрлеләрнең кораб-каекларга утырышып, Чулман дәрьясыннан Зур Идел суына төшкәннәрен генә көтеп йөрде. Аннары Илбуга бәктән «ханга кушылам» дигән хәйлә белән биш йөз җайдак талап алды да котырынган әмир Биләр каласына кайтып керде. Капкаларда торган сакчыларны әүвәл җир өстенә салып таптаттырды. Исән калганнарының колакларын кисеп, күзләрен агызып, буш далага куды.

— Теге чакта, үги анасы белән уйнап яткан чакта, хан аларның өсләренә килеп чыккан өчен үч ала бу, — дип сүз йөртте «озынколак».

Ләкин әле биләрлеләрнең күрәсе гыйбрәтләре алда булган икән. Кичке шәфәкъ якынлашып килгән чакта, әүвәл хан сарае эчендә ачыргаланып елаган тавыш купты, аннары дуңгыз суйгандагыдай чинаш-үкереш ихатага күчте. Тыкрыкларга поскан, келәт-мунча артларына качкан кешеләр ишетеп-барлап торды. Вәлидә ханәш тавышы иде бу, азгын Айсылуның җан авазы иде. Аны үгездәй мөгрәгән Тимер-Мөэминнең үкерүе генә күмеп-күмеп алды.

— Бу кәнтәйне әнә теге арбага бәйләп, ботларын аерып салыгыз да көмеш эретегез тизрәк, көмеш эретегез! Юха еланның җан җиренә коябыз аннары, җан җиренә!

Беркадәр арадан соң Айсылуның илереп-шашып кычкырган авазы гына яңгырап ишетелде дә, күк күкрәгеннән соң бушанып калган җиһан сыман, бары да тынды. Таң атканда, Тимер-Мөэмин инде Биләрдә юк иде…

Мөхәммәт хан, кайткач, Айсылуның каберенә барып өзгәләнде:

— Теге имгәк үзем үстергән агач җимеше бит. Ачы, агулы, йөрәкләрне телә. Терсәк якын да соң, тешләп булмый. Ниләр кылыйм? Сыкрыйм, түзәм инде.

18

Вәзир Даянның итәгенә дә утлы күмер төште. Тимер-Мөэмин белән Габбас Болгардагы Ибраһим янына чапкын җибәргән, ди.

— Бөтен мәхшәрне Даян гына китереп чыгарды. Ул сатмаса, безнең атай берни сизми иде. Даян урыслардан әллә никадәрле этлек өйрәнеп кайткан. Атай белән араны бозып, безне тәхеттән коры калдырырга җыена ул. Үзенең малае Насыйрны утыртмакчы була.

Ибраһимның колагына менә шундый сүзләр җиткергәннәр. Ибраһим исә нинди бизмәнгә салып үлчәгәндер инде, Биләргә килеп, әтисенә әйткән:

— Мине дә үз якларына аударып, түнтәреш ясарга йөрми микән болар? Нинди, дип, шул, сине еккач, үзләре хан булырга җыеналардыр инде. Мәгәр тәхетне бүлешә алмый алар. Сине ексалар да, үзләре яшь әтәчләр сыман чукышып бетәчәкләр.

Мөхәммәт хан төпчек малае Габбасны чакыртты. Вәзир Даян ялган ишек артына качып тыңлап торды. Габбасның авызында гел тозсыз сүз:

— Нишләп Тимер-Мөэмин котыртсын инде мине? Ибраһим янына җибәргән нинди чапкын ди ул? Ибраһим, эт җан, үзе чапкын юллап, мине вәзиргә каршы чыгарга өстереп ятты ласа. Күрәләтә торып атайга каршы күсәк күтәрергә мин соң тинтәкмени?

— И-и, минем артта әнә никадәрле елан күче җыелып яткан икән, — дип шаккатты хан. — Җүкәтауда Илбуга бәк ике еланны куенына яшереп асрап ята. Болгарда Ибраһим теш чыгарган. Юк, болай булмый. Утлы кисәү белән тоздырып атарга кирәк сезне!..

Нәтиҗәдә ил өстендә фәрман яңгырады:

— Әмир Ибраһим илә Илбуга бәкне Чулман буйлап югарыга таба озатырга! Чулманга Туймас елга килеп кушылган төштә, тау башында, яңа кирмән-кала төзесеннәр!..

Даянның улы Насыйр Биләргә кайтып төште. Вәзир пайтәхеттә күп тотмады аны. Бер кичтә, тәмам караңгы төшкәч, Даян үзенең улын урамга дәшеп алды:

— Иң кирәкле коралларыңны җыйна, юлга чыгачаксың.

Насыйр коралланып ияргә менгән чакта аны капка төбендә тагын ике җайдак көтә иде инде. Берсе — әтисе, икенчесе элек күргән-белгән кеше түгел. Шәһәр капкасыннан далага чыккач кына әтисе аның иңенә кулын салды.

— Учакка якын утырсаң, утка пешәсең икән, улым. Ә без, сантыйланып, учакның уртасына ук барып кергәнбез бит. Күкерт шикелле янып көлгә калуың бар. Монда туфан. Ата улын, ана кызын белми. Ил тынганчы берәр якка китеп, чит

гыйбрәтне мыегыңа чорнап йөрү күпкә хәерлерәк. Әнә Әтилгә бар. Манас каган олыгайды хәзер, иртәгә анда нинди мәхшәр кубасын беркем белми. Ә безнең мәмләкәткә һәр төбәктә күз-колаклар кирәк. Сарай тирәсендә сайрап яткан кеше түгел, күп йөргән — күп белә, моны сизгәнсеңдер.

Даян читтә торган җайдакка таба баш изәде:

— Монысы сиңа юлдаш. Чит җирдә әнә шундый иптәш булмау нык үтерә. Исеме Байдар аның. Без аны таулар арасындагы алачык яныннан эләктереп алып кайттык. Хатыны бала тапкан да шунда төпләнеп калырга уйлаганнар. Мәгәр әүвәл гади Әмин качса, алар артыннан Дәмин белән Мөхәммәтәмин дә качса, ил кем белән калсын?.. Ә үзе бик тә балалар ярата икән. Үзенең йодрык чаклы Сал-Салы турында сөйләп, колак итеңне ашаячак әле.

Соңгы тапкыр кочаклашып аерылгач кына, ата кешенең ерактан эндәшкән тавышы ишетелде:

— Сиңа да вәзир булып кайтырга насыйп итсен, улым.

19

Вәзирлектән колак кагуга ук Нуретдин Җаек белән Кондырча арасында каңгырап йөргән улы Рахман янына чыгып качты. Аның артыннан үләксә калдыгы эзләгән сыртлан кебек бик озак иснәнеп барырга туры килде аңа. Бактың исә, Рахман Үтәтишек кыясы артына, юлчылар, кәрванчылар мәңге аяк басмас Тозлы күл буендагы камышлыклар арасына ук кереп поскан икән. Кайчандыр меңәр җайдак белән исәпләнгән нөгәре хәзер инде сасы көзән кырып чыккан тавык өере шикелле сирәкләнеп калган. Кичәге әмир өчен махсус корыла торган ефәк чатырлар да, җарияләр өчен чигү җепләре белән нәкышләнгән аеры тирмәләр дә юк инде биредә. Иске кәвеш хәленә төшкән кадерсез җайдакларның күбесе хәзер җиргә чокып ясалган кысан куышларда яшәп ята. Әле ярый Рахманның үзенә тишек-тошык киезләрдән корган ике тирмә калган.

Рахманны сакал-мыек басып бетергән, карашында нур юк. Әтисен күргәч тә тәгәрәп төшмәде ул. Ирен читләрендә шайтан таягындагы чәнечкеләр сыман мыскыллы кеткелдәү пәйда булды. Аннары күңелендәге үч-кәһкәһәне яшереп тормыйча, агу сипкән төсле әйтеп салды:

— Нәрсә, сине дә тешләре сынган арба тәгәрмәче сымак болгап аттылармы? «Озынколак» җиткерде, ишеттем мин. Мөхәммәт чуклы пумала белән куган сине.

Нуретдин ярсуын көч-хәл белән тыйды.

— Газиз атаңның бәхетсезлек сазлыгына кереп батуына

нигә сөенәсеңдер? Алайга китсә, күреп торам, син дә күлнең төбен күккә аскан Искәндәр Зөлкәрнәен[1] түгел әле.

Зәһәрлек укалары көзге кырау суккан кычыткан яфраклары кебек шәлперәеп төшкәч, бергәләп уй йөрттеләр:

— Чит-ят җирдә аяк сузып булмас, — диде ата кеше, Рахманның яраннары керткән сөҗүне суыргалап. — Болгар җиренә кайтып, янә тамыр җибәрүне чамаларга кирәк. Әнә Бәнҗәгә һаман әмир куелмаган. Булат батыр каланы үз кулына алса да, Мөхәммәт ханның аны олугбәк иткәне юк. Нишләп итсен? Булат — кара гавам арасыннан калкып, балчыктан көрәк булырга маташкан колчура бит. Мөхәммәтнең үз малайлары арасыннан да һичкайсына таянмалы түгел. Берсе бозау булып сөзә үз атасын, икенчесе буар елан сыман. Ю-у-ук, Мөхәммәт аларның берсен дә тиз арада гына үзенең тагарагына якын китермәячәк әле. Ә безгә йоклап калмаска кирәк. Сугым вакытында ач этләрнең кисеп ташлаган үт яисә талак тирәсендә ни рәвешле бөтерелеп йөргәннәрен шәйләгәнең бармы? Алардагы әрсезлек! Алардагы елгырлык! Безгә дә әнә шул ач этләр шикелле ташланып эләктерергә кирәк бер калҗаны!

— Ә Бәнҗәне каптырып булыр микән? — дип, бик шикләнеп кенә сүзгә кушылды Рахман. — Анда мине бер дә сөймиләр бит. Үч алырга кыҗрап йөрүчеләр дә йөзләгәндер, баксаң.

Нуретдин янә зәһәрләнеп кул селтәде.

— Аларга төкерәсе. Йөгәненнән иң беренче булып кем каптыра, атка да шул менә. Ә сыртына менгәч, һәр ат буйсына ул. Бер ишенә солыны, икенчеләренә камчыңны гына кызганмаска кирәк. Иң алама, аксак бүре дә ачыгавызлы корбанын үзе эзләп таба. Гел шыр ялан өстенә сузылып ятсаң да, бер калҗа да синең авызыңа үзе тәгәрәп керми. Әйдә, җыен, сиңа баш ия белмәгән Бәнҗәнең умырткасын сындырырга киттек!..

Алар калага күзгә төртсәң күренмәслек караңгы төн уртасында якынайган иде. Диварларга мәче сыман тавышсызтынсыз менеп, әмир сараена соңыннан бердәм ташлануда иде исәпләре. Ялгыштылар. Рахман башкисәрләренең айлар буе сукыр тычкан сыман җир куышында яшәп яту хикмәтедер инде. Дошман ыстанында аерата уяу, сизгер булу дигән кануннарны онытканнар болар. Рахман нөгәрендә унбашы булып йөргән бер пошмасы имән манара баскычында черем итеп утырган үз ишедәй икенче боламык сакчыга килеп төртелгән бит. Йокы аралаш тегесенең бөтенләй өне алынгандыр инде, әүвәл, манара басмаларына даң да доң килеп бәре-

[1] Искәндәр Зөлкәрнәен — Александр Македонский.

лә-бәрелә, аска калкан очты, аннары суярга салган дуңгызныкы сыман чинап үкергән тавыш купты.

— Карау-у-выл, шайтан, шайтан!

Казан астына ут куярлык та ара үтмәгәндер, барча дивар өсте торгак сакчылар чылбыры белән тулды. Әллә кайдан гына сөйрәп чыгарып, очларына җитен чорналган дистәләгән кисәү кабыздылар. Дивар өстендә лас-лос китереп орган чукмар, кылыч авазлары ат иярләрлек вакыт буе гына яңгырап торды да Рахман башкисәрләренең мәетләре каланы урап алган чокыр төбенә очты. Төн караңгы дип тормадылар тагын, Рахманны таныдылар. Кала өстен кәһкәһә белән илереп кычкырган аваз күмеп китте.

— Бәнҗәне элек үзең тотып көчләгән мескен кызлар сымак итәк ачып ятыр дип уйладыңмы әллә? Моннан ары якын-тирәдә иснәнеп йөрисе булма! Тагын килсәң, печеп җибәрәбез!..

Ак-караны күрми, атларын җан-фәрман камчылый-камчылый, әллә никадәрле вакыт буе дала буйлап юырттылар алар. Рахман ияре астындагы чаптар янып аугач кына, иректән тукталдылар. Рахман әле җирдә гыжлап яткан атны типкәләде, әле камчысы белән яман болгый-болгый, әтисенең ботларын көйдереп-көйдереп алды.

— Бер сакчысыз калдым. Син генә әрәм иттең аларны, син котырттың!..

Тыныч лангач, янә Нуретдин акыл биргән булды:

— Булат безнең арттан эзтабарлар җибәрмичә калмас. Алар безне янә тау-таш арасына поса дип көтә инде. Бәнҗәнекеләр Җаек буеннан, буш даладан эзләп иза чиксен, ә без Нур-Суарга киттек, илнең үзәгенә! Анда минем бажай, Аксак Әхмәт әмир. Анда безнең Ватан! Үз кабиләләренең үксез балаларын алар кадерсезләп читкә типмәс әле!..

Кичә генә ил тоткан вәзир белән вилаять чаклы вилаятьне дер селкетеп йөргән аталы-уллы Нуретдин һәм Рахманның кайтып төшүе Аксак Әхмәт өчен бәйрәм булды. Иш янына куш табылмый димени? Аксак Әхмәт үзе дә инде байтак айлар буе Мөхәммәт ханга каршы теш кайраган икән. Эчләре үч тулы качаклар аның сараенда пәйда булуга ук, чатан әмир агуын ачып салды:

— Тәхеткә ни өчен Алмыш хан нәселе генә хуҗа булырга тиеш ди соң әле? Нәрсә, минем Нурый бабам колчура булганмы да, Алмыш мөгезлеме? Безнең Нурый бабай да кабилә юлбашчысы булган, Алмыш та бәк. Моннан утыз-кырык ел элек Алмыш бердәм хан итеп сайлап куелган дип кенә без соң хәзер таждар тәхетеннән гомерлеккә колак кагыйкмыни? Үзебез әле бер хәл. Ә артыбызда урман сыман үсеп килгән угланнар илә оныклар ничек итеп гафу кылсын без-

не? Юк, ул хан сайлап куя торган горефләрне кабат кайтарырга да оланнарга юл ярырга кирәк!..

Мөхәммәт хан каршында бил бирмәүне аерым акча сугудан башлап җибәрделәр. Биләрдәге хан өч бәрәнне бер алтын динарга сатып ала, ә Нур-Суарда Аксак Әхмәт ике бәрәнгә дә шул ук хакны түли. Хәзәрләрдән, аймык-угызлардан килгән күпчелек сәүдәгәрләр Суар базарына сукмак салды. Мөхәммәт хан Биләрдә шартларга җитешеп котыра, ди. Ә Нур-Суарда инде яңа әмер:

— Биләрдә Аллаһны, динне олылый белүче дә юк бит анда. Адәм рәтле мәчет тә төземиләр. Чит дәүләтләр алдында хурлык, оят. Хан нәфсесе туймас. Үзебезнең Нур-Суарда дүрт манаралы мәчет күтәрәбез. Ханлыктагы иң олы Җәмигъ мәчет Нур-Суарда булыр!..

Әйткән сүз — аткан ук. Бер җәй эчендә күз нурыңны алып торырлык мәчет күтәрделәр. Аксак Әхмәт Биләрдәге Хәсәншәех сәетне чакырып чапкын куган.

— Иң олы Җәмигъ мәчет безнең калада хәзер. Динне мыскыл итмә, Суарга кил.

Хәсәншәех сәет Мөхәммәт тыйганга гына, тешен кысып кына бармый калды. Ә Аксак Әхмәт ыжлап та карамады.

— Алай икән, без үзебездә яңа сәет булдырабыз инде. Мөхәммәтнең әтисе Габдулла хан Миңлебакир вәзирне читкә типкән иде, менә шуны чакырып китерәбез.

Мөхәммәт хан моны ишетүгә, чынлап торып, тиресенә сыеша алмыйча, ярсып күпты:

— Аһ, икейөзле, аһ, мәкерле соран! Миңлебакир вәзирне минем әткәй түгел, ә шул Нур-Суардан килгән Талиб куды. Әхмәт, шуны белә торып, юри нахак гайбәт тарата бит, аксак тәре!..

— Әхмәт салымны үзенә башка җыя. Аның сиңа салым китереп йөрергә исәбе юк, — дигән хәбәр дә килеп ирешкәч, Мөхәммәт ханның түзем чиләге корыды.

— Чапкыннар җибәрегез! Ашлы, Кашан, Жүкәтау, Бәнҗә әмирләре икешәр меңле чирү җыеп килсен! — дип, тәрәзә пыялаларын дерелдәтерлек итеп үкерде ул. — Өй келәмен буйый торган юньсез мәчене нәҗесенә борыны белән төртеп ипкә китерәләр. Мин бу аксактан кан костырам әле!..

Юк, аксак әмирне кыйнап ипкә кертү кирәкмәде. Аның кул астындагы вилаять чигендә ун мең җайдаклы гаскәр күренүгә үк, Аксак Әхмәт качак Нуретдин белән Рахманны гаярь хан кулына илтеп тапшырмакчы булды. Тегеләр дә, азау тешен чыгарган эт җаннар, чатан әмирнең мәкерен алдан ук сизенеп, Нур-Суардан качып өлгергәннәр. Аксак Әхмәткә Мөхәммәт ханны япа-ялгыз гына, кала читенә чыгып, тезгә чүккән көе каршыларга туры килде. Олау-олау, кәр-

ван-кәрван байлык туплап куюы гына җитмәгән, хәйләкәр әмир вәлидә ханәш Айсылу урынына сайлап алу өчен илле сылуны да җыеп куйган иде. Бу кадәрле күндәмлек, басымчаклык күрсәтү күзен томалады, Мөхәммәт хан җарияләр чатырына кереп онытылды.

Соңыннан, шәһәрдән чыгып китешли, качак Нуретдин ташлаган сүзне әйтеп көлдерделәр: «Кәҗә — хайван, бажай — туган түгел. Моңа ышанып килгән җүләр икән бит мин».

20

Мөхәммәт хан, пайтәхеткә кайтып барышлый, нәкъ Биләр белән Суар уртасында яткан уйсулыкта бәйрәм оештырды. Йөзәрләгән тәкә суйдылар, атта узыштылар, уклар атыштылар. Кичке шәфәкъ якынлашып килгәндә, өлкәнрәк ирләр-агайлар учак тирәсенә җыелып гәп куертты, яшьләр су коенды.

Чирмешәннең суы май шикелле җылы, сихерле чак. Аксак Әхмәт биреп җибәргән җарияләр, Мөхәммәт хан белән әмир-бәкләрнең күңелләрен күреп йөргән кәнизәк-сылулар әүвәл артыш, зирек куаклары, кызыл тал ышыгында йөзеп-чумып азапланганнар иде дә, үзләре генә чыркылдашудан ямь тапмадылар, күрәсең, берзаманны болар егетләр өере янына килеп җитте. Ә сыңар ук та очырмыйча җиңү яулап кайткан газиләргә нәрсә? Болай да йөрәкләре былбылдай очынып торган егетләргә бу сылулар затлы бүләк сыман! Су төбенә чумып шаяралар, «теге төшеңне тотам, бу төшеңне тотам» дип кычкырып өн алалар, ат урынына пошкырып куалыйлар. Чирмешән өстә казан кебек кайный, чыр-чу килгән авазлар чакрымнарга ишетелеп тора. Яр башында утырган ирләр дә күз салгалый. Юк, «тотам-тотам» дип шапырынса-янаса да, егетләр кызларның бер генә гаурәт җиренә дә кагылмыйлар. Хәрәмләшү, азыну-тузыну юк Болгарда.

Булат батыр башта Мөхәммәт хан казаны янына утырып торган иде. Монда Болгар иленең иң абруйлы түрәләре генә җыелышкан. Ашлыдан — әмир Сәлман, Кашаннан — Мөхәммәт ханның энесе Габделвәһап. Жүкәтаудан яубашы Мөбарәк бар, аның каравы хан угыллары булып йөргән Габбас әмир белән Тимер-Мөэмин юк. Шулай, ышаныч югалткан, ханга каршы өргән бәндәләрне чакырмыйлар монда. Булат та менә хан казаны, хан чатыры янына тәүге тапкыр чакырылган кеше. Ничәмә-ничә айлар буе Бәнҗә башында Булат утырса да, әле шушы Аксак Әхмәткә каршы күтәрелгәч кенә Мөхәммәт хан аны әмир итеп таныды, тулы хокук-

лы хуҗа ясап куйды. Аңлый, чамалый Булат. Үз тәхетен ныгыту өчен шулай кыйлана хан. Аңа әле бүген менә шулай кирәк. Ә иртәгә ни кыйланыр икән дә ниләр кылыр — моны Мөхәммәт хан үзе белә микән? Иллә мәгәр син хан кунагы бүген, хан яраны, шуның кадерен бел.

Янда Сәлман сайрый:

— Нуретдин, кайәр, бигрәк ышанычсыз бәндә икән, сатлык. Теге чакта, Минай ханны алып ташларга барган вакытта да, мине чак кына төп башына утыртмады, кабих. Мөхәммәт хан өч мең җайдаклы чирү таләп итте, хәзер үк бир, ди. Ә үзе өстәвенә корабларга, каекларга ишкәкче итеп утыртырга яңа нөгәр сорый. Мин Ашлыны басу сымак ачык капкалы итеп, бер сакчысыз калдырып китиммени инде?..

— Аксак Әхмәт тә ике яклы пычак. Үзе алдыңа юаш маэмай сымак шуышып килгән була. Ә үзе һаман, сасы көзән сымак, олаулардагы байлыктан күзен алмый. Шуңа көзән, дим мин. Көзән дә шулай, бер тавыкны буа башласа, икенчесеннән күзен алалмый, ди. Ә-ә-әй, бигрәк саран соң бу Аксак Әхмәт!..

Моны хәтта Мөхәммәт хан да тыңлый-тыңлый туеп бетте бугай. Ул берзаманны чатыр авызына табарак шуышып күчкән иде, шуннан файдаланып, Булат батыр да урыныннан купты:

— Булмаса, мин дә Чирмешәнгә төшеп юынып меним әле. Юлда гел юыртып йөреп, тузанга батып беттем.

Артта ялагай Сәлманның чыш-пыш килгән сүзләре яңгырап калды:

— Бу да юха елан. Нуретдин илә Рахман әмирне сатып кына кеше булды. Моңа бик ышанма…

Булат сөзәк яр читендә су эченә аякларын тыгып утырган бер сылуны инде күптән күз уңына алып куйган иде. Туп-туры шуның янына төбәп китте. Булат өчен сер түгел, Мөхәммәт ханның кыпчаклардан алып кайткан хатыны Зөбәрҗәттән туган Зөлфия бу. Яшь әле ул үзе, чынлап санасаң, унбише тула микән? Ләкин җиләк сыман тулып ташкан инде. Әнә килмәгән бер җире юк. Каен сыман зифа, озын гәүдә. Тыгыз матур ботлар. Очына чия төше кунган түгәрәк мул күкрәкләр. Карлыгач канаты шикелле кыйгач кашлар. Уйчан икәнлеге сизелсә дә, нур бөркегән карлыгандай күзләр. Аны йөзәрләгән болгар кызлары арасыннан да җиңел аерып була. Зөлфия — бишектән төшкәннән бирле кояш астында йөргән кеше шикелле каратут йөзле, каратутрак тәнле. Әмма болгар кызлары кебек салмак, үшән түгел. Кара, Булатның янына килеп җитүен шәйләүгә җәйран шикелле ничек сикереп торды! Ни әйтсәң дә, дала кызы шул бу!

Зөлфия ике учы белән күкрәк очларын каплап баскан

булган, ә көмеше шыр ачык! Булат, ирексездән елмаеп, карашын яшерергә мәҗбүр булды. Әйе, сез кайвакытта шулай ачык авызлы да, ник юмарт та була беләсез инде ул, кызлар!..

— Йә, син нишләп су кермисең, кызый? Нигә болай ялгыз утырасың? — дип, теленә килгән тәүге сүзләр белән авыз ачты Булат.

Ә Зөлфия ник коелып төшсен!

— Менә берәр батыр егет урламасмы дип көтеп торам әле, — ди. — Алайса, арпа басуына куйган карачкы урынына мине һәммәсе дә урап кына үтә.

Зөлфиянең мәрҗән шикелле ялтырап торган тешләренә карап, Булат та елмаймый түзмәде.

— Һе-һе! Ханәкә янына теләсә кем килеп орынырга берәүнең дә башына тай типмәгән инде.

— Сиңа типкәнмени?

Бу юлы инде талир тәңкә тавышлары белән зеңләп, тыелмый көлештеләр. Булат батыр хан чатыры ягына караш ташлап алды. Мөхәммәт хан да авыз ерып тора. Болай булгач, эшләр пешә дә пешә икән!

— Әйдә, ятим баладай калтырап торма инде, суга сикер, кызый! — диде дә икенче минутта Булат әүвәл Зөлфияне төртеп төшерде, аннары айгыр сыман, бөтен байлыгын күрсәтеп, елга суына чумды. Янә дөньяларын онытып көлә-көлә йөзә башладылар.

Алар хан чатыры янына иртән генә кайтты.

21

Нуретдин белән Рахман дәрья яры буйлап Әтил каласы ягына качкан иде. Бәнҗәне урап үтеп Сарытауга җитүгә, көтелмәгән тозакка тап булдылар.

Авыш тау итәгенә корбанына ябышкан карчыга-лачын төсле берегеп үскән каен, зелпе, чаган, юкә агачлары арасыннан сузылган юл. Артта калган Болгар мәркәзе ягыннан эңгер-меңгер төшеп килә инде. Алда, җайдакларны ымсындырып, шәфәкъ яктысы гына уйнаштыра. Ботаклар, яфраклар арасыннан уйнаклап, юл өстенә саран яктылык төшкән. Җәнлек, кош-корт кычкырган авазлар ишетелми, урман тып-тын. Һава җиләсләнде, тәмам күз томаланганчы юыртсаң да була. Болгар чигеннән тизрәк чыгып ычкынырга кирәк.

Тирә-яктагы табигатькә алданып, алны-артны чамаламый бара иде алар. Бермәлне үзләрен әүвәл яндагы агачлар өстеннән сызгырып очкан кыл-арканнар чорнап алды, аннары

икесе тиң ат аяклары астына капланып төште. Искә-аңга килеп өлгергәндә, Нуретдин белән Рахман икесе дә бауларга чорналган көенчә юл өстендә ауный, ә күкрәкләренә инде теткәләнеп беткән киемле юлбасарлар менеп баскан иде. Баягы җайдаклар белән юлбасарлар бер-берсенең йөзләренә текәлделәр дә шаккаттылар.

— Нуретдин вәзир? Әмир Рахман? Кит, җаныгызны орыйм! Безнең кармакка мондый асыл кошлар килеп эләгер дип кем уйлаган? Әй, юлбасар Балак! Әй, егетләр! Боларны күрәсезме?

Ике качак түрә дә, билгеле ки, шундук таныдылар. Берьялгызы көе таш кирмән яулаган сыман оран сала-сала кычкырганы — кайчандыр Бәнҗә каласында Минай ханны чәнчелдереп төшәргә җыенган колчура Шоңкар инде. Икенчесе — әле Талиб хан, әле яһүдиләр тәлинкәсен ялап йөргән пычрак җанлы Балак. Боларның артларына тезелеп баскан өч-дүрт ирне генә танып булмый. Ләкин болары да илсез-йортсыз калган юлбасарлар инде, моңа шик юк.

— Азат итегез, ычкындырыгыз безне! — дип үкерде Нуретдин, гарьлегенә түзә алмыйча җиргә тибә-тибә. Әмма сизде, ат кылыннан үргән арканнар, ул чәбәләнгән саен, тәнгә ныграк үтеп керә, бәдәннәрне кисә башлый икән.

— Кемгә кул күтәргәнегезне күрмисезме әллә? Азат итегез, дим!

Шоңкар, керфек тә какмыйча, ирен чите белән көлеп сүз ташлады:

— Ник күрмик ди, шәп күрәбез, Нурый. Әле кайчан гына син олуг вәзир Нуретдин дигән түрә булып хисаплана идең. Бармак башы белән селкетүгә, әллә ничаклы олысларны, калаларны аякка бастыра идең. Бездәй бичара колчураларны гына түгел, зур-зур олыс тоткан бәкләрне дә дар астына, зинданнарга озаттыра идең. Ә хәзер үзең дә кол син. Нәкъ безнең шикелле үк илсез-җирсез калган бичара кол! Җүнле хуҗаның ертык җиләненә дә ярамас ямаулык син! Синең үзең белән дә, малаең Рахман белән дә хәзер җүнле хуҗа арт ягын да сөртеп азапланмый. Тф-фү, сатлык ишәк!

— Боларны аяк сөртеп, төкереп ташлаганчы, чишендерик әле, — дип сүзгә кушылды Балак. — Икеләтә файда. Без дә киенәбез, алар да шәрә көе качып китә алмый.

Махсус әмер биреп тору кирәкмәде алай. Җәягә ук корырлык та ара үтмәгәндер, артта торган ирләр качакларны анадан тума хәлгә калдырып ташладылар. Җиргә чокып ясаган куышлары да янда гына икән. Кичә генә вәзир белән әмир булып йөргән ике түрә кыл-арканга уралган көенә атна буе балчык идән өстендә хәрәкәтсез ятты.

22

Беркөнне кич Камышлы күл ягына җибәрелгән шымчы — сакау Хәлим кайтып, бутый-бутый тезде:

— Олы к-к-кәрван к-к-күл буенда төн к-к-кунарга к-к-калды. К-к-кырыктан артык дөя. С-с-сыртларына тау к-к-кадәрле төргәк төягәннәр. К-к-куйлар, бәрәннәр бар. Унбишләп к-к-кенә кушчы. Өч с-с-сәүдәгәр. К-к-камыш арасында яткан чакта төгәл ишетеп к-к-калдым. Әтилдән К-к-кашанга бара торган яһүдиләр болар. К-к-кәрванбашының исемен Юзикәй диделәр бугай.

— Юлга җыенығыз! — дип, шундук әмер бирде Шоңкар. Нуретдин белән Рахман да инде күптән иректә йөри иде. Алар тарафына да кырыс карап алды.

— Әзергә бәзер корсак үстереп ятарга хан түгелсез әле. Кәрванны талауда сез дә катнашасыз.

— Әгәр кәрванбашы Юзикәй атлы булса, ул мине таный ла! — дип карышып карады Нуретдин, әмма Шоңкарның кылыч сабына ябышуын күрүгә үк, шым калгандай булды.

Юлда хәтәр ашыгып барсалар да, күл буена төн уртасы узгач кына килеп өлгерделәр. Кәрван корып урнашкан ыстан уртасындагы кисәүләргә карап, иң беренче, Балак тотакаба сөенгәндәй булды.

— Учаклары сүнеп бара. Кушчылары йоклагандыр инде. Бигрәк әйбәт.

Вакыт төн уртасы булса да, куна тактасы шикелле таптакыр дала өсте бит, байтак шәүлә ерактан ук шәйләнеп, күзгә ташланып тора. Шуңа күрә ашыкмыйча гына ыстан өстен кабат-кабат күздән кичерделәр. Дөяләр аякларын янга сузган көе күши. Куй-бәрәннәр җылы саклау өчен бер-берсенә терәлешеп яткан. Уртага корылган өч тирмәнең берсеннән дә тавыш ишетелми. Төнгелеккә торгак булып калган биш кушчының өчесе учак янына сузылышкан, икесе күл буендагы агач төбендә йокымсырый сыман.

— Вакыт! — диде Шоңкар тәвәккәлләп. — Сакчылар биш кенә. Шундук бәйләп атабыз.

Юлбасарлар, гаярь боландай сикереп, ыстан уртасына ташланганнар иде, бик нык ялгыштылар. Аларның ерактан төнге сакчылар дип санаган шәүләләре карачкы булып чыкты. Җансыз курчакларны бәйләп азапланганда, дөяләр артына, камыш арасына поскан кушчылар болгарларның өстенә ябырылды.

— Артка, артка! — дип оран салды Шоңкар.

Ул үзе, урыннарыннан дәррәү сикереп кузгалган дөяләр арасыннан ыргылып, ыстан читенә очты. Аңа тагын ике-өч

шәүлә иярде. Ләкин ыргаклы сөңгеләр тотып йөгерешкән сәүдәгәрләр белән кушчылар берничә юлбасарны эләктереп өлгерделәр. Артта юхаланып кычкырган Балакның тавышы ишетелде:

— Мин яһүди бит, мин яһүди! Сезнең туганыгыз! Үтермәгез, зинһар!

Аны таш өстеннән тәгәрәгән буш мичкәнеке сыман иләмсез каты аваз күмеп китте:

— Ah, син яһүдимени әле, сатлык тәре?! Юлбасарлыкта йөреп, безнең динне мыскыл итәсеңме? Менә сиңа, үз хәйләсе белән икмәк таба белмәгән үләксә җан! Эткә — эт үлеме! Менә сиңа, менә!

Ыстан уртасында әллә сөңге сабына, әллә тимер кисәгенә даң-доң килеп бәрелгән кылычның зыңлавы гына яңгырап торды һәм күз ачып йомарлык арадан соң барысы да тынды. Шоңкар үзеннән аерылып читкә чапкан Нуретдиннең курка-курка сөйләнгән ике-өч җөмләсен генә ишетеп калды:

— Юзикәй танып өлгергән булса, эшләр харап, улым! Хәзәр каганы ягына юл бикләнде. Юзикәй каптырса, дарга аса безне. Инде хәзер кай тарафка качыйк?

23

Насыйр белән Байдар каганат башкаласында көннәр буе авыз ачып йөрде.

Әтил дигәннәре, и-и, зур икән! Хак булса, монда сиксән меңләп кеше яши, диләр. Бардыр, бардыр. Ястык сөйгән килен күсеннән ташыган әче камырмыни, дәрьяның ике як ярына да җәелеп урнашкан ул. Уңда — әниләренең канаты астына томшыкларын төрткән каз бәбкәләре шикелле бербөтен сыенып утырган өйләр, сулда — учтан качарга җыенып чәбәләнгән кәлтә кебек боргаланган вак-вак урамнар. Таштан, бүрәнәләрдән салган йортлар, сарайлар күзгә бик ташланмый. Күбесе — балчык белән тирес катнаштырып суккан саман йортлар. Байтак йортларның бөтенләй түбәләре дә юк шикелле. Алар урынына — йә бүрәнәләр өстенә өйгән туфракса, йә үгез, дөя тиреләре белән аралаштырып салган камыш. Мондый йортларда ничек янгыннардан исән каласың да, дошман чирүе капкалар, диварлар аша үтеп керсә, баскыннарның акыртып талавыннан ихатаңны ни рәвешле саклап булсын инде?!

Ә шулай да матур, тыныч Әтил. Гөлбакча диярсең, һәммә яктан яшеллеккә чумган. Урамнарда, таштан салган зуррак йортларның ихаталарында сәрви, элмә, зәйтүн, хөрмә куакла-

ры күкрәп утыра, арада керпе сыман бөгәрләнгән күгән[1]-сырганаклар[2], борыннарын күккә сузган каурыйларга охшаган карагайлар, кипарислар да күп. Гажәп, монда Идел ягына таба йомыркадагы чебигә охшап борын төрткән вак-вак чишмәләр дә байтак икән.

Манасий каганның сарае сарай гына түгел, олы кирмән. Диварлары гына да өч катлы, ди. Эчтәгеләре күренми, ә ап-ак таштан биек итеп салынган тышкы диварны дилбегә озынлыгы ара саен икешәр торгак саклый. Насыйр барып бер икесенә сүз кушып караган иде, аптырашка калды. Калкан, кылыч аскан сакчыларның һәммәсе дә йә Хорасан ягыннан килеп ялланган, йә болгар-бортаслы мөселман булып чыкты.

— Олы сөңге асып, озын көн буена челләдә пешеп йөрергә яһүдиләрнең башына тай типкәнме әллә? — дип аңлатты дөя иярткән баручы бер сәүдәгәр, бу хакта сүз күзгаткач. — Алар дивар артына качып, Каф тау ягыннан, Көбә үзәннән китерелгән шәрабларны озын чәйнек борыныннан чөмереп ятарга гына оста.

Диварлар артына качкан дөнья — серле, хикмәтле ул. Анда нинди мәкер, хыянәт, угрылык кисәүләре көйрәп яткан ын узгынчы сәүдәгәр, йә булмаса, капка төбенә бөкрәйгән угыз, төрекмән сакчысы каян белсен?..

Ә каган сараендагы хәлләр, чынлап, шәптән түгел. Манасийның төпчек малае Иосифка да егерме яшь тулды. Казан тирәсендә, атлар ябылган лапасларда, мунчаларда яраннары белән калган саен телендә гел бер үк төрле агу:

— Минем атайга озакламый җитмеш тула ласа. Ата-бабайлардан килгән йоланы да исебезгә төшерергә вакыт.

«Анысы нинди йола икән тагын?» дигән сыман яраннар аның йөзенә текәлсәләр, Иосиф читкә карап кына зәһәрлеген сибә.

— Соң, Овидий атлы ерак каганыбыз ук шундый йола калдырып киткән ләбаса инде. Җитмеше тулган кешенең акылы алышына. Аңа сабыйлар зиһене әйләнеп кайта башлый. Вакытында тәхет чистартмасаң, каганатка бәла килүе бар. Овидий менә шуларны алдан ук күреп торган да, әтисен тотып суйгач, бөтен ил буенча фәрман тараткан бит. «Җитмеш яшькә җиткән кешеләр йә үзләренә үзләре кул салырга тиеш, йә мин аларның гомерләрен кыям!» Минем атайдан да берәр төрле хикмәт корып арынмый булмас бугай...

Бәла аяк астыннан килеп чыга дигәндәй, Әтилдәге хәлләрне ут эленгән казан шикелле кыздырып җибәрердәй сәбәп тә табылды бит. Әтилгә терәлеп утырган төрекмән

[1] Күгән — терн.
[2] Сырганак — облепиха.

сәүдәгәрләре бистәсенә көтмәгәндә-уйламаганда мең кешелек угрылар чирүе бәреп керде. Таларга ярардай бар байлыкны кырып-себереп алып киткәннән соң гына бары да ачыкланды.

Булыр-булмас оранчылар Әтил урамнары буенча болай кычкырып йөрде:

— Киев каласыннан җыелышып килгән юлбасарлар алар. Башлыклары — бөлгенлеккә төшкән бояр Савилий, ди. Алар Дон белән Идел елгаларының бер-берсенә иң нык якынайган ике араны иңнәренә көймә күтәргән көе узып килгән икән. Менә шуңа күрә аларның кайсы яклап килүен дә шәйләп өлгерүче кеше табылмаган. Кала диварларының дала ягына шул нисбәттән сакчылар да куелмаган икән.

Хактырмы бу хәбәр, әллә юкмы, ләкин кансыз Иосиф әлеге вакыйгага бик тиз рәвештә үзенең камыт-ыңгырчакларын атландырып куйды.

— Каган картайды, каган җүнсез, — дип котыртты ул янә яраннарын. — Үзенең чалбар бөрмәсен төймәләрлек тә рәте калмаган карттан ничек итеп ил чикләрен биктә тотуны таләп итәсең ди? Илне саклап калыйк дисәк, котылырга кирәк карт каганнан, котылырга кирәк…

Тамчы тама-тама ташны тишә, дигәннәре, валлаһи, хак икән. Яшь Иосиф янында биеп-ялагайланып йөргән яраннарның һәммәсе дә берәм-берәм күнде. Кап-караңгы төн уртасында йокы бүлмәсенә үтеп кереп, Манасий каганның йөрәгенә пычак кададылар. Таң атканда, Иосиф алтынланган түбәле биек баскыч өстенә чыгып күренде. Әлеге алтын чатыр-баскыч алдындагы җирләр инде әллә кайчан ук юри туфрагын алып чокырланган иде. Читтән карасаң, шәп бит! Каган үрелеп буй җитмәс биеклеккә, әйтерсең лә болытлар өстенә менеп киткән. Ә кирәк чакта, фәрман тыңлар өчен җыеп ала торган сәүдәгәрләр, һөнәрчеләр, колчуралар аста. Шулай, син сарык көтүе, кара гавам, урыныңны бел!

Менә бүген дә үзенең йөзен күрсәтергә түбәнчелек иткән яңа каган чокыр эченә тезелгән ун мең гаскәригә тәүге фәрманнарын ишеттерде:

— Манасий каганның ачыгавызлыгы аркасында урыс угрылары пайтәхетнең үзәгенә тикле үтеп керде. Хәзәр каганаты көчсезләнгән, дигән хәбәр таралмасын өчен ул угрылар чирүен тоташы белән юк итәргә кирәк. Яков, Абрам, Савва меңлекләре! Урыс угрылары артыннан куа чыгыгыз да миңа атаманнары Савилийны тере көе тотып китерегез!

Чокыр эчендәге мәйданнан өч мең җайдак чыгып югалуга, аларның урынын яңа гаскәр алды. Болытлар канаты белән бер биеклектә торган алтын түбәле чатыр эченнән яшь каганның яңа бер фәрманы яңгырап ишетелде.

— Манасий каган дилбегәне кулдан ычкындырган, казна буп-буш. Каганат чигендә ялгыш берәр йөз генә дошман күренсә дә, сыңар алайны киендерерлек тә сәрмая юк. Аланнар, чиркәсләр инде алты-җиде ел буена ясак китермәгән. Авызыңа китереп тондырган йодрыкны эт шикелле каптырып алмасаң, бер дошман да тешең барын белмәс. Хәзер үк, шушыннан ук юлга чыгыгыз да ул колларны тезгә чүктерегез! Манасий сыман баштан сыйпап йөри торган заманалар үтте, хәзер мәмләкәт тәхетендә яңа каган!..

Урыс угрылары артыннан җибәрелгән меңнәр бер тәүлек дигәндә кире әйләнеп кайтты. Хәбәрләре мактанырлык булгач, чокыр эченә янә башкаланың һәммә почмагыннан куып китерелгән җаннарны тутырдылар. Алтын түбәле чатыр астына баскан каган алдында өч меңбашы да берьюлы җавап тотты.

— Угрыларны Җидеколак елгасы ярында чолганышка алдык. Һәммә угры кылычтан үткәрелде. Синең тез алдыңа китереп салу өчен атаманнары Савилий белән дүрт йөзбашларын гына исән калдырырга туры килде.

Мәйданга арканнарга чолгалган йөзбашлары белән Савилийны чыгарып бастырдылар. Һәммәсендә күкрәкләренә чаклы салынып төшкән сакал, барчасының йә кулында, йә тәнендә яра. Кайберсеннән һаман да кан саркый, аларга өшәнмичә каравы да читен.

Яшь каганның гына төге дә селкенмәде, әмере кансыз чыкты:

— Йөзбашларын кисәкләргә чапкалап үтерегез!

Айгырдай тап-таза, япь-яшь угры йөзбашларны «ә» дигәнче турап ташладылар. Инде чират аңа җиткәндер дип Савилийга күз атканнар иде, һәммәсе ah итте. Атаманның әле генә бөдрәләнеп торган, саламдай чәчләре күз ачып йомган арада көл төсенә кергән.

— Мине дә үтерегез, — дип эндәште ул, Иосиф тарафына текәлеп, бер дә курыкмыйча.

Иосиф болытлар өстеннән көлеп җавап бирде:

— Ә-ә, ю-у-ук! Сине үтермибез. Яһүдиләргә каршы кул күтәрергә ярамаганлыкны гомерең буе сөйләп йөрергә тиешле тере балбал итеп калдырабыз сине. Без синең күзләреңне генә төртеп тишәчәкбез!

Җәллад шул минутта ук Савилийның ике бәбәгенә утта кыздырылган ике пычак тыкты. Кичен сукыр Савилийны кала диварлары артына чыгарып ташладылар. Икенче таңда ул инде юк иде. Кала буйлап байтак көннәр буе сәер хәбәр йөрде:

— Иосиф бу төрекмән бистәсен талауны үзе башлап оештырмады микән? Угры дигәннәре Иосиф акчасына ялланган бичаралар гына түгел микән?..

Әлеге сорауларга җавапларны беркем белә алмады…

Иосиф озаткан икенче гаскәр ике-өч айдан соң, ярык тагарак алдында калган балыкчы карт сыман, башын салындырып, кире кайтып төште.

— Аланнар да, чиркәсләр дә христиан диненә күчкән. Хәзер аларның артында юнаннар кайсары калкан булып тора. Алан-чиркәс җәйләүләренә таш ыргытсаң, кайсар безнең каганатка яшен сыман бәреп керәчәк, ди…

Иосиф гаскәрләргә яңа фәрман бирде:

— Безнең Идел буенда да бурычын онытkан колчура бар. Болгар өстенә барып ташланыгыз! Хәрамханәдәге аларның аманат кызлары әби булды инде. Биләрдәге Мөхәммәт яңа кызлар биреп җибәрсен безгә, соңгы ун ел буена җыелган ясакларын бирсен. Ул гына да җитми. Әтне чылбырга утыртсаң, юаш, күндәм була. Аның үз кызын алып кайтыгыз сез миңа, үз җанашын. Аны шулай ипкә китерербез!..

Насыйр белән Байдар вакытында кайтып кисәтсә дә, Мөхәммәт хан сугым малы сыман калтырап төште.

— Йосыф каган безгә каршы егерме меңлек чирү юллаган бит, аланнарга каршы җибәргән кебек кенә түгел. Җитмәсә, без барып ышыкланырдай, безне яклап калырдай кайсар да юк. Ә ялгыз көе генә ни кырасың? Сыңар бармак белән чокыр казып та, җәя корып та булмый. Аннары, таянырдай малайларым булса да бармыни соң минем? Юк инде, тәкәбберлек күрсәтеп, һаваланып кына мәмләкәтне канга батырып булмас. Иелгән башны кылыч кисми, диләр. Өне тыгылсын, тиешле ясакны да, аманат та бирәм.

Мөхәммәт хан үз йортыннан унбиш яшьлек кызы Зөлфияне аманат итеп озатмакчы иде. Бәнҗә каласыннан, шаша-котырына, Булат батыр очып килеп җитте.

— Мин Зөлфиягә күптән гыйшык тотам. Каганга озаттырма, миңа хатынлыкка бир. Мин аннан башка бер көн дә яши алмыйм, — дип, әүвәл ипле генә итеп ханәкәнең кулын сорады ул.

Мөхәммәт боз шикелле үзгәрешсез калды.

— Юк инде, ил өстенә яу чакырып булмый. Алмаш кызым да юк. Зөлфия булгач Зөлфия, шуны озаттырам. Бик кыжрасаң, ул әйләнеп кайткач ярәшерсең әле.

Булат Болгар тарихында моңарчы күрелмәгән тәкъдим ясап карады:

— Зөлфияне бирмә. Каганның өне тыгылсын дисәң, мине сатып җибәр. Зөлфия хакына мин кол булырга да риза.

Мөхәммәт, ирен читләре белән генә көлемсерәп, һаман мыскыллавын дәвам итте:

— Ә син болай да минем колым түгелме соң инде? Бер тәкәне ике кат печмиләр бит.

Бәгыре-җаны күбәләк канаты кебек утка пешкән Булат батыр тешләрен шыгырдатып, сыкрый-сыкрый әйтте:

— Ханнар колагына колчуралар ялваруы барып ишетелсә, йә еланнар тез өстенә чүгәр, йә гөләп чәчкәләре энәләрен коеп бетерер, ди. Кызыл кар яуганчы көтсәң дә, алай булмый икән. Мәгәр бик белеп тор, син бүген бер әмиренне югалттың, саңгырау хан. Сиңа колчура шикелле гомер буе бушка бил бөккәнче, мин, ичмаса, бер көнгә генә булса да бөркет булып калам...

24

Каган гаскәрләре Сарытауга килеп җиткән төшләреннән кире борылдылар. Үз әләме астына баскан биш йөз җайдак белән Булат батыр аларны, үзәннәргә, чокырларга ышыклана-ышыклана, гел озатып барды. Күзәтүгә җибәрелгән иравыл җайдаклары әледән-әле хәбәр итеп тора:

— Ялга туктаган саен Зөлфия ханәкә сәрдәр чатырында. Сәрдәр чирүләрне таркатмый тота әле.

Ниһаять, күңелне җылытырдай тәүге хәбәр килде:

— Сәрдәр олы чирүне өч канатка бүлде. Ике нөгәр китте, сәрдәр үзе өч мең җайдак белән Идел буенда ыстан корып ята.

«Каган әмере үтәлгәч кайгырмый бу сәрдәр. Моңа адым саен туктап күңел ачса да була, — дигән уйлар яндырып узды, әмма батыр үзен бик тиз кулга алды. — Эчтән көя торган вакыт түгел. Зөлфия чатырын ачыкларга кирәк».

— Үзем белән унбиш-егерме генә юлчы алам, — дип кырт кисте ул үзенең йөзбашларына. — Башкаларыгыз тын да алмый посып утырыгыз.

Кичке эңгер-меңгердә, Сарытау итәгендәге аю баланы, бүре юкәсе куаклары артына качып, озаклап күзәтте ләр. Сәрдәр сәфәр ыстанын да, каган сараеның диварлары сыман, өч кат итеп корган. Һәрбер чылбыр саен дистәләгән учак, йөзәрләгән сакчы. Сәрдәр — үзе кереп бикләнгән чатыр зурлыгындагы алтын бәһасе тора микәнни, кит, куркак җан!..

Гаскәр калган үзәнлеккә кайткач, йөзбашларын җыеп, Булат батыр сүзне кыска гына тотты:

— Сәрдәр чатырына сыңар күсе дә үтеп кермәле түгел. Адашкан бозау сымак арттан ияреп йөреп, вакыт әрәм итмик. Моннан алты-җиде фәрсах ераклыкта ике тау арасына кысылган иңкүлек бар. Ике якта кыя. Ишетеп тә беләсездер әле, Пар-Чукмарташ, диләр. Әйдә, сәрдәрне урап үтик тә шунда көтеп карыйк. Әгәр сәрдәр анда килеп керсә, чирүне сузып аппармыйча булмый. Ике яклап тау башыннан ук яудыру, таш яудыру өчен иң-иң кулай урын...

Шул сәгатьтә үк кузгалып, таң атканчы юырттылар. Менә ул — сихерле Пар-Чукмарташ. Асылда да, иңкүлекнең ике ягына билгесез пәһлеван аягүрә бастырып калдырган гөрзиләрне хәтерләтә икән. Дөрес, ул дәү гөрзиләр артына әле тагын вак-вак таулар сузылып яшеренгән. Болары — үсеп кенә килүче, иңкүлек суына күбенергә салган чукмарлардыр инде.

Кыялар өстенә менгәч, эреле-ваклы ташларны ташый-ташый, тау-тау итеп өя башладылар. Шул чагында сыңар Чукмарташ өстенә торгаклыкка баскан йөзбашы хәбәр салды:

— Без килгән юл өстендә ялгыз җайдак йөри. Безнең ниятне сизеп алган шымчы булмаса гына ярый инде тагын.

Дистәләгән кеше, чуерташлар артына кача-поса, кат-кат күзәттеләр. Валлаһи да, ялгыз җайдак бит бу, һичбер юлдашы юк. Барып сыенырга куышы булмаган сукбай сыман бер урында бөтерелеп йөри. Сөңгесе, җәясе дә юк шикелле. Килеш-килбәте болгар кешесенә тартым кебек. Һәрхәлдә аймыклар, угызлар сыман баш түбәсенә киез эшләпәләр элмәгән бу. Ләкин ара бик ерак бит, тәгаен генә ничек ачыклыйсың?

— Игътибар итмәгез, — дип кул селтәде Булат. — Хәзәрләр кырып-талап үткән далаларда нинди генә юлчы киләп сарып йөрмәс? Берәр кәрваннан адашып калган йә юл белергә җибәрелгән чапкындыр әле, баксаң.

Ялгыз җайдак берзаман юкка чыкты. Өйлә намазы үтеп барган чакта Сарытау ягында тузан болыты күтәрелгән иде. Сәрдәр гаскәре бу, башка берни түгел.

Салкын таш өстенә ятып, озак көтте алар. Һәр яугирнең күзе юлда гына. Сәрдәр гаскәре буар елан сыман сузылып, ашыкмыйча атлый. Боларның тамак тук, шул рәхәтлектән хәзер йоклый-йоклый барсалар да була.

— Теге җайдак ияртеп килә бит боларны, карагыз әле, кара! — дип хәвефләнеп кычкырды кинәттән генә сакта яткан йөзбашы. — Безнең эзгә баскан шымчы булып чыкты бит бу, каһәрең, сатлык булып чыкты!

— Тавыш-гау куптарма!

Кыя түбәсендә шундый кыска гына әмер яңгырады, аннары, һәммәсе дә бер булып, дошман гаскәр өстенә текәлделәр. Әйе, алда, тавис каурыйлары белән бизәлгән көмеш очлым кигән яубашы янәшәсендә, таныш җайдак килә. Куллары бутый-бутый нидер сөйләп бара, авызы ерык. Моның белән янәшә атлаган җайдакларга да кызык, ахры, вакыт-вакыт, атларны сискәндерердәй итеп, кешнәп көлешәләр.

Дошман ташкынының беренче рәтләре ике тау арасына килеп керүгә үк, Бәнҗәнең үзеннән чыккан яугирләрне корт чаккандай булды.

— Бәрәч, бәрәч! Бәнҗәдән Мөхәммәт хан куган Шоңкар бит бу!

— Фетнәче, гыйсъян Шоңкар!

— Шоңкар? Шоңкар!..

Һәммәсе аһ итте. Илдәшләрен сатлык, хыянәтче дип тамгаларга әле берсенең дә теле әйләнмәде. Шулай да Шоңкар — дошманнар арасында, ә буар еланны утлы божра эченә алырга кирәк иде. Булат батырның күк күкрәгендәй көчле оран салган тавышы яңгырады:

— Хәзәрләргә үлем!

Ике кыя арасына нечкә тасма булып сузылган тар иңкүлек эчендә кисәк кенә гарасат һәм туфан купкан сыман булды. Чукмарташ кыялары өстеннән, ике яклап та, тоташ ук яңгыры яварга тотынды. Зәһәр тузан болыты, коточкыч тавыш куптарып, аска казан, чүлмәк, тәгәрмәч, камыт олылыгындагы ташлар очты. Кыя билендәге баскычларга, терсәкләргә эләгеп, чуендай ул ташлар йөзәрләгән кыйпылчыкларга әверелде, дошман җайдакларын, чаптарларны хәнҗәр урынына кисте, тураклады. Аста дистәләгән чаптар изелде, йөзәрләген җайдак ияр астына ауды. Ышыкланырдай-качардай куыш эзләп, кешеләр кыя баскычлары астына ташландылар. Шашынган һәм котырынган атлар, кая туры килсә, шул якка сикереп, берсен-берсе изә, таптый башладылар. Иңкүлекне өшәнеп кешнәгән ат, ачыргаланып кычкырган ирләр тавышы күмеп китте...

Игътибарсыз калдырылган Шоңкар кайсыдыр кыя астындагы куышка ташланган иде дә, артта хәзәр яубашының илереп үкергән әмере яңгырап ишетелде:

— Әнә теге болгар еланын качырмагыз берүк! Шул соран елан гына безне шушы үлем үзәненә алдап алып керде!

Хәзәр яугирләре качкан куышлар, чокырлар, ташлар арасыннан Шоңкар өстенә ук давылы очты. Алар качак егетнең арык гәүдәсен бер минут эчендә карбыз урынына теткәләп ташладылар...

— Шоңкар өчен үч! — дип кычкырды бәнҗәле бер болгар, җәясенең тәтәсен ычкындырган чакта.

— Зөлфияне, Зөлфияне алып качалар бит! — дигән икенче бер аваз һәммәсен сискәндерде.

Аска текәлделәр. Хәзәрләрнең яубашы, чыннан да, ханәкәне ияренә аркылы ташлаган көе читкә качып котылмакчы була.

Булат батырның өшәнгән тавышы әйтерсең лә таш кыяларны да уятып, ярып үтте.

— Зөлфияне, Зөлфияне коткарыгыз тизрәк! Аска! Һөҗүмгә! Аска!

Иллегә якын ир, өермә сыман кузгалып, кыя өстеннән аска ташландылар. Алар ясаган чөй әүвәл дошман җайдакларының сафын хәнҗәр кебек икегә ярып керде.

Чөй башында Булат батыр үзе. Җилән итәкләре ике канат сыман як-якка аерылган. Кулындагы кылыч ялт-йолт килеп тора. Күзләрендә бетмәс-төкәнмәс дәһшәт. Тагын биш-алты гына адым. Аннан... аннан ул Зөлфия җанашын кочагына эләктереп читкә ычкыначак. Зөлфия ханәкә. Җанаш...

Өлгермәде егет. Яннан килеп чыккан бер угыз пәһлеваныныңкылычы аның гәүдәсен икегә телеп атты...

25

— Чулман буйлап дошман төшеп килә!

Ак Идел тамагындагы Каракүл ямыннан ак күбеккә баткан чапкын килеп шушы хәбәрне әйткәч, әмир Ибраһимны аяз көнне яшен суккан кебек булды. Кисәк кенә бөтен тәне калтырый башлады аның, зиһене томаланды. Ак Идел белән Иж елгалары аръягында Болгар хәтле Болгарга каршы чукмар күтәрә алырдай көчкә ия бер дәүләт тә юк бит. Ул якта шул урманнарга кереп качкан мукшылар, арлар, чирмешләрдән кала, хәтта берәр куәтлерәк кабиләнең дә күренгәне, булганы юк әле. Каян чыккан дошман чирүе бу? Сиздермәстән килеп талыйм дисәләр, Идел буенда Ашлы каласы бар. Аннан түбәндәрәк, Чулман тамагында, Кашан бар әле тагын, Болгар каласы бар. Нигә болар Чулман буйлап килә? Монысы кем, кайсы сатлык өйрәткән яңа сукмак тагын? Иң мөһиме, нинди дошман соң бу?

Әмир Ибраһим яңа кирмән төзелешен саклаучы гаскәр башлыгы итеп җибәрелгән Илбуга бәкне дошман чирүенә каршы озатырга мәҗбүр булды.

— Сиңа бер йөз генә яугир бирә алам, — диде ул Илбугага, аның сорау тулы карашыннан качу өчен Чулман өстенә борылып. — Иж тамагы каршында камышлы бер утрау бар. Дошман каекларга, корабларга утырып төшә, диләр. Чулман уртасында тырпаеп утырган утрау үткен хәнҗәрдән бер дә ким түгел. Аңа җиткәч, дошман кәрваны кавын сыман ике өлешкә бүленмичә калмас. Ачыкла, бел. Нинди яңа дошман бу, кайсы яктан килә, ничаклы яугире бар? Аннары аларга сиздерми генә кире борылырсың.

Илбуга ияр өзәңгесенә сул аягын куйгач, «онытма, мин кисәттем» дигән шикелле, Ибраһим өстәп куйды:

— Кара аны, яуга керәсе булма...

Күзәтче булып озатылган ирләр арасыннан егермеләбе камышлы утрау эченә кереп яшеренгәч тә, тирә-яктагы табигатьне күреп, шундук сихерләнде.

Күк йөзе зәп-зәңгәр. Анда-санда гына ак каурый шикелле сузылган вак болытлар йөзә. Бөтен тирә-якны, Чулман

өстен тургайлар, былбыллар сайравы күмеп киткән. «Иң зифа тавыш миндә генә! Арада мин оста!» — дип узышалармыни?! Ике як ярны каплаган тал-тирәк куаклары артында ялгыз ләкләк кычкырган аваз да ишетелгәләп куя. Ярдан дулкыннар өстенә шомырт, балан, гөлҗимеш ботаклары сузылып төшкән. И, гөлҗәннәт! Дөньяңны оныт та сокланып ят. Ә монда, шушы ожмах бакчасын җимерергә, туздырырга дошман килә, диләр. Нинди миһербансызлык, вәхшилек, гаделсезлек хөкем сөрә соң бу җир йөзендә?! Нишләп адәм балалары тилергән әтәчләр шикелле үзара чукышалар? Нигә алар ипле генә, тыныч кына яшәп ята алмый?

…Чулман өстендә икешәр-өчәр катлы киндер җилкәннәрен корып килгән каеклар пәйда булды. Бишәү, тугыз, унбиш. Артта тагын, тагын… Биегәйтеп ясалган диварлы каек саен кырык-илле яугир. Качып яткан берәр шымчыфәләннең сизмәгәндә генә сәрпи ук очыруы мөмкин дип тә шикләнми бит болар. Өсләрендә көбә киемнәр юк, һәммәсе тезләренә җиткән киндер күлмәк кигән. Аякларында илнекөнне күргән юкә чабаталар. Арада кара сакаллылар да күренә, әмма күбесенеке җиз төсендә, алар себерке сыман җәеләп күкрәкләргә яткан. Юньле ризыкны байтак көннәр буе күргәннәре юктыр инде, ахры, корсаклары сыртларына ябышкан, беләкләре ап-ак. Ә җырлыйлар! Әнә берсе каек башындагы мичкә өстенә менеп утырган да салмак кына суза. Калганнары ара-тирә генә кушылгалый:

Ты беги, мой конь, к моему двору,
Ты беги, конь мой, все не стежкою.
Ты не стежкою, не дорожкою,
Ты беги, мой конь, все тропинкою,
Ты тропинкою, все звериною…

— Ah, каһәре, урыслар бит болар!

Илбуга үзенең янәшәсендә көтмәгәндә телгә килгән юлдашының авызын каплап ятты:

— Шыбырдама, Гата, үзем дә күреп торам.

Утрауга кәрван ахырынарак баскан, борыны, ян-яклары көмеш япмалар белән бизәлгән каек якынлашты. Каек кына түгел, диңгезләргә дә чыгарып җибәрерлек олы кораб инде бу. Биек дивар артына поскан борынында әнә биек итеп ясалган күперчеге дә бар. Дивар асларыннан берсе-берсе биш каз канатыннан да зуррак итеп ясалган ишкәкләр чыгып тора. Корабның арткы өлешендә авызы-борыны бөкеләнгән агач мичкәләр катлы-катлы булып тезелешкән. Ризык-зиннәтләре шушында боларның, димәк. Чирүнең авызы шушы корабка текәлеп каткан инде. Их, моны ничек итеп күккә очырасы?!

Илбуга кораб күперчегенә менеп килгән ике ир тарафына күз атты да авызы кайнар ашка пешкән шикелле куырылып калды. Берсе — кәрванны җитәкләп килгән угрылар башлыгыдыр инде боларның. Ә менә икенчесе… Бәнҗәдән, Биләрдән, ахыр чиктә бөтенләй Болгар җиреннән сасы пумала белән куылган әмир Рахман бит бу! Ah, кабих җан! Ah, иманы-дене коргаксыган бүкән! Ничек кенә җир йотмый да моны, шушы эт җан, аяк табаннарын ялау өчен, ничек итеп яңа хуҗаларны юллап табаладыр?

— Яңа корган кирмәннәренә төшеп җитәргә күп калмады инде, — дип телгә килде сатлык. — Ханның үз малае төзегәнгә күрә, Ибраһим кирмәне дигән булалар да, исеме юк әле. Иллә мәгәр хан малае төзи бит, анда байлык муеннан инде ул. Рәхәтләнеп, эченә чумып йөзәргә дә була!

Сатлык Рахманның ялагай сүзләреннән соң угры баскыннар башлыгының күңелендәге өмет-хыял рәшәдәй уйнаклый башлады, күрәсең, тегесе тәнен шүрәле кытыклаган төсле кеткелди-кеткелди көлеп үк җибәрде.

— Кулга гына төшерик, сине буш калдырмам.

Илбуга чит-ят баскын белән качак болгар кыяфәтен күздән кичереп чыкты. Теге ир үз өстенә тимер челтәрләр белән бизәлгән кыска, күн бишмәт шикелле япма киеп алган, әмма җиңнәре юк. Башында — артына тимер челтәр тагылган көмеш очлым. Аннан нәкъ борын өстенә туры китереп тимер тел асылынган. Үгез күненнән ясалган киң каеш астында беләк буе хәнҗәр. Янда — уч төбе кадәр киңлектәге ике ягы да үткен озын кылыч.

Рахман-уйнашчыга күннән теккән япма тәтемәгән. Бил каешына кыстырган пычак та картайган сугымчы кулыннан төшеп калган сыман. Баш түбәсенә дә бәрән тиресеннән генә теккән мескен бүрек кигән. Үзенә калдык сөяк сыныгы ыргытткан баскыннарның табан асларын ялавын ялыйдыр ул, иллә мәгәр кадер-хөрмәт дигәннәрен барыбер дә күрми бит бу йолкыш! Ә шулай да җиләне кабарып-бүртеп тора. Бу — хәйләкәр. Җилән астына җиңел көбә яшермәдеме икән?..

Кичен болар Мәләкәс дигән кечкенә бер елга тамагына төнгә тукталдылар. Яр тулысынча ак ташлардан хасил, шуңадырмы елга өсте учак яккан шикелле гел яктырып тора. Илбуганың ирләренә, чаптарларны каршы як ярдагы наратлар эченә яшереп, баскыннар ыстанына ялан-кырда кибән шикелле калкып торган таулар итәге аша урап якынаерга туры килде.

Болар чатыр, тирмә корып азапланмый икән. Бер-ике урында гына ботак-сатакларны җыештырып, сөңгеләр өстенә җәеп куыш ясаганнар. Яубашлары, сатлык Рахман, күннән теккән җилән аламасы кигән меңбашлары — һәммәсе дә шул куышлар янына корылган казан тирәсендә. Ә бүтән баскыннарның

күбесе әнә үз учакларындагы утлы кисәүләрне читкә типкәннәр дә көл өстенә тәгәрәшкәннәр инде. Яр өстенә, каеклар тирәсенә генә кырык-илле торгак утырышкан.

Илбуга унбашларын чакырып киңәш-уңаш тотты:

— Егерме-утызлап ирне атаманнарының корабына юлламыйча булмас. Анда — баскыннарның ризык мичкәләре, тимер көбәләр, саугатларга әзерләнгән зынҗыр. Суга гына батырсак, баскыннар иртәгә аларны, көне буе чумып булса да, кире ала инде. Шуңа күрә ул явыз корабны яндырырга кирәк.

— Ач эт ярсу була, соңыннан боларның кирмәнгә котырган шикелле ташланулары да бар, — дип сүз кыстырды Гата.

Илбуга аны җөпләгәндәй дәвам итте:

— Ярсысыннар, әйдә. Аның каравы боларның җегәре бик озакка бармас. Ә без... ә без менә Гатаның унлыгы белән баскыннар ыстанының үзәгенә үтик. Ә-әнә теге куыш корылган җиргә. Анда безне зәһәр бүләк көтә. Рахман сатлык җанны тере көе эләктерергә кирәк. Кирмәнгә алып кайтып җәза кылачакбыз без ул сатлыкка, үзебезнең җирдә!..

Баскыннар ыстаны уртасына елан шикелле шуыша-шуыша гына якынайдылар. Дошман озын көн буена урман кисеп кайткан диярсең, гырлый-гырлый йоклый. Ботаклардан ясалган куышлар янына куелган ике сакчы да сүнгән учак тирәсенә бөгәрләнеп сузылганнар инде. Урманнар артыннан таң сызылып килә.

— Син әнә теге яклап шуыш, әнә теге яклап, — дигән шикелле, Илбуга Гата тарафына кул изәде. Үзе куышлар авызына таба шуышып китте. Менә болгарлар ясап кидергән күн читекләр. Менә сакал-мыек тирәсе токмачларга укмашып беткән сатлык Рахман. Авызын тавык йомыркасын бөтен көе йотарга җыенган сыман олы итеп ачкан. Тамак төбеннән бер генә аваз суырылып чыга:

— Гы-ыр, гы-ыр.

Илбуга әүвәл киерелеп аның бугазына хәнҗәр сабы белән тондырды да, теге камыт бавы сүтелгән ат шикелле туарылып төшүгә, авызына йодрык чаклы чүпрәк тыгып куйды, кулларын-аякларын кыл-арканнар белән чорнап алды. Монысы хәзер тын чыгарырлык түгел, аны Илбуга эзеннән килгән пәһлеван яугир сөйрәп чыгып китте. Ә Болгар җиренә елан сыман качып кына, шуышып кына кергән баскыннарның башлыклары кайда?

Гата белән икәүләп яндагы куыш авызына ташланганнар иде, аннан бер-берсенә терәп тезелгән казан төпләре генә чекрәеп карап тора. Илбуга белән Гата куыш тирәсен тагын-тагын капшап карадылар. Әллә нинди иске чабаталар, ер-

тык күлмәк чокып чыгардылар, ә баскыннар яубашының эзе дә юк. Әйтерсең лә аннан җилләр искән…

Илбуга Чулман аръягындагы наратлыкка әйләнеп кайткан чакта, егетләр сатлык Рахманны ару гына изгән иде инде. Атаманны таба алмаган кызудан Илбуга үзе дә теге хыянәтчегә бер-ике мәртәбә тамызып, сылап алды. Яман усал кысылган иреннәре арасыннан берничә генә сүз сытылып чыкты:

— Синдәй нәҗесне дә күтәрә бит туфрак, и-их, үләксә!..

Ирләр ияр өстенә менеп алуга ук, үзенең дә, баскыннарның да бөтен серен сатып бетерде очсыз Рахман:

— Растуфныкылар алар. Нәрә дигән олы күл буенда шундый бер кирмән бар. Атай алып барып керде мине анда, атай алып барды. Кияү каласына төбәп киткәч, Кәлҗәмә дигән суга җиткән идек. Урыслар аны үзләре Келәзмә дип йөри. Болар Болгар илә алу-сату итә торган кавем түгел, безне белүче юк, әйдә, шуларга сыеныйк, дигән булып, атай мине шунда алып китте. Растуфка җитсәк, тегеләрдә ачлык. «Өсләренә барып таларлык кем бар? Давай, юл гына күрсәт», — дип, атайның бугазына пычак терәделәр. Күрә торып үләсе киләмени? Атай юл өйрәтеп җибәрде инде менә.

— Ә үзе кайда соң әле ул, кабих җан? — дип түзмичә бүлдерергә мәҗбүр булды Илбуга.

— Ул, Растуф ушкуйларына ияреп, Кияү каласы ягына төшеп китте.

— Ah, пычак кергере җан! Растуфларга Кияү каласы урысларын да кушып, бөтенесен берьюлы Болгарга каршы өстермәсә ярый әле тагын, — дип сүгенде Илбуга, һаман ярсый төшеп. Ләкин бераздан, кышкы буранлы далада янә каты сукмак тапкан юлчы сыман, үз эзенә кайтты. — Бөтенесе ничә юлбасар?

— Өч мең кеше җыелып чыккан иде, бер-ике йөзе чирмешләр ягындагы сазлыкта батып калды. Ямансаз диләр икән аны чирмешләр үзләре дә…

Рахман, Туймас елга тамагына кайтып җиткәч, артына ава язды. Егет чакта бу якка да ауга килгәннәре бар, элек монда Чулман белән Туймас арасына кысылган Шәрә таудан гайре берни дә юк иде бит. Ә хәзер?

Чулман елгасы сыенып аккан биек тау сыртына ап-ак таштан кирмән күтәргәннәр. Дүрт почмакта түп-түгәрәк итеп ясалган дүрт манара утыра. Һәркайсында дошман гаскәре өстенә уклар яудырырлык, сумала, кайнаган су, утлы күмер коярлык итеп уелган озынча, тар «күзләр». Манаралар берберсе белән җитмеш-сиксәнешәр адымлы таш диварлар аша тоташканнар. Диварларның бер ягында гына күтәрмәле капка калдырылган, башкалары кыя сыман тоташ. Эчке яктан кирмәнне янә бер мәртәбә карагай, имән, нарат бүрәнәләр белән

ураганнар. Ак диварлар белән бүрәнәләр арасына ком-таш тутырылган. Бүрәнәләр ягы тәбәнәгрәк, аның өстенә берьюлы өчәр-дүртәр рәт сакчы тезелерлек киң басмалар корылган. Менә хәзер, шушы гына минутта, кирмәнгә хәвеф тудырырдай бер дошман юк, ә торгаклар, барыбер дә, бөтен тирәякны күз уңында тота. Боларга эссе кояш та, җил-яңгыр да комачауларлык түгел. Диварлар өстенә тәртә юанлыгы чепчи каеннарны, усакларны тезеп түбә ясаганнар.

Саклык чаралары әле шушылар белән генә бетсә икән! Юк, кирмәннең дүрт ягы буйлап та алгы якта йөзәр-йөзәр җайдак кереп чуммалы чокыр казыганнар. Ул чокырның дивар астындагы як ярында баш-башларын сөңге сыман очлап тезгән кат-кат бүрәнәләр. Кирмәннең бердәнбер капкасы каршына гына күпер көйләгәннәр, ләкин анысын да теләсә кайсы минутта сүтеп ташлап була. Кирмәннән илле-алтмыш адымнар ераклыкта текә тау итәге, анда махсус китереп аударылган ком өемнәре дә хәнҗәр очы сыман үткен вак таш өемнәре. Бар, сиздермәстән генә һөҗүм итеп кара син боларга. Әле шушы текә тау итәгенә дә үрләп менә алмыйча, никадәр ат корсагын ярачак, ничаклы баскыннар гарип калачак бит. Менә ичмаса кирмән дисәң дә кирмән! Рахманның үз гомерендә сыңар йорт булса да төзегәне бармыни соң аның? Эх, син, кайәр суккан, эт талаган язмыш!..

Кирмән артындагы уйсулыкта әле тагын дистәләгән йортлар күтәргәннәр. Болары әллә кайдагы комлыклардан, елга буйларыннан ташыган ташлардан салынган түгел инде, шул гадәти нарат, каен, усак бүрәнәләрдән генә. Урманы да Чулман ярына, бу кыя-тауга терәлеп тормый бит әле аның. Һәр агачны әнә теге яктагы, Иж елгасы буендагы карурманнар эченнән сайлап китертергә кирәк. Ният иткәч, бары да тырышканнар. Кирмән әзер, өстәвенә яндагы агач бистәдә ике яңа урам тернәкләнеп килә. Моны озакламый йә калачык, йә шушы яктагы олыс үзәге итәрләрдер инде. Исемен, мөгаен дә, Ибраһим кирмәне-мазар дип тәгаенләрләр. Ибраһим хан булса, кала аты Илбугага күчәр. Шулай, ил-мәмләкәт файдасына тырышып бил бөккәч, ташларга язылып та кала кеше исеме, халык хәтереннән дә озак онытылмый. Ә Рахманнан бу җиһанда нинди эз калсын ди? Уйнашчы дигәнме, сатлык йә баскынмы?..

Әмир Ибраһим Рахман белән сүз алышып тел пычратырга да теләк белдермәде. Әллә кичә генә әмир чаклы әмир булып йөргән бу бәдбәхет тоткын бүген аның өчен черек агачтан каерып төшкән сыңар ботак кына. Ул бауларга чорналган көенчә җирдә аунап яткан Рахманның янына да килеп карамады. Тоткынны иярге аркылы салып кайткан җайдакларга текәлеп әйткән усал тавышы гына яңгырап ишетелде:

— Сатлыкларны нинди тәкъдир көткәнен баскыннар да белсен. Сабак алмаслармы? Әнә кирмән диварына илтегез дә шуңа бәйләп куегыз бу имгәкне. Үзе Болгар өстенә иәртеп килгән баскыннар ук теткәләп бетерсеннәр. Моңа шул төс.

— Юк, үтертмәгез мине, үтертмәгез! Мин синең аяк астыңда тузан булырга риза, Ибраһим, кол булырга риза. Диварга гына бәйләттермә мине! Моннан ары Болгар хакын гына хаклап яшәр идем. Үтертмәгез мине! — дип, Рахман җир өстендә тәгәрәп-аунап йөрде, колак салмадылар.

Дивар өстен кирмән сәрдәре Илбуганың кырыс әмерләре күмеп китте:

— Казаннар астына ут элегез! Ике йөз җайдак бистәне саклап кала, бүтәннәр кирмән эченә! Соңгы сакчы әрәм булмый торып, капканы төшерү юк!..

Әле төш вакыты җиткәнче үк баскыннар чирүе Чулман ярын кырмыска өере төсле тоташ сырып алды. Әллә болар таш кирмәнне курчак кала сыман гына кабул итте инде, көймә-каекларын сакларга торгаклар да калдырып тормыйча өскә ябырылдылар. Баскыннарны сафка-рәткә тезеп торучы юк, күзәтү йә сынау йөзлекләре җибәрү юк, хуҗасыз кәрван очраткан чүл бүреләре шикелле, ак-караны күрми алга ташландылар. Чулман өстендә берсен-берсе әйдәкләп кычкырган тавышлар гына яңгырап-яңгырап ала:

— Нигезен дә калдырмыйбыз бу кирмәннең, тетеп бетерәбез!

— Растуфта балалар ачка кыркылып ята, энәсен-җебен дә калдырмыйча талап чыгачакбыз!

— Син ни кишерема дип төрткәлисең, Сидор? Көймәләрне тутыргач бергә кайтасы бит, шул чагында муеныңны өзәм!..

Ком-таш сибеп чыккан текә тауга менә башлауга ук борыннары белән җиргә капландылар. Әллә ничәсенең маңгае ярылып чыкты, йөзләбенең сакал-күлмәкләре тоташ канга батты. Бише-уны аска очты бугай, кылыч, сөңге, калкан тавышлары зеңләп купты, ун-унбише хуҗасыз хәнҗәр-кылычларга кадалып яраланды. Сүгенә-җикерә, әйтерсең лә гарасат кузгаттылар:

— Ah, каһәреңне өшкерим! Болгар еланнары безне тозак корып көткән!

— Шушы тауның түбәсенә менеп җиткәнче үк кырылып бетәбез бит!..

Иллеләп ир, кабат Чулман ярына ташланып, каек-көймәләрдән алдан ук әзерләп килгән баскычларны сөйрәп чыгардылар. Бу эшләре уңышлырак булды, ике-өч дистә чамасы гына кардәшләрен изеп, өске якка менеп өлгерде. Бүредән өреккән көтүдәге маллар сыман этешә-төртешә алга йөгерсәләр, тагын кискен упкын, тагын сөңге булып тырпайган очлы бү-

рәнә башлары. Ул арада таш диварлар ярыгыннан шөпшә күчедәй сызгырып очкан ук давылы. Дистәләгән, йөзәрләгән мәет. Дуңгыз тавышлары чыгарып чиный-чиный артка томырылдылар. Ә көймә-каекларда каткан ипи дә юк. Озын мөгезле, әмма инде яраланырга өлгергән хәлсез үгезне тотып ботарларга җыенган ач бүреләр кебек шуыша-шуыша, янә кирмән диварлары ягына борылдылар.

Һөҗүм иртәдән кичкә чаклы өч көн буе барды. Янда, уйсулыкта калыккан агач бистәдән олау-олау күмер һәм янган-көйгән кисәүләр генә өелешеп калды. Якын-тирәдәге яланлыкта авызга алырдай ни бар — һәммә үлән-чирәмне тел белән ялап алгандай кырып бетерделәр. Кирмән тирәли казылган чокырлар мәет белән тулды. Баскыннарның сафы бозлы яңгыр чүкегән суган кыякларын хәтерләтеп анда-санда гына тырпаешып калды. Көймә-каекларын Илбуга сәрдәр кирмән тышында калдырган җайдаклар урлап китте. Ә кирмән диварлары өстенә бер тапкыр да менә алмадылар.

— Шайтан каласы бу! Шайтан үзе ярдәм итә явыз болгарларга. Исән чакта ычкынырга кирәк! — дип, ниһаять, өченче кичтә акылга килделәр дә Чулман тамагына таба чигенделәр.

Илбуга аларны атна буе эзәрлекләп барды. Куе чытырманлыклар арасына яшеренеп, көн-таң атса уклар яудырдылар. Болгар чигеннән чыгып ычкынган чакта баштагы өч мең ирдән өч йөз өрәк кенә торып калган иде. Аларын да чирмеш урманындагы Ямансаз үз эченә йотты. Ростов ушкуйлары Чулман юлын дистә еллар буена бөтенләй онытты-лар. Аның каравы Болгар җирендә Шайтан каласы дигән өр-яңа кушаматлы кирмән яшәп калды.

26

Тол кенәзбикә Ольганың инде битләре җыерчыкланып бетте, чәчләре агарды, ә үзе һаман яшь Святославка мөстәкыйль рәвештә идарә итәргә һичбер ирек бирми, этлек артыннан этлекне эшләп кенә тора. Святослав яслар[1] белән касогаларга[2] каршы яу сәфәренә чыгып киткән иде, «чукынган әбекәй» ике сөекле оныгына, «ачтан үлмәскә» дип, шәхси биләмәләр өләшергә тотынган.

— Үз корсагыгыз турында үзегез кайгыртырга да, идарә итәргә дә өйрәнерсез, — дип, Ярополк белән Олегны әүвәл Новгород каласына озаткан бу.

Новгородныкылар гаҗәп вәсвәсәле, вәкарь, эре көрпәле

[1] Яслар — бүгенге осетиннар.
[2] Касогалар — черкеслар.

халык. Алар борын аслары да кипмәгән бала-чаганы санга сугамыни?!

— Без үзебезгә үзебез баш та, түш тә. Киев этләренең поты бер тиен! — дип, малай-шалай ике кенәзне дә куып җибәргәннәр.

Лышык-лышык борын тартып әйләнеп кайткан Ярополкка «изге әби» аптыраудан үзенең өр-яңадан калыккан биләмәсе — Вышегородны биргән. Ә Олегы древляннар башкаласы исәпләнгән Коростеньда туенып яшәргә тиеш икән.

Әгәр карт толбикә Святославның сөекле улы Владимирны да искә алган, санга суккан булса, яу сәфәрендә үлем белән качышлы уйнап йөргән тәкәббер кенәз, бәлки, ул кадәре котырынмас та иде. Ләкин кенәзбикә Ольганың ике оныкны үсендереп, өченчесен күз чалымына да китереп карамавы Святославны чыгырыннан чыгарды, тырнак астына кайнар энә кадагандай итте.

— Нәрсә, Ярополк белән Олег — аксөяк кенәзләр дә, Владимир минем өчен чит-ят баламыни? — дип ажгырып кайтып кергән улының сүзләренә каршы карт толбикә ыжлап та карамады.

— Владимир — колчура Малуша баласы, уйнаштан туган нәстә. Ә Ярополк белән Олег — никахлы кенәзбикә дәвамчылары. Аермалары — җир белән күк арасы. Син кайда гына, нинди генә кәнизәкләр тотып измәгәнсеңдер дә, синең аска яткан кайсы гына хатын бала тапмагандыр? Нәрсә, хәзер шул җилдән туганнарның барысына да кала-кырмәннәр бүләк итикмени?

— Никахлап кавышмый яшәсәк тә, Малуша — минем икенче хатыным. Владимир — өчесе арасында иң яраткан, иң акыллы улым. Ярополк белән Олег шикелле үк ул да кенәз, ул да тәхеткә һәм биләмәгә лаек! — дип, Святослав чигенми тәкрарлагач, карт толбикә бик тә җиңел генә хәл итте дә куйды.

— Кенәз буласы килә икән, әйдә, исбатласын!

— Нинди юл белән, ничек?

— Ишеткәнең бармы, Хәзәр диңгезе аръягындагы сәхрәләрдә мондый бер йола яши. Андагы ханнарның балалары бик тә күп булып, хан шуларның берсен генә өстен күрә, үзенә тарта икән, башка туганнары шул ала карганы йә, кулаягын бәйләп, коега салалар, йә башын гына калдырып комга күмәләр, ди. Күктәге Тәнре яклыймы бу ала карганы, әллә кире кагамы — менә шулай ачыклыйлар икән. Әйдә, синең ала каргаңны да шулай сынап карыйк. Моны мин генә түгел, дистәләгән боярлар таләп итә.

Кабилә хәтле кабиләләрне буйсындырып, кала артыннан кала яулап йөргән Святослав әнисенең шушы сүзләреннән соң коелды да төште.

— Нәрсә, Владимирны да тере килеш күмәргә җыенасызмыни?

Ольга керфеген дә какмый тезеп китте:

— Юк, үтермибез дә, күммибез дә аны. Без Владимирны кулына бер корал, бер пычак та тоттырмаган көе урманга җибәрәбез. Ул нинди генә хәлгә төшсә дә, үзенең кем баласы икәнен әйтергә тиеш түгел, авылларга-бистәләргә ризыкярдәм сорап керергә тиеш түгел. Менә шундый кыргый шартларда ул үзенең гомерен саклап кала ала икән, димәк, анда — синең кан, синең акыл. Исән-сау әйләнеп кайта икән, әйдә, чукын, теләсә кайсы калага утырт аны, үз урыныңа калдыр. Ул чакта бер сүзем йә үпкәмне ишетмәссең.

— Владимирның сынавы күпме вакыт сузылырга тиеш була инде?

— Төп-төгәл бер ел.

Святославның күзләре әйләнеп чыга язды, теле көрмәкләнде:

— Б-б-бе-е-ер ел?

— Әйе, төгәл бер ел.

Бик озак вакыт буе ишекле-түрле килеп йөргәннән соң Святослав, ниһаять, кул селтәде:

— Ярар, өнегез тыгылсын. Җибәрәм мин Владимирны. — Святослав әнисенә төбәп бармак селкеп алды. — Мәгәр сездән курыкканга түгел. Мин Владимирның исән-сау көе әйләнеп кайтасына ышанам. Владимир — минем бала, ул җиңәчәк!..

Владимир әбисе белән әтисенең таләбенә күнде, карышмады. Үзен кызгандырып күз яшьләре түгеп тә азапланмады, бер сынык икмәк тә алмады. Баскыч төбендә яткан тал таягын гына элөктерде дә сызгыра-сызгыра сынау, чит-ят җирләр, билгесезлек эченә чыгып китте.

Аны озатканнан соң Святослав атна-ун көн чамасы түзде әле. Аннары сарай эче тарайды, әнисенә, хатыны Евпраксиягә күтәрелеп карый алмас булды. Читлеккә ябылган арысландай дәшми йөрде-йөрде дә, Киев боярларын җыеп, аларның өнен алды.

— Безнең кенәзлектә кемнәргәдер биләмәләр җитми башлаган, җир тарайган икән. Шуңа күрә мин сезгә яңа яу сәфәре игълан итәм. Кемгә яңа җирләр яисә байлык кирәк, кулына корал алсын. Дошманнар алдында куркып тору бетте. Көнчыгышка карап юлга чыгам. Моннан ары минем үземнән алда һәр дошманга менә шундый кисәтү барып ирешәчәк. «Сезнең өскә барам!» Мондый кисәтү кай тарафка гына барып ирешмәсен, дошман алдан ук белеп һәм калтырап торсын. Димәк, Святослав килә, җиңү өчен килә!

27

Әмир Ибраһим янына Биләр каласыннан чапкын килеп җитте.

— Идел буйлап дошман бәреп керде. Яуны Кияү каласының олуг кенәзе Святослав үзе җитәкләгән, Мөхәммәт ханга «синең өскә барам» дигән мәсхәрәле кисәтү җибәргән, ди. Святославка ияреп егерме меңнән артык баскын килә икән*. Урысларның элгәре безнең җиргә мондый олы чирү илә, ә иң мөһиме, кенәз кул астында кергәне юк иде. Мөхәммәт хан зур хафага төште. Ул һәрбер улы үз янына басуны таләп итә.

— Нуретдин эше бу, — диде күкерттәй кабынган Ибраһим, ияр өзәңгесенә басканчы ук тоташ кара көеп. — Шул эт җанның эше. Нуретдин түгел бу, дөресе, Нурый этдин. Эттән туган нәрсә! Шул гына иярткеп килгән инде тегеләрне безнең ил өстенә. Һаман җир дә йотмый бит, ичмаса, шул хәсисне!..

Әзерлек чыра телеп ут куярлык арада тәмам булды.

— Сиңа ике йөз генә газине калдырам, өч йөз ирне үзем белән алам, — диде Ибраһим, Илбуга каршында гафу үтенгәндәй. — Растуфларны кудык, бу тарафта хәят күк йөзедәй аяз булып калды. Мәгәр Растуфлар безнең уяулыкны йоклатырга җибәрелгән төлке генә булган. Ә ханлыкны таларга чыккан бүре көтүе Идел буенда хәзер, мине дөрес аңла.

Илбуга белән кочаклашып аерылганнан соң ияр өстенә менгәч, Ибраһим ашыга-кабалана янә өстәп куйды:

— Син Иж аръягындагы арлар вә мукшылар белән бозылыша күрмә. Алар белән дус яшәргә тырыш. Җай чыккан саен аларга шайман, тауар, икмәк, ярма юлла. Хәвефмазар туса, шуларны соңыннан ярдәмгә чакырырсың. Урман бәндәләре булсалар да, аларда мәргәннәр күп. Таныргә була. Ә мин Нократ буендагы авыллардан ирләр җыеп китәм. Чирү таләп итеп, ул тарафка барма.

Инде тузан болыты күтәреп Нократ ягына таба юнәлгәндә, Ибраһим, өзәңгеләренә күтәрелеп, борылып аваз салды:

— Ә кирмәнне моннан ары үз исемең белән ата. Йә Илбуга каласы булсын, йә Албуга булсын! Буга — «үгез» дигән сүзне аңлата бит. Болгар иленең чик буендагы үгезе дигән атаманы ала икән, бик хуп, бик урынлы. Ул моны аклап өлгерде дә инде. Киләчәктә дә тезгә чүкмәс үгез булып калсын. Хуш, Илбуга!..

Нократ, Нырсы, Бәтке елгаларын үтеп Кашан каласына җитүгә үк, бары да ачыкланды. Әмир Ибраһим чишмә

---

* Киев кенәзе Святослав Болгарга яу белән 964 елда килә.

төбенә карагандай дөрес әйткән икән — Үзи, Тын, Урыс дәрьялары[1] буендагы халыкларны Болгар иленә качак вәзир, сатлык мәхлук Нуретдин иәртеп килгән. Яубашлары — Кияү каласының үзеннән үк чыккан егерме җиде яшьлек Святослав, ди. Ерак яу сәфәренә әле тәүге тапкыр гына чыгуы икән. Җиңелеп кайтудан шүрләгәндер инде, кул астына егерме мең кешелек гаскәр туплап килгән. Боларның бер өлеше Ука, Идел буйлап көймә-каекларда төшкәннәр, ди. Аның өстенә Иделнең ике ярыннан җидешәр-сигезәр меңле ике олы нөгәр басып кергән. Шунысы гаҗәп: нөгәрләрнең берсе ат өстендә, икенчесе бөтенләй җәяү килгән. Җәяү булганнары ул икешәр-өчәр айлык юлны ничек үтте дә, ни ашады икән? Хәер, ниятләре-ысуллары мул булгандыр инде. Әнә бит, урманнарга качып өлгермәгән чирмеш ыруларын-авылларын тоташы белән талап чыкканнар, ди.

Болар Атабай авылына килеп җиткәч, Чулман суына да бик очынып-жилләнеп кенә барып кермәкче булганнар. Ләкин, Атабай белән Болгар урнашкан ике як яр арасындагы су өстенә йөзәрләгән көймәләрне тезеп, аларның һәркайсына күкерт, сумала, җитен, мамык төяп, Мөхәммәт хан Чулман тамагын тимер йозак белән бикләп куйган. Урысларның өч-дүрт йөзләп ташбашы әле шуңа да игътибар бирми борыннарын сузып караганнар. Әмма, ут эленгән уклар яңгыры астында көймәләрдә тоташ янгын купкач, һәммәсе дә шундук күккә очкан. Аннары араларында мондый дуамаллар табылмаган инде. Аптырагач, шул үзләренә күптән таныш элекке юлга — Ашлы каласына карап төбәлгәннәр. Ә Ашлыдагы әмир Сәлман сакалына ут капканчы йоклап ята торган ачыгавызлардан, үшәннәрдән түгел. Ул каладагы бар халыкны күтәргән дә Зөя буендагы чытырманлык эченә кереп качкан. Дошман инде ничәмә-ничә көннәр буе буп-буш Ашлы каласында бер кабымлык ризык та таба алмыйча аптырап йөри икән.

— Урыслар хәзер анда кышкы өнгә яткан аю сыман аяк табаннарын гына суырадыр инде.

Болгар яугирләре шулай көлә. Күз тимәсен, кәефләре әйбәт.

Ибраһим әтисе Мөхәммәт ханның ыстанын Чулман уртасындагы утрауда эзләп тапты. Элек бу утрауда зур-зур ярминкәләр генә үткәрәләр, су уртасында булганга күрә исеме дә Ага-базар иде. Әтисе һаман да шул, һәр яклап су саклауны сәбәп иткәндер инде, менә үзенең яу ыстанын да шушыңа кертеп корган. Дөрес, чирүнең бер өлеше

[1] Үзи, Тын, Урыс дәрьялары — Днепр, Дон, Рось елгалары.

Болгар кирмәнен сакларга озатылган, ә төп гаскәр Ашлыга капма-каршы ярда, Баллы Арка дигән калку җирдә тупланып тора икән.

Мөхәммәт хан ничә айлардан соң тәүге тапкыр улын кочагына кысып каршылады. Сере тиз ачылды.

— Теге ике имгәкнең берсе дә килеп күренмәде әле, — диде Мөхәммәт хан, Ибраһимның йөзенә туры карамыйча. Сизелеп тора, ул хурлана иде. — Тимер-Мөэмин белән Габбас турында әйтәм... Ничә чапкын җибәреп карадым, бер җавап юк. Минем дөмеккәнне көтәләрдер инде.

Ибраһим сүзне читкә борырга ашыкты:

— Никадәрле чирү җыя алдың, атай?

Ханның иңбашлары бу юлы да сугып имгәтелгән каз канатлары кебек салынып төште.

— Газиләрнең саны унике меңгә дә тулмады шул әле. Сәлман Зөя аръягында качып йөри, ашлыларга өмет баглап булмый. Яу башланса, Сәлман шул арткы яктан килеп кенә ярдәм итсә инде... Җүкәтауны әйттем. Тимер-Мөэмин белән Габбас анда яткан чакта, Җүкәтаулар иманга килмәсләрдер... Бәнҗәгә дә таянырдай түгел. Аларны Йосыф каган, елан сыман авызын ачып, йотарга әзер тора. Ә монда, минем кул астында, Биләр белән Кашан гына инде.

— Ярар, ияр өстендә йөргән баһадирга ясин чыгарга ашыкмыйк әле, атай, — дип, Ибраһим тизрәк әтисен юатырга ашыкты. — Менә мин дә меңнән артык гази туплап килдем. Җан биргәнгә җүн бирер, ди, Ходай. Дошманны пайтәхеткә барыбер үткәрмәбез.

Мөхәммәт ханның да кәефе күтәрелде, ул Ибраһимның салпы ягына салам кыстырып алды:

— Улларыңның барысы да синең сымак таянырдай булса иде дә бит! Юк шул, әй генәм, юк шул...

Ибраһим каударланып янә сорау бирде:

— Мин мин инде ул. Ә менә таянырдай, ышанырдай җүнле сәрдәр бармы?

— Баллы Аркадагы чирү өстенә Даян вәзирне башлык итеп куйдым. Урыс арасында йөргән шымчы бит ул дигән булып күпләр яратмыйлар. Аларга сатылгандыр, арткы яктан пычак кадамасын, дип сөйләнүчеләр дә байтак кына. Мәгәр аның нәкъ менә шул урыслар арасында яшәгән булуы бәһасез өстенлектер. Чөнки аңа урысларның холкы-дуамаллыгы да, яу алымнары да күптән таныш. Ахыр чиктә ул аларның китек якларын да, мөгаен, сиңа-миңа караганда шәп беләдер. Менә шуңа күрә мин Даянны төп чирүгә сәрдәр итеп куйдым. Йә, син хуплыйсыңмы?

— Хуплыйм, атай, — диде Ибраһим, икеләнүгә шик калдырмастай вәкарь тавыш белән. — Эт өрә тора, бүре йөри

тора. Читтә өреп яткан һәр көчеккә каршы таш ыргытып булмас. Иллә мәгәр андый көчекләрнең авызлары томалансын өчен, Даян вәзир янына, әйдә, мине дә җибәр.

Мөхәммәт хан мондый җылы сүзгә күптән сусагандыр инде, Ибраһимны янә кочагына алды:

— Алай да син бар. Синнән кала тагын кемгә генә таяныр идем, улым?!

28

Даян Ибраһимны сөенеп каршы алды. Сәгате-минуты белән Баллы Аркадагы ыстанның буеннан-аркылысына уратып алып чыкты. Үзенең теле-телгә йокмый, бертуктаусыз сөйли. Аңлашыла, бергәләп җавап тотардай яңа иптәш табылуга ихлас сөенә бу.

— Газиләрне бишәр йөзлек алайларга бүлдек. Монда, Баллы Арка өстенә өч мең генә ирне бастырып куйдык. Биш меңләп гази әнә тегендә, күл буенда ята. Күз күремендә өч мең генә ирне ялтыратып йөртсәк тә, урыс баскыннары һаман һөҗүм белән килми. Аптырагач, теге ярга ике йөз җайдакны иравыл итеп куйдык. Башлыклары — Байдар. Теге, атаң Йомрыташ яныннан җәтмә белән эләктереп кайткан батыр, беләсеңдер инде. Ул уңъяк ярга чыгуга ук Кашкатау түбәсен эләктерде дә алды. Әнә кып-кызыл балчыклы бүрекне күрәсеңме? Кашкатау ул. Ашлыдан бер фәрсах тикле дә ара юктыр, урысларның борын төбендә генә. Әй, ул Байдар хыялый да инде! Үзе урысларның күзләренә сукыр черки булып керә торган ташбаш, үзе сабый бала төсле хыялый. Авыз суларын корытырдай булып, гел малае турында лыбыр-лыбыр сөйли: «Сал-Сал, Сал-Сал». Әй, тапкан соң исем!

Ибраһимга да кызык булып китте. Ул иреннәре буйлап таралган елмаюны да тыеп маташмады.

— Нинди Сал-Сал ул тагын? Йә, миңа да сөйлә.

— Һе, аны Байдар пәһлеванның үзе булып сөйләргә кирәк ләса, — диде Даян, үзе дә көлә башлап. — Ә андый осталык минем ише каткан телнең кулыннан киләмени? Бер кичкә кер мичкә, әй лә, сөйләп карыйм.

Даян ирен тирәләрен ялмады да, яңакларын күпертеп, Байдар кыяфәтенә кереп, тезеп китте:

— «Сания дә качак, мин дә качак, урлап ятак бүлдек. Ә урлап ашаган мал татлы була икән. Сания шәпле минем. Бер ел көттереп йөргәч, ниһаять, малай тапты. Әйтергә генә ансат, авырлыгы бер пот. Бер пот инде, бер пот, валлаһи, малайкаем. Кочакка да сыймый. Өнгә кереп чумган аю сымак бу, ими суыра да йоклый, суыра да йоклый. Ике яше

тулганчы имидән башка бернине дә авызына алып карамады. Сания коры сөяккә калып бетте, җаный. Кочаклап ятарлыгы да калмады мескенкәйнең. Шуннан малайга әйттем. Җитте, шайтан, хатын минем үземә дә кирәк, ботка аша, ипи аша, дидем». Бәрәч, бәрәч, малаең шулай ятак, никах турында да сөйләшә беләмени, дип сорыйбыз тегеннән. Байдар авыз ера. «Юк, ди, ике яшенә җиткәнче авыз да ачмады, ди». Аннан тагын сөйли. «Ике яше тулгач, көчкә беренче мәртәбә «әннә» диеп әйтте. Әле анысы да шул имидән аерып ач тотканга гына. Бер мәлне түшәм сайгакларын селкетерлек итеп үкерә бу, малай. Вә-ә дә вә-ә, авызына мендәр каплап та туктатырлык түгел. Хатын елый, мин тик утырам. Үз балаң тавышы туйдыра димени? Мин түзәм. Ә хатын, чыдамыйча, ботка пешереп бирде. Бармак башы хәтле эре ярмадан, арпаныкын. Агач җамаякны чүмәкәй итеп тутырдым да алдына китереп куйдым. Үземнең чүмеч хәтле кашыкны тоттырдым тегеңә. Хәзер инде үз көнеңне үзең күр, аша, мәйтәм. Күз ачып йомган арада ялт иттереп куйды. Кашык белән өстәл төя-төя янә сорый, шайтан. «Фал, фал!» «Әннә»дән кала әйткән икенче сүзе шул булды малайның. «Әттә» дип тә күңелне күрмәде бит, ичмаса, уйнаштан туган нәрсә! Фал, ди, тагын ботка фал, ди. Менә шуннан соң аңа Сал-Сал дидем дә исем куштым инде».

Ирләр утардан киң яланга качып чыккан кырыкмыш тайлар шикелле ихахайлап, кешнәп көлештеләр. Иделнең аръягындагы Байдар өчен дә, үзләре күрмәгән-белмәгән сабый Сал-Сал өчен дә бәхетле иде алар бу минутта. Күңел юаткач, беренче булып, әмир Ибраһим болытлардан җир өстенә төште:

— Бүген кичкә тагын бер-ике йөз җайдакны юлга әзерлә әле син, Даян сәрдәр. Ашлы каласының тирә-юнен үз куллары-быз белән капшап кайтмый булмас. Караңгы төшүгә үк Идел суын кичеп чыгачакбыз. Ходай язган булса, бәлки, әле урыс ыстаны эченә дә үтеп керә алырбыз. Бер-ике меңбашларын чәлдереп, баскыннарның өнен алсак, ярап торыр иде.

29

Караңгы төн уртасында бугазына килеп терәлгән хәнҗәр салкынлыгын тоеп күзен ачкач, Евсей бояр тынсыз-өнсез калды. Алтынчы дистәсен тутырып килгән чакта беренче мәртәбә Болгар дигән илгә каршы яу сәфәренә ияреп чыкты. Аеры бер биләмә, биштәр-биштәр алтын-зиннәткә өметләнеп ничаклы юл үтте, газап чикте. Дошманнардан бигрәк үзенең туймас тәгамле юлдашларыннан сакланып чатырын

да кала читенә, хәвефсезрәк җиргә корып яткан иде. Әмма һәр бармакка уймак кигән сыман саклану да ярдәм итмәде шул. Төн уртасы узгач, аның чатырына аю шикелле иләмсез гәүдәле шымчы үтеп керде. Җан кыярга килгән Газраилгә тиң мондый катыйль нигә дип нәкъ менә Евсей боярны сайлаган соң?

— Шыбырдама, бояр! — дип телгә килде аның күкрәген тезләре белән сытып баскан карачкы иясе. Әллә узган юлы кайнар булып чыккан, әллә дулкынлана бу — моның тавышы гыж-гыж килә иде. Барыбер дәвам итте: — Син мине беләсең, минем кул ялгышмый. Тын чыгарсаң, шундук суеп атам. Ләкин ипле генә килешү икебезгә дә файда. Давай, акыллы бул.

— Әт... тәч! — диде тик бераздан гына Евсей бояр. — Даян? Даян түгелме соң? Каян килеп, ничек? Мин сине моннан ун-унбиш еллар элек үк югалттым ла инде.

Даян Евсей боярның күкрәгеннән төште, әмма утын әрдәнәсе чаклы зур хәнҗәре әле һаман ялык-йолык килеп ялтырап тора иде.

— Бөтен тирә-юньдә аяклы колак йөри, ипләп кенә сөйләш, — дип кисәтте Даян. — Әйе, сине ташлап кайтканыма ун ел чамасы гомер үтеп китте. Сезнең Киев каласында яшәсәм дә, болгарлы идем бит мин. Үз илемә чакырып кайтардылар. Хәзер вәзир. Ханның уң кулымын.

Евсей үз колакларына үзе ышанмыйча күтәрелә төште. Ирен кыймылдатып әйткән ике-өч сүзе генә ишетелеп калды:

— Кит, әкәмәт, булмас. Кит, әкәмәт.

Даян исә җеген-җеккә китереп сөйләвен генә белде:

— Илнең иминлеге өчен ханнан кала, иң беренче чиратта, мин җаваплы. Святослав безнең гаскәрне тар-мар итә, калаларны талап чыга икән, минем урын дарда. Ярар, минем гомер алай тау-тау алтын бәһасе тора торган бик зур байлык түгел. Хәер, синеке дә. Яу башланса исән чыгасыңмы әле син, ятып каласыңмы — гүпче билгесез бит. Ә исән калырга да, баеп кайтырга да форсат җитәрлек ул. Ил вәзире булган танышларың синең сукмагыңда гел-гел очрап тормас. Менә моның кебек малга риза буласың икән, уртак сүзгә юлны эзләп була.

Даян өстенә киеп килгән кап-кара чикмән астыннан киң каеш суырып чыгарды. Чатырның ярым ачык торган ишегеннән төшкән яктылык та җитәрлек, каешның саф алтыннан коелган аелы ялт-йолт уйнап күзне камаштыра иде. Җитмәсә, Даян каешның эчке якка яшерелгән унлап кесәнең берсен генә ачып җибәрүе булды, аннан җир өстенә салган киезгә дистәләгән алтын тәңкә чылтырап килеп төште. Юк, кызыкмаслык түгел иде бу зиннәтләр. Евсей боярның күзләренә шундук шайтан уты кунды, кулын бизгәк тотты.

— Миңа нинди әмер җиткерәсең? Бурычым нидә? — дип сорады ул, кайнар чәй эчеп авызы пешкән кешедәй хапхоп һава сулап. Аннары «тартып ала күрмә» дигән сыман киң каешны бер мизгел эчендә тезләре астына яшереп тә куйды.

Даян хәзер инде дөя сыртында утырган килеш кенә хезмәтчесенә аяк юарга боерган кәрванбаш тавышы белән Евсей колагына таләпләрен тезде:

— Кенәз Святослав хозурына бар да колагына тукы. Бу — аның Идел буена төбәп оештырган беренче яу сәфәре. Җиңелә калса, болгар гына түгел, мукшы, чирмеш, башкорт, вотяк халыклары, Ростов кенәзләре алдында да гомер буе юып булмас хурлык. Иртә уңмаган кич уңмас, ди, алдагы яулары да хуш буламы әле? Шушыларны уйласын-үлчәсен дә Биләр өстенә барып маташмасын. Җир йөзендә Святослав кылыч күтәрергә бурычлы, ул үч алырга тиеш хакимнәр бар. Әнә хәзәр каганы Йосыфка сезнең вятич кабиләсе дә, Ростов, Смоленск кенәзләре дә дистә еллар буе ясак түли, каган хәрамханәсенә иң сылу кызларны озатып ята. Без дә каганның олтаны астыннан котыла алмый иза чигәбез. Сөяк бүлә алмаган сукбай этләр сыман талашканчы, Святослав белән Мөхәммәткә үз сыртларыннан Йосыф каганны чәнчелдереп төшерү — дан. Менә шушы җырны җырла кенәз колагына, шундый юлга күндер.

Евсей боярның юл чатында хәер сорашып утырган дәрвишнеке кебек талымлы һәм ач карашын күргәч, Даян үзенең кашларына хәтле төшереп кигән кара башлыгын салып ташлады. Чүпрәк астында саф алтыннан койган очлым ялтырап китте.

— Бу хан бүләге түгел, минем очлым гына, — дип аңлатты Даян. — Кенәз күнә икән, хан да әҗерле булып калмас калуын. Ә җавап хәбәрең әзер була калса, менә сиңа бәләкәй көмеш аел. Моны күрсәтсәң, юлдагы һәр болгарлы минем чатырыма чаклы озатачак сине. Шүрли күрмә, сиңа тырнак очы белән дә кагылучы булмас.

Тулган айдай балкый башлаган Евсей, кулын күкрәгенә куя-куя, ант сулары эчәргә тотынды:

— Син теге чакта, урыс җирен Әкбәр уйнашчыдан азат иткән чакта, минем гозеремне аяк астына салып таптамадың. Шуннан бирле синең каршыңда бурычлы йөри идем. Моннан ары бер сүзеңнән чыкмам. Миңа ышан.

Боярның тавышы әллә нишләп шундук ясалма һәм төче булып ишетелде Даянга. Шуңадырмы, чатыр ишегенә кулын сузган чакта, кире борылып ирен арасыннан ысылдарга барыбер онытмады:

— Кенәзеңне кисәт. Башны култык астына кыстырып кайтуга караганда, алтын очлым киеп китү күпкә шөһрәтлерәк.

30

Икенче көнне Кашкатау буена урыс ыстанынннан чапкын килеп җитте. Даян шундук тойды: егерме җиде яшьлек Святослав үзен күрше ихата тавыклары янына барып кергән әтәч урынына бик тәкәббер тота һәм тез чүгәргә исәпләми иде.

— Кичә алтын очлым бирепи-их, сантыйга калдым! — дип сүгенде Даян, әле чапкын янына каршы чыкканчы ук. — Бездә сәрдәр дә менә шундый алтын очлым кия, дип, сандык капкачын ачып салдым бугай. Хәзер баскын кенәз базар халкы сыман сатулашып, үз бәһасен арттыру ягын гына карап торыр инде.

— Кенәз язмышны сынап карамакчы була, — дип белдерде чапкын. — Ул Ашлы каласы белән ике арадагы кырда батырлар алышы үткәрүне таләп итеп куя.

Батырлар алышы үткәрү — Болгар иле өчен аяз көнне уйнаган яшен шикелле кыргый күренеш түгел. Монда бишектән сикереп төшкән һәрбер бала-чага сабан туе саен, бәйрәм саен бил алышулар, аркан тартыш, ат чабышы, мәргәннәр бәйгесе сыман ярыш күреп үсә. Чапкын каршына да, сафны бозып, уннан артык җайдак чәчрәп чыкты.

— Һи-и, аңа гына калса, үткәрәбез аны!

— Ярар, алышабыз, батырыгыз чыксын!

Урыс чапкыны каршына Даян сәрдәр чыгып баскач кына артка чигенделәр. Даян карашы белән үтәли көйдерерлек итеп текәлде. Тешләрен усал шыгырдатып сорау бирде:

— Кенәз эргәсендә Евсей бояр бар идеме, юкмы?

— Янында торып калды.

— Димәк, синең кулга көмеш аел эләкмәгән инде?

Чапкынның шайтан биетүне күргән сыман авыз ачып утыруын күргәч, янә тешләрен кыса-кыса сүгенергә булды:

— Вәт, туймас тамак! Вәт, имгәк җан!

Аннары гына үзенең ил-яу өчен җаваплы сәрдәр булуын исенә төшерде, ахры, тыныч кыяфәткә кереп аваз салды:

— Алышның шарты бармы? Батырлар нинди корал белән сугышачак, дип әйтүем.

— Юк, бернинди дә таләп куймадылар. Алыш алыш инде. Кем ничек булдыра, ничек җиңә ала — анысы батырларның үз карамагында.

— Аңлашылды, — диде Даян сәрдәр. — Хәрамнәрсез генә алышсыннар иде…

Урыс чапкыны Ашлы кала ягына китеп барды. Берәр сәгатьтән соң дошман гаскәре шәһәр капкасыннан ургылып чыкты да тере дивар булып тезелеп басты. Даян сәрдәр белән Ибраһим икесе дә кызу-кызу күз йөгертеп чыкты. Ун мең чамасы ир-ат кына монда. Ярты гаскәр Ашлы эчендә

калган. Димәк, болгарларның андый-мондый этлек эшләвеннән бик нык шүрли болар.

Урыс төмәненең бер канатында көбә-очлым урынына кайры тун һәм арткы як итәге муенга асылынган тирән бүрек кигән, беләкләренә сагыз кушып катырылган күн калканнар элгән ике мең чамасы җайдакның аерымрак оешып басуын шәйләгәч, Даян үз күзләренә үзе ышанмыйча башын чайкап куйды.

— Әмир, әмир! — дип, тиз-тиз эндәште ул, шөбһә-хәвеф белән. — Әнә теге, бер як читтәрәк аерылып торган нөгәрне күрәсеңме? Бәҗәнәкләр бит болар, валлаһи, бәҗәнәкләр!

Ибраһим да теше сызлаган сырхау шикелле йөзен чытты.

— Менә монысы инде бик яман фал, Даян, — диде ул да әрнеп. — Башка халыкларны болай итеп үз кубызына биетә башласа яисә сатып алса, урыс кенәзләре безне дә берзаманны аяк астына бөкләп салачак бит…

Даян белән Ибраһимга иярәп Иделнең уңъягына йөзеп чыккан ирләр саны бер меңгә дә тулып җитми иде. Шуңа күрә, сәрдәр әмере буенча, сулъяк ярда калган барча җайдак Баллы Арка өстенә тезелешеп басты. Уңдагылар Кашкатауның бар итәген каплап таралдылар. Янәсе, менә күр, бәһалә, баскын кенәз, синең безне җиңәрдәй-тузгытырдай көч-куәтең бармы? Тик онытма, биредә сәрдәр генә. Ханның кул астында син күрмәгән-белмәгән тагын бер чирү яугирләр сакта тора әле!..

Иңгә-иң торып баскан урыс сафы арасыннан чем-кара айгырга атланган җайдак аерылып чыкты. Болгарлар күз белән ашардай булып аңа текәлделәр. Аты гаярь. Күкрәк тирәсе дә, ботлары да баудан ишкән сыман. Сагыздай чем-кара ялы-койрыклары кояш яктысында ялт-йолт килеп тора. Маңгаенда ап-ак йолдызы бар. Бәкәлләре дә тоташ актан. Тояклары нәни чүлмәк кебек. Айгыр аз гына кымшанса да, тирә-якка белен кадәр чирәм кубып оча.

Җайдак үзе карап торышка әле яшь күренә. Башына тимердән чүкеп ясаган олы очлым кигән. Салам кебек сап-сары чәчләре эскәк белән кыздыргандай бөдрәләнеп тора. Сирәк-мирәк үскән сакал-мыегы да сары. Йөзен күгәрчен күкәе белән рәттән куярлык бар, аны эреле-ваклы тәкәрлек басып киткән. Олы гаскәр исеменнән алышка үзен чыгаруга сөенәдер инде, сап-сары мыегы астында шундый ук сап-сары тешләре ялтырап күренеп тора. Бер карасаң, ул өеннән, әнисеннән качып уенга гына чыккан бала-чагадан әллә ни кайтыш түгел. Әле ярый, тимер тәңкәләрдән ясалган озын көбә өстеннән иңнәренә кызыл җәймә япкан. Шул җәймә генә аның кыяфәтенә җитдилек һәм мәһабәтлек өсти…

Даян сәрдәр Кашкатау итәгенә тезелеп баскан болгарлар өстенә караш ташлап алды. Әнә кылычын кыныннан суы-

рып чыгарган көе Ибраһим урынында алгысынып тора. Аның артына Кашан бәге Габделвәһап баскан. Алардан арырак — болгарларны тәүге булып дошманның борын төбенә, Кашкатауга алып чыккан Байдар. Янәшәдә — Даян сәрдәрнең үз малае Насыйр. Тагын дистәләгән гаярь ир-егетләр. Һәркайсы да үгез хәтле үгезне бер сугуда аяктан егардай гайрәтлеләр. Әмма... Болгарның йөз аклыгын саклап калуны кайсы пәһлеванга гына тапшырырга соң? Кем сынатмас? Илне тоташ кан коюдан, кара яу михнәтеннән кем коткарыр?..

Ибраһимның аргамагы алга сикереп чыкты.

— Үзем орышам! Минем атайны аның улыннан да алда кем якласын?

— Артка чиген, әмир! — дип, үзен-үзе белештерми кычкырып җибәрде Даян. — Бәйләп салган малны чалып ташлау берни тормый. Атаң илә син дә харап булсаң, без бәйләп ташланган бичара мал хәленә калачакбыз. Аннары болгарлар кайсы таждар өчен генә яуга керер икән?

Сафлар арасыннан авыр чукмарын чөеп уйный-уйный, Байдар калкып чыкты:

— Мин Иделне беренче кичеп чыктым. Син нәүбәтне болай итеп бозма әле, әмир. Кемгә орыш язган тәкъдирендә, кемгә тәхет. Мин бит синең тәхетеңә бер дә борын тыкмыйм. Син дә орыш-алышларга, әйдә, борын тыкма.

Байдар бәхәсләшергә урын калдырмастан урыс сафына таба юырттырып китте. Ирләр күзәтеп калды. Аты Алмачуар ерак юлда йөреп гадәтләнгән. Моның берчакта да хуҗа-җайдакны ташлап качасы юк. Байдар үзе дә, күз тимәсен, аргамак өстенә коеп куйган кебек. Иңбашлары кибән өярдәй таза. Муены симертелгән үгезнеке сыман. Куллары имән кәүсәләре, йодрыклары бәләкәй чүлмәк чаклы. Мондый пәһлеванны кемнәр генә җиңә алсын инде? Чукмарының җиле тиеп китсә дә, теләсә кайсы ирне карачкы урынына тетеп ата бит бу!..

Җайдаклар анда-санда колмак белән әрем сибелеп үскән киң яланның калкурак урынына җиткәч тукталдылар. Ике җайдак, тынмас дошман булып, бер-берсенә каршы килеп бастылар. Икесе дә ике якка күз йөгертеп көчләр тикшерделәр. Әнә урыс гаскәренең уртасына кып-кызыл япмага төренгән кенәз чыгып баскан. Сәер, моның аргамак өстенә ябылган җәймәсе дә кызыл, очы өскә бөгелгән итекләре дә шундый. Әйтерсең лә ул гаскәр уртасында канга сусаган, канга баткан сөзгәк үгез сыман. Янында яраннары. Әллә кемнәр түгел. Иле белән халкы читкә типкән сатлык Нуретдин. Карашында ачлык, нәфесе уты сүнә белмәс Евсей. Кәләш сорап килгәч кулларына черек кавын чыгарып тоттырылган кияүләр шикелле каушап калган меңбашлары, бояр, пәһлеваннар.

Болгарлар ягында да башын горур тоткан ирләр әллә ни күп түгел. Әмир Ибраһим ияре өстенә кылыч салган булган, ләкин өзәңгеләренә хәтле дер-дер килә. Байдар белеп тора, яуга, орышка атлыгудан туган шаукым тәэсире бу. Даян сәрдәр дә эче тулы ут булганга күрә бер урында басып тора алмый, елан куган сыман әрле-бирле йөри. Калган меңбашлар да бер-берсенә туры карамыйлар. Болар да хәвефле. Һәммәсе дә алыш-орышның нәтиҗәсен көтә.

Ниһаять, батырларга бер-берсен сынарга да чират килеп җитте. Урыс баһадиры кулына тәртә чаклы юан сөңге тоткан, билендә кылычы, хәнҗәре бар. Байдарның да бил каешында кылыч, ә кулында үгез боты хәтле олы чукмар. Аргамаклар алда ни көткәнен сизенәләр бугай, борын тишекләре дөянеке сыман киерелгән, кайнар сулыш бәрә.

— Алеша, Алеша! Алга ыргыл, алга! Бүкән сыман бәреп төшер болгар карачкысын! — дип, урыс баһадирын дәртләндереп кычкырган сүзләр ишетелде.

Болгарлар да бурычлы калмадылар. Ялан өстен күк күкрәгәндәй тавыш каплап китте.

— Урыс аламасын кавын сыман тетеп ташла, Байдар! Үләксәсен дә таба алмасыннар!..

Ике баһадир да айгырларның касыгына типте. Бер мизгел эчендә ялан өстендә явыз туфан, гарасат үзе купкан сыман булды. Атлар сөлек кебек сузылып капма-каршы оча. Яллары тузгыган, койрыклары кипкән камыш себеркесе төсле тармакланган. Борын тишекләре дәү ирләрнең йодрыклары сыйрдай булып киерелгән. Икесенең дә тояк астыннан бияләй-бияләй чирәм чәчрәп оча.

Байдар әле бер дилбегә кадәр ара калганда ук күрде: урыс пәһлеваны сөңгесен дошман айгырының күкрәгенә төбәп килә иде. Аһ, мәкерле! Ул Байдарны атсыз калдырмакчы, ялан буенча куып йөртеп, көтүдән аерылган бәрән урынына изеп таптамакчы! Акылың кот икән, таптамый тор әле!

Байдар йөгәнне кисәк каерып аргамагын читкә тайпылдырды, үзе ул арада дошманының сөңгесенә олы чукмар белән орып узды. Ару эләкте бугай, Алешаның сөңгесе кызыл балчык өстенә чәчрәп очты, егет кырт тукталды. Байдар аргамагын кире боргач кына үкереп аваз салды:

— Ат хәтле атка кул күтәрәсеңмени, имансыз җан? Мин сине моның өчен эт урынына тотып ярмасаммы?!

Алеша сөңгесен кабат кулына эләктергән иде инде, ярсый-ярсый янә Байдар өстенә очты. Ләкин никтер ул сөңгесен сул кулына күчергән, ә уң кулының учын нәни кошчык тоткан сыман бик сак кына йомарлап килә иде. Урыс баһадирының нинди этлек әзерләп өлгергүен Байдар тоймады да. Ике аргамак бергә тигезләнүгә үк Байдарның йөзенә

соскыдан сибелгәндәй бер уч ком килеп бәрелде. Пәһлеванның ике күзе дә шундук томаланды, кулыннан чукмары төшеп кала язды.

Байдар кул аркасы белән күзләрен ышкыган чакта, янда янә дошман аргамагының тояк тавышлары ишетелде. Байдар башын селки-селки күзен ачты. Бөтен дөнья куе томан, кара төтен эченә кереп чумган кебек. Шулай да әнә ниндидер тау килә аның каршына, зур карачкы килә. Байдар чукмарын югары күтәрде, аңа бәрелеп корыч кылыч тавышы даң-доң килде. Көндәшен чукырга ябырылган әтәч сыман кыйлана бит урыс, зәһәр кылыч тавышы һаман тына белми.

Ниһаять, аерылдылар. Урыс чирүе ягыннан эт өстергән сыман тавыш килә:

— Алеша, кылыч белән тура, кылыч белән!

— Алеша, сөңгең белән болгар карачкысын урталай яр!

Байдар әле алышка керешкәнче үк сайлаган калку урынга янә барып басты. Әнә мәкерле урыс та яңа һөҗүмгә әзерләнеп тора. Ләкин аны юньләп күреп булмый. Ике яңак буйлап та яшь тәгәри, бөтен ялан көймә өстенә сузып салган сыман чайкала. Ничек кенә, нинди генә чара табасы соң?

Байдар сул иңбашын каплап япкан җиз калканны җиргә тотып атты. Авырлыгын янә үлчәгән төсле кулындагы чукмарны кат-кат сикертте дә, котырынып-ярсып, анысын да читкә болгап атты. Юньләп күреп булмый. Дошманны бер сугуда йә имгәтергә, йә бетерергә кирәк. Байдарның кулы ялгышса, бу мизгелдә Алешаның аны урталай өзүе бар. Ул чагында хурлык. Ул очракта җиңелү. Илне тоташ талап чыга алмасалар да, урыс гаскәре барыбер ясак таләп итәчәк, ир-егетләргә, хатын-кызларга коллык янавы бар. Юк, ярамый! Дошманыңның бугазын чәйнәп булса да өз, әмма җиңелә күрмә! Өеңдә газиз улың Сал-Сал да бар бит әле. Ул синең җиңелү хурлыгыңны ничек күтәреп яшәр?..

Байдар ияр артына тагылган бер аршын озынлыгы гына сөңгесен сөйрәп чыгарды да, аның ыргаклы ягын дошманына төбәп, калкулыктан түбән томырылды. Ун дилбегә озынлыгы ара калып бара, биш дилбегә, ике…

Менә аргамаклар күкрәкләре белән бәрелеп үрә торды. Ике кыя бер-берсенә бәрелеп чәкәштеләр диярсең, ике якта ике гаскәр гү-шау килеп купты. Ике аргамак өстеннән дә ялан чирәменә ике пәһлеван мамык сыман очып килеп төште. Ә аннары яшүсмер Алеша җир өстеннән иң беренче булып сикереп кузгалды да көрәк йөзедәй киң, иләмсез кылычын бауга чорналган шикелле кымшана алмый яткан Байдар пәһлеванның бугазына тыкты. Канга баткан Байдар авызыннан тик бер генә сүз сытылып чыкты:

— Сал-Сал…

Святослав өчен күк капусы ачылгандай булды.

— Безнең батыр җиңде, Алеша өстен чыкты! Мәрхәбә, мәрхәбә! — дип ярсып кычкырды ул, иңнәренә канат үскән сыман. — Без изге юлда, сугыш алласы безнең эшне хуплый!

Урыс гаскәре инде болай да чик-чаманы белмәгән кыргыйлар төркеме урынына тантана итә, шашына, котырына иде. Берәүләр очлымнарын салып күккә чөя, икенчеләре кылычсөңгеләрен калкан йөзенә бәрә-бәрә дөңгерди. Тилебәрән орлыгы ашаган сыман һәммәсенең күзе акаеп чыккан, авызларын бүрек йотардай ачып үкерәләр:

— Безнең батыр җиңде! Алеша, Алеша!

— Болгарларны турап бетерәбез!

— Боларны шәрә калдырганчы таламыйча торып, кире борылмыйбыз!

Бер-берсен ишетүче, берни аңлаучы юк. Үзара кочаклаша-кочаклаша бииләр, сикерәләр.

Святослав үзенең фәрманын көч-хәл белән генә ишеттерә алды:

— Алга, болгарлар өстенә! Миңа Мөхәммәт ханны тотып китерегез!

Ашлы диварлары тышында торган ун мең кешелек урыс гаскәре бер мең болгар яугире өстенә ябырылды. Тоташ ташкын булып купкан дошманны күрүгә үк әмир Ибраһим белән Даян сәрдәрнең кабаланып кычкырган әмерләре яңгырап узды:

— Кашкатауга, Кашкатау өстенә чигенегез!

— Дошман Иделгә юлны бикли алмасын, ике як итәккә ике чылбыр булып тезелегез!

Даян белән Байдар инде әллә кайчан үк Иделнең бу як ярына йөзгә якын арба чыгарып куйган икән. Күз ачып йомган арада әнә шул арбалар артына кереп яшереналәр. Һәммә арбалар да янга яткырылды, өсләренә киез ыргыттылар. Урысларның беренче сафы кул сузымы арага якынайгач, ыстаннар артыннан аларның өстенә үк яңгыры очты. Беренче рәт чалгы белән чабып ташланган шикелле кырылып ауды, икенчеләре кыяга килеп төртелгәндәй капылт туктадылар.

— Алга, алга! — дип кычкырды котырынган кенәз. — Алар биш-алты йөз генә бит, кырып бетерегез!

Урыс белән бәҗәнәк сугышчылары берсен-берсе таптый, изә-изә, өр-яңадан алга томырылды. Күбесенең кыяфәтләре үк өн алырлык иде. Атналар-айлар буе җылы су күрмәгән сакаллары себеркегә охшаш. Кайсыларының киндердән суккан ыштан балаклары эт талаган кебек сипелеп беткән, чабаталары тишек, кайсылары бөтенләй яланаяк. Ярты гаскәр-

нең кулында сөңге-кылыч, калганында тәртә озынлыгындагы ике япьле сәнәк, йә булмаса чалгы.

Арбалар ышыгында яткан бер мең болгар ире ук яңгыры очырып та, кылыч болгап та каршы торып карады. Егылганнар урынына яңалары басып, чылбырдагы өзеклекләрне ялгарга тырыштылар. Артка чигенүче яки яу кырын ташлап качучы җебегән күренмәде. Ләкин урыслар күп, бәҗәнәкләр дә шулар арасында. Алар тау башыннан ычкынган таш өермәсен хәтерләтеп, юлда очраган бар нәрсәне сытып килә иде. Берзаманны алар тау итәген каплап яткан ике чылбырны да өзеп-йолкып узды. Әле аягүрә калган болгарлар да, яралылар да яубашлары ягына борылып кычкырдылар:

— Без боларны тыеп торачакбыз. Син кач, әмир, син кач!

— Сәрдәр, сәрдәр! Идел аръягына качып котылыгыз!

Тагын бер талпынса, урыс явы болгарларны тетеп атачак иде. Монысы көн кебек ачык. Ниһаять, Даян сәрдәрнең карары ишетелде:

— Булды, бетте. Каекка сикер, әмир!

Ибраһим әле һаман кулына кылыч тоткан көе дошман сафларын каршыларга әзер тора иде. Аның кымшанмыйча басып калуын күргәч, Даян инде ярсый-ярсый килеп ябышты:

— Безгә синең Тимер-Мөэмин борадәрең шикелле ханнар кирәк түгел. Синең хакың безнең өчен Тәңре хакына тиң. Чиген, әмир!

Яу кырына соңгы тапкыр караш ташлады да Ибраһим җиңел каек эченә сикереп керде. Шул мизгелдә үк ике ир Идел уртасына төбәп ишкәк ишәргә тотынды. Бау белән тагылган шикелле, аларга Даян сәрдәр каегы ияреп чыкты.

Бераздан Кашкатау өстендә орыш-алыш тавышлары тынды. Урыс яугирләре арбаларны әйләндереп-җимереп болгар ыстанын айкап карадылар да, эскәк очына каптырырдай да ганимәт-зиннәт таба алмагач, кенәз ягына борылып үкерделәр:

— Без ни хакына дип кенә кан койдык соң? Монда пычак та юк.

— Байлык Иделнең теге як ярында. Болгарларның чын лагере шунда, — дип кычкырды Святослав, кылычы белән каршы якка төбәп. — Идел суын йөзеп чыгабыз да Болгар илен талап бетерәбез!

Яңа кан һәм тәүге җиңү күреп, урыс ирләре дә, бәҗәнәк җайдаклары да шашкан иде инде. Меңбашлары тарафыннан әмер ишетелүгә үк, йөзәрләгән ирләр суга сикерделәр. Кемдер арба, бүрәнә, каек калдыкларына ышыкланып акты, кемдер көбәсен, коралларын салмый гына йөзде. Идел уртасындагы чоңгыллар эченә җитүгә, дистәләгән ирләр үлем җәтмәсеннән котыла алмыйча, су төбенә китеп югалдылар. Исән калганнар дәһшәтләнеп-шашып сулъяк ярга чыкты.

Урысларга чит-ят ярда сафларга, чылбырларга тезелеп торырга ирек бирмәделәр. Баллы Арка өстеннән аларга әүвәл ук яңгыры яуды, аннары җайдаклар төркеме айкап-турап узды. Ике меңгә якын юлдашларын югалтуга ук, исән калганнары кабат Идел суына чумды. Яралылар, чукмар йөзе күреп миңгерәгәннәр янә чоңгыл төбенә китеп югалдылар. Ашлы кирмәне ягына йөзеп чыга алганнар, ярга баскач, Святослав йөзенә текәлеп сүгенделәр:

— Ни пычагыма дип син безне үлем авызына алып килдең?

— Кырык дала аръягындагы Болгарга килеп әрәм булганчы, борын төбендәге Галич, Волынь кенәзлекләре юк идеме әллә?

— Шушы кадәр ерак җиргә килеп, сыңар алтын кисәге дә таба алмыйча, буш кайтабызмыни?!

Кара янып чыккан Святослав кенәз айгыр касыгына тибә-тибә җавап тотты:

— Юк, кире чигенү юк! Болгарлар барыбер безгә каршы торырдай гаскәр туплый алмый. Бәнҗәгә таба күчеп Иделне кичәбез дә Жүкәтауларын, Биләрләрен талап мал җыябыз. Яңа сәфәргә, яңа яуга җыеныгыз, руслар! Зиннәт һәм дан безне алда көтә!..

32

Мәгърур Иделнең ике як яры да күкрәп-яшьнәп, дөбердәп килгәннән соң яңгыр тамчыларын көтеп җиткермичә алданган җиһан сыман булды. Әйтерсең лә ике гаскәрнең дә очып китәр канатлары сынды.

Урыс ыстанында тыныч лык юк, күмәк аптыраш, хәвеф, тәшвиш хөкем сөрә. Пәһлеваннар орышында Алеша җиңеп чыккач, алар әүвәл күк күкрәвенә тиң тавышлар куптарганнар, шашып сикерә-сикерә тантана иткәннәр, кылычсөңгеләрен, калкан-очлымнарын болгый-болгый Святослав кенәзне күмәк яуга әйдәп масайганнар иде. Кашкатау буендагы ансат җиңүдән соң да, ай-яй, очындылар. Ләкин Идел аръягындагы Баллы Арка янында утта янгач, кикрикләре шиңде. Җен башка, пәри башка дигәндәй, дошманны тыеп үз ояңда сугышу белән үзең дошман өстенә ташлану, һөҗүм ясау җир белән күк аермасы икән шул ул. Ә бөтенләй чит-ят булган Болгар җирендәге яуларны, сәфәрләрне дәвам итсәң, син бу илдән исән-имин кайтып китә алырсыңмы, әллә инешләр, сазлыклар эчендә ятып калырсыңмы? Өстәвенә болгарлар әле һаман, мөгаен дә, барча гаскәрне дә күрсәтеп бетермидер. Алар үз илендә.

Алар сафына сәгать саен яңа нөгәр, яңа алайлар өстәлеп торуы бар.

Святослав кенәз капкын авызына килеп басканмыни, һични кыла йә кузгала алмый. Зиһенендә умарта күче шикелле мең төрле уй.

Болгар өстенә килгәч, ул аю өненә башын тыккан мескен аучы хәленә калды бугай. Ни Киев ягыннан өстәмә гаскәр көтәрдәй бер әмәл юк, ни Болгар аюы якасыннан тоткан көе һич җибәрми аны. Коллар һәм ганимәт хакына ялланган бәҗәнәкләр дә язгы боз шикелле ышанычсыз. Аларның теләсә кайсы минутта урысларны ташлап китүе, йә булмаса, дошман ягына качып чыгуы бар. Ә нинди дә булса катгый карарга килми мөмкин түгел, түгел! Бу — Святославның беренче яу сәфәре, җиңелеп йә ташлап кача икән, моннан ары сукбай эт тә ияреп чыкмаячак аңа. Яусыз китү хурлык. Ни кылырга хәзер?

Уйлар арба тәгәрмәче шикелле әйләнә-әйләнә дә, һаман бер үк эзгә кайтып төшә. Моннан койрыгы ялкынга өтелгән мескен бүре кебек тавыш-тынсыз гына чыгып качам дисәң, Болгар ханы исән-имин җибәрәме сине? Ай-һай, дошманың хакында бик тә беркатлы һәм мокыт уйлый торган сантый булма алай! Капкындагы Святославны тотып тунамаска ул җүләрме әллә? Әле Киев ягына таба чигенсәң дә, Мөхәммәтнең сине юл буена шөпшә күче сыман талый-талый озатуы мөмкин. Үтерүен дә үтермәс ул, бәлки, иллә мәгәр калҗакалҗа итеп умыра-умыра шыр сөяккә калдырыр, җелегеңә үтәр. Ә кысыр сарык хәлендә кайтып егылган мескенне Киевта кем жәлләсен? Анда әнә Рюрик нәселеннән булган Мстислав, Олеглар бар. Җиңелеп кайттыңмы, ат караучы кол урыны сиңа! Сау бул, тәхет!..

Святослав Ашлыдагы әмир Сәлман йортына кереп оялаган иде. Батырлар алышыннан әйләнеп кайтканнан бирле күрше капка төбендә Евсей бояр белән сатлык Болгар эте Нуретдин дә, тагын бер-ике меңбашы бөтерелеп йөрде. Болар инде «жиңү» юарга керешкәннәр бугай, төсле керәч корган тәрәзәләр аша һаман саен көчәя генә барган кычкырышкөлеш авазлары яңгырап ишетелә. Святослав түзми йөзен чытты. Әллә бөтен каласына ут элдереп ычкынырга инде? Янгын мәхшәрендә, ичмаса, исән-имин качып булмас микән? Ә бу Евсей ише, Нуретдин ише этләр ник кадалып китми, аларга төкерәсе!..

Болгарлар ыстанында да тынлык хөкем сөрә. Чатырлар-тирмәләр янында да, юлларда да һичбер хәрәкәт юк. Яугирләр дә, яубашлары да үләт афәтеннән качып, үз почмакларына кереп сыенганнар. Һәрбер ирне үзенчә уй, үзенчә шеш талый.

Байдар пәһлеван орышта оттырды, әрәм булды. Бик яман фал иде бу. Ходай Тәгалә ярлыкамый безне дигән кайгы басып китте. Болгарлар яңа бәрелешләрдә дә җиңелү һәм хурлык көтә иде. Кашкатау өстендә тар-мар ителгәч, тагын өшәнделәр. Димәк, Ходай Тәгаләнең бездән борылуы рас икән бит. Димәк, безне янә коллык, янә хурлык көтеп торуы бар. Ходайның рәхмәте, әле ярый, дошман гаскәренә Иделнең сулъяк ярына күчәргә ирек бирмәделәр. Дошман, меңәрләгән ирләрен калдырып, кабат иске оясына кереп бикләнергә мәҗбүр булды. Ләкин сугыш төгәлләнде, дошман безне ташлап качачак дип тынычланырга, шатланырга, ай-һай, иртә әле. Шымчылар кайтып әйтте, урыслар Бәнҗәгә таба яңа күчеш ясарга әзерләнә, диләр. Аларны туктатырдай көч-куәт юк. Тимер-Мөэмин белән Габбас әмирләрнең чирүе һич күренми. Өстәмә гаскәрләргә өмет тотып булмый. Күмәк орышлардан, бу сазлыктан ничек кенә исән чыгарга соң? Урыс гаскәре белән яңа бәрелештән ничек котылырга?

Ибраһим әмир читлеккә ябылган җанвар шикелле тызбыз бәргәләнә. Телендә гел бер үк төрле зар, бер үк кайгы:

— Аһ, әрәм булды бу Байдар дигән батыр, аһ, сынатты! Шуның аркасында гына Кашкатау өстеннән тар-мар ителеп качтык. Безнең язмыш һаман кыл өстендә. Ул баскын кенәз ачудан Ашлыга ут төртеп китмәсә генә ярар иде!..

Түзем канатының каурыйлары тәмам коелып беткәч, Даян сәрдәр дә, чатыр почмагыннан кузгалып, җитди аваз салды:

— Ярар, алма пеш, авызга төш, дип көтеп ятып булмас. Көн кичке якка авышты, бүген яңа һөҗүм белән килмәячәк болар. Аларның яртысы хәзер җиңелү кайгысын хәмер мичкәсенә төшеп юа булыр. Ибраһим әмир юраган шикелле, боларның Ашлы каласына ут ташлавы мөмкин. Каланы әрәм итмик, аны без төзисе. Иң яхшысы, әйдә, бал белән ширбәт төйик тә үзебез кенәз янына кунак булып барыйк.

— Ни сөйлисең, сәрдәр? Нинди кунак тагын? — дип, әмир Ибраһим изүенә килеп ябышса да, Даян вәзир һич тә каушамады. Кысла сыман артка шуышыпмы, елан шикелле тартылып-сузылыпмы — моңа фәкать алга бару булсын.

— Син урысларның күңелләрен аңлап кына бетермисең, әмир. Ә мин ун ел буе алар арасында яшәп кайткан кеше, байтак гадәтләрен яттан беләм. Күңелләре яраланган чакта да, шатлык барында да күкрәкләрен сабый бала имезгән ана төсле ачып куя алар. Ә инде берәр тустаган да кабып алдылармы, ул чагында туарылып елый башларга да бик күп сорамыйлар. Мондый чакта авырткан сөякләренә һәм мин-минлекләренә генә кагылырга ярамый

аларның. Киресенчә, аларны үсендерергә, күңелләрен күтәрергә кирәк. Шулай итсәң, урыс иртәгә үз дошманы белән дә килен төшерешә ул.

Ибраһим көпә-көндез яңа ай күргәндәй аптырап уйга калды. Әле Даянның күзләренә килеп текәлде ул, әле баш чайкады. Элек шымчы булган, аннары вәзир хәтле вәзиргә әверелгән Даян, кара, ни өйрәтә?! Сыный гынамы соң бу, чынлап сөйләвеме?

— Кунакка барып керсәк, тотып та суймыйлармы? — дип, түзмичә, янә очып килеп җитте Ибраһим берзаманны.

Даян элеккечә суза-суза тәкрарлавын белде:

— Суй-мый-лар, валлаһи, суймыйлар, дим. Алар хәзер үзләре үк ни кылырга белми. Кашкатауда бер меңболгар ирен кырып бетерсәләр дә, Иделнең бу ягында алар икеләтә-өчләтә корбан бирде. Болгар уртасына килеп кергән көе алар бүген тоташ камалышта утыра. Яңа һөҗүм, яңа яу башларга куәтләре, дәрманнары бетте. Алар хәзер мәкер-хыянәттән, безнең көтелмәгән һөҗүм ясавыбыздан дер калтырап тора. Шуңа күрә хәзер хәмер чөмерә инде алар. Кайгы-шөбһәләрен шулай бушаталар. Мин аларны беләм... Аннан, аннан, туктале син, әмир... Син кунак булып үзең барырга җыенмыйсыңдыр ла инде, туганкаем?

— Ә нигә? Ник бармаска әле? — дип, Ибраһим Даян сәрдәрнең каршысына килде.

Даян әүвәл шайтан кытыклаган кебек кычкырып көлде, аннары каршысында мөгезле кеше күргәндәй тораташтай калды.

— Туктале, туктале син, әмир. Бу бит уен түгел. Урысның аның исерек чакта акылы керәле-чыгалырак. Син хан малае. Исән-имин качып китәр өчен сине аманат итеп алулары мөмкин. Ул чагында нишлим? Әле гел аманат итмәгән очракта да бәла. Минем сине урыс кенәзе янына алып чыгуымны белсә, Мөхәммәт хан мине беренче каен ботагына асып кына куя. Ю-у-ук, Ибраһим, алай шаярмыйк без. Сиңа да гомерең жәл, миңа да жәл.

— Ә мин әмир булып чыкмыйм, — диде Ибраһим берзаманны. — Минем атай да меңбаш булып йөргән бит әле Бәнҗә каласында. Мин дә меңбаш булып барам, йә йөзбашы. Миңа урысның чын йөзен аның ыстанына кереп күрү кыйммәт. Алдагы язмышны кемнәр белгән әле? Тәжрибә бөкре түгел, ул җилкәгә ятмый. Киләчәктә һәр сабакның кирәк булуы бар.

Ниһаять, хәл иттеләр. Ибраһим гап-гади йөзбашы булып киенде, Даян үз урынында, сәрдәр көе калды. Кичке шәфәкъ яктысында ияр өстенә кыю менсәләр дә, ут офыкта түгел, гүя боларның күкрәк читлегендә дөрләп яна иде.

33

— Кунаклар, кунаклар бар! — дигән хәбәрне ишеткәч тә, Святослав кенәз аптырауга төште. Чит-ят мәмләкәттә, чолганыш уртасында нинди кунак тагын? Мескен хәлдә яткан Святослав кемгә кирәккән дә, үз тиңенә санап кайсы бәндә аның янына килергә җөрьәт итте икән?

Святослав болдырга чыгып баскач, авыз ачты да калды. Нинди галәмәт, кайсы әкият бу? Мондый могҗиза Ашлы урамына кай тарафтан иңгән?

Әмир Сәлман йорты каршындагы зур мәйданның һәрбер почмагында вак-вак учак яна. Якынлашып килгән җәйге, җылы төн кала өстенә куе, кара шәлен дә ябып өлгермәгән әле. Әмма кичке эңгер-меңгердә дә мәйдандагы утлар сихри сәйләп сыман чәчелеп җемелдиләр.

Мәйдан читенә ян-яклары аллы-гөлле ефәк һәм бәз тукымалар белән бизәлгән өчме-дүртме бөркәвечле арба кереп баскан. Шуның икесеннән чаң[1], кубыз, сорнай тавышлары яңгырап ишетелә. Ә уртадагы арба япмалары астыннан мәйдан уртасына аккош сыман тезелешкән кызлар чыгып килә. Йә Илаһи Тәңре! Җир йөзендә шушындый да сылу, шушылай да ымсындыргыч кызлар буламыни?!

Егермегә якын кызның һәркайсы да ярым шәрә көе. Сылуларның кайбер төшләрендә генә җептәй нечкә, нәфис каплавыч бар. Аларның камыштай озын һәм зифа аякларын, аккош канатыдай йомшак беләкләрен ялтырап торган ефәк каплап алган. Ләкин ефәк япмаларның һәммәсе дә үтә күренмәле. Ефәк аша сылуларның барча кайнарлыгы, чибәрлеге, даны чәчрәп тора.

Кызлар арбалар арасыннан йөзеп чыгуга ук бар мәйданга таралып бии башладылар. Һәркайсы да чәчләренә калфак кадаганнар, кул очларында беләзек һәм уймак. Җил искәндә җилфердәгән чәчәк тажы сыман аз гына селкенделәр исә дә, уймак-беләзекләр чәлт-челт килеп, чәкчек итеп аваз биреп тора. Боларның хәтта тубыкларында да нәни кыңгырау бар. Аяк баскан саен алар әле көмеш тәңкә сыман зең-зең итеп, әле ярсу чишмә тавышы белән челтерәп тора.

Ә кызларның биюләре инде! Йә Илаһым! Җир йөзендә шушындый гүзәл биюләр дә булса була икән!

Сылулар күзгә күренмәс җеп очына тагып куйган шикелле бөтенесе бергә хәрәкәтләнә. Йомшак мендәрләрен әле бер, әле икенче якка сикертеп котырталар. Болай да менә өзеләм, менә өзеләм дип торган камыштай нечкә билләре ут-

[1] Чәң — кыллы музыка коралы.

лы күмер өстенә эләккән елан тәне сыман боргалана. Өреп кабарткан шикелле тулы күкрәкләре тасма япмалардан сикереп чыгардай булып уйнаклый, бөтерелә. Әй, ул сирәкмирәк кенә ялтырап киткән сихри чиякәйләр! Әй, ул тезләреңә генә утыртып тотардай зифа сыннар!..

Салмыш урыс ирләре инде тагын да түзеп тора алмыйча, киемнәрен ерта-ерта мәйдан уртасына сикереп чыккан иде, әллә каян гына ике-өч дистәгә якын сакчы пәйда булды. Аркылы китереп тоткан сөңгеләреннән тыгыз божра ясап куйдылар да, сылуларны нәкъ уртага алып, Святослав баскан болдыр каршысына озата башладылар. Ул арада мәйдан читендәге арбаларның ефәк япмалары астыннан ике мәһабәт ир сикереп килеп чыкты. Мәйданны түгәрәкләп баскан урыс ирләренең һәммәсе аһ иттеләр. Святославка төбәлеп атлаган беренче ир үзенең алга таба сузган кулларына саф алтыннан коелган нәни казан күтәреп килә иде!

— Монысы сиңа тагын яңа бүләк, олуг кенәз, — дип телгә килде йөзбаш киемендәге мәһабәт ир. — Сиңа нәкъ менә казан бүләк итүебезнең яшерен сере дә юк. Казанны һәрчак үзара килешеп яши белгән, бер-берсенә ярдәмгә ашыккан дуслар белән генә бергә асалар бит. Ошбу казан — икебез өчен тугра. Моннан ары үзара яу йөрүләр, кан коюлар бетсен. Болгар белән урыс халыклары гомер буе уртак казан асып, аш бүлешеп, бер-берсенә кунакларга йөреп кенә яшәсеннәр иде.

— Машалла, машалла!

— Ярабби Ходаем! Амин, амин! — дип эләктереп алды болгар сакчылары.

Көттеребрәк булса да, урыс ирләре дә барыбер кушылдылар:

— Бик хуп, бик хуп!

— Үзара яу йөрүләр, кан коюлар бетсен!..

Махсус бояр килеп болгар вәкилләрен кунакка чакырып алды:

— Олуг кенәз сезне үз йортына, кичке ашка дәшә.

Ибраһимның йөзе борыч капкан төсле сытылды, йодрыклары усал йомарланды. «Үз йорты, имеш, үз йорты, каһәрен генә өшкерим! Басып керү тәтегәч, Ашлы каласын да, Сәлман бәк йортын да үзенеке итеп исәпли бу. Без, болгарлар түгел, ә килмешәк кенәз үзен безнең җирдә хуҗа итеп тоя. Оят, хурлык!»

— Борчылмагыз, — дип тынычландырырга ашыкты Даян сәрдәр үзен урап алган кардәшләрен. — Урысларның кунак агулый торган яман гадәте юк. Дөрес, исереп алсалар, болар ду китереп үзара сугышмыйча калмый. Кунак булгач, безгә тимәсләрдер.

Өстәл артына утырышкач, Ибраһимның ымы буенча зал түренә янә биюче яшь кызлар тезелешеп чыкты. Тагын чаң, кубыз моңнары сибелде, кызлар ярым шәрә күкрәкләрен, ботларын уйната-уйната өр-яңа биюләр биеделәр. Святослав кенәзнең, барча боярларның күзләре корбан эзләп тапкан ач бүренеке төсле уйнаклады.

Урыслар беренче тустаган хәмерләрне бушаткач, Ибраһим туганлашу, дуслык турында сүз кузгатып, Святославның кылын тартып карамакчы иде.

— Нинди киленнәр алмашу, туганлашу хакында сөйлисең син? — дип кырт кистереп каршы төште кенәз. — Көчсезләр һәм җиңелгәннәр белән килен алышырга, солых төзергә мин сезнең алда колчурамы әллә? Сезнең ише басымчак халык түгел, хәтта үз туганнарым — Ростов, Галич, Новгород кенәзләре белән дә килен алышканым юк. Киев — барча урыс җиренең башкаласы, Ростовныкылар миңа тиң түгел. Мин бүтән якка карап табынам бүген. Әнә кул сузымында гына юнан кайсары бар, ахыр чиктә хәзәр каганы бар. Ичмаса, шулар каршына барып бил бөгәм дә килен төшерәм мин. Ә синең болгар кызларың... Әнә, күрәсеңме, берьюлы ничә дистә бии. Алар барысы да минекеләр бүген. Килен итеп төшереп тә тормыйча, бөтенләй бушка гына.

Ибраһимның битенә төкерделәрмени, башын аска иде. Үз ватаны өчен гарьләнүдән бөтен тәне ут булып янды. «Мескен булма, җиңелмә, коллыкларга төшмә, — дип, үз-үзенә әмерсабак биреп утырды ул. — Җавап кайтарырдай, илеңне яклардай куәтең булмаса, сине менә шулай, сөяк көткән эт хәленә калдыралар икән».

Әмма мин-минлеген учына бөтереп тыкды да, Ибраһим бөтенләй көтелмәгән яктан китереп сукты:

— Мөхәммәт хан янына илчеләр килеп китте. Йосыф каганнан, хәзәрләрдән инде, — дип, кайнар чәй эчкәндәй тарта-суза гына, Святославның йөзенә дә карап тормыйча сөйли башлады ул. — Йосыф үзара берлек төзергә чакыра безне. Тигез, гадел берлек. Аманатларыбызны да кире кайтарачак.

Святославның ияге соскы шикелле салынып төште, күзен черки кергән сыман челт-челт йомгалады. Телен, кышкы зәмһәрир салкында пычак йөзенә тидереп өттергән шикелле, көч-хәл белән кыймылдатып дәште:

— Берлек... Берлек... Аннары нишләмәкче?

Ибраһим һаман кенәз ягына борылып карамыйча да тезде:

— Нәрсә булсын, яу сәфәренә чакыра инде. Әйдә, Киевны тез астына бөгеп салабыз, ди. Яулап алгач, гадел бүлешмәкче. Киев, Вышегород, Переяславль калалары — миңа, Чернигов белән Осколны сезгә калдырам, ди.

Святослав чыгырыннан чыкты. Эчендәге ярсу, нәфрәт ут урынына талый иде, ахры, ул изүләренә тикле йолкып ачты:

— Килмәгән, яуламаган, ә үзе шулай, инде алдан ук, калаларга чаклы бүлешеп куйдымыни?

— Әйтеп торам бит, бүлешә инде менә.

— Ә сезнең ханыгыз нишләмәкче? Мөхәммәт кушыламы?

— Элек исәбе юк иде, хәзер уйга калды. Чөнки, иң беренче башлап, Мөхәммәт ханга син китереп суктың.

Святослав ике чигәсен тотып уйга калды, кара янып чыкты. Бераздан карашында шәм яктысы кебек кенә җылылык бөреләнде.

— Әгәр Әтил каласы өстенә үзем очып кунсам?

— Ә мин сиңа шуны кинаяләп утырам бит инде.

— Йосыф каганны җиңеп булырмы соң? Сез дә миңа кушылмассыз инде?

Сүз ике малай-шалайның йодрык сугышы турында барган кебек, Ибраһим кулын селтәп кенә урыс кенәзен котыртуын белде:

— Ә-әй, син каганны берүзең дә сытып үтәсең бит. Йосыф Манас түгел, бу булдыксыз. Бу хәрамханәдәге җарияләренең итәгеннән аерылып урамга чыгуны да белми. Маназка ялланган бәҗәнәкләр, аланнар күптән качып бетте. Йосыфның сарай сакчыларыннан башка гаскәре юк.

Святослав казаннан гына алынган кайнар итне бүләргә әзерләнгәндәй җиңнәрен сызгана, иреннәрен ялмый башлагач, Ибраһим кабалана-кабалана тезде:

— Каганны чәнчелдереп төшерсәң, үзеңә дан. Ясак түләүдән, аманат кызлар озатудан азат булачаксың. Вятичлар, Ростовныкылар каган коллыгыннан котылачак. Кичә каганга озаткан байлыкларын аларның иртәгә сиңа түләве бар...

Святослав чыраена да, ниһаять, җан керде. Ул бер-бер артлы ике-өч җамаяк шәрабны әйләндереп куйды. Ә исереп алгач, үз янында болгар кунаклары барлыгын да күз чалымына китереп маташмады.

— Әнә теге, зәңгәр ыштанлы кыз, үземә бүген! — дип, төкерекләрен чәчеп кычкырды да, өстәл-урындыкларны аудара-аудара чыгып, кенәз биюче кызларга таба кулын сузып китте.

— Ә-ә-әй, бәләкәч! Син минеке бүген!

Аю сыман алпан-тилпән атлап килгән кенәзне күрүгә үк унике-унөч яшьләрдәге болгар кызы коелып төшкән иде. Святослав аңа ушка килерлек тә ара калдырмады, әзмәвердәй гәүдәсе белән сытып, тал чыбыгыдай нәфис сылукай өстенә сузылып ятты.

34

Яңа таңда Мөхәммәт хан вәкилләре Святославның Идел ярында корылган яңа чатырына вак-төяктән хасил бүләк китерделәр. Саф көмештән ясалган ике чәйнек, көбә, тәпси[1], алтын сәдәфләр тезелгән сыңар йөгән, асыл ташлы хәнҗәр. Мөхәммәт бүген төнлә генә кенәз белән аның боярлары кочагында яткан биюче кызларны да кабат урысларга кайтарып бирде. Сер бирәсе килмичә, юмарт кыйланып сөйләнгәләп куйды:

— Бүре теше тигәнне бүрегә бирү хәер. Чит ир назын татыган кыз-кыркынга ышаныч юк. Алар инеш суына утыртып агызган чүмеч төсле. Теге якка, бу якка янтаеп чөмерә-чөмерә, барыбер батмый калмый.

Ибраһим әмир әтисеннән тартынмый-нитмичә, таш чәйнәгән сыман иреннәрен кысып, усал сүгенеп торды:

— Дошман алдында тез чүктек. Иминлекне сатып алабыз. Бүре булып бүреләр дә кулга бирелмиләр. Ә без үзүзен дә яклый алмаган мескен хатын төсле. Кем иренми, шул килә дә баса. Дәүләтебез көчсез. Кайчан гына тураеп басарбыз да, башкаларга тиңнәр булырбыз без?..

Көндез Святослав, күркә сыман кабарынып, барча Болгар кунаклары алдында игълан итте:

— Сезнең белән бүтән сугышмыйбыз. Идел тамагында уртак дошманыбыз, Иосиф каган, икебезне тиң сыер урынына савып, тантана итеп ята. Хәзәр каганатын җимермичә торып, беребезгә дә бәхет киләсе юк. Мин Әтилгә юнәләм. Үземнән алда менә мондый хәбәр җибәрәм дә, тәкәббер каганның яңагына ялтыратып, ушын алып куям. «Синең өскә барам!» Каган, ханнар ханы, мин бердәнбер, дип масаеп яшәмәсен, калтырап торсын әле...

Шул сәгатьтә үк Ашлы каласыннан еландай шуып чыгып, урыс гаскәре хәзәр даласына төбәп китте. Әмирләр, бәкләр Мөхәммәт ханга шундук шөбһә белдерделәр:

— Йортларны, сарайларны да җимермәде бу кенәз, кала диварларына да ут төртмәде. Әй-яй, шикле! Берәр нинди мәкер-хәйлә корып, безне төп башына утыртырга җыенмый микән бу?

— Мин дә шикләнәм, — дип кушылды Мөхәммәт хан, бераз көттеребрәк. — Артыннан күзәтмичә, сакланмыйча булмас. Идел буйлап бер меңкешелек иравыл җибәрегез. Башка алайларны да таратмыйбыз, һәрбер яугир сәфәргә чыгарга әзер торсын...

Урыс гаскәре бер фәрсах арасы узып күздән югалгач та, ике җайдак Мөхәммәт хан каршына зур күн капчык ките-

[1] Тәпси — ризык ташый торган таба, поднос.

реп ташладылар. Капчык җир буйлап тәгәри, улый, чәбәләнә, моны ниндидер гадәти ау эте яки лачындыр дип кенә кабул итеп булмый иде инде.

— Сезнең түшкәдән кисеп ташланган үт безнең ашның да тәмен боза, каһәр! — диде капчыкны озата килгән сап-сары сакаллы җайдакларның берсе. — Этләр авызына үзегез ыргытыгыз.

Хан әмерен көтеп тормадылар. Ике сакчы, иярдән сикереп төшеп, капчык авызындагы элмәкне кисеп атты. Капчык эченнән ярга ыргытылган балык сыман хап-хоп сулый-сулый атылып килеп чыккан карачкыны шәйләп алуга ук һәммә яугир кылыч сабын кысты. Шик юк, аяк асларына сасы көзән сыман китереп ташланган бәндә заманында ил тоткан, аннары үләт чирле эт урынына читкә куылган саклык вәзир Нуретдин үзе иде.

Элеккеге кәпрәю-көрпәләнүнең эзе дә юк монда. Вәзир чакта көн саен ялтыратып кырылган яңаклар, түгәрәк пөхтә сакал урынына йонын коя башлаган сарык йоны сыман мунчала. Өстендә терсәкләре бәсәреп, итәкләре чукланып беткән чапан, аякларында авызын ачкан кәвеш. Билендә мунчаладан үргән юкә бау аламасы, чапан эчендә көл-корымга буялып беткән шәп-шәрә тән. Шушы карачкы да җир йөзендә адәм булып исәпләнә диген!

Сорау бирүче түгел, хәтта мәсхәрәләп сызгыручы кеше дә табылмады.

— Күземә күрсәтмәгез, — диде Мөхәммәт хан, кичәге вәзир ягына борылып та карамыйча гына. — Моны Борак сәрдәр сымак зинданга ташлаттырсаң таман булыр иде дә бит. Мәгәр Борак сымак печән биреп, ачка интектереп түгел, ә хан өстәлендәге ризыкны ташыттырып, дөмегергә ирек бирми газапласаң шәбрәк булыр иде. Әмма без ялгыз түгел шул, күршеләр күзе дә бар. Дөрес аңламаслар. Ике атка иярләгез моны. Урыс баскыннары да сабак алып китсен...

Берничә минуттан соң болгар җайдаклары сафыннан Святослав чатырына таба пар ат чабып китте. Ике ияр уртасында сугым пычагыннан качарга омтылган мал шикелле бер сын бәргәләнә. Юк, хәзер үкереп елардай куәте дә калмаган инде аның, каргаган яки ялварган тавышлары да бөтенләй ишетелми. Ул әле бер, әле икенче ияр аелына үрелеп, үзен бәйләгән элмәкләрне тешләре белән чәйнәмәкче була. Яшисе килә шушындый мескен, хөрәсән, беткән бәндәнең дә.

Пар ат кашанлылар чатырына таба якынайган иде, җиде-сигез ир сөңгеләрен һавага күтәреп усал болгадылар да, бүре тавышлары чыгарып улый башладылар. Өннәре алын-

ган атлар бер мизгелдә кыяга килеп бәрелгән диңгез дулкыны сыман өскә сикерделәр, икенче мизгелдә икесе ике якка аерылып та китте. Яшел чирәмдә, кышкы кар өстенә сибелгән ап-ал миләш тәлгәшләре шикелле янып, кан тамчылары гына чәчрәп калды.

35

Әтил каласына төбәп юлга чыккач, Святослав кенәз әүвәл бер генә кыек адым да ясамады. Гаскәре ике канатка бүленгән, берсе Җигүле тау ягына кыйбла тотып бара, берсе дала тарафын, очсыз-кырыйсыз ялан-далаларны каплап төшә. Җайдакларның күпчелеге уяулык дигән бишмәтне салып аткан, хәзер ияр өстендәге килеш йокымсырап бара. Бояр-лар өсте ябулы арбалар эченә, ышыкка кереп качкан. Күзәтү булмагач, аларның яраннары да пар ат иярләре арасына тарттырылган җәтмәләргә сузылып, гырлый-гырлый йоклый. Сафлар сүтелгән бау сыман таралып беткән, алай-нөгәрләрнең рәте-чираты юк. Болар яу сәфәренә чыккан булуларын бөтенләй оныткан сыман, сак-иравыл йөзләрен дә куеп тормаганнар. Суга салган юкә шикелле мәлҗерәгән гаскәр хәрби көчтән бигрәк сәүдә юлына чыккан кәрванны хәтерләтә. Шушы таркау, үшән ташкыннарга карап алдануың мөмкин.

Ике елга булып сузылган гаскәрнең фәкать бер төенендә генә уяулык, җанлану, бәхәс ишетелә. Бу — болгар кызлары утыртылган олау. Кайнар кочак, иркә-наз шикелле җәннәт, мондый тәм-том төнлә белән гади сугышчыга гына түгел, йөзбашларга да эләкми. Төн — ул боярлар, наиблар, меңбашларның туе. Алар кәнизәкләрне кат-кат юындыра-юындыра, әче бал ташый-ташый, кичтән таңга кадәр рәхәт чигә. Ә йөзбашлар, ташбаш сугышчылар, иравыл, ганимәт, мөлкәт өчен җаваплы түрә-түмгәк җәннәт олавы янында көндез генә җай эзләргә, бәхетле ятак хакына гомере белән шаярырга мәҗбүр. Уен-муен түгел, бу кыйммәтле олау янына әледән-әле шәхси орыш өчен сайланган пәһләваннар килеп чыгыштыра. Алар инде наибларны, меңбашларны да күз чалымына кертми. Аларның чүлмәктәй йодрыклары, тәртәдәй чукмарлары астына килеп эләктеңме, гарип калуың да ерак йөрми. Шуңа күрә гади сугышчылар, сөяк өмет иткән эт көтүе шикелле, җәннәт олавы тирәсендә көндез генә бии.

Бүген бәхет Переяславльдан килгән Устин атлы егеткә эләккән иде. Шырдый-бырдый түгел, Ашлыда Святослав кенәз үзе иркәләгән яшь сылукай арбасына чуму насыйп булды аңа. Әмма бөркәвеч астына эләккәч, болан баласыдай нәфис кыз өстенә котырган эт шикелле ак-караны күрми сике-

рә алмады ул. Кызый чибәр, аның карлыгандай кара күзләренә, чия төсле кызыл иреннәренә, алма кебек тыгыз, түгәрәк күкрәкләренә сокланып карап тормыйча түзеп булмый. Устин да, тәэсирләнеп-шашып, әнә шул алмадай күкрәкләрне учларына алды, аларның каен җиләге шикелле очларын иреннәре белән иркәләде, куллары нәфис ботлар арасына кереп оялады. Устинның әле озак, бик озак вакыт буена шушы җәннәт бакчасы эчендә йөзәсе килә иде.

Ләкин көтмәгәндә, арбаны дөбер-шатыр китереп, бөркәвеч астына Галич пәhлеваны Ермил килеп керде. Үләксә тапкан чүл бүресе сыман күзе-башы тонган, көрәктәй дәү кулларын уктай атылып чебеш алырга төшеп баручы карчыга канатлары шикелле ике якка җилпеп өскә килә. Алагаем чишенеп һәм озаклап кинәнергә ният иткән, ахры, чабата олтырагын да бәйләп тормаган бу.

— Күз алдымнан олак, селәгәй! — дип кенә үкерде дә, Ермил гөнаhсыз Устинны кәнизәк кыз өстеннән тышка алып атты.

Арбаны тирәләп барган ач көндәшләр буш мичкә, бакыр ләгән дөмбердәткән тавышлар чыгара-чыгара, ихахайлап, котырып кешнәделәр:

— Нәрсә, авызыңнан майлы калҗаны тартып алдылармы?

— Анасының имиеннән аерылган сабый шикелле нәүмиз калдыңмы, егет?

Ат тояклары, тузан арасына иске кәвеш төсле килеп төшкән Устин яшьле күзләре белән сихерле арба ягына төбәлеп ысылдады:

— Ничава, ничава, сәфәр озын әле, син кабихтән үч алырга форсат чыкмый калмас.

36

Ибраhим әмир белән Даян сәрдәр җитәкләгән болгарларның меңе дошман иравылларыннан кача-поса Идел яры буйлап шуышып төште. Шымчы җайдаклар баскыннар хәрәкәтен күз уңыннан бер дә ычкындырмый, арадашчылар әледән-әле кайтып җавап тота иде:

— Святослав Җигүле тауга таба төбәп бара. Алайларын уңга-сулга җибәреп чирүне тараттырмый.

— Баскыннарның икенче яртысы буш далалар буйлап сузылган. Аларда тәртип, уяулык чалымнары бөтенләй юк.

Алда Җигүле тау түбәләре тәгаенләнә башлагач, сагаерлык хәбәр кайтып җитте:

— Даладагы гаскәр Җигүле тауга таба борылды. Мөгаен, Святослав белән кушылырга исәп тоталардыр.

Чыннан да, Җидеколак дигән сәер атамалы елга тамагында дошман чирүләренең ян-як алайлары бер-берсенә килеп тоташтылар. Меңбашлары, боярлар, мөнадиләр[1] ике нөгәр арасында чабып йөрде. Көтүче чыбыркысы сыман сузылган баскыннар гаскәре берзаманны корбан эзләп тапкан буар елан шикелле җыерылды. Алайларның һәммәсе дә хәзер арткы аякларына басып дошман өстенә сикерергә әзер торган җанвар хәленә килде. Идел буйлап озата төшкән болгарлар да ук очырырга җыенган тәтедәй киерелделәр.

— Бортаслар җиренә килеп җиттек. Бәнҗә каласы кул сузымында гына. Боларның берәр нинди этлек эшләве бар. Барча йөзләргә дә фәрман җиткерегез. Һәрбер яугир орышка әзер торсын, — дип, тәүге әмерләрен озатты Даян сәрдәр.

Шулай да калкулыклар артында, тирән ерымнар эчендә барган болгар җайдаклары әле һаман эленке-салынкырак, пошмас кыяфәттә атлавын дәвам итте. Аеруча сәрдәрнең улы Насыйр үзен иркен тота иде. Шул һич тә көтелмәгән риваять бәян итте:

— Ошбу Җидеколак әллә ни зур елга булмаса да, хәзәр даласыннан Иделгә ком ташый. Шул сәбәпле Җидеколак тамагыннан бераз гына астарак кичү хасил булган. Аны Идел аша иң сай кичү, диләр. Ә сай булгач, билгеле ки, аймыклар да, кыпчак, бәҗәнәкләр дә иң әүвәле шуннан файдалана. Урысларның вятич кабиләләреннән, алан-чәчәннәрдән талап алган барча малны, коллар кәрваннарын менә шушы кичү аша куып чыгаралар. Идел буйлап төшкән сәүдәгәрләрне дә шушы урында тозак корып сагалыйлар икән. Шул нисбәттән ошбу төшне Җидеколак дип атаганнар да инде. Моны җиде колаклы, җиде күзле булып кичү дә артык гамәл түгел...

Насыйр Болгардагы болгану-мәхшәрдән качып, хәзәрләрдә шымчылыкта йөреп кайткан кеше. Аны Манас каганны үтереп тәхеткә Йосыф сикереп менгән чакта Әтилдәге сарай эченә үк үтеп кергән, диләр. Бардыр, бардыр. Насыйр утлар-сулар кичкән, елгыр сәйях, аңа ышаналар.

Насыйрның сәер бәяны болай гына да тәмамланмаган икән, егет янә күпләрне сагайтырлык сүз башлады:

— Узган ел урысларның Савилий атлы бер бояры харап булды монда. Юк, үлүен үлмәде ул, мәгәр барыбер дә үзенең сантыйлыгы аркасында тоткынлыкка төште. Әтил каласында каганнар алышыну, андагы башбаштаклык хакында ишеткән дә, тегеләрнең уяусызлыгына өметләнеп, таларга, баерга дип ашкынып килеп җиткән. Кияү каласындагы кенәзләрен дә кисәтеп тормаган ул. Башка боярларны да үз ар-

[1] М ө н а д и — ханнарның фәрманнарын җиткерүче кеше, глашатай.

тыннан чакырып маташмаган. Имеш, берүзе генә искәрмәстән килеп төшә дә хәзәрләрне чалып ташлаган мал урынына рәхәтләнеп туный. Меңнән артык угрыны үз артыннан иярткән дә килгән. Асылда да болар Әтил каласына терәлеп торган Төрекмәннәр бистәсен тоташ талаганнар. Ул нигъмәтләрен-малларын моннан ике фәрсах арасындагы Чуерташлы мәгарә эченә дә кертеп тутырганнар. Шул вакытта койрыкларын җыеп сыпыртсалар, ак сакаллы карт булырлар иде дә бит. Юк шул, нәфесләре янә Әтил ягына борган. Ә хәзәрләрнең яңа каганы Йосыф бу юлы инде менә шушы Җидеколак ярына тозак корып куйган. Урыс угрылары шуңа эләккәннәр. Каханга ялланган төрекмән җайдаклары урысларны тоташ турап чыккан. Исән калганнарын Әтилдәге коллар базарында мин дә күреп кайттым. Башлыклары Савилий утыз яшьләр чамасындагы бер пәһлеван иде. Андагы үгез шикелле таза буй-сын дисеңме, ул беләкләр дисеңме! Йодрыклары — чукмар! Иллә мәгәр аның дүрт йөзбашын базар уртасына куелган Салкын-таш өстендә кылыч белән телгәли башлагач, Савилийның күкрәккә җиткән сакалы күз ачып йомганчы ап-ак булды. Ә аның үзенең гомерен кыймадылар. Йосыф каган әмере буенча, җәлладлар аның ике күзен төртеп тиштеләр дә каладан читкә чыгарып җибәрделәр. Кайда йөридер ул хәзер, исәндерме-юкмы, беркем белми. Аны әлегә чаклы хәзәр даласында һичкемнең күргәне, очратканы юк. Ошбу Святослав та, Йосыф өстенә барып, Савилий бояр өчен үч алуны максат итми микән?

Бер Даян сәрдәр генә көттереп телгә килде:

— Сукыраеп далада йөрүләрдән Ходай Тәгалә үзе саклый күрсен!

Ибраһим әмир янәшәсендәге меңбашлары белән яраннарның барчасы да Насыйр хикәяте белән сихерләнгән сыман әллә ни кадәрле ара дәшми барды. Ибраһим үзе Даян сәрдәр белән аеры калгач кына, ниһаять, авыз ачты:

— Улың Насыйр сөйләгәннәрдән сабак алдыңмы соң? Безгә һәрбер чит мәмләкәт, чит-ят кала эченә шымчыларны озатып тору кирәк. Әгәр дошманнарыбыз арасында күзколаклар булдырмыйбыз икән, безне дә әнә шулай Савилийныкы сыман кара язмыш көтә. Бу Святослав кенәз чатыры артына да икеме-өчме шымчы тагарга онытма син…

Җидеколак елгасының бер як яры куна тактасыдай шома, тигез, икенчесен эреле-ваклы чокырлар, ерымнар ергалаган. Святослав шул ерымнар ягында төн кунарга ният итте бугай, зур гына чокыр тирәли туктап, арбалардан ике катлы ыстан кора башладылар. Чокыр эчендә дүртме-бишме чатыр үсеп чыкты, дистәләгән учак тергезделәр. Уйнашчы хатын өстенә сыланган сөяркә ир сыман, хәтфә дала буйлап

зәңгәр төтен сузылды. Яңа суелган ит исе, шулпа исе борын яфракларын ярып үтте.

— Болай булгач, Святослав таң атканчы беркая да китми. Ялга тукталабыз, — дип, күрсәтмәләр бирде Даян сәрдәр.

Болгарлар да яр астына яшереп кенә учак кабыздылар. Кайнар аштан соң барча ирләр киез келәмнәр өстенә сузылыштылар.

Төн уртасында барчасы да хәвефкә баткан мөнадинең оран авазыннан сикереп торды.

— Урыслар юк! Святослав безне алдап качкан!

Ибраһим әмир белән Даян сәрдәр, аның артыннан ук иравыл йөз ирләре урыс ыстаны торырга тиешле чокырга томырылды. Килсәләр, чокыр эчендә дистәләгән учак кына янып ята, сыпылып-тишелеп беткән чабаталар ауный, тик бер җан иясе дә юк. Ибраһимның борыны салынып төште.

— Артыннан күзәтеп баруыбызны сизгән бит бу. Йә арада бер сатлык бар. Шуңа бездән арынуны кирәк тапкан. Мәгәр кайсы якка киткән? Безгә каршы этлек эшләмәсме?

Баш ватып торырга, гөманларга ирек бирмәделәр. Ак күбеккә баткан чапкын килеп җитте.

— Святослав Бәнҗә каласына бәреп керде! Святослав бортасларны талый!

— Әх, бәдбәхет! Әх, мәкерле төлке! Урыс белән якыная калсаң, сугыш балтаң билдә булсын икән, — дип сытып сүгенде дә Ибраһим әмир, шундук яу атының касыгына типте.

— Бар йөзне дә һөҗүмгә әзерләгез! Даян сәрдәр, Мөхәммәт хан янына чапкын җибәр! Баскын кенәзнең талап капкан һәр калҗасын костырырга кирәк...

Ни галәмәт, Святослав кирмән тирәли дә, кала диварлары өстенә дә каравыл бастырмаган. Ул үзен бөтенләй йә хуҗа, йә үч-җәзага тарымас сәргаскәр дип санагандыр инде. Берзаманны диварлар эчендә, Бәнҗә урамнары башында болгарларның берьюлы йөзәр-йөзәр җайдагы үсеп чыккач, урыс кенәзенең күзләре маңгаена менде.

— Сак божрасы оештырыгыз, сак божрасы! — дип ярсый-ярсый кычкырып караса да, йорт-келәтләр талап йөргән юлбасар җайдакларны җыеп китерердәй яубашы табылмады. Ул арада инде тоткынлыкка төшкән Бәнҗә ирләре дә һушка килгән иде. Кемнәрдер ярым исерек урыс сугышчылары кулыннан кылыч-сөңгеләрен талап алды, кемнәрдер койма-читәннәрне җимереп коралланды. Ә аннары инде бортаслар белән болгарлар бергәләп баскынарны изә башладылар. Святослав үзенең кул астына эләккән меңбашларны, боярларны типкәли-типкәли искә китерергә мәҗбүр булды.

— Казан төсле сак божрасы оештырыгыз, дим бит мин

сезгә, җыен имгәк! Каланы таларга киткән бар гаскәрне җыеп китерегез!

Озакламый мәйдан уртасында сукса үгезне егардай пәһлеваннар сафы пәйда булды. Боларның кыяфәте үк дәһшәт бөркиде. Саксызрак якынайган болгарларга биш-алтысының ат тоягы сыман йодрыгы да эләккәч, әрдәнә, такта, тәртә белән генә коралланган бортаслар карчыга күргән чебеш өере сыман читкә сибелделәр. Пәһлеваннар арасында аеруча Галич егете Ермил барысын да балчык чүлмәк урынына сытып килә иде. Көтмәгәндә мәйданга алып килә торган бер тыкрык башыннан йомран шикелле сызгырган ук атылып чыкты. Икенче мизгелдә, муенына килеп кадалган ук сабына ябышып, Ермил җиргә ауды.

— Наз уйнаган чакта айгыр белән үгезгә дә, эт белән мәчегә дә аяк чалучы юк. Сиңа сабак булсын! — дип кычкырган урыс авазы ишетелде, хуҗасын гына чамалый алмадылар.

Мәйдан уртасына эт көтүе сыман куып китерелгән чабаталы урыслар кереп тулды. Мизгел эчендә болгар яугирләрен тыкрыкларга кысып чыгардылар. Ләкин үзен хуҗа итеп, тыныч хәлдә тоючы табылмады. Төнге караңгылыкта күзгә күренмәгән сарай, келәт, өй түбәләреннән мәйданда исәнгерәп торган баскыннар өстенә меңәрләгән ук яңгыры очты, дистәләгән урыс ирләре күкрәкләренә, муеннарына, эчләренә тотынып җир өстенә ауды.

— Кала читенә, далага чигенегез! — дип үкерде берзаманны түземлеген җуйган Святослав кенәз. — Калага ут төртәбез!

Болгар белән бортас ирләре күпме генә уяулык күрсәтмәсен, кисәү күтәреп йөгерешкән баскын сугышчыларны ут очыртып чүпли алмадылар. Күз ачып йомган арада каланың дистәләгән почмагында янгын купты. Хыянәтче очкыннар елгыр тиен сыман түбәдән түбәгә сикерде, бар урамга зәһәр төтен тулды. Дәһшәтле дулаган усал җил тавышын, елау-сыктауларны яубашларның әмере күмеп китте:

— Каланы коткара алмыйбыз, диварлар артына йөгерегез!

— Далага чыгыгыз, далага!

Урыс җайдаклары каланы иң беренче булып ташлап чыккан иде. Яланда аптырашып, кайгырып тормадылар. Боярларның әмере яңгырауга, баскын җайдаклары тигезле-тигезсез сафларга тезелде дә, төнге караңгылыкта, мунча ташына салган боз шикелле эреп, шундук гаип булды.

Дулый-дулый, дөрли-дөрли янган Бәнҗә каршындагы яланнарда бортаслылар төркем-төркем тезелешеп калды. Аларны сызланмыйча, сыкранмыйча күзәтү дә мөмкин түгел иде. Һәркайсының яңагында кайнар яшь эзләре, әрнү, сагыш. Бик күбесе юньле киемен дә эләктереп чыга алмаган.

Кайсы яланаяк, кайсы ярым шәрә. Байлыгын коткарырга ымсынган кешеләрнең дә зиһеннәре ычкынгандыр инде. Кулларына тотып чыккан әйберләр арасында җыен шырдый-бырдый: ашъяулыклар, урындык, таба, мендәр.

Таң атуга, Мөхәммәт хан гаскәре килеп җитте. Бәнҗә өстенә күз йөгертеп чыккач аңлатмалар бирү артык иде. Мөхәммәт хан ачулы карашы белән Бәнҗә хакиме булып исәпләнгән бәкне эзләп тапты. Уртларын шыгырдатып, тереләй йотардай булып бер генә сүз катты:

— Йә, артабан да Болгар мәмләкәтеннән аеры буласызмы?

Бәнҗә бәге сарык лапасына бүре кертеп гөнаһланган ялкау эт шикелле шуышып килде дә, ханның итегенә борын төртә-төртә, еламсырап-сыкрап тәкрарлады:

— Юк, бортасларның моннан ары болгарлардан аеры буласы юк. Без мәңгегә бергә!

Хан озак көттермичә болгар ирләренә әмер бирде:

— Бүген үк Бәнҗәне өр-яңадан төзергә керешегез! Иллә мәгәр кылыч-садакларыгыз билегездә булсын!

37

Иосиф каган сараенда бүген тагын бәйрәм. Аланнар, ләкеләр көндез каганга олау-олау ясак алып килде, искеләре урынына унбер-унике яшьлек малайларны аманатлар итеп китереп тезде. Хезмәтчеләр мунчаларда шундук утлар кабыздылар, хәрамханәдәге кыз-тәкәләр аманат малайларны ләгәннәрдә юды, табиб булып йөргән фарсы ирләре һәркайсының тәненә зәйтүн, сырганак майлары сөртеп чыкты. Әллә нинди сихерчеләр кереп, почмак саен канәфер, яран, нәркис, бөтнек, гөләп ботакларын яндыра-көйдерә хуш ис тараттылар. Пешекчеләр хөрмә, әфлисун, йөзем китереп тезде. Сорнайчылар, кубызчылар ян-як бүлмәләргә җыелып утырдылар. Хуҗаларның һәр минутта килеп кереп уйнаш коруы бар, якты дөнья белән хушлашасың килмәсә, һәр тарафта әзер тору кирәк.

Ә хәзергә Иосиф каган әле сарай уртасында күңел ача. Ләке, алан кенәзләре белән бер мәҗлестә утыру, билгеле ки, каган өчен дан-дәрәҗә түгел. Ләкин ул кыргый таулардагы кенәзләрнең кайтыр юлда әзери, чәчән авыллары яныннан үтәсе бар. Күрсәтелгән сый-хөрмәтне бәян итми калмаслар, Иосиф каган даны кыргый тауларга да китә бирсен.

Өстәлләр сый-нигъмәтләр белән сыгылып тора, әмма ләке, алан кенәзләренең күзләре гел зал түренә көйләнгән мәйданчыкта. Анда анадан тума чишенгән япь-яшь кызлар елан сыман боргаланып бии. Каханның кулында сәйлән чылбыр. Иосиф бер очыннан күтәреп шул чылбырны өстәл өсте буй-

лап уйнаклата, ә кызлар, сихерләнгән сыман, сәйләннәр хәрәкәтенә ияреп яңтаялар. Кахандагы чылбыр уң якка бөгелеп дугалана икән, шәрә сылулар да йомшак мендәрләрен шул якка күпертеп бөгеләләр, сулга икән сулга. Иосиф сәйләннәрне өстәл өстенә ташласа, чибәркәйләр идән буйлап тәгәрәп боргалана. Сылуларны мондый көйле уенга күнектерү өчен бик аз вакыт китмәгәндер инде, ә шулай да күзәтеп утырган чакта кызык, рәхәт.

Мәйданчыкта кызлар бер-бер артлы алышынып тора. Иосиф мактанмыйча түзми:

— Әнә сул яктагы каракай — бортас кызы. Теге, ерак почмактагы бөдрә чәчле сылу — аймыклардан. Аның янәшәсендәге кара чутыр — тажик кәнизәге. Ә менә монысы, ак чәчлесе — вятичлардан бүләк.

Тауныкыларга аеруча ап-ак карда юган җитен сыман чәчле кыз ошады. Ул башкаларга караганда озынчарак буйлы, ботлары да озын, тыгыз; күкрәкләре чәйнек шикелле кабарып, сөзеп тора. Җитмәсә, кыз кымшанган саен, шул күкрәкләр су өстендәге калкавычлар шикелле сикереп уйнаклыйлар.

Иосиф тау кенәзләрендәге ач карашны тоеп алды бугай, ияге белән ым кагып вятич кызын үз янына дәште. Кызый гаурәт җирен каплап йөгереп килгәч, каган алан кенәзенә борылып хихылдады:

— Вятич сылуы ни дә, алан сылуы ни, җан җирләре бер үк. Ышанмасаң, әнә тотып кара.

Алан кенәзе болай да ымсынуын көч-хәл белән тыеп утыра иде. Каханнан рөхсәт булгач, сылуның ике кулын да читкә этәреп куйды. Кытай әлифбасын күргән сыман исе китеп дәште:

— Әт-тәч, бу төше дә сары!

Каган үзе дә, өстәл артына тезелешкән вәзир-яраннар да сарай түшәмен күтәрердәй итеп дәррәү кешнәделәр. Алан кенәзе исә тыелып кала алмады, кызыйның «җәннәт»ен әүвәл бармаклары белән кармалады, аннан борынын тыкты. Хәзәр хуҗалары янә өстәл төя-төя кешнәвен дәвам итте.

Нәкъ шул мизгелдә залга яралы бер чапкын атылып килеп керде. Йәрты йөзе, муены канга баткан, җилән-күлмәкләре умырылып беткән. Йөгерә-йөгерә сулышы капкан бугай, сүзләрен дә юньләп әйтә алмый:

— Каган, дошман! Калага... Идел яклап... дошман бәреп керде. Әллә... урыслар гаскәре инде ул, әллә Мөхәммәт хан?.. Берни аерып булмый... Ләкин яралансалар, урысча сүгенәләр.

— Кайсы калага? — дип үкереп урыныннан сикереп купты Иосиф каган. — Кайсы калага бәреп керделәр, дим?

Чапкын канлы иреннәрен ялап янә тәкрарлады:

— Әтилгә… пайтәхеткә… бәреп керделәр, каган. Сугыш хәзер урамнарда бара. Дошман гаскәре… кул сузымында гына.

Иосиф каган сый тулы өстәлләрне әйләндереп атты, колакларны сытардай куәтле, әче тавышы яңгырады:

— Каравылбашлар белән сәргаскәрләр кайда? Дошман пайтәхеткә бәреп кергәнче нәрсә караганнар? Мин аларның муеннарын чаптырам, дарга астырам, суям!

Агарынып калган вәзирләрнең берсе өшәнеп кенә иреннәрен ачты:

— Теге, Киев кенәзе Святослав, бер ай чамасы элек «Синең өскә барам» дигән кисәтү җибәргән иде, хәтереңдәме, каган? Әллә шул Святослав-ташбаш килеп җитте микән?

— Каганга каршы корал күтәрергә аның башына тай типкәнме әллә?

— Бәлки, болгарлар, бортаслар белән бергә кушылгандыр, кемнәр белсен инде?..

Залга, ниһаять, каравылбаш үзе килеп керде. Бу да яраланган, муенында сынган ук сабы тырпаеп тора. Куәте дә беткән икән инде, тавышы гырылдап-гыжлап чыга:

— Каган… дошман… Киевтан… Святослав…

Иреннәрен йомуга ук каравылбаш таш идән өстенә бау кисәге төсле авып төште. Моны инде дар-балталар белән өркетү артык иде. Иосиф ишек төбендә торган сакчыларга төбәлеп әмер бирде:

— Миңа калкан-кылычларны китерегез! Әтилне саклауны үз кулыма алам!..

Сарайдан чыксалар, пайтәхет өстендә Идел яклап әллә ничә урында янгын дөрли. Урамнарда сугыш. Кычкыру һәм сүгенү авазлары каган кирмәненә якынаеп килә, димәк, вәзирләр, сәрдәрләр көмеш тәңкәләр хакына яллаган тажик, аймык, кыпчак җайдаклары баскыннарга каршы тора алмаганнар.

— Аргамакны китерегез миңа, айгыр китерегез! — дип үкерде Иосиф каган, бер өер бүре улавын күмәрдәй иләмсез тавыш белән. — Каравыл һәм җансакчылар алае, минем арттан!

Кирмән диварларының тышында ук Святослав белән йөзгә-йөз килделәр. Каган әләмнәрен шәйләп алгач, баскын кенәз аеры батырайды:

— Тантана итәсе көннәреңбетте, каган. Мин синең кирмәнең урынында көл калдырып китәм. Саклардай-яклардай куәтең бар икән, минем белән шәхси алышка чык!

Иосиф иреннәрен мәсхәрәле бөреп җавап тотты:

— Колчура белән орышып, каган дәрәҗәсен мыскыл итеп булмас! Синең ише сукбай, юлбасарга минем җансакчы да артык. Батыр булсаң, әнә ат караучы Җәкәү белән орыш!

— Әх, куркак җан! Әх, печтерелгән тәкә! — дип, гарьлә-

нүдән ярсып, Святослав, кылычын болгый-болгый, каган тарафына томырылган иде, күмергә буялган шикелле чем-кара бер гарәп тәртә сыман озын сөңге белән тәкәббер кенәзне ияреннән чәнчелдереп атты.

Дөя сыман озын буйлы гарәп инде аты белән бастырып килә иде, әле ярый Святослав кенәзне яраннары тояк астыннан йолкып өлгерделәр. Кенәзнең нинди мөшкел хәлгә калуын күреп калдылар, ахры, берничә минуттан кирмән алды урыс җайдаклары белән шыгрым тулды. Кайсы көянтә буйлы кылычын болгап якыная, кайсы ыргак башлы юан сөңге сузган. Тәкъдир — явыз, аның белән шаяру-алышуда отышның булганы юк.

— Ахмак таждар гына каланы саклап үлә, — дип пышылдады Иосиф каган үзен тирәләп алган вәзирләргә. — Акылы бар хаким алайларын коткара, халкын яклый. Святослав көл итәм дип өркеткән кирмән урынына мин яңадан бишне төзеп куям. Ә гаскәремне кырдыртсам, яклаучысыз сукбай хәленә калам.

Иосиф артка тезелешкән җансакчылар алаена борылып әмер бирде:

— Шәһәр буйлап мөнадиләр җибәрегез, каланы ташлап чыгабыз. Тәбегә элөккән күсе хәленә калгач, Святославның минем алга шуышып киләчәген сез соңыннанрак күзәтерсез әле...

Каган сарае да кулларына төшкәч, урыс баскыннары атна-ун көн буе туй иттеләр. Берәүләре хәрамханә эченнән чыкмый рәхәтләнде, икенчеләре хәмер-шәраб күленә чумып йөзде, уяураклар урамнан урамга күчеп йортлар таладылар. Ләкин пайтәхет дигәннәре яртылаш янып беткән, өстәвенә инде монда яшәгән болгар-таҗиклар да күз төшәрдәй ихаталарны айкап үткән иде. Баскын сугышчылар арыш капчыкларына күлмәк-челтәр, таба-соскы сыман иске-москы гына җыеп кайтты.

Берзаманны айныдылар болар. Күпчелек сугышчылар йөзбашлары, меңбашлары аша Святославтан туган якка кайтуны таләп итте. Ерак юлларда йөреп үзе дә арыган кенәз, ниһаять, бер таңда иярләргә менәргә әмер бирде. Чабата олтырагы сыман сузылып кирмән-кала читенә чыкканнар гына иде, баскыннарны төрле яклап Иосиф каган чирүе чолгап алды. Иосиф тауларда йә күлләрдә яшерен тоткан хәзинә хисабына яллагандыр инде, гаскәрендә баштанаяк коралланган бәҗәнәк алайлары, алан җайдаклары.

— Артка, кире диварлар эченә! — дип, Святослав ярсый-ярсый кычкырып караган иде дә, урыс гаскәренә чигенергә ирек бирмәделәр.

Иосиф алайлары баскын гаскәрне, сазлык эченә баткан фил өстенә ябырылган карга өере төсле, төрле яктан килеп

чукыдылар. Святослав арбалардан түгәрәк ыстан да корып карады, вакыт-вакыт үзе башлап һөҗүмгә дә күчте, файдаотыш дигәннәре барыбер күренмәде. Бәҗәнәк һәм алан җайдаклары, кыйгач ташкын булып килә-килә, урыс гаскәренең яртысын кырып салды, ыстан канга батты. Ахырда, инде аптыраганнан гына, яңа төрле әмер бирде кенәз:

— Әйдә, менә монда чөй шикелле булып тезелегез! Очка үзем басам. Минем арттан калмый ташланырсыз.

Һавадагы аккошлар чылбыры шикелле очланып сугышуны тау җайдакларының күргәне юк иде. Әүвәл алар урыс баскыннарының нинди мөгез чыгарганын да аңлый алмый аптырашып тордылар. Ә аланнар һәм бәҗәнәкләр искә килгән чакта, Святослав гаскәре, янгын купкан амбардагы күселәр сыман, чолганыштан чыгып качкан иде…

Яһүди Иосиф каган шул көнне үк кичен сараена вәзирләрен, яубашларын, базарлар тотучы, кәрваннар йөртүче байчураны, үзенә тез чүккән барча күрше бәкләрен җыеп сабак бирде.

— Урыслар безнең өскә килгәнче башта болгарларны юк итәргә маташканнар икән. Болгарларны тезгә чүктерсәләр, билгеле ки, байлыкларын талау белән генә канәгатьләнмичә, аларның иң чибәр, булдыклы кызларын хатынлыкка алып китәрләр дә үзләренә гаярь уллар таптырырлар иде. Ә иегетләре исә, колчура рәвешендә, урыс гаскәре сафында урыс тәхетенә хезмәт итәр иде. Болгар билен сугып сындырсалар, ah, көчәясе, көрәясе булган урысларның! Ярый әле, дуга кебек итеп бөгә алмаганнар. Шуңа күрә сезгә нәзер һәм әманәт. Моннан ары болгарларны саклагыз, аларга тимәгез сез. Болгарлар — урыслар белән яһүдиләр арасындагы калкан. Урыс болгарны тез астына салса, аннан безнең чират.

38

Мөхәммәт хан йортын кырау сукты, ахры. Болгар каласыннан Бәнҗәгә тагын күңелсез хәбәр килеп җитте:

— Әмир Тимер-Мөэмин үз чирүен алып Растуф өстенә барган. Аңа Җүкәтау белән Кашандагы башкисәр олаучылар да ияргәннәр. Тимер-Мөэмин, Сура елгасын кичкәч, кырыкка якын урыс авылын яндырып, талап үткән. Хәзер Растуф кенәзе Касьян безнең мәмләкәткә җавап явы әзерләп ята икән. Тимер-Мөэмин үзе әле дә әйләнеп кайтмаган, хәзер аны чирмеш олысларын талап йөри, диләр.

— Болгар иле турында кайгыртучы яңа хуҗа, яңа кahарман табылган, әх, имгәк җан! — дип сүгенде Мөхәммәт хан, чын күңелдән сызып. — Әле Йосыф каган белән Святослав

кенәз талавыннан котылган юк, ә бу инде өстәмә дошман эзләп, ил өстенә яңа кайгы-михнәт чакырып ята.

Башкаларны кисәтми-нитмичә, Мөхәммәт хан үзенең юл киемнәрен барлап чыкты, кулына кылыч, камчы, көмеш очлым тотты. Чатыр ишегенә карап алгач кына, әмир Ибраһимның иңенә йөзен төртеп, әрни-әрни дәште.

— Үземнең өй эчендә тәртип салалган юк, ә мин, ахмак, илне гөл итмәкче булып хыялланып йөрим... Кайтмый булмый. Илне янә дошман явын каршылау өчен әзерләргә кирәк. Туган улкаемның гөнаһысын атасы булса да юа алмас микән?..

Ишек чаршавын ача башлагач, кире борылып, күңелендәге соңгы серен әйтте:

— Сине гомер буе үз янымда гына тотар идем дә бит, ни үкенеч, син монда да кирәк...

Кала-авыллар арасын чабып узган саен, Мөхәммәт ханны язгы кар сулары, ерганаклар кебек төрле яктан агып килгән яңадан-яңа хәбәрләр каршылады.

— Растуф кенәзе Касьян Чаллы каласын тоташ яндырып чыккан. Хәзер ул кала урынын Корым-Чаллы диеп атаганнар икән.

— Чирмешләр Тимер-Мөэмин гаскәрен тозак куеп саклап торганнар да Ямансаз дигән баткаклыкка кертеп батырганнар. Болгар җайдакларының нәкъ yртысы шул сазлыкка чумып юкка чыккан...

Болгар үзәгендә үз кесәсендәге шикелле иркенләп актарынган Касьян кенәз гаскәрен Мөхәммәт хан Илбуга каласы янында эзләп тапты. Шүрләп-икеләнеп тә тормады ул, Болгар белән Кашаннан җыеп чыга алган барча хәзинәсен бөркәвечле арбаларга шыплап тутырды да дошман ыстанына үзе барып керде.

— Дуамал улымның гөнаһысын юар өчен үзем килдем, кенәз. Теләсәң, ас мине, теләсәң, кис. Ләкин Болгар буйлап яу йөрүне туктат.

Инде бөкресе чыга башлаган, ак сакаллы Касьян, шайтан биетүне күргән сыман, Мөхәммәт ханга текәлде дә катты. Ул, мөгаен, хан кадәрле ханның үз каршына ялынып килүен күрүгә караганда «Идел кирегә ага башлаган» дигән сүзләргә тизрәк ышаныр иде. Күрәсең, нәкъ шул нисбәттәндер ул Мөхәммәт ханга ярты сүз җавап та кайтара алмый торды.

— Безне әле генә Киев кенәзе Святослав шәрә калдырып китте, — дип, җае чыккач дәвам итте Мөхәммәт хан. — Бәнҗә көл эчендә. Хәзәр каганы Йосыф ел да килеп талый. Яңа яулар күтәрергә көч-куәт юк... Малаемның ахмаклыгы өчен мине кичер. Үз кызымны сиңамы, малаеңамы биреп

туганлашыр идем, анысы да юк. Зөлфиям хәзәр каганының хәрам сараенда… Ә зиннәткә-малга кызыгасың икән, арбаларым әнә. Шуннан ары сынык алтын, сынык көмеш тә юк. Өстемдәге киемнәрне салдырып алсаң гына…

Касьян күңеле саңгырау түгел икән. Чынлап еласаң, сукыр күздән дә яшь чыга дигәндәй, Мөхәммәт хан ачыктан-ачык сөйләве белән Ростов кенәзен аркасына салды. Ул төнне әче бал, мәҗлес, бетмәс-төкәнмәс вәгъдәләр белән үткәреп җибәрделәр. Икенче көнне үк Касьян кенәз үз биләмәсенә кайтып китте. Әле һаман тыныч лык таба алмаган Мөхәммәт хан чирмешләр ягына чапкыннар юллап караган иде, Тимер-Мөэминнең шартын җиткерделәр.

— Гаебемне беләм, тәхетне өмет итмим. Атай миңа Тубылгытауны бирсә, эт баласы сыман шуышып кире кайтам. Бирми икән, бар чирүне алып, хәзәр каганы янына ялчы булып китәм…

Икеләнү-газап эчендә бер ай вакыт узды. «Акыл — күәс чиләге төбендәге әче камыр да, бер чеметем тоз да түгел шул ул, аны күршеләргә кереп кенә әҗәткә алып булмый», — дип әрни-тилмерә сызланды хан. Ә аннары инде, янып көлгә кала язгач, әрсез улы янына яңа чапкын куды.

— Кайтсын, ачуланмыйм, Тубылгытауны бирәм.

39

Атна буе барган сырхау-газаплардан соң Мөхәммәт хан үзенең ятагында төнге күл өстендәге үрдәкләр шикелле шым да итми йоклап ята иде, тиз-тиз атлап кергән каравылбаш тавышына сискәнеп баш калкытты.

— Әтил каласыннан сәүдәгәрләр кәрваны килеп төште. Алар синең кызың Зөлфияне монда алып кайткан.

— Кызымны? Зөлфияне? — дип, Мөхәммәт хан, сызлануларын онытып, шундук сикереп торды.

Хан үз өстенә әле җиләнен кияргә дә өлгермәгән иде, тын бүлмәгә сулышы капкан Зөлфия йөгереп керде.

— Әти, әтекәем!

Мөхәммәт ике адым алга атлады да тәмуг газаплары кичеп кайткан кызын көзге яфрак шикелле калтыранган кочагына кысты.

— Балакаем минем, балакаем!

Бер-берсенең кочагыннан аерыла алмыйча, байтак тын тордылар. Зөлфиянең тәне песи тырнагына капкан кош баласы сыман сулкылдады, ханның яңагыннан ут шикелле кайнар күз яшьләре акты. Ата кешенең иреннәре, торып-торып, һаман бер үк сүзне пышылдыйлар иде:

— Теге чакта яклап кала алмадым, кичер мине, балам. Кичер, балам.

Ниһаять, Зөлфия үзенең йөзен әтисенең күкрәгеннән алды. Мөхәммәт тәүге тапкыр гашыйк булган егетләрдәге шикелле талымлы һәм туймас караш белән томырылды аңа. Үз күзләренә үзе ышанмады. Егерме яшен яңа тутырып узган Зөлфиянең ирен читләренә, күз тирәләренә җыерчыклар яткан. Чигәләрендә, маңгай өсләрендә дистәләгән чал чәч ялтырый. Күзләре сүнеп баручы учакныкыдай нурсыз, салкын, төссез. «И-и, балакай! Сират күперләрен кичеп кайткансың икән бит син!»

Зөлфиянең киемнәре дә үзгә. Балтырларын кереш белән буган киң балаклы буйлы-буйлы ыштан. Ияргә атланырга җайлап куйган төсле алгы итәкләрен бил тиңентен кискән җилән-халат. Беләкләрендә, муенында сары гәрәбәдән тезгән сәйләп-муенсалар. Чәчен, ат койрыгы сыман ясап, артка салындырган. Колак яфракларында бизәксез-нисез тәлинкә чаклы алка. Бармак очларында махсус үстерелгән мул тырнаклар. Гаҗәп, Зөлфия хәзер сөрмә-иннекләрне дә мул куллана икән. Аның ике кашын-керфекләрен чигәләренә чаклы сузган сөрмәләре болгар кызын бөтенләй чит-ят кавем баласына әйләндереп куйган.

Аш бүлмәсенә чыга башлагач, кызының атлап йөрешен күреп, ата кеше янә хәйран калды. Зөлфия аягына кысан башмак кигән сыман вак-вак итеп атлый, корсагы алга чыккан. Атлаган саен йөзе җимерелә, сызлануын сиздермәскә теләп, иреннәрен тешли. «Әллә берәр төрле чире бар микән дә, каган моны шул сәбәпле азат итте микән?» — дип шөбһәләнеп уйларга мәҗбүр булды ата.

Табын янына утыргач, Зөлфия Әтилдә булып узган хәлләрне ике-өч сүз белән генә бәян итте:

— Урыслар бәреп кергәч, каган каладан чыгып качты. Мине Әтилдәге болгарлар коткардылар. Рәхим байга ияреп монда кайттым. Дала буйлап кына, кача-поса…

Мөхәммәт хан кызының сәламәтлеге турында кабат-кабат сорап караса да, Зөлфия һичбер төрле җавап кайтармады. Аның каравы мунчадан соң имче карчык кереп тишкән серләр хан бәгырен тимер ыргак сыман телеп үтте.

— Хәрамханәдә бахырның бар әгъзасын актарып эштән чыгарганнар…

Икенче таңда әтисе янына килеп керүгә үк Зөлфия тик бер сорауны гына бәгыреннән сыта-сыта дәште:

— Бәнҗәдәге Булат атлы батыр күптән өйләнгәндер инде, әйеме, әткәй?

Мөхәммәт хан, кызының ярын җуйган аккошныкы шикелле сагышлы һәм өметсез карашын тотып алгач, утка пеш-

кән карак хәленә калды. Ул йөзен аска яшерде, кызының күзләренә күтәрелеп кабат бага алмады. Җавабы да иләк аша үткәргән шикелле өзек-өзек чыкты.

— Булат батыр... юк инде ул, балакаем. Сине коткарам дип... каган чирүе артыннан барып... әрәм булды...

Кичен Болгардагы Җәмигъ мәчет манарасыннан кәүсәр чишмә челтерәве кебек саф тавышлы бәхетсез бер кызның җыруы ишетелде.

Вак инешләр кушылып, гөрләп ага
Дәрьяларга, олы Итилгә.
Газиз башың, әй, хур була икән,
Япа-ялгыз калсаң чит илдә...

Иртән манара янындагы чирәмлектә Зөлфиянең җансыз гәүдәсенә тап булдылар.

40

Киевка кайтып кергәч, Святослав үзен беренче мәртәбә чын хуҗа шикелле иркен тотты. Әнисе Ольга сырхаулап түшәк өстенә ауган, уллары Ярополк белән Олег читтә. Владимир, Киев боярлары билгеләгән сынауларны үтеп, исәнсау көенчә кабат әйләнеп кайткан. Күргән михнәтләре турында кыска гына сөйли:

— Күпчелек вакытны мәгарәләр эчендә үткәрергә туры килде. Кулга нинди җан иясе килеп капса, шуны ризык иттем. Бака, күсе, әрлән, кыр кәҗәсе, тиен — берсе-бер калмады. Ике мәртәбә үлемнән чак котылдым. Берсендә ач аю килеп ябышты, икенчесендә бүреләр көтүен турап качтым. Иллә мәгәр кыргый җанварлар янәшәсендә көн күрүе хәвефсезрәк икән...

Сорап тору артык: Владимир үзенең әле һаман эт типкесендә йөрүе белән риза түгел. Сынау үтсәң кенәз итәбез, дип вәгъдә бирсәләр дә, боярлар Владимирны тәхет-биләмәләр тирәсенә якын җибәрмиләр. Святославның хатыны Евпраксиянең теле элеккечә, һаман игәү сыман.

— Уйнаштан туган малаең турында сүз кузгатып авыз пычратмале! Үз өеңдәге ике улың үсеп килә, менә шуларга зур-зур биләмәләр өләшергә вакыт...

Сөйкемлеме, сөйкемсезме, хатын ул — күләгә кебек. Аны чөйгә элеп куеп кына чыгып качып булмый. Святослав та дәшми-тынмый гына җай эзләде. Балтыйк буендагы Новгород каласы әле булса кенәзсез-хакимсез көенчә яшәп ята икән. Святослав боярлар белән дә, кенәзбикәләр белән дә киңәшеп маташмады, Владимирга ерактагы шул каланы бирде.

— Бар, тәхетләренә утыр, идарә ит. Әбиең элегрәк аларга башлык итеп Ярополк белән Олегны җибәреп караган иде дә, Новгородныкылар кире куды. Алар баш июне яратмый, алар вәкарь. Ләкин мин синең ялгызыңны гына җибәрмим, наиб итеп сиңа үз агаңны — Добрыняны бирәм. Монда аны дошманнарның суеп ташлавы бар, Новгородка куллары җитмәячәк. Ерак калада, ичмаса, баш сакларсыз. Бергәләп тотынсагыз, Новгородны кулга алуыгыз да мөмкин. Ятып калганчы, атып кал, ди. Әйдә, тәвәккәлләгез…

Владимир белән Добрыня чыгып киткәннән соң ай артыннан айлар уза торды, Киевка бертөрле дә яман хәбәр кайтып ирешмәде. «Һе, каенана сыман пырдымсыз Новгород халкына да ачкыч табар кияү табыла икән», — дип, үзүзен юатты Святослав кенәз. Аннары утлы кисәү шикелле хатирәләр хәтер казанын кыздыра башлады. «Мине Әтилдә алан белән бәҗәнәк җайдаклары гына мыскыл итте. Сораннарның өсләренә үч алырга барам!»

Җәй башында каладан калаларга катгый фәрман очты:

— Яңа яу сәфәренә кузгалабыз. Кала кенәзләре берәр меңлек дружина белән шундук килеп җитсен!

Киевка егерме биш меңгә якын сугышчы кереп тулгач, хыянәт ачыкланды. Кырпу-ат таулары[1] итәгендә утырган Аксайгак каласыннан Богдан атлы кенәз бер йөз кешелек тә чирү җибәрмәгән.

— Алга, әүвәл Аксайгак өстенә! — дип җикерде котырынган хаким. — Кирмән урынында кара казык кына утыртып калдырабыз!

Талау сәфәренә чыккан алайларга олау-биштәрләрне кайсы төбәк байлыгы белән тутыруның аермасы гел юк. Аксайгак каласына ач бүреләр көтүе сыман барып ябырылдылар да сарык тиресе урынына өзгәләп ташладылар. Шәһәрдәге халыкның урак өстенә дип хәстәрләп куйган һәм кимичә, күз карасы кебек саклап тоткан чабаталарына тикле талап чыкты алар. Святослав шуннан ары гына төп гаскәрне бәҗәнәкләр өстенә алып китте. Көрпәле кенәзнең гадәти кисәтүе инде Киевтан ук чыгып очкан иде.

— Әзер торыгыз, сезнең өскә барам!..

Бәҗәнәкләр хакиме Коркыт хан баскыннар ташкынын Тын белән Сал елгалары кушылган үзәнлеккә килеп каршылады. Ул Святославны бәҗәнәкләр җиренә бөтенләй аяк бастырмаска ниятләгән иде. Ләкин урысларның егерме биш мең кешелек коточкыч гаскәр туплап чыгу мөмкинлеген күз чалымына да китереп карамаган. Шулай да Коркыт хан — дала яугире ул. Тау мәгарәләре, үзәнлекләр-ерымнар эченә

[1] Кырпу-ат таулары — Карпат таулары.

качып көткән дошман тозаклары аның өчен кыргый яңалык түгел. Сабый чактан башлап кырыкмаса кырык төрле дошман белән яуга кергәне бар, Аллага шөкер, башы исән әле. Бу юлы да бозлы яңгыр астында калган тавык көтүе кебек калтырап төшмәде, кыю, төгәл әмерләре яңгырап ишетелде.

— Камай, Әҗми! Гаскәрне икегә бүлегез! — дип кычкырды ул үзенең яубашларына. — Бер төмәнне Тын дәрья артына алып чыгып, кәстәнә урманы эченә яшерегез. Икенче төмән белән үзем монда калам.

Тозак төмән күздән югалуга, Коркыт хан калган җайдакларын ике елга яры буйлап чылбыр сыман итеп тезеп куйды. Чылбыр сыек, ике-өч кенә саф. Дошман чөй ясап яисә йодрыктай тупланып килсә, майга кадалган хәнҗәр шикелле үтәли тишеп чыга. Коркытка шул гына кирәк, аннары ул ике канат белән ике тәртә сыман китереп сылаячак.

Коркыт хан җансакчылар алае, яраннары белән Тын елга ярындагы калкулык өстенә менеп басты. Үзе алда. Кыяфәт сокланырлык. Канга буяп чыккан төсле кызгылт аргамагы уйнаклап, биеп тора. Йөгән, ияр, өзәңге-дирбияләр — һәммәсе дә алтын тәңкә белән бизәкләнгән. Садагы, хәнҗәр кыны, җиләне дә алтын җепләр кушып нәкышләнгән. Ә муенына озын челтәр яткан биек очлымы, кылычы, күн бияләй кунычлары гап-гади, саф корычтан. Коркытны ерактан меңбашы яки җансакчылар түрәсе дип кенә кабул итәр идең, аның очлым түбәсендә тавис йоннары белән бизәлгән нәфис башак җилферди. Аның ише билге башка бер генә җайдакта да юк.

Коркыт ханның йөзе чүл гарәбенеке төсле кара янган. Хан, хаким, меңәрләгән җаннар хуҗасы дип, кыйланып-эреләнеп, сарай эчендәге тәхеттә генә утырмый бу, димәк. Яңаклары җилдә яргаланган. Чал йөгерә башлаган мыек чылгыйлары ике яклап ияккә асылынган. Борын өстенә бөтәрләнеп килгән куе кашлар астында ике күзе күмердәй янып тора. Карашында икеләнү-шикләнү дигән коткыларның эзе дә төсмерләнми.

— Ана бүре, кыргый ана бүре, — дип бәяләде Святослав, тау башында балбал сыман басып торучы Коркытны күрүгә үк.

Аннары инде карарын да әйтте:

— Иң беренче булып, әнә шул бүрене үтерәбез. Э-э-эй, Аксайгак гыйсъяннары! Гөнаһыгызны юарга сезгә форсат чыкты. Миңа Коркыт бүрене тотып китерегез!

Бояр тиуннары, җансакчылар Аксайгак каласыннан җыеп китерелгән алты-җиде йөз ирне сөңге, кылыч очлары белән төртә-төртә калкулыкка таба куалады. Сарайларга, келәтләргә качкан җирләреннән йолкып чыгарылган кешеләр бит, мескеннәрнең кыяфәт шәптән түгел. Кайсы өстенә итәге чел-

тәрләнгән иске бишмәт, аягына тишек чабата кигән, кайсы яланаяк, бер генә кат киндер күлмәктән. Чирү дип аталган бу көтүнең артысы сөлге белән кылыч эләктереп өлгергән, калганнарының кулында чалгы кисәкләре, сәнәк, күсәк. Тормыштан инде әллә кайчан ук гайрәт чиккәннәр, ахрысы, сугымга озатылган сарык көтүе урынына тота-каба торып йөгерделәр. Барган шәпкә җан ачысы белән кычкыралар.

— Илем өчен түгел, балаларым өчен!

— Шушы көнгә калдырган җансуярга ләгънәт!

— Ләгънәт, лә-ә-әгъ-нә-ә-әт!

Бичаралар хан менеп баскан тау битенә дә җитә алмадылар. Бәҗәнәк мәргәннәре аларны ат өстендә утырган килеш кенә сәрпи ук очыртып кырып салды. Болытлар шикелле акрын-ипләп кенә аккан Тын елга ярында берничә минуттан соң фәкать ыңгырашу-сызлану авазлары гына ишетелә иде.

Святослав бернинди бәла-каза күрмәгән кешедәй, дәртле тавыш белән кычкырып фәрман бирде:

— Чернигов белән Оскол меңнәре, алга! Аксайгак хәерчеләренең хурлыкларын юып кайтарыгыз!

Святослав Коркыт хан чигенмәс, үҗәтлегенә барыр, дуамалланыр дип өмет иткән иде, бәҗәнәкләр хакиме калкулыкны вәкарь ир очсыз фахишәсен ни рәвешле көндәшенә калдырса, шундый ук җиңеллек белән ташлады да китте.

— Куркак җан! Боламык, чүпрә! — дип, Святослав ярсый-ярсый җикеренгән булды, Коркыт хан, төкерәм мин сиңа, дип котырта диярсең, әйләнеп тә карамады.

Святослав тәмам туарылды, үзен-үзе белештерми шашты.

— Яуга, яуга! Болар дала бүресе түгел, хуҗа ыргыткан сөяк хакына ялланган эт көтүе. Боларга таулар арасына качып сарыклар гына көтеп йөрисе бар. Алга, алга! Бу куркак этләр өерен турап бетерегез!

Урыс алайлары бәҗәнәкләр өстенә оясыннан чыгып качкач яңа агач куышы тапкан умарта күче сыман ябырылды. Бернинди хәйлә белми болар, тозакны абайламый. Арыш көлтәләрен чабагачлар белән кыйнарга чыккан игенчеләр кебек, күсәк-кылычларын болгый-болгый, болар, мүкләк сыер төсле, алга-артка карамыйча, чабаталарын сөйрәп атлауны гына беләләр. Нәтиҗәдә Коркыт ханның тозагына килеп эләктеләр. Аның Тын белән Сал елгалары буйлап тезелгән ике чылбыры хәвеф сизгән кош канатларыдай капылт җыелды да урыс чирүен ике яклап кабат китереп кысты. Үзәнлек тар, чолганышта калган урыс сугышчылары мичкәгә тутырылган маймыч шикелле кайнаша, чигенергә качарга бер ара юк. Бәҗәнәкләр очырган һәрбер ук дияр лек чираттагы корбанын эзләп таба. Үзәнлек өстендә кычкырыш, мәхшәр, тәшвиш.

— Ни пычагыма дип кенәз безне бәҗәнәкләр өстенә алып килде? Боларның һәркайсы ат өстендә, ә без ничек качыйк?

— Көбә күлмәкләр юк, тимер калканнар юк, ничек сугышасы?

— Үлем үзәненә килеп каптык, үлем үзәненә!..

Шулай да сан сан инде ул. Егерме биш мең ир-ат булып килгән гаскәр берзаманны бәҗәнәкләрне елгалар ярына илтеп кысрыклады. Урыс ирләренең тегермән канатлары сыман бертуктаусыз әйләнеп торган кылыч-чукмарлары меңәрләгән бәҗәнәк җайдакларын иярләреннән суырып алды, сытты, чәрдәкләде. «Дуамал орышта бу урман-саз карачкыларына каршы торып булмый икән», — дип нәтиҗә ясады Коркыт хан да, дошман өстен чыга башлаган бер минутта. Шундук әмер бирде:

— Артка, артка, елга аръягына!

Бәҗәнәк җайдаклары куна тактасыннан җил себереп төшергән кибәктәй капылт юкка чыкты. Урыс алайлары алачык мичендәге тимер сыман кызган иде инде, калканнары-кылычлары белән суга сикерделәр. Арттан Святослав шашып куалады.

— Алга, алга! Бәҗәнәкләрне кырып бетерәбез!

Коркыт хан тозактагы төмәнен тезеп караса да, файдасы күренмәде. Тау түбәсеннән ычкынган таш өерен хәтерләтеп килгән урыс алайлары яңа төмәннең алгы сафларын да сытып-җимереп узды. Дошмандагы мондый чая дуамаллык дала яугирләренең өнен алды бугай, әле бер, әле икенче баштагы җайдаклар йөзәрләп-йөзәрләп кача башладылар. Йөзен әче әрем капкан шикелле сыткан Коркыт ахырда җансакчыларына тешләрен кысып ысылдарга мәҗбүр булды:

— Оран салыгыз. Бердәм чигенәбез.

41

Святослав бәҗәнәкләрне пайтәхетләренә чаклы тын да алдырмый куды. Кенәз инде боларны ояларына кереп бикләнерләр дип өмет иткән иде, Коркыт хан Тын елга ярында утырган Саркел каласын урап кына үтте. Күзләрен акайтып төбәлгән меңбашларга Коркыт көнбагыш ярган шикелле ансат бәян итте:

— Диварлар эченә, тозакка барып кермим. Илсез калсам калам, әмма чирүсез калмыйм.

Меңбашлар арасында пышылдашу, ризасызлык тугач, янә кушып китте:

— Әнә Йосыф каган да әүвәл Әтил каласын ташлап чык-

кан иде. Соңыннан үзе шушы урман карачкысын кибәргә элгән бозау тиресе урынына умырды, өзгәләде. Шулай түгелмени?

Ниһаять, ризалаштылар. Бәҗәнәкләр гаскәре, Маймыч[1] елгасын кичеп, Көбә үзән ягына чигенде. Святослав Саркел диварларын җимереп керде. Керүен керде, әмма ике-өч урамны айкап чыгуга ук акайды да катты. Моның исеме генә пайтәхет икән ләса! Кая карама, саман шакмаклардан төзелгән йорт. Тәрәзәләренә карындык тарттырып куелган, түбә урынына камыш. Ихатадагы агач сәкеләр, катлы-катлы челтәрләр өстендә эремчек кибеп ята, сарай артларында кавын-карбыз үсә, йөзем бакчасы бар. Боларны иярләр өстенә төяп буламыни? Төясәң дә, ни пычагыма кирәк? Байлыклары, алтыннары кайда?

Кала уртасына җитәрәк кенә таштан салынган йортлар тезелеп китте. Коркыт хан сарае әнә нәкъ уртада, калкулыкта икән. Тирә-юне бакча, вак-вак күлләр, җиде-сигез манара кукраеп утыра. Кенәздән дә алдарак Чернигов сугышчылары килеп җитешкәннәр. Алар инде әнә сарай артындагы келәтләрдән сыртларына салып савыт-саба, ефәк-парча төргәкләре, тимердән ясалган кылыч-калкан ташый.

Сарайга узгач, затлырак күренгән беренче бүлмәдә үк алты-җиде иргә тап булдылар. Көмеш җепләр белән нәкышләнгән җиләннәренә, йомшак күн итекләренә карап, боларның хан даирәсендәге түрә яки туган-тумача икәнлеген чамалау кыен түгел. Аныграк сорашып торырга ара да бирмәделәр.

— Ханның казна сакчылары, битекчеләр, мулла-имам болар, — дип пышылдады Святославның колак төбендә инде баскыннар ягына авышкан бер сатлык җан.

Святослав әүвәл түрәләргә ияк кагып дәште:

— Хан казнасы кайда?

Түрәләрнең уклау йоткан сыман сүзсез торуын күргәч, җансакчыларының берсенә ым ташлады. Кылыч ялтырап алды, бер түрәнең башы идәнгә тәгәрәп төште. Святослав янә мәгарә салкынлыгы белән соравын кабатлады:

— Ханның хәзинәсе кая яшерелгән?

Бәҗәнәк ирләре эндәшмәде, тик алар да берәм-берәм башсыз калып ауды.

— Табарбыз, сездән башка да бик тиз ачыкларбыз, — дип, кансыз, канәгать рәвештә сөйләнде баскын кенәз. — Хуҗасын сатмый торган этләрдән азат халыкларның булганы юк әле.

Святослав, җил-җил атлап, сарай түренә томырылды, яран-

[1] Маймыч — бүгенге Маныч елгасы, Дон кушылдыгы.

нары чак-чак җитештеләр. Хан залының ишекләрен тибеп ачуга, һәммәсе дә таш балбал шикелле катып калды.

Залның нәкъ урта бер җирендә хәнҗәрдәй казык тешләрен ыржайткан ике каплан йөри. Идәнгә утлы күмер сибелгән төсле бик тә сагайганнар, хәвефле ымсыну күрсәләр, болар теләсә кемне ботарларга әзер. Аларны чакырылмаган кунаклар өстенә сикерүдән муеннарына тагылган нечкә чылбырлар гына тотып тора төсле. Чылбырларның очы тәхет ягына сузылып юкка чыккан.

Зал түрендә, өстенә ефәк-парчалардан махсус чатыр корып куелган калкулыкта, ап-ак яулыкларга төренгән ике хатын утыра. Артларында берсеннән-берсе сабыйрак өч кыз, ике малай. Хатыннарның берсе яшь, төскә-биткә чибәр. Икенчесенең яулык читләреннән чалара башлаган чәчләр күпереп чыккан, йөзен язгы басуныкына охшаш ерганаклар ярган. Күзләре көл сипкәндәй төссезләнсә дә, карашы горур, тәкәббер, вәкарь. Үзе башлап, шунсы сүз ташлады.

— Гөнаһсыз кешеләрне газаплама. Хан хәзинәсенең кайда икәнлеген барыбер белә алмассың.

— Син кем, Коркытның хатынымы? — дип сорады кенәз, моны ачыклауның отышы булмаса да.

Өлкән хатын ияген калкыта төште.

— Коркыт ханның әнисе булырмын мин. Телем-телем итеп турасаң да, мин улымны сатмыйм. — Ана кеше якыннарына таба баш изәде. — Хәер, киленем дә, оныкларым да сатмый. Өркетергә маташып азапланма. Без сезнең кебек урман кыргыйлары нәселеннән түгел!

Ярсудан үзен-үзе белештермичә, Святослав ике генә адым алга атлаган иде, капланнар, коточкыч ырылдап, аның тарафына сикерделәр. Корыч чылбырлар гына кенәзне үлем тырнагыннан саклап калды. Святослав капылт артка томырылды, бөтен тәне энә кадагандай куырылды, мизгел эчендә шабыр тиргә батты. Артына әйләнеп күз ташлаган иде, тәхетне тирәләп баскан балаларның, аналарның карашында һаман һавалану, нәфрәт, үч очратты. Түземлеге бетте. Бусагадан атлап чыгышлый, меңбашлары тарафына җилкә аша гына әмер атты:

— Ишек-тәрәзәләрне томалап ут төртегез. Бөтен елан бергә янып бетсен!..

Яртылаш янып көлгә әверелгән калага кайтып кергәч, Коркыт хан кара нигез өстенә тезләнеп ләгънәт орды:

— Хатынны алыштырып, балаларны яңадан табып була. Газиз аналарны алыштырып булмый. Әнкәм өчен гафу итәсем юк. Үч алмыйча үлмим. Барыбер башына җитәм. Каргыйм ул кыргыйны. Аллаһтан ялварып каргыйм. Бәддога ул чабаталы урман кыргыена! Нәләт аңа, ләгънәт!

42

Святослав Киевка әйләнеп кайтса, газиз Малушасы җир йөзеннән киткән. Ни булгандыр аңа, бер атна эчендә саргаеп кипте, диделәр. Ат караучы Йомыкый Герасим гына гайре сәер, аеры сүзләр сөйли:

— Евпраксия бер ай буе аучылардан бүреләрнең үт куыгын ташыттырды миңа. Сукыр Маланья йортында камырга шуны кушып икмәк пешерделәр…

Бер ел чамасы да вакыт үтмәгәндер, кенәзбикә Ольга, гел тәгамнән калып, түшәк өстенә ауды. Көннән-көн күзгә күренеп кибә, су да капмый, тәүлек буена сызланып-аунап чыга. Святослав аның янында көн дә елый-елый газаплана, үзе һаман керә. Үз-үзен, күңелен, хисләрен аңлый алмый. Югыйсә шушы ана аңа Тәңре ярәштергән Малуша белән кавышырга ирек бирмәде, Владимирны туган онығы итеп танымады, Святославның үзенә гел-гел аяк чалды. Ә хәзер менә җир йөзендә шушы анадан да газизрәк бер бәндә юк. Әби-бабаларның «кан тарту» дип сөйләгәннәре шушымы соң әллә?

Улы кергән саен, кенәзбикә Ольга, иреннәрен чак-чак кыймылдатып, һаман бер үк сүзләр тәкрарлады:

— Яуга йөреп кенә илне ныгытып булмый. Сабый бала сыман өлкән туганга тартыл. Безгә абый кеше — Кайсаркала. Юнаннарга елышырга кирәк. Җиһанда гадел дин тик аларда гына. Христиан динен өйрән. Шул юл гына безне үсешкә алып чыгар…

Бер таңда кенәзбикәнең гәүдәсе Святославны тынсызхәрәкәтсез көе каршылады. Карт ананы Үзи елгасы ярына чыгарып җирләделәр. Әле үзе исән чакта үк Ольга кабере өстендә учак ягып биюләрне тыеп әманәт әйткән иде. Христиан горефләре буенча тырыштыргач, хушлашу корырак, күңелсез килеп чыкты. Святославка кабер янында япа-ялгыз калу да тәэсир итте бугай, беренче мәртәбә Саркел каласын, Коркыт ханның ут эчендә калган гаиләсен искә төшерде ул.

— Алар мине каргагандыр инде, — дип, үкенеч күленә чумарга мәҗбүр булды. — Аеруча Коркытның карт анасы нәләт укый-укый каргагандыр. Ана каргышы төшми калмый, диләр. Менә җимешен бүген җыям. Киевта минем өчен газиз бер кеше юк. Кире кайтмыйм, аңа аяк тартмый…

Святослав шул көнне үк Киевны ташлады да Переяславец дигән кирмәнгә күчеп китте. Новгород каласына да кенәз хәбәре белән канатланган чапкын очкан иде.

— Киевны Владимирга бирәм. Улым монда кайтсын.

Новгородта яшүсмер улы янында зирәк акыллы Добрыня агасы да булганлыгын искә алмаган иде, тәртәгә тибә торган чыгымчы ат шикелле тискәре җавап кайтты:

— Тәхеткә якын йөргәннәр башын югалта ул. Безгә иске Новгород каласы да ярап тора.

— Алайса, пайтәхеткә Ярополк кайтсын, — дип, кулын өметсез генә селтәп, ул Вышегород каласына яңа чапкын куды.

Үзе айлар буе базга чумган шикелле дәшми-тынмый яшәде-яшәде дә, чукышмыйча тора алмаган юньсез әтәч сыман, Святослав яз көне тагын халыкны яу сәфәренә җыеп чыгып китте.

— Бу юлы Дунайдагы болгарларны тез астына бөгеп салабыз. Алардагы Петр кенәз хәзер кайсар дигән дәрәҗәне йөртә, шуны үзебезгә тартып алабыз, — ди.

Тота-каба яңа пайтәхет төзү белән мәшгуль болгарлар, билгеле ки, көтелмәгән дошман явын кайтарырга әзер тормаганнар. Борын төпләрендә каек-баркас белән килгән алтмыш меңлек гаскәр пәйда булгач, юньле-рәтле каршылык күрсәтә алмадылар. Картаеп барган кайсар үзе яу кырына чыгып та карамады. Акча хакына ялланган угыз белән мадьяр яубашлары каланы ташлап качты. Әле тернәкләнеп кенә килгән пайтәхетне җимерттермәс өчен Петр кайсар Святослав ыстанына каек-каек алтын озатырга мәҗбүр булды.

Кан коюсыз, ансат җиңүдән соң Святослав чик-чаманы җуйды.

— Безгә каршы торырдай каганат юк. Әйдә, Кайсаркаланы барып җимерәбез, — дип, ул бөтенләй акылыннан шашты.

Дунай ярында бик тиз генә баеп алган меңбашлар, бояр-лар, bahадирлар — һәммәсе дә сүз куешкан сыман бердәм булып аны якладылар. Каек-баркаслар, кораблар көньякка юл алды. Ләкин капкан саен калҗа гына булып тормый икән. Диңгездә купкан давыл урыс каекларын йомычка урынына әйләндереп атты. Меңәрләгән-меңәрләгән сугышчылар, туймас кенәзгә ләгънәт укый-укый, су төбенә китте. Исән калганнары Камчы[1] елгасы тамагындагы, Варна буендагы яр өстенә чыгып егылдылар. Святослав һаман акылына килмәде, коры сөяккә калган илдәшләрен һаман алга куды.

Юнаннарга ялланган алан белән угыз шымчылары инде әллә кайчан ук Кайсаркаланы кисәтеп куйган иде. Юнаннар кайсары Цимисхий үзе ниндидер кыргый урыс кенәзе хакына ияр өстенә менеп тә вакланмады. Аның гаскәрен баскыннарга каршы Склир белән Патрикий атлы сәргаскәрләр җитәкләп алып килде. Святослав, әтәчләнеп, юнан пәһлеваннарына каршы орышка үзенең ике bahадирын чыгарып караган иде дә, ач-ялангач ирләр тамчы да елгырлык күрсәтә алмыйча әрәм булды. Аннары урысларны Дунай тамагына чаклы ут уйнатып кире кудылар. Ахырда баскын-

[1] К а м ч ы — Дунай янәшәсендә, Кара диңгезгә коя. Бүген дә шул исемне йөртә.

нар сафында ун мең чамасы гына сугышчы торып калды. Алары да аксак-туксак йә яралы иде. Святослав, май урлап тотылган мәче сыман башын түбән иеп, юнан сәргаскәрләре каршына үзе китте.

— Болгарлар моңа чаклы сезгә ясак түли иде, элеккечә калсын, мин аларга тимим. Кайсаркала Киев өчен һәрчак абый иде, шулай булачак та. Гаскәремне бүгеннән үк кире кайтарып җибәрәм, ә үзем сезнең кайсарыгыз каршына бүләк төяп барам.

Болгарлардан таланган барча алтыннарны юнан корабларына күчереп төяделәр. Баш сәргаскәр Склир алданрак киткән иде, ул урыс кенәзен Адрианополь ярына килеп кайсар Цимисхий белән бергә каршы алды. Святославны гапгади бер көймәгә күчереп утырттылар, үзе ишкәк ише. Ике хакимне күз алдыннан кичерү үзе үк гыйбрәт иде.

Кайсар сөткә чумдырып коендырган шикелле ап-ак аргамак өстенә менеп алган. Өстендә шакмак тәңкәләрдән тезелгән алтын көбә, башында таҗ. Кулына иң очына саф алтыннан ике башлы сәмруг кош ясап куелган кайсар чукмары тоткан. Өзәңгеләр, атның авызлыгы, кайсар кигән бияләй кунычлары, итек типкеләре — бары да саф алтыннан. Кояш нурларыннан аларның һәммәсе дә күзне камаштыра, кайсарга текәлеп карап булмый, ул күктән җир өстенә төшкән зур алиһә кебек. Янында алтын-көмеш җепләр белән чигелгән җиләннәргә, чикмәннәргә төренгән руханилар, вәзирләр, сәргаскәрләр. Артта ап-ак парчалардан, ефәкләрдән корган олы чатыр. Яр өсте, гомумән, әкият, җәннәт, сер, могҗиза сыман. Аңа аяк басу өчен дә йә әүлия, йә пәйгамбәр булырга кирәк төсле.

Ә аста, сагызлары кубып төшкән балыкчы көймәсендә, ишкәкләрдән кулларын аера алмыйча, урыс хакиме утыра. Өстендә тезгә төшеп җиткән киндер күлмәк, балаклары капчык сыман киң киндер ыштан. Бозау тиресен аннан-моннан иләп теккән итекләре авыз ачкан. Бер колакта тимерче чүкеп ясаган алтын алка... Кенәз өстендә шуннан гайре бер байлык юк. Баш түбәсендә бер уч итеп калдырылган чәч тотамы җилдә уйный. Мыек чылгыйлары ияген үтеп, муенына хәтле салынып төшкән. Куллары сөялгә батып, яргаланып беткән. Куе кашлары астыннан төбәлгән утлы карашында кимсенү, көнчелек һәм нәфрәт*.

Үзенең нинди отышлы кыяфәттә торуын чамалый, билгеле. Иң беренче булып кайсар телгә килде:

— Ә мин синең әниеңне, кенәзбикә Ольганы әйбәт белә идем. Әгәр христиан динен алданрак, унбиш-егерме ел элек

* Әлеге күренеш рус рәссамы К.Лебедев рәсеме буенча тасвирланды.

үк кабул иткән булса, бәлки, мин аңа өйләнеп тә куяр идем әле. Чибәр иде, кәһәр!..

Кайсар Цимисхий, башын артка ташлап, ихахайлап көлде. Святослав уртларын шыгырдатып кыскан көенчә көчхәл белән түзде.

— Менә шул мәрхүмә әниеңә рәхмәт укы, кенәз. Аны белмәгән булсам, мин сине үземнең каршыма кол урынына, богауланган көе китертәчәк идем…

Кенәз шуннан соңгы сүзләрне ишетмәде. Чатыр эченә кереп, ишек төбендәге өстәл артында утырулар да, урыс сугышчыларының кайсар каршына капчык-капчык алтын ташуы да төштәге шикелле генә үтеп китте. Святослав өчен иң мөһиме инде ачыкланган иде. Бу җиһанда җиңелмә, адәм мәсхәрәсенә калма, тезгә чүкмә икән. Тәкъдир усал, кансыз, явыз. Тезгә чүккән кешенең башына төкерәләр, ул хуҗа кимереп ташлаган сөяк-санакны ишек төбендә көтеп утыручы мескен эт баласы хәленә кала икән. Сабак алып китәргә кирәк моннан, онытылмаслык сабак!

43

Гаскәреннән аерылып калган, чит-ят илдә йөргән Святослав бу көннәрдә туган җиренең нинди ут эчендә янганын бөтенләй дә белми, шуның белән берникадәр бәхетле иде әле. Ә Кияү каласында янә кан-яшь, кайгы-хәсрәт, мәхшәр.

Урыс гаскәре Кайсаркала ягына төшеп китүгә үк, Киевның имән диварларын ашлык көлтәләре урынына җимерәсыта, Коркыт бәреп керде. Урамнарда кырылудан качып котылган сигез мең ир кенәз сараена кереп бикләнделәр.

— Кенәзегез Ярополк чыгып бирелсен, ул чагында башкаларга тимим! — дип боерды ияр өстендә тау кыясыдай горур утыручы Коркыт хаким.

Кәрниз тәрәзләре ярыгыннан көнләшердәй җавап кайтардылар:

— Кенәз качты, күптән Переяславецтагы кәнизәкләре куенында рәхәтләнә инде.

— Ул чагында сәрдәр тезен чүксен.

Авызларына су капкандай, бер төрле дә җавап бирмәделәр. Коркыт һаман көтте. Берзаманны сарай артындагы келәтләр ягыннан кулына йөгән тоткан, йолкыш кына кыяфәтле ир-ат килеп чыкты. Башында эт талаган сыман йолкынып беткән бүрек, өстендә кырыкмаса кырык ямау салган бишмәт, аякларында ыштыр да урамыйча гына элөктереп чыккан тишек чабаталар. Берьюлы йөз черки кереп тулган шикелле, күзләрен челт-челт йома, юкә бау белән буган ыштан-

нарын әледән-әле күтәргәләп куя. Килеш-килбәте үк акылы зәгыйфь мескеннеке сыман. Өстәвенә, як-ягына каранып, тилемсә тавыш белән кычкыргалап куя:

— Росток, Росток! Кая йөрисең, имгәк?

Бер мәлдә, батырланып, хәтта бәҗәнәк җайдакларына да бәйләнә башлады бу:

— Минем Ростокны күрмәдегезме, оланнар? Бер аягы аксак.

Үзенә таба караш ташлаучы да табылмагач, йолкыш ират кала диварлары ягына атлап китте. Коркыт ханның түзем мичкәләре коргаксый башлаган иде, кәрниз тәрәзәләренә төбәлеп янә аваз салды:

— Сәрдәрне чыгарыгыз каршыма. Сәрдәрегез минем колым булырга риза булса, калагызга тимим.

— Сәрдәр яраланган. Шуны чүпрәк белән бәйлисе бар. Аннары чыгарабыз, — дип суздылар-суздылар да ахыр чиктә kahkaһәле җавап ыргыттылар: — Ат юллаучы булып кыйланып, сәрдәр Претич әнә борын төбегездән чыгып ычкынды бит. Әй, син, ахмак Коркыт!

Егермеләп җайдак, үк шикелле атылып, мәйданнан чыгып очты, бәҗәнәкләр ханы корыган агач сыман хәрәкәтсез калды. Вәт ачыгавыз! Вәт юеш борынлы малай! Көтүче хезмәтен балачактан бирле яттан белүче дала кешесе саналып йөргән була һәм шуны кара эшне татып та карамаган түрәбояр алдый! Адәм мәсхәрәсе, хурлык, оят!

— Сарайга ут төртегез! — дип, үзен-үзе белештерми фәрман бирде Коркыт. — Кансыз урыс минем әнкәйне шулай әрәм итте. Боларны да шул рәвешчә юкка чыгарабыз!

Киев урамнарын ялкын чолгауга үк бәҗәнәкләр көньякка юл алды. Канлы үч сугышы әле һаман тәмамланырга исәпләми иде...

Святославны Үзи елгасы тамагында, бусагалар артына ышыкланып каршы алды ул. Кенәзнең җансакчылар алае саранча көтүе талаган иген басуы шикелле сирәгәеп калган, алары да хәлсез, ач-ялангач. Сәрдәр булып ияреп йөргән Свенельд карт, Киевтан качкан Претичка ышанмалы түгел. Шулай да, Коркыт ханның буар елан сыман сузылган җайдаклар чылбырын күргәч, Святослав качмады, чигенмәде, иң беренче булып яуга томырылды. Бу орышның соңгысы икәнен дә, үч явының фәкать җан кыю белән генә тәмам буласын да аңлый, тоя иде. Үк шикелле төбәлеп, ул туп-туры Коркыт каршына барды, курыкмыйча шарт-таләбен куйды.

— Кылычтан орышабыз!

Кайчандыр берүзе ун ир-атны турап сала торган Святослав хәзер инде кибеп беткән корык сурәтенә охшап калган иде. Гомер буе ауга йөреп, кылыч болгап үскән дала яугире-

нә каршы тора алмады. Бер-ике мәртәбә капландай сикерүгә үк, Коркыт хан урыс кенәзенең муенын кыеп атты. Аннары кичәге дошманының башын бөтенләй кисеп алды да аны бәҗәнәкләр арасында иң мәһир кул остасы саналып йөргән җайдак итәгенә ыргытты.

— Моннан касә яса. Дошманнар каршында киләчәктә юри шуннан эчәм.

Яудан биш-алты иярчене белән бергә карт төлке Свенельд бояр гына качып котыла алды*.

44

Киев каласына үги бала сыман гел михнәт-хәсрәт чигеп, елап-сыктап яшәргә язган, ахры. Олуг кенәз үлеме турында хәбәр кайтуга биш-алты ай вакыт та үтмәгәндер, урыс илендә коточкыч яңа чир канат ярды.

Святослав хәл итеп киткәнчә, Ярополк инде ничә еллар буе Киевта утыра, Олег Коростеньда, Владимир Новгородта яшәп ята иде. Кайсы углының бөек кенәз булып калачагы хакында әтиләре әманәт әйтмәгәч, әлбәттә инде, туганнар берберсенә баш бирергә һич тә атлыкмады. Әкияттәге аккош, кысла һәм чуртан шикелле, йөк арбасын һәркем үз көенә тартуны кулай күрде. Калалар арасында чапкын йөртү, хәбәр алышу гадәтләре бетте. Мөгаен, мондый башбаштаклык әле тагын еллар буе дәвам итәр иде, көтелмәгән бәла бар дөньяны әйләндереп атты.

Ярополк беркөнне яраннарын җыеп ауга чыгып китте. Ниятләре — Үзи ярыннан ерак булмаган бер урманда кеш, селәүсен, төлкеләрне сугып алу иде. Төшке аштан кичкә чаклы ияр өстеннән бер дә төшми байтак юырттылар. Кенәзнең йөзе корыган агач ботакларына сыдырылып бетте, бер чокырда абынып аты ауды. Ярополк инде ачуыннан, гайрәт кайтудан шартлар дәрәҗәгә җиткән иде. Шул чагында тирән ерым эченнән биш-алты җайдаклы гына төркем килеп чыкты. Башлыклары — атаклы Свенельд боярның Лют исемле әрсез, ташбаш улы. Моның хакында әле элегрәк тә «байчуралар ишек төбендә ыштырларын сүткән, кәвешләрен каккалаган арада тәрәзәдән кереп, яшьрәк хатыннарын да, кызларын да кызыл әтәч сыман таптап чыга» дип гайбәт сатып көлдерәләр иде. Менә хәзер инде Лют, карак мәче кебек, Ярополк кенәзнең биләмәләренә дә килеп кергән. Корбан итеп өзгәләргә ятим бәрән эзләп тапкан ач бүре шикелле, Ярополк моңа ябырылды:

---

* 972 елда булган вакыйгалар.

— Кызылъяр ягындагы барча урман гомер-гомергә минем атай биләмәсе булды. Син ничек чит утарга аяк басарга җөрьәт иттең, уйнаштан туган нәрсә?

Лютның сыңар колагы да селкенмәде.

— Кем чит утарда йөри дә, кем уйнаштан тумаган чын хуҗадыр әле? Синең әбиеңне яшь чагында гел минем атай куенында яткан, диләр. Без синең белән икәү агай-эне булып чыкмагаек.

Лют корсагына шап-шоп суга-суга, зәһәр кычыткан чаккандай кaһкaһәләп, ихахайлап көлде. Моның әрсез кыланышын, пычрак гайбәтләрен дистәләгән ир-ат ишетеп-күреп торды. Кайнар көе бозлы суга китереп тыккан пыяла савыт сыман, Ярополкның түзем касәсе кисәкләргә шартлап ярылгандай булды. Үз-үзен белештермичә, ул садагына ябышты, икенче мизгелдә бояр улын бугазына кадалган ук ияреннән йолкып, әйләндереп атты…

Улының үлеме турында хәбәр алуга ук, Свенельд бояр Коростеньга очты. Әүвәл древлян аксакалларын күреп котыртты ул, ә аннары, күз яшенә батып, Олег янына керде.

— Абыең акылдан шашкан, Ярополк чирле. Киев боярлары аны сөймәми. Алар атаң урынына тәхеттә сине күрү турында хыяллана. Тәхет даулап килсәң, бар дружина синең якка чыга. Абыеңны үт куыгы сыман кисеп ташлау өчен иңиң күлай вакыт.

Яп-яшь Олегның берьюлы җиде кияү тапкан тол хатын шикелле ни кылырга белми утыруын күргәч, Свенельд ишек катында әзер торган аксакалларга ым ташлады. Тегеләр дә телләрен телгә йоктырмыйча котыртуны белде:

— Игорь бабаң килеп тураганнан бирле древляннар Киев өчен чит-ят. Без һаман шул Киев сорыкортларына ясаксалым түләп интегәбез. Без сиңа ияләштек, син күптән үзебезнеке. Абыеңны тәхеттән алып атсаң, без, древляннар да, сиңа кушылыр идек…

Ниһаять, Олег сынды. Древляннар умарта күчедәй шашып яуга кузгалдылар. Бер илдә дә сатлык яисә шымчы бәндәләрнең бетеп торганы юк. Бер тәлинкә кайнар аш хакына Киевка да соран чапкын очты. Энекәшенең хыянәте турында хәбәр алуга, Ярополк барча дружинасы белән каршы чыкты. Бертуган абзый белән энекәш тиешле кешеләр Обруч дигән кала янында, кырда очраштылар. Олег яуга йөреп чыныккан, орыш күреп үскән сәрдәр түгел. Ярополк үзенең җайдакларын бәҗәнәкләр алымы белән ташкын итеп яуга ташлауга ук, Олег, әмер-фәлән биреп тормыйча да, кала ягына качты. Аңа йөзәрләгән, меңәрләгән ирләр иярделәр. Барча качкын җайдак шәһәр капкасы каршындагы күперчеккә сарык көтүе сыман килеп тыгылышты. Арттан кил-

гән ташкын әүвәл Олегны йомычка урынына күпердән алып атты, аннары яшь кенәз өстенә йөзәрләгән ат гәүдәсе очты…

— И-и-их! Син бит миңа бертуган энекәш идең. Абыеңа нигә кул күтәрдең? — дип, әллә юри, әллә чынлап өзгәләнде күпер читенә килеп тезләнгән Ярополк. — Синең җаныңны кыючы дигән хурлыклы дан күтәреп ничек яшим инде? Әгәр, синең өчен үч алырга атлыгып, минем өскә Владимир килсә?..

Юкка гына калтыранды кенәз. Бер мәртәбә бүре авызыннан качып котылган бәрәннe гомер буе һәр куактан куркып яши, диләр. Кече яшьтән бирле читкә тибелеп үскән Владимир да, Обручтагы фажига хакында ишетүгә, диңгез кичеп, варяглларга качты. Сөяк-санак көткән эт шикелле айлар буе ишекапка төбен саклап караса да, король янына барыбер кертмәделәр. Җавап яңакка суккан шикелле усал, кансыз иде.

— Син колчура Малуша баласы. Король ялчы-колчураларны тыңлап вакыт әрәм итми…

Владимир, тәвәккәлләп, алпар көбәләренә төренде дә варяглар сафында норман гаскәрләренә каршы яуга китте. Заманында, әле яшүсмер көе, ач аю белән алышка чыккан кеше булуы хәтерендә яңаргандыр инде. Бер орыш вакытында норман баһадирын ияреннән сугып очырды ул. Варяглар да тиешенчә бәяләде, ахры, король чатырына якын җибәрделәр.

— Бер мең алпар бирәм, — дип, «мәрхәмәт» күрсәтте баш аксөяк. — Аннары сезнең үз илегездә Рогволод атлы энекәшем Полоцк каласына хуҗа. Ачкыч таба белсәң, ул да сиңа сугышчылар бирер. Новгород каласын кайтарып алгач, миңа бүләк һәм кәнизәкләр юлларга онытмассың…

Ярополк Новгородка яңа хаким утыртып куйган, ә тегесе каланы гына түгел, якындагы чуд белән кривич кабиләләренең утарларын да талап чыккан икән. Кичәге кенәзнең корыч көбәле алпарлар гаскәре белән кайтуын күрүгә үк, барысы да Владимир әләме астына килеп кушылдылар. Ишек төбенә эт шикелле сөйрәп китерелгән хаким колагына Владимир, бармак яный-яный, бер үк сүзләр тезде:

— Ярополкка җиткер. Мине илгә үги иткән өчен аны гафу кылмыйм. Үч алмыйча торып туктыйсым юк. Яуга әзерләнсен…

Король юлламасын тотып кайткан сукбай Владимирны Рогволод атлы варяг кенәзе хәтәр җылы кабул иткән иде. Нияте бүтән икән.

— Ярополк миңа бертуктаусыз яучы юллап тора. Рогнеда атлы кызымның кулын сорый. Вакытында кайттың. Туйда икегезне бер өстәл артына утыртып дуслаштырмый булмас. Ярополк — кияү, син кода тиешле кеше туры киләчәксез. Икегез дә миңа бүләк-санак белән ярдәм иткәләрсез…

Болай да гомер буе иң ачы давылда иксез-чиксез диңгез

уртасында калган ялгыз көймә сыман бәргәләнгән, җәфа чиккән Владимир хәзер инде Рогволодның өстәлләрен әйләндереп ташлардай булып кызып чыккан иде, җиләк-җимеш, шәраб күтәренеп залга кенәз кызы Рогнеда килеп керде. Кәүсәр чишмә суында коендырган шикелле алсу тәннәр, махсус акшарлаган сыман ап-ак толым, төбен күреп булмас зәмзәм коесыдай чиста-зәңгәр күзләр, камыштай зифа буй-сын, пешеп җиткән дәү алмалар кебек төртеп торучы ике дәртле күкрәк.

Рогнеда җиләк-җимешләрне куйгач кәс-кәс басып залдан чыгуга ук, Владимир, ис-акылын җуйган кеше төсле, Рогволодның кулларына барып ябышты да шашып-шашып ялварырга кереште:

— Кызыңны миңа бир, мине киявең ит, мәрхәмәтле кенәз?! Новгородның бар байлыгын сиңа китереп бирәм.

Варяг кенәзе Рогволод сукбай Владимирны юлда табылган эт баласын тибеп очырган кебек итеп кенә үзеннән читкә этте.

— Фу-у! Пычратмале минем керсез тәнне! Ни сөйлисең, йолкыш? Нинди кияү итү, кыз бирү ди тагын? Минем колчура Малуша баласына өләшә торган кадерсез кызларым юк. Үзеңә тиңнәрне әнә йә лапаска, йә базарга чыгып эзлә!..

Битенә лач итеп төкерелгән Владимир бу юлы инде тыелып кала алмады. Ул зал диварларына элеңгән зиннәтле кылычлар арасыннан берсен элөктерде дә варяг кенәзен күз ачып йомган арада икеләйгә ярды. Рогволодның залга атылып килеп кергән ике малае да урыс кенәзенең шашкын кылычыннан котыла алмадылар. Алар да утын әрдәнәсе сыман ярылып ике якка ауды.

Куркынып-өшәнеп залга йөгереп кергән Рогнеданы кочагына сосып, Владимир бер генә сүз әйтте:

— Миңа кияүгә чыкмыйсың икән, сине дә суячакмын!

Ис-акылын җуйган варяг кызы урыс кенәзенә каршы тора алмады. Владимир шушында ук шаулап туй уздырды.

…Новгород, Полоцк, чуд, кривич, варяг сугышчыларыннан, тагын әллә нинди яллы сукбайлардан хасил бетмәс-төкәнмәс яу ташкынын күргәч, Ярополк Киев диварлары артына кереп бикләнергә мәҗбүр булды. Владимир да үз гаскәренең көченә ышанып җитми иде, ике як та ай буена җитди һөҗүм ясарга тәвәккәлләмичә тик торуны отышлырак күрде. Ул арада тәхет язмышын хәл итү астыртын, мәкерле эш йөртә белүчеләр һәм сатлык-хыянәтчеләр кулына күчте. Шулар тау битенә чокып ясалган куыш эчендә ятучы Владимир каршына Киевның Блуд атлы боярын тотып китерделәр. Владимир өстәлгә бер чүлмәк алтын тәңкә чыгарып куйды, фахишәдәй юха елан тавышы белән ысылдый-ысылдый, вәгъдәләрен тезде:

— Киевны алырга ярдәм итсәң, син миңа икенче атам төсле гомер буе якын булачаксың. Тәхеткә утыруга, беренче бояр итәм!

— Син гаскәреңне җый да юри генә чигенеп тор, кенәз, — дип, хыянәтче бояр шундук җавап сүзен әйтте. — Ярополкны синең каршыңа мин үзем китертермен…

Ә ачлы-туклы гаскәр белән камалыштa яткан Ярополк өчен сатлык җанның икенче мәкере дә әзер иде.

— Боярлар сиңа каршы түнтәреш әзерлиләр. Алар сине, арканнарга чорнап, теге уйнаштан туган сукбай кулына илтеп тапшырмакчы. Сиңа, җансакчыларыңны алып, каланы калдырып тору хәерлерәк булыр. Теге сукбай каладан чигенүгә кире әйләнеп керерсең. Ул арада хыянәтче боярларның исемен ачыкларбыз.

Каладан чыгуга, җансакчылар башлыгы, кенәз Ярополк каршына килеп, үзен явыз ир-ат көчләүдән сакларга җыенган гөнаһсыз кыз шикелле ялынып караган иде:

— Әйдә, угызлар йә бәҗәнәкләр янына барыйк та шуларны акчага яллап карыйк, кенәз? Өстәмә гаскәр күрсә, Владимир да кире әйләнеп кайтмас.

Тыңламады Ярополк кенәз. Мие шулпаланган карт шикелле һаман сүзсез-нисез Тын елга ягына чигенүен белде. Аннары инде мәкерле Блуд юллаган чапкын куып җитте.

— Владимир качты. Түнтәреш әзерләгән боярларны зинданнарга яптык. Кенәз кире кайтсын.

Киев диварларына җитеп килгән чакта Ярополк белән аның яраннарын Владимирның тозак алайлары турап атты. Ярополкның көмәнле булып калган хатыны Ангелина да төскә-биткә күзләрне камаштырырдай чибәр иде. Владимир әлеге юнан сылуыннан да баш тартмады, хатынлыкка алды*.

45

Гомер көчек түгел, аны бауга-чылбырга утыртып кына тотып торып булмый. Мөхәммәт хан да биреште, олыгайды инде. Ә күк капусы тәбәнәкләнгән кешенең күңеле астан көчле агымсу ашаган язгы боз шикелле көпшәкләнә, юкара ул. Мөхәммәт хан да, кыртлы тавык урынына, әледән-әле балаларын үз янына чакыра торган булып китте. Җае чыккан саен әле оныклары туу хөрмәтенә, әле яңа мәчет манарасы бастыру уңаеннан корбан чалу мәҗлесе яисә ат чабышы, мәргәннәр бәйгесе үткәреп күңел ачты. Тәртә арасына керә белми торган, чыгымчы Тимер-Мөэмин дә инде күптән хан

* 976 елда булган вакыйгалар.

сарае эргәсендә иде. Көннәрдән бер көнне мәҗлес вакытында юктан гына тавыш чыгарды ул.

— Идел яклап ушкуйлар өере бәреп кергән, чирмеш олысларын тоташ талаганнар, — дип, чапкын кереп хәбәр салган иде, Тимер-Мөэмин шуны эт шикелле каптырды да алды.

— Ме-е-нә-ә-ә, ме-е-нә-ә! Растуфка җавап явы белән барган өчен мине эттән алып эткә салган идегезме? Имеш, Мөэмин туймас тамак та, Мөэмин Болгар иле өстенә яңа яу чакыра. Әнә кыстатып тормады ул шәрә урыс, сәбәпсез-нисез көенчә тагын басып керде. Карак бүре сымак, бер сарыкны сыртка салачак та җәза-кыйнау күрми чыгып качачак ул. Күтәрергә куәте җитмәгән ачудан әле башка малны буып китмәсә ярый тагын. Чирмеш олыслары өчен кан костырырга кирәк алардан! Өсләренә җыелып барырга да Болгар юлын мәңгелеккә онытырлык итеп дөмбәсләргә кирәк! Ә без теләсә кайсы бозау килеп талый-талый имгән чагында да ирек куя торган сыер сымак юаш, ә без ачыгавыз!

Табын янына җыелып утырганнар арасыннан җавап итеп бер Ибраһим гына аваз салды:

— Әйе, без ачыгавыз, без җебегән, абзый кеше, анысын дөрес әйттең. Иллә мәгәр тәхетне вә илне чит-ят дошман өстенә яу йөреп яки талау юлы илә ныгытмыйлар. Урланган мал бер көнлек кенә калжа ул, каптың-йоттың — бетте. Илне әнә суырга әзерләгән мал урынына күреп, үз ризыгың, үз куәтең илә көрәйтергә, симертергә кирәк. Андый малны, гадәттә, басуга чыгарып түгел, аран эченә бикләп симертәләр. Ә безнең Болгар иле — өстенә ыштан кию гадәтен дә онытткан тол хатыннарга охшап калды хәзер. Кем иренми, кил дә эссеңне бас — каршы торучы юк. Без дә шулай. Чикләребез Сура, Ука елгаларына, Нократ башына тикле барып җитә, вәләкин ул якларда бер генә ныгытылган бистә йә кирмән юк. Күршеләрне караклыкта гаепләү, бүрәнә аша бүре куып артларыннан йодрык болгап калу, ай-яй, җиңел ысул. Ә йортыбызга юньле-рәтле ишек илә йозак куя белмәгән өчен, тәүдә килеп, үзебез гаепле ләбаса, фәкать бер үзебез!

— Әй, алай комы коелып, бөкресе чыгып беткән картколарылар сымак көпә-көндез ишек-тәрәзә бикләп көн күрергә җыенасың икән, бар соң, урыс белән янәшә утыр да яшә! — дип, Тимер-Мөэмин шәрран ярып тузынырга тотынды.

Мөхәммәт хан улларының янә әрепләшеп-якалашып таралуыннан куркып калган иде. Сүзләрен кабадан йон тартып җегерләгән шикелле сайлап суза-суза гына ул да үзенең карарын ирештерде:

— И-и-ипләп кирәк, оланнар, и-и-ипләп кирәк. Тимер-Мөэмин угылым да, Ибраһим да хаклы. Дошман килеп кыйнаганда кул кушырып утыру да ару түгел, илне-йортны йо-

закка бикләп кую да бик мәслихәт. Әйдәгез, болай итик. Берәр әмир илә берәр сәрдәр Ука, Сура буена барып әйләнсен дә урыс белән ике арада кирмән-киртә төзердәй урын сайлап кайтсын. Мөэмин улым, турысын әйтим, сиңа ышанып җитмим. Ушкуйлардан үч алырга кыжрап, синең уч төпләреңбии-ик кычытып тора. Бер йөз җайдак биреп юлласаң да, синең күршедәге урыс утарларын талап чыгуың бар. Шуңа, әйдәгез, Ибраһимны юллыйк. Ул бура бурый-бурый шомарган балта сабы сымак ипле кеше, нужа шулпасын да күп төмергән. Яңа кирмән урынын хаталанмый, каударланмый гына тәгаенләп, Ходай кушса, бәлки, әле нигезләп тә кайтыр…

Әмир Ибраһим, бер мең җайдак, балта осталары, ташчылар һәм пешекчеләр алып, икенче таңда ук юлга чыгып китте. Сәйяхчыларны Чулман тамагына чаклы ияреп озаттылар. Хатын-кызлар, бала-чага яшереп кенә балавыз да сыкты. Болгарлылар арасында Тимер-Мөэмин генә учларын угалап, авыз ерып калды. Юкка булмаган бу.

Тоз яларга килгән сыер шикелле, ул шул көнне үк Мөхәммәт хан янында бөтерелеп йөри башлады. Җыры гел бер:

— Ничә айлар буе ауга чыкканың юк. Бәкләр, морзалар сине картайган дип уйлар. Бала-чытырман үзәнендә кыр кәҗәләре белән җәйрән мыжгып тора. Әйдә, шунда киттек.

Тамчы тама-тама ташны тишә, диләр, Мөхәммәт хан да сынды. Ерак олыслардагы морзаларны, кала олугбәкләрен кузгатып тормыйча, курсыбайдагы мәргәннәрне, сарай тирәсендәге түрәләрне генә алып, Чирмешән буендагы үзәнлеккә килеп урнаштылар. Чатырларны корганнан соң җыелган беренче казан янында ук Тимер-Мөэмин янәшәсендә күләгәдәй тагылып йөргән карачкыны күреп, һәммәсе дә дәррәү сискәнделәр. Дөрес, кемнәрнеңдер аны элегрәк тә ерактан гына чамалап-шәйләп калганы бар, әмма йөзгә-йөз килеп очрашканы юк иде әле.

Тимер-Мөэмин аны Ростовка ясаган талау сәфәреннән табып-иәртеп кайтты. Кыяфәте тәһарәтеңне алырдай иләмсез һәм котсыз. Аның каршында йөзьяшәр имәннәр дә чүгеп куя бугай, буе дөядәй озын. Бүреген салса, башы кабак кебек олы, өстәвенә чебеннәр таеп егылырдай пеләш. Ике кулы тезләренә җиткән. Гел бөгелеп йөри. Ә инде йөзекыяфәте! Төшеңә керүләрдән Ходай Тәгалә үзе саклый күрсен! Ике бармак калынлыгы тап-тар маңгай. Карчыгадан йолкып алынгандай кәкре борын. Шуның өстенә бөтәрләнеп килгән куе кашлар. Ике төймә кебек елтырап торучы бәп-бәләкәй күзләр. Табак хәтле чырай, соскы шикелле салынып төшкән ияк. Тарак-сабынның йөзен дә күрмәгән куе җирән сакал. Аңкавына сыймыйча, ирен читләренә бияләй шикелле бүселеп төшкән теленнән селәгәй агып тора. Каеш-

ланып каткан күлмәк-бишмәтеннән үләксә исе аңкый. Албасты дисәң дә албасты бу, башка берни түгел! Тимер-Мөэмин ник ияртkән аны, ни сәбәпле монда алып килгән?..

Икенче көнне ике төркемгә бүленеп, дулкын сыман якякка таралдылар. Тимер-Мөэмин, арт ягына борыч сөрткән шикелле, гел әтисе янында бөтерелде, Ростов карачкысы җиргә убылгандай юкка чыкты. Тимер-Мөэмин Мөхәммәт ханны җәтмәгә эләктергән җәен урынына гел куе таллыклар, баланлык, әрәмәлек ягына сөйри иде.

— Җәйрәннәр шәрә ялан буйлап утлап йөрергә сыер көтүе түгел. Мондый миең кайнап чыгарлык челләдә акыллы мал күләгәдә качып ята бит ул. Күбәләк куа чыккан малай-шалай кебек булма, атай. Әйдә, әрәмәлек эченә керәбез, әйдә инде, әйдә!

Мөхәммәт хан әнә шул рәвешчә кармакка килеп капты. Куак төбенә качып көткән Ростов карачкысы аны чытырман эченә барып керүгә үк ияреннән сарык бәрәне урынына йолкып суырды да, тезләре өстенә аркылы ташлап, умыртка сөяген нәкъ урталай сындырып-өзеп атты. Ә бер-ике минуттан соң үзәнлекне инде Тимер-Мөэминнең тилереп үкергән, тантаналы тавышы каплап киткән иде:

— Мөхәммәт хан вафат, атай вафат! Ул канат астында йөрткән Ибраһим Болгарда юк. Атай урынына мин хан булып калам!..

Ибраһим әмирне фаҗигале хәбәр Елантау өстендәге ыстанда куып җитте. Әле бернинди карарга да килмичә, тирәюньнең гүзәл табигатен күреп кенә ял-табынга тукталганнар иде. Искитмәле урын!

Янда шома тасма булып сузылган Идел җәйрәп ята. Аңа төбе аермачык күренеп торган чиста зәңгәр сулы кечерәк бер елга килеп кушылган. Исемен белүче юк. Елантау астында шул елга яклап дистәләгән чишмә челтерәп ага. Тауның мәгърип һәм шималь ягына эреле-ваклы әллә ничә күл тезелеп киткән. Якын-тирәдә генә чирмеш, мукшы, болгар авыллары яшәп ятадыр инде. Бер-ике күл суына юкә кайрылары китереп тутырганнар. Шушы күлләр янәшәсендә мәһабәт дәү казанны хәтерләткән олы иңкүлек бар. Ул казан эченә ярдәм көч булырдай вак-вак бистәләрне яшереп төзеп була. Шәрекъ ягына таба гәрәбә муенса ташлары кебек сузылган иң олы өч күл ярында кыргый кабан дуңгызлары утлап йөри. Кайбер пешекчеләрнең, морзаларга ияреп, бу якларга элек тә килгәне бар, әлеге зур сулыкны Олы Кабан, Урта Кабан, Кече Кабан күлләре дип атаганнар икән. Әйдә, шулай булсын. Иң мөһиме: яңа кала, яңа кирмән корып кую өчен үтә кулай төбәк. Елантау үзе армас-талмас Идел, исемсез елга, исәпсез-хисапсыз күлләр, хәтфә үзәнлек-

ләр, тирән, киң ерымнар, чокырлар уртасында мәгърур кыя сыман калкып тора. Моның өсте берьюлы ун бистәне сыйдырырдай иркен. Әгәр шушы биек тау читенә бүрәнә диварлар, каравыл манараларын, имән капкалар да төзеп куйсаң, бу кирмәнне бернинди дошман көче дә яулап алачак түгел! Болгар терәге булачак өр-яңа каланы нәкъ менә шушы биеклек өстенә торгызырга кирәк!

Ибраһим Елантау битендә әнә шул рәвешчә хыялланып-очынып тора иде, дала якта җан-фәрман очкан ялгыз чапкын пәйда булды. Ат кадерен белүче ир болай каударланмый, димәк, хәбәре мал кызганып торырдай арзан түгел моның.

Ияреннән сикереп төшүгә үк, чапкын, тезләренә чүгеп, башын җиргә ора-ора әйтеп салды:

— Әмир, бәла! Мөхәммәт хан вафат!

Ибраһим чигәләрен кысып ыңгырашты. Керфекләрен ачкач, иреннәре арасыннан тик бер генә сорау сытылып чыкты:

— Мөэмин үтердеме?

— Ул яллаган катыйль. Ауга чыккач, билен сындырдылар...

Байтак ара үткәннән соң гына әмир Ибраһим ияргә сикереп менде. Ният иткән карары тайпылышсыз, катгый яңгырады.

— Яңа кала өчен бик шәп урын иде, кызганыч, аны ташлап китәргә туры килә инде. Тимер-Мөэмин безгә тыныч-имин яшәргә ирек бирмәячәк. Илне генә түгел, үзебезнең башны да саклап калу өчен ышыграк җир эзләмичә булмый. Хуш, туган ил!

46

Ерак-ераста, Болгар иленнән җиде дала, җитмеш дәрья артында яткан Мәвәрәннаһ җирендә дә канлы сугыш бара. Караханнар каганлыгы белән сәманиләр солтанлыгы ничәмә-ничә еллар буена үзара суешалар. Мондый кырылышка бер гасыр элек үк караханнар хакиме Кадыйр каган нигез салган, диләр. Аннары яу-талашны аның улы-оныклары Басыйр хаким, Садыйк, Сөләйман дәвам иткән. Бүген карлукълардан, чагыл, яхмә, төргәш кабиләләреннән торган чирүләрне сәманиләргә каршы Сөләйманның малае чыбыркылап куа. Аның чын исемен белүче дә юк. Кара халык арасында фәкать кушаматы белән генә искә төшерәләр — Бөкре Карун.

Сал-Сал батыр ике ел буена менә шушы яу эчендә йөри. Аны каган җайдаклары Алатау өркәчләре артына кереп качкан кышлактан нәкъ ул балигъ булган көнне алып китте. Әүвәл гади нәүкәр булып йөргән иде, хәзер инде түрә. Соңгы өч

ай дәвамында әмир Әбүгали курсыбаендагы йөзбашы ул. Мондый мәрхәмәткә, мондый дәрәҗәгә юлыгуның сере бик зур.

Беркөн төнлә Сал-Салны тирмәдән биш йөз җайдак башлыгы булып исәпләнгән Гайсә батыр үзе уятып алып чыкты. Сал-Сал шундук пыш-пыш килеп төпченергә тырышып карады, тик Гайсә бер сүз дәшми. Кирмән елгасы дип аталган инешкә таба иярттe дә китте. Инеш буендагы тирән чокырга төшсәләр, тоташтан тимер көбәләргә төренгән йөзләп җайдак тора. Арада көмеш очлым түбәсенә затлы каурыйлар кадаган бер түрә бар. Чокыр эче сумала төтене шикелле бик караңгы булса да, Сал-Сал аны барыбер чалымлады. Бөкре Карун дип мыскылланган каганның энекәше Фаикъ әмирнең улы Әбүгали бит бу. Аның әтисе Хорасан атлы олы илгә хуҗа, каган һәрчак диванына чакырып киңәшләшә торган зур аксөяк. Әбүгалинең үзенә бертөрле дә аерым биләмә-кала эләкми бугай әле. Ул хәзергә каганның канат астында вәзир сыйфатында йөрергә генә мәҗбүр. Менә шул Әбүгали башлап сүз кузгатты:

— Без ният иткән олы эшне җыен әтәк-сәтәк белән илә ерып чыгып булмый. Әүвәл үзебезнең каравыл алайлары тозагыннан сиздермичә үтеп китәсе бар. Алар илә кан коймаска исәп. Ә аннары сәманиләр солтаны Нух-Мансур яшеренгән Бохарага үтеп кермәкчебез. Анда нинди капкын, нинди тозак көйләп куйганнардыр, алдан белеп булмый. Менә шуңа күрә без ошбу махсус нөгәргә бер йөз меңнән артык нәүкәр арасыннан иң-иң елгырларны, иң-иң көчлеләрне генә сайлап җыйдык…

Сал-Сал өчен монысы зур яңалык түгел. Ул үзләренең төмәнендә бер ел дәвамында иң гайрәтле батыр исәпләнә. Аны бил алышында да, мәргәннәр ярышында да һичбер нәүкәр һаман җиңә алмый. Сал-Сал әле барча гаскәр бәйгесенә дә чәчрәп чыгар иде, аның каган-әмирләр күзенә күренердәй юньле аргамагы, көмешләнгән ияре, көбәсе, очлымы юк…

— Үзебезнең тозак чылбыры аша үткән чагында да, сәманиләр җәтмәсенә килеп эләксәк тә, һичбер кемне көтеп торыш булмый, — дип, кансыз тавыш белән кисәтергә онытмады әмир Әбүгали. — Яраланып авучылар табыла-нитә калса, андыйларны ташлап китәчәкбез.

«Безнең баш бәясе, ай-һай, кыйбат икән!» — дип, эчтән генә янып сыздылар. Йөзләрендә ул-бу чагылмады. Һәркем аңлый иде: Әбүгали аларны бик тә тар кешеләр даирәсенә тартып кертте, бәлки әле каган колагына да барып ирешмәгән яшерен сер ачты, моны тишкән шалпавызга исән котылу юк…

Караханнар чиген саклаучы тозак чылбырын, басу-кырдан үз ихаталарына кайтып баручы казлар көтүедәй тезелеп, бик сак кына үтеп китмәкчеләр иде дә, исән-имин котыла алмады-

лар. Каравыл алайлары боларны сәманиләр ягына качып китүче сатлык җаннар дип кабул иткәннәрдер инде, куа чыгып, өермәдәй ук яңгыры очыра башладылар. Егермедән артык җайдак җиргә егылып калды. Гайсә батырның беләге генә яраланган иде, Әбүгали аны үзе барыбер икегә телеп атты.

— Минем аягыма герләр кирәк түгел…

Ә инде Бохара диварлары каршына барып җиткәч, Сал-Сал, шайтан биетүне күргән төсле, авыз ачты да катты. Монда әмир Әбүгалине көтеп торганнар лабаса! Ул бер манара каршына басып күренүгә үк, асылмалы күперне төшерделәр дә ян капкадан эчкә уздырдылар. Карахан җайдаклары исәпсез-сансыз сәмән йортлардан, йөзәрләгән пулат-алачыктан, эреле-ваклы манараларлардан хасил кала урамнарын да тоткарлыксыз үтте. Шәһәрне икегә бүлеп аккан Чәрсу инеше ярында, Солтан Нух-Мансур үзе яшеренгән мәһабәт таш кирмән капкалары каршында гына усал туктаттылар.

— Әмиргә үзе белән ун җансакчы алып керергә генә рөхсәт, башкалар монда кала.

Әбүгали юлда вакытта сынап-бәяләп өлгергән, ахрысы, ул үзе белән Сал-Салны да алды. Нух-Мансурның ерак бабасы Исмәгыйль Сәмани үзе төзеп калдырган кирмән эченә кергәч, егет яңа дөньяга килеп эләккән шикелле гел шаккатып барды. Шушы таш диварлар эчендә дә дүртме-бишме сарай, кайсы түгәрәк итеп, кайсы сигезпочмаклап ясалган биек манаралар, шифалы яңгырдан соң үзара ярышып үскән гөмбәләр шикелле ак пулатлар. Аларның диварлары гына түгел, баскычлары, түбәләре, хәтта ихаталары да төрле-төрле төстәге ташлар, пыяла шакмаклары белән бизәкләнгән. Зур мәйданның һәрбер почмагында зәйтүн, күгән, элмә, хөрмә, әфлисун агачлары чәчәк атып утыра. Уртада агымнары төрле биеклеккә сикереп уйнаклаган фонтан. Аның тирәсендә гөлләп, лалә, канәфер, яран, нәркис түтәлләре тезелешеп киткән. Шулар арасында аллы-гөлле тавис кошлары кукраеп һәм кәс-кәс басып йөри. Йа Ходаем! Җәннәт дигәннәре менә кайда икән!

Сал-Сал әллә солтан хәтле солтанның үзен күрергә насыйп булыр микән дип хыялланган иде, күктәге йолдызлар колчуралар учына килеп төшми шул ул. Әбүгали каршына шушы кала хуҗасы, әмир Хәләф чыкты. Сихри фонтан янындагы бер почмакка барып утырдылар. Чыш-пыш килеп сөйләшкән сүзләре Сал-Сал колагына усак яфраклары лепердәве сыман чак-чак кына ишетелеп торды:

— Килешенгән вәгъдәләребез шул көенчә кала. Уртанчы кызым Зәйтүнәне сиңа хатынлыкка бирәм.

— Бәрәч, бәрәч! Солтан миңа үзенең төпчек сеңлесе Саимәне бирү турында авыз ачкан иде.

— Саимә ни, Зәйтүнә ни, барыбер түгелмени? Мин —

Мансурның энекәше, Зәйтүнә тәнендә дә солтан каны ага. Ә Саимәне башкача телгә алма, аны газнәвиләр шаһы Маликка вәлидә хатын итеп биреп җибәрдек без.

— Барыбер гадел түгел.

— Аның каравы туену өчен солтан сиңа Сәмәркәндне дә бирә.

— Ә анысы хакына мин нишләргә тиеш?

— Солтан сиңа теге чакта ук киная салган иде. Бөкре Карунны котыртып яуга чыгару шарт. Безнең чирү аны Карт Җиңги дәрьясы янында тозак корып көтеп торачак…

Сал-Сал, үз колакларына үзе ышанмыйча, тораташ шикелле катып калган иде, янга баскан нәүкәр касыгына төртте. Сөйләшү тәмамланган, Әбүгали ат таптаган табак шикелле сытык чырай белән кирмән капкасына таба атлап бара икән.

Кабат караханнар ягына кәлтә елан сыман шуышып, исәнсау чыктылар. Кайтуга, Әбүгали Сал-Салны үзенең шәхси тән сакчыларыннан хасил курсыбаена чакырттырып алды. Иртәгә Сал-Сал инде иң гаярь бер йөз җайдак башлыгы булып яңа яуга чыга…

Чыннан да, сәманиләр Бөкре Карун гаскәрен Карт Җиңги елгасы ярында, биек тау өркәчләре артына качып каршылады. Елга буендагы үзәнлеккә бер төмән чамасы гына җайдакларын тезеп калдырганнар. Бөкре Карун кичә генә ияр күргән селәгәй малай түгел, тик нигәдер ул ярты гаскәрен шул җәйрән баласы төсле кеп-кечкенә дошман төмәне өстенә ташлаттырды. Тау түбәсеннән ычкынган таш туфаны сыман тузгып очкан карахан ташкыны мескен төмәнне бәрән көтүе урынына сытып-изеп узды. Шул чагында гына тау өркәчләре ышыгыннан Нух-Мансур белән әмир Хәләф нөгәрләре калкып чыкты. Үзәнлектә тантана итә башлап сукырайган караханнар өстенә, канатларын җәйгән бөркет төсле, ике яктан төшеп ябырылдылар. Яу чоңгыл шикелле үз эченә тартты, Бөкре Карун сак чирүен дә калдырмыйча кырылыш-орыш үзәгенә куды. Үзәнлектә коточкыч суешу, мәхшәр купты.

Сал-Сал батыр йөзе Бөкре Карун белән әмир Әбүгали чатырлары корылган калкулыкны ышыклап баскан иде. Берзаманны үзләренә таба үзәнлек читеннәнрәк шыпан-шыпан гына якыная башлаган нөгәрне шәйләделәр. Сал-Сал җайдаклар уртасында баш түбәсенә көмеш очлым элгән Хәләфне таныды да агарынып калды. Әле кайчан гына шушы кеше әмир Әбүгалидән кияү ясамакчы, өстәвенә Сәмәркәндне бүләк итмәкче иде бит. Хәзер шушы ук бәндә, бер төркем еланны иәртеп, Әбүгалине буып ташлар өчен якыная. Ничек шулай икейөзле була ала кеше, нинди хәл бу?

Артта Бөкре Карунның ачыргаланып кычкырган фәрманы яңгырап ишетелде:

— Әнә теге шайтан таягын, әмир Хәләфне тотып китерегез миңа! Исән көе тотып китерегез! Мин үзем аның йөрәген суырып алам!

Сал-Сал үз-үзен белештермичә алга томырылды. Аның яшендәй уйнаклаган кылычы астында җиде-сигез сәмани авып калды. Кыр казлары сыман чөй ясап тезелешкән башка караханнар да дошман нөгәрен камышлар эченә барып кергән каек кебек ерып килә иде. Сәманиләр әмирләрен саклый алмадылар. Сал-Сал батыр аны бер мизгелдә ияреннән оя-да утырган бала каз шикелле йолкып күтәрде дә, тезләре өстенә аркылы ташлап, каган чатыры тарафына очты.

Җирдә сукыр эт баласы кебек шыңшый-шыңшый ауна-ган Хәләф янына иң беренче булып Әбүгали килеп җит-кән иде. Ул кылычын кыныннан елан чаккан сыман ка-баланып тартып чыгарса да, Бөкре Карун җан кыярга ирек калдырмады.

— Тукта, ашыкма син, әмир! Ансат үлем илә котылма-сын. Бу имгәкне мыскал-мыскал телеп, ярасына тоз сибә-сибә газапларга кирәк. Солтан атын алып кәпрәйгән Нухка сабак булсын.

Әбүгали, сазга кереп баткач ябышырга салам тапкан сы-ман, Сал-Сал ягына борылып ысылдады:

— Хәзер үк телен кис ошбу хәсис җанның! Хәзер үк кис! Аннан күзен чокы! Турап, өзгәләп бетер! Бу хәсисне син эләктереп кайттың. Кахан сиңа каршы килә алмый.

Менә шул минутта үзенең күңелендә нинди ут уйнавын Сал-Сал бер тамчы да аңламыйча калды. Әүвәл хәтерендә Бохара урамнары, солтан кирмәнендә кәс-кәс басып йөргән вәкарь тавислар яшен шикелле сикергәләп узды, ә аннары ияреннән икегә теленеп ауган Гайсә батырның газап тулы карашын очраткандай көйде. «Түрәлек хакына мине сата-сыңмыни, әй, егеткәй?!» — дип эндәшкән әрнүле авазы ише-телгәндәй булды.

— Юк, юк! — дип ярсый-котырына кычкырып җибәрде Сал-Сал. — Мин бит катыйль түгел! Мин үземне сатмыйм!

Янда Әбүгали зәһәр елан сыман янә ысылдады:

— Җир йөзендә яшәтмим мин сине! Нәселеңне корытам! Таптыйм, изәм, сытам!

— Бик хуп, сатлык әмир, — дип кенә Әбүгалинең бите-нә ташлады да Сал-Сал батыр, шундук ияр өстенә сике-реп менде. — Җилне куып тотардай этләр таба алсаң, әйдә, эзләп кара.

Берничә мизгелдән соң Сал-Салның дөя шикелле дәү, мә-һабәт аргамагы буш дала ягына таба томырылып-шашып ча-ба иде. Ботак-чатаклы имән түмәре сыман коточкыч күсәк тоткан батырны куа чыгучы ташбаш табылмады.

Сал-Сал инде ярты ел буе Алатау мәгарәләре эченә качып яши. Монда иптәшләр күп. Богау чылбырларын өзеп, зиндан ишекләрен җимереп коллык михнәтеннән котылган азатлар бар. Йортын-ихатасын соңгы мендәренә, иләк-табасына тикле талап чыккан каган салымчыларын кыйнап йә үтереп качкан ярлылар дистәләгән. Кәрваннарда ерак араларга йөргән чакта йоклап хуҗасының малын урлаттырган кушчылар, шул ук кәрваннарны үрмәкүч шикелле сагалап талаганда йә атамансыз, йә үзләре кул-аяксыз калган юлбасарлар хәтсез. Әле тагын каган гаскәренә алынудан качкан салам сыйрак, үзенә кайда да җылы оя коралмаган сукбай, үзенең үтә дә акыллы, тик бердәнбер дип санаган буп-буш фәлсәфәсен тыңлатырга үшән колак табалмыйча аптырап йөргән суфый-дәрвиш, дала уртасында тырпаеп утырган йомрытау шикелле шыр-ятим калган малай-шалай, йорт-лапасы янган хәерчеләр, кыяфәтләренә күз ташларга да куркыныч гарип-горабалар. Чын ир итеп исәпләрдәй качаклар өч йөз чигенә җитеп килә бугай, ә ярты-йорты әтрәк-әләмнәре санап бетергесез.

Сал-Сал менә шулар арасында башлык булып йөри. Үзе моны сорап та алмады, дәгъва-киная да белдермәде, тик яннарына килеп кушылганнан бирле барча качак аңа буйсынып яши. Шул печән кибәнедәй зур гәүдәсе, имән ботагы шикелле таза беләкләре, чүлмәк чаклы дәү-дәү йодрыклары — һәммәсе дә аны башкалардан аерадыр инде.

Качаклар күбесенчә ау-балыкка йөреп тамак туйдыралар. Бер аягын атлаганда икенчесен эткә ашатырдай итеп, карт-корылар төсле ярым йоклап барган кәрваннарны талау-чишендерү дә болар өчен чит-ят шөгыль түгел. Атаманнары Сал-Сал кайчакларда, шашынып китеп, хәтта әмир, бәк, каган көтүләрен дә талап кайта. Ләкин үзе моннан ләззәт тапмый, ахры, аннары атна-ун көн буена сөмсерен коеп, авызына су капкандай йөри.

Менә бүген ул учак янында күмерләрне болгаткалап утырды-утырды да бөтенләй дә көтелмәгән яңалык ачып салды:

— Моннан кул сузымында гына, ике көнлек арада, минем әткәй белән әнкәй яшәп ята. Дөрес, әти булган кеше үземнеке түгел, үги атай. Ләкин уникe-унөч ел чамасы нәкъ шул кеше мине үзенең куенына сыендырды, ашатты, киендерде. Ә мин, игелексез, инде ике ел буена шуларның хәлләрен дә белмим.

— Соң, әйдә, әйдә, хәзер үк җыеныйк та китик, — дип, берничә елгыр җайдак урыннарыннан сикереп купкан иде, Сал-Сал шып туктатты.

— Ата-ана йорты көтү җыеп кайта торган базар түгел.

Аннары… аннары мине анда каган яисә Әбүгали этләренең көтеп торуы бар. Үзем генә кайтам, миңа иярмәгез…

Алатау ерымнары эченә поскан кышлакка Сал-Сал югыйсә кичке караңгылык иңгән чакта гына килеп кергән иде, чыра янып сүнәрдәй ара узуга, авылның икенче очыннан җайдак чыгып очты.

Сал-Сал өйгә иңгәч, Сания белән Исәнбай икесе дә улларының кочагына килеп сыендылар. Яңакларында шатлыклы күз яшьләре. Сәке читенә, урындыкларга тезелеп утыргач та, сокланулы караш белән Сал-Салны күзәтәләр. Сокланмаслык түгел. Баш түбәсе түшәмгә тигән буй-сын. Тәнендә үгезләрне сугып егардай гайрәт, тазалык бар. Яуга чыгып киткән чакта иреннәре өстендә мамык сыман йомшак төкләр генә иде, хәзер сагыз япкан шикелле куе кара мыек. Менә шунысы тәэсир итте бугай, Исәнбай әкә хәтер казанына чумып алды.

— И-и, мин Болгардан алып кайткан чакта менә мондый мендәр шикелле бәләкәй генә сабый бала идең, инде менә түшәм җимерердәй батырга әйләнгәнсең. Күз генә тимәсен, и-и, гомерләр!

Болгар атамасын телгә алгач, Саниянең карашында да әүвәл очкын уйнап куйды, әмма икенче мизгелдә үк йөзен болыт каплап киткән сыман булды.

— Болгарлар дөньяда моннан унбиш ел чамасы элек үзләре коллыкка сатып җибәргән Сал-Сал атлы сабый барлыгын онытканнардыр инде. Аллага шөкер, исән калдык әле. Аллага шөкер, Исәнбай табылды.

Әлеге күңелсез хатирәләр белән Сал-Сал бала чактан бирле танышып үскән, шуңа күрә ераста калган, инде онытылган Болгарны искә алуларын бер дә сөйми иде. Ә менә бүген, саташкан ай сыман, бөтенләй икенче яктан килеп ачылды ул.

— Минем Болгарны барып күрәсем килә, — дип, Исәнбай әкәнең йөзенә текәлеп сөйли башлады Сал-Сал. — Берүк ачуланма. Син миңа чып-чын икенче ата булдың, игелекләр кылдың. Мин сиңа рәхмәтләр укып гомер буе дога кылачакмын. Иллә мәгәр ошбу җир йөзендә минем үз атам да булган. Мин аны хәтерләмим. Ә менә болгарлар үзләре кайчандыр җиһанда Байдар атлы баһадир яшәгәнен, аның шулар иле, шулар азатлыгы өчен җан биргәнен искә алалар микән? Шуны беләсем, ачыклыйсым килә. Мине атам каны үз янына тарта.

Сал-Сал инде, әнисе тарафына борылып, үз карарын әйтте:

— Мин Болгарга китәргә булдым, әнкәй.

Сания күз яшьләренә буылып, сыгылып төште. Берничә сүзе генә аермачык булып ишетелде:

— Китмисең, китмисең син, үз иленә кайтасың, газиз ба-

лам. Үзеңне кабат монда көтеп җиткерүләр насыйп булмас инде…

Сал-Сал урамга атлап чыккан иде, күрше койма-капка артына яшеренеп торган алты-җиде ир килеп ябырылды. Сал-Сал шуларның бер-икесен генә чөеп атарга өлгерде, калганнарын тау-таш арасына поскан качаклар уктан чүкеделәр. Тегеләр качкан урыннарыннан аягүрә күтәрелгәч кенә танып алды батыр. Үзе белән бергә мәгарәдә яткан, яуга йөргән иптәшләре икән.

— Мине каган яисә Әбүгали яллаган этләрнең сагалап торуы бар, дип, үзең кисәттең бит, — ди-ди көлешәләр хәзер.

Тау битенә менгәч, үзе уйнап үскән кышлак өстенә әйләнеп, усал итеп сүгенеп куйды Сал-Сал.

— Сатлык җаннары юкка чыксын өчен моның бер башына очкын элеп китү дә артык булмас иде. Юк шул, бармый, кулым күтәрелми. Бу бит — мин ятимне сыендырган авыл.

48

Дала яклап очкан яңа чапкын күренде. Бүген таңнан башлап бишенчесе инде. Манарадагы күперчекләр өстенә менеп баскан тоткавыллар өчен бу яңалык түгел. Янкалага ялгызак көенчә дә агылалар, олаулап-олаулап та. Кайсысы Болгарның үзеннән үк төбәп килә, кайсылары аеры-аеры көе Бәнҗә, Кашан, Ашлы каласыннан. Хәтта арбасына соңгы сыер-сарыкларын тагып юлга чыккан арлар, чирмешләр, мукшылар да очраштырып тора. Идел яры буйлап менсәләр дә, эзләп табалар Янкаланы, Ука ярына барып төртелсәләр дә, барыбер адашмыйлар. Болгар илендә рәнҗетелгән һәркем шушы кирмән диварлары артына кереп сыеныр оя эзли, һәрбер сәйях шушында мәрхәмәтле ышык-түбә таба. Ә кирмән капкалары каршына килеп егылган юлчыларның зар-хәсрәте бер үк.

— Тимер-Мөэмин яңа салым салды. Хәзер инде базарга чыккан өчен генә түгел, аңа кергәнче үткән кала капкалары, авыл күперләре өчен дә бугаздан буып талый.

— Болай да, авызыбызны ачсак, үпкә күренеп тора. Ә Тимер-Мөэмин түбәгә чыгарылган һәрбер мич морҗасы, лапас артына өйгән һәрбер кибән өчен дә салым талап ыштансыз калдырмакчы…

Менә шушы кайгы-афәтләрдән котылмакчы булып, кара халык Янкалага агылып кына тора. Иделгә Ука елгасы килеп кушылган төштә бер ел гына элек калыкты ул. Ләкин даны инде ерак ларга китте. Әлегә юньле-рәтле исеме дә юк үзенең. Ерактагы бер төбәккә килеп тәүге бура бурау бәхетенә ирешкән төзүчеләр һаваланып үзенчә сукалыйлар:

— Саескан тавы башына менеп беренче казыкны кагучы кеше әмир Ибраһиммы? Шулай булгач, Ибраһим кирмәне бу, бетте-китте!

— Һе, алайга китсә, Чулман буендагы Шайтан каласына беренче казыкны кагучы кеше дә шул Ибраһим. Хәзер инде ул кереп чыккан барча кирмәнне дә аның исеме белән атыйкмыни?

Әмир Ибраһим үзе бернигә дәгъваламый. Тәүге юлдашларын тынычлыкка чакырып, ипле генә дәшә:

— Хикмәт исемдә түгел, тора-бара меңгә төрләнер ул. Иң мөһиме, бу — урысларның борын төбенә китереп салган беренче зур кала. Шулай икән, әйдә, әлегә ул Яңа кала аты белән йөрсен.

Менә биш-алты ай буе мондагы халык аны, үзенчә җиңеләйтеп, Янкала дип сөйли. Үпкәләүче кеше һич сизелми. Монда, гомумән, борын салындырып йөрүне бер дә өнәмиләр. Урыны ул түгел. Әле Идел, әле Ука елгасының аръягында урыс юлбасарлары, әрсез ушкуйларның яңа нөгәрләре пәйда булып тора. Янкалада һәрчак уяу, сак йөрергә, бердәм, дус яшәргә кирәк. Шушы кануннарны сакламасаң, мүкләк бәрән кебек, көтүдән аерылып калуың бар…

Яңа чапкынны манара астындагы асылмалы капка каршына килеп җитүгә үк җиңел таныдылар.

— Даян вәзирнең малае Хәзәр Насыйр бит бу. Нишләп сакчыларсыз гына йөри икән?

Тоткавылларның теле гел искечә. Тимер-Мөэминнең Даянны түрәлектән алып атканына әллә кайчан инде, болар аны һаман «вәзир» диләр. Насыйрның да Йосыф каган сараена шымчылыкка барып кайтуына ничәмә-ничә еллар үтеп киткән, әле булса Хәзәр дигән кушаматы калды. Монда иркенлек, хөррият, башбаштаклык. Хәтта Тимер-Мөэминне дә «хан» дип олылап телгә алучы юк…

Насыйрны әмир сараен әйләндереп алган биек ихата эченә тоткарлыксыз-нисез үткәрделәр. Ихата уртасында күлмәкләрен салып аткан көенчә бүрәнә бурап маташучы Ибраһимны күргәч, юлчы кунак күрше хатын мунчасына адашып кергән шикелле аптырап ук калды.

— Бәрәкалла! Син үзең монда сугымчы да, пешекче дә, табынга кунаклар чакыргач алларына чыгып биюче дәмени?

— Әйе, нәкъ шулай, туганкай, — дип, Ибраһим башын артка ташлап, рәхәтләнеп көлде. — Үзем менә шушылай итеп үрнәк күрсәтмәсәм, башкаларны ничек бушка эшләтәсең? Аннары эшсез яткан тимер тутыга бит ул. Мин үземә нинди шөгыль табыйм?

— Әйтерсең лә син эшсезлектән коргаксып интегәсең. Ярты ханлыкны авызыңа караттың ла инде.

Шул рәвешчә хуҗа кешенең салпы ягына салам кыстырып алгач, ниһаять, Насыйр җитди сүзгә күчте:

— Хан котыра, әткәйне богаулап зинданга ташлаттырды. Яңа салым салгач тимерчеләр бистәсе, бердәм кубып, хан кирмәнендәге капкаларны җимереп аткан иде, аларны, янәсе, минем әткәй котырткан булып чыкты. Мин Болгардан төнлә генә качтым. Юлда җан өшеткеч хәбәр куып җитте. Хан йөздән артык тимерченең кулларын чаптырган, ди.

— Ә-ә-әй, бәдбәхет! Әх, канечкеч көзән! — дип ачынып бүлдерде әмир, Насыйр дәвам итте:

— Хан әле яз көне үк меңбашларын, морзаларын далаларга юллап, кыпчакларны, угыз-бәҗәнәкләрне яллый башлаган иде. Берме, икеме төмән туплап алгач, синең өскә җибәрмәсә ярый. Хәзер хәтта хәзәр каганыннан да курыкмый ул, ә синең исемеңне ишетүдән дер калтырап тора. Чөнки хаксыз изелгән барча халык синең яныңа кача, шушы Янкалада терәк эзли. Син тәхеткә лаек төп дәгъвачы гына түгел. Син гади халык ышанычы, ил калканы. Менә ни сәбәпле ханга куркыныч син…

Насыйр килгәннән соң бер атна чамасы гына вакыт үткән иде, дала өстенә кара тузан болыты күтәреп якынайган атлы гаскәр күренде. «Тимер-Мөэмин юллаган катыйльләр йә җәзачылар чирүеме әллә?» — дип хорафатка бирелә башладылар. Дивар өстендәге агач басмалар ирләр белән тулды. Сумала, су, вак таш тутырылган казаннар астына ут яктылар. Көбә-очлымнарга төренеп алган әмир Ибраһим үзе манарага менде.

Юк, болар Тимер-Мөэмингә яллангән умырткасыз колчуралар түгел. Хан үзенең башбирмәс энекәшен һәм ул төзегән кирмәнне җир йөзеннән себереп ташлау өчен бер төмән җайдак та кызганып тормас иде. Ә болар сан ягыннан бер меңгә дә тулмый. Өстәвенә алар әнә ничек иркен атлап, туарылып килә. Әйтерсең лә яу сәфәре кануннарын бөтенләй онытканнар. Әйтерсең лә боларны учларында биетеп тота торган бер сәрдәр юк. Барча җайдак, көтүчесез калган мал шикелле, озын чылбыр ясап таралышкан. Җәяләре аркада, сөңгеләре өзәңгегә асып куйган килеш. Кайберләре хәтта йөгән тотып та азапланмый бугай, байтак атлар пошкырапошкыра башын болгап бара. Иң койрыкта дөяләр иярткәннәр, аларны куучы кушчылар да сирәк. Валлаһи, ник туганына үкенеп йөри торган җыен пошмас әтрәк-әләм, йолкышлар өере ләбаса бу!

Җайдаклар кирмән дивары алдына сузылган биек ур каршына җиткәч, Ибраһим аларны янә кат-кат күздән кичереп чыкты. Чүл гарәбенекедәй чутыр тәннәр, сирәк сакал, чылгыйлары озын булып асылынган мыек, сөякләре ике як-

ка төрткән киң яңаклар, тап-тар кысык күзләр. Күбесенең өсләрендә мамыктан сырган бишмәт яисә җиңнәре балактай киң чапан, башларында өчпочмаклы киез эшләпәләр яисә бөдрәләнеп торган йоннары да кыркылмаган сарык тиресеннән тегелгән түмгәк шикелле түм-түгәрәк бүрек. Юк, болар Ибраһимга электән үк таныш бәҗәнәкләр дә, кыпчаклар, аймыклар, угызлар да түгел. Алайса, каян гына килеп чыккан җайдаклар бу? Алар кемнәр?

Сафлар арасыннан печән кибәнедәй зур гәүдәле бер пәһлеван аерылып чыкты. Бу башкаларына бөтенләй охшамаган. Буе тегеләргә караганда бер карышка биек, яңаклары озынча, йөзе япь-яшь, ә үзен, ай-һай, иркен, горур тота.

— Кала бәгегез бардыр, сөйләшергә чыксын!

Дивар өстендә күк күкрәгән сыман шаркылдап җавап кайтардылар. Ара-тирә мәсхәрәләп кычкырган сүзләр дә ишетелеп торды:

— Мүкәләп чыксынмы соң ул, әллә башын игән көе аягүрә күренсә дә гафу итәсеңме?

— Монда бәк-морзалар түгел, әмир хуҗа! Белеп сөйләш, йолкыш!

— Эт талаган мондый ыбыр-чыбырларны кайдан эзләп таптың?..

Мондый тавыш-гарасаттан дөя чаклы аргамагы гына пошкырынып куйды, ә җайдакның кылы да селкенмәде. Саңгырау кеше төсле, тавышын күтәребрәк, янә кычкырды ул:

— Мин бит сезгә, кала бәгегез монда чыксын, дидем. Әгәр курка икән, мин чирүне бер чакрымга читкә җибәреп торам.

Япь-яшь пәһлеван артына борылып ике-өч фәрман да ыргытып өлгермәде, җайдаклар, җәйрән шикелле сикергәләп, шундук диварлардан читкә ыргылдылар. Менә шул вакытта хәйран калды әмир. Сәер, гаҗәп! Бу йолкышлар, мондый әтрәк-әләм юлбарыс көтүе сыман җыерылып, әсәренеп, дәһшәт кузгатып та чаба белә икән!

Ибраһим ур артына яшь пәһлеван шикелле үк япа-ялгыз чыкты. Ике-өч адым ара калдырып туктагач, кәләш күргән кебек сәерсенеп бакты. Гайрәт ташып торган мәһабәт сын, йөзендәге һәрбер бөртек, һәр күзәнәк саен таныш чалым. Каян, ничек хәтерли ул аларны? Кем соң бу егеткәй, йа Ходаем, кем?

Түзмичә сорады ул:

— Син кем буласың, батыр? Кай яклардан килдең? Нинди чирү бу синең кул астында?

— Бик ерактан килдек без, әмир, бик ерактан, — дип башлап китте батыр, ә Ибраһимны янә эчтән корт талады.

«Сөйләме гел безнеңчә. Бернинди алышта, бәйгедә очраткан юк. Кем соң бу егеткәй, кем бу?»

Колагына батыр сүзләре ишетелеп торды:

— Кызылком сахралары артыннан, Алатау буйларыннан ук кузгалдык без. Минем кул астында карлукълар, мангытлар бар. Юлда кыпчаклар, угызлар өстәлде. Болгар җиренә кергәч, хәтта әле бортаслар, суарлар да килеп кушылдылар. Барысы да хан-каганнар йә әмир-бәкләр талавыннан качып китүчеләр. Мин берсен дә кире кумадым. Кем коткару сорап яисә терәк-куыш эзләп килә, барысын да канат астыма җыйдым. Минем чирүне җәберләнгән, изелгәннәр көтүе дип атасаң да була, гадәләт вә хөррияткә сусаган ихтилалчылар дисәң дә хата түгел.

Ибраһим төрттереп сорау бирүдән тартынмады:

— Бортас, суар җирләре аша үтеп киткәнсең. Нишләп Тимер-Мөэмин ханга барып ялланмадың?

Егет ачу-ярсуыннан кайнар казанга чумдырган кысла сыман кызарынып чыкты.

— Этнең ялваруы Ходай Тәгаләгә барып ишетелсә, күктән ит явар иде, дип әйтә торган иде бер аксакал. Синең колаклар да шулай саңгырау икән. Әле генә әйтеп тордым ласа. Минем җайдакларым — элек тә хан-әмирләр тарафыннан таланган вә җәберләнгән ирләр. Ни йөз белән мин аларны тагын бүре авызына илтеп тыгыйм?

— Алайга китсә, мин дә әмир инде.

— Әмир әмирен, анысын яхшы беләм. Иллә мәгәр син абзыең тарафыннан читкә тибелгән, үзеңә тиешле тәхеттән коры калган әмир. Ә җәберләнеп бергә җыелганнар — ауга чыккан аксак-туксак, карт яисә яраланган бүре көтүе белән бер ул. Андый бүреләрнең көче, игътибары дошманнарга каршы юнәлтелгән була. Ахыр чиктә алар бер-берсен тиктомалдан тотып ашамыйлар.

Ибраһим көлемсерәп куйды, янә сорау бирде:

— Ә дошманны җиңгәч, кая барырлар соң ул бүреләр?

— И-и-и, Ибраһим әмир! — дип башын чайкый-чайкый сузды батыр. — Җиңүчеләр ияр-тәхет дигәненә менеп алгач, янә җәберләнгән, кимсетелгән, таланган як табыла, хасил була бит ул. Җир йөзендә кимсетелгән, изелгән халыкларның мәңге бетәсе юк.

— Һе! Һе-һе! Әрекмән шикелле беркатлы гына түгел икәнсең син, батыр. Син беркатлы түгел, — дип кабатлап тордыторды да Ибраһим әмир, бер бармагын егет йөзенә ук шикелле төбәп, капылт сорап куйды:

— Исемеңне син кем дидең әле?

Егет әмир хәйләсен шәйләп өлгермәде, тиз-тиз җавап бирде:

— Сал-Сал.

— Сал-Сал, Сал-Сал, — дип кабатлады янә аптыраган әмир. — Минем бу исемне әллә кайчан ук иштекәнем

бар иде бит инде. Кайда ишеткәнне генә хәтерләмим. Әтиең кем синең?

Искә-аңга килгән Сал-Сал батырның йөзе калкан сыман кырысланып калды. Җавабы да боз шикелле салкын, җансыз чыкты.

— Анысы мөһим түгел. Бездә ил өчен игелек кылган кешеләрнең исемен-шәҗәрәсен ятлаучы юк. Без — черегән капчык бавы шикелле кыска хәтерле кавем.

Берникадәр аптырашып торганнан соң әмир телгә килде:

— Бөтен мәмләкәтләр буйлап туплаган ул мескеннәр чирүе белән ни кылырга җыенасың инде?

Сал-Сал батырның йөзе элеккечә кырыс, җитди иде. Усалланып дәште:

— Мыскыл итмә, әмир. Ир-егетләрнең асылы яуда йә орышта сынала ул. Син дә сынап кара.

— Кайда, ничек итеп?

— Менә шушында, кырда. Син ике йә өч йөз яугиреңне чыгар. Ә мин бер йөз генә җайдак чакырып алам. Минекеләр җиңеләләр икән, бөтенесен ияртәм дә кире борылып китәм. Ләкин ук очырып, кылыч белән турап, чынлап сугышыш юк. Юньле җайдак үзен болай да раслый ала, кан коюсыз гына орышсыннар.

Ибраһим байтак вакыт буе баш чүмечен кашырга мәҗбүр булды, аннан гына, кулын селтәп, үз карарын әйтте:

— Әйдә, орышсыннар. Ичмаса, каладагыларга бер тамаша булыр.

Йке якка да катгый фәрман китте. Кирмән эчендәге һөнәрчеләр, хатын-кыз, бала-чага — һәммәсе дә дивар өстенә тулды. Ибраһим белән Сал-Сал гына тегендә-монда күчеп маташмады, алар яндагы калкулыкка, ерга менеп басты…

Сал-Сал болай дуамалланыр, әтәчләнер-кукраер дип уйламагандыр инде, Ибраһим әмир үз ягыннан, чыннан да, өч йөз ирне чыгарырга әмер биргән иде. Тегеләр ике-өч катлы чылбырдан хасил тыгыз бөжра булып тезелделәр. Һәрбер яугир сөңге урынына тоткан тәртәләрен алга төбәп баскан, бөжра дошман күргәч энәләрен кабарткан усал керпе сыман. Ирләрдәге килеш-килбәт җитди, арада берәү дә уйнарга исәпләми, һәркайсы кыргый даладан килгән җайдакларга сабак укытмакчы. Ләкин болардагы көрпәлек-һавалану, масаю-тәкәбберлек озакка бармады шул.

Менә Идел ярындагы үзәнлектән йодрык-төен булып йомарланган «дошман» калкып чыкты. Шикләнерлек түгел, җайдакларның саны бер йөздән дә артып китми иде. Алар үткен сөңге шикелле тезелешеп алга томырылуга ук, дивар өстендәгеләрнең һәммәсе аһ итте. Сөңгенең нәкъ очына, башак өлешенә икешәр өркәчле, зур-зур дөяләрне бастырып куйган болар.

Җайдаклары өркәчләр арасына кереп поскан, ә дөяләр сыртыннан бастырык кадәрле энәләр сузылып килә. Аргамаклар иярләгән ирләр чүл бүресе, фил, юлбарыс авазлары чыгарып бертуктаусыз улый, кайберләре хәтта ат сыртына менеп баскан көе аягүрә оча. Берзаманны җайдаклар яшен суккан сыман капылт юкка чыкты. Аларның ияр астына чумып юыртуын бик аз кеше генә абайлап-шәйләп калды.

Божра ясап тезелгән урыс сугышчылары дала явы, дөя, җайдаклар чаялыгы күреп үскән нөгәр түгел. «Дошман» йөзендәге очлы башак кыл икегә ярып керүгә үк, дистәләгән ирләр янга тәгәрәп калды, божра үзе кулдан ычкынган керәч тәлинкә шикелле яргаланып бетте, «керпе энәләре» юкка чыкты. Ияр астыннан күтәрелгән дала җайдаклары урыс ирләрен кыл арканнар атып чүпли башлагач, Янкаланыкылар инде, карчыгадан качкан тавык чебиләре кебек, читкә сибелеште. Берничә минуттан соң урыс ирләренең күпчелеге балчык урлар артына кереп поскан, калганнары яу кырында арканнарга уралып ята иде. Дивар өстендәгеләр ачыну-рәнҗүле бәя җиткерделәр:

— И-и, җыен җебегән, куркак! Шушы йолкышларга да каршы тора алмадыгыз. Тимер-Мөэмин төмәннәре килсә, сездән нинди җиңү өмет итеп булсын?..

Үз гаскәренең йомшаклыгын күреп пошаманга төшкән Ибраһим да «дошман» йөзе белән сокланuын яшерми сорап куйды:

— Боларны мондый орыш алымнарына ничек өйрәттең син?

— Һе, һе-һе! — дип көлемсери-көлемсери җавап бирде Сал-Сал, нәкъ баягы Ибраһим әмир сыман. — Без ярты ел буе дистәләгән вилаять, олыс, ханлык тозакларын үтә-үтә килдек. Авызына су керсә, аю булып аю да йөзәргә өйрәнә ул. Без дә, юлда туктап ыстан корган саен, күнекмәләр ясадык, өйрәндек инде менә.

Ибраһим әүвәл, сыный-сыный, батырның йөзенә озак текәлеп торды, аннары кайнар итеп кочагына кысты.

— Мин чын, ышанычлы сәрдәр эзләп табалмыйча күпме иза чиктем. Әйдә, сәрдәрем бул, Сал-Сал!

49

Таҗларын ача башлаган чәчәк бөреседәй гүзәл Айзирәкне Ибраһим әмирнең сараена кергәч очратты ул. Гөлләргә су сибеп йөргән чибәр кызыкайны шәйләдә дә гүя телсез калды. Уйнак колын сыман нәфис, сылу буй-сын. Әле хөрмә кебек кенә төрткән нәни күкрәкләр өстенә сузылган ике йомшак толым. Карлыгач канатыдай кыйгач кара кашлар.

Шомырт сыман янып торган күзләр. Әле тапланырга өлгермәгән язгы агач яфраклары кебек эчкерсез, җылы караш. Һәр бал кортын каршыларга әзерләнеп көткән чәчәк тажы шикелле мөлаем, сусыл, назлы иренкәйләр.

— Ә мин сине беләм, Сал-Сал батыр, — дип, үзе эндәште ул. — Хәзер бөтен халык сине генә сөйли. Янкаланы таң калдырдың бугай.

Сал-Сал тыенкы гына көлемсерәп куйды, әмма җавап кайтарырга сүз тапмады. Айзирәк үзе ризык алып кайткан әнисен каршылаучы кош баласы кебек чыркылдавын белде:

— Каладагылар сине генә уйлап баш ваталар хәзер. Җиде дала аръягыннан монда кайтып җәфаланмас иде, ул безнеңчә сөйләшә, ул болгарлы, диләр. Ә асылда кем син, Сал-Сал чын атыңмы? — беркем белми. Син миңа да сер чишмәссең инде?

Нинаять, батыр да аваз бирде. Ләкин әллә табышмак, әллә тозак корды.

— Ник чишмәскә? Чишәм! Мәгәр монда түгел.

— Ә кайда соң? — дип, уенга кушылды сылу.

— Дивар аръягында, дала кочагында. Җиде-сигез генә төн кунсам да, инде күреп кайттым. Ука буендагы Каенлы тау астында Ана сөте дигән чишмә тибеп ята.

— Беләм, беләм, анда булганым бар, — дип, Айзирәк ботактан ботакка очкан тутый кош шикелле канат кага-кага чыркылдады.

— Белсәң, кояш баткач, менә шул чишмә буена кил. Шунда серләшербез. — Егет «син шикләнмә» дигән кебек янә өстәп куйды. — Курыкма, сиңа кагылмыйм мин. Башкаларга урлап качарга да ирек бирмим.

Энҗе сәйләп тавышлары чыгарып, Айзирәк янә көлде:

— Һе, синдәй аю да урлатып тормас инде. Тик... әти генә...

Сал-Сал урмандагы коточкыч янгын давылы уртасында калган сыман зур хафага төште.

— Әллә чыгармыймы?

— Элегрәк ул бер сүз дә әйтми иде. Хәзер генә менә... — Айзирәк, олы гөнаһ кылган кеше төсле, үзенең күкрәкләренә күз ташлады. — Тоткавыллар башлыгына әйтеп куйган. Имеш, аның рөхсәтеннән башка бер адым да читкә атламаска.

Сал-Сал батыр өстеннән тау төшкәндәй җиңел сулап куйды.

— Аңа гына калса, хәл итәрбез. Сине капкаларда туктатучы булмас...

Айзирәк күк йөзенә тулган ай калыккач кына килеп җитте. Сал-Сал инде әллә кайчаннан бирле, читлектәге арыслан шикелле йөренгәләп, утлар йота-йота көтеп тора иде. Җи-

ңел юырткан чаптар күренүгә үк, иңнәренә канат үскән сыман, аңа каршы очты. Сылукайны ияреннән алып, сабый чагыннан бирле бергә үскән сеңлеседәй назлап, күкрәгенә кочты. Талымлы һәм кайнар иреннәре берсен-берсе эзләп кушылганчы, һавада гомергә сыңар тапкыр гына кабатлана торган тылсымлы сүзләр асылынып калды:

— Мин бу көнне ничә еллар буе тилмереп көтеп йөрдем. Күктәге меңәрләгән йолдызларны көнләштереп, ниһаять, мин бит сине, сине эзләп таптым. Алай да туган җиремә әйләнеп кайтканмын мин.

— Мин дә сине көттем, Сал-Сал абый. Далаларга, яланнарга чыгып эзли-эзли, син батырны көттем…

Җиһан әле генә бәби тапкан бәхетле һәм назлы ана сыман тынып, җиңеләеп калган. Күк йөзе бәллүр чишмә төбедәй чалт аяз. Анда качышлы уйнарга чыккан сабыйлар, яшьтәшләр шикелле йөзәрләгән йолдызлар, адашлар үзара күз кысыша. Үзенә яр таба алмыйча саргайган сазаган кызыкы кебек салкын, боек йөзле ай кыршауга утыртылган кебек тәгәрәвен белә. Ара-тирә генә җилбәзәк хатын шикелле анда-монда сибелгән вак болытлар йөзеп үткәлиләр. Үзен оныттырмас өчен генә, бишектәге сабый бала сыман уфылдап, саташкан җил сызгырып-исеп уза. Кайсыдыр почмакта, өенә кайтмый калган әрсез ир шикелле, кәккүк-ябалаклар аваз биреп куя. Мәңге-мәңге йокламаска сүз биргән тынгысыз инеш-чишмәләрнең тонык челтерәве килеп ишетелгәли. Табигатьнең камил, бөтен, истирахәт кичереп яткан чагы!..

Таган кебек атынган-очынган күңелен көч-хәл белән тыеп, Сал-Сал сорап куйды:

— Сиңа ничә яшь соң әле, бәгырькәем?

— Унөч тула инде… озакламый.

Сал-Сал үзеннән бигрәк сылукайны тынычландыру өчен өстәп әйтте:

— Яраешергә була икән инде.

Айзирәк язгы аҗаган, җәйге салават күпере сыман уйнаклаган күңелен тыеп кала алмады.

— Ошыйммы мин сиңа, Сал-Сал абый? Егетләрнең күзе төшәрлекме, матурмы мин? Яшермә, дөресен әйт миңа, дөресен әйт! — дип, ис-акылын җуеп шашынды ул.

— Матур, матур, искитәрлек сылу, — диде Сал-Сал, кабаланып, Айзирәкнең талым-уенына каршы тора алмыйча.

Япь-яшь кызыкайның мич ташыдай кызган шашыну-сырпалану чүпрәсе басылмады. Утардан чыгып качкан колын кебек уйнаклап, ул яндагы биек таш өстенә сикереп менде. Берничә мизгелдән соң тирә-якка Айзирәкнең хәситәсе, эчке күлмәкләре, гаурәт япмалары очып төште. Иреште-реп-үчекләп эндәшкән назлы тавышы чишмә челтерәвен күмеп китте:

— Мин йокысы туеп уянган кошмын бүген. Мин яңа гына туган җилнең үзе хәзер. Теләсә кая очып китә алам. Мин ирекле, мине тыючы юк. Менә, кара, менә, кара миңа, Сал-Сал абый. Синең өчен генә чишендем мин. Сине гашыйк итәрлек матурлыгым бармы минем, бармы?

Сал-Сал Айзирәккә текәлде дә әйтерсең лә утлы күмер йотты. Чибәркәйнең буе-сыны яшь каендай зифа. Биле ике учка сыеп бетәр төсле. Нәни алма шикелле төрткән имиләре түм-түгәрәк, тыгыз. Шул алмаларның нәкъ урта бер җиренә килеп кунган чия төшләре — алсу, ләззәтле, ымсындыргыч, газиз. Иң ярсу, иң мәһабәт газәлләргә дә биргесез төз аяклар озын, нәфис, дәртле. Ә шул аяклар уртасындагы сихри капка әйтерсең лә ожмах, җир җәннәте! Дөньяда шушындый да камил затлар, гүзәллек һәм тылсым була икән, йа Ходаем!..

Сал-Сал инде дә түзә алмыйча күзләрен чытырдатып йомган гына иде, Айзирәк таш өстеннән сикереп төште дә уйнак җил шикелле килеп сарылды аңа. Тел очында һаман сәйләп чылтыравы:

— Тотып кара инде мине, Сал-Сал абый. Сиңа ошыйсым килә бит, менә, тотып кара.

Җәннәт бакчасына кереп адашкач, Сал-Сал зәмзәм суы йоткандай бөтенләй онытылды…

Янкала диварларына якыная башлагач кына шәйләп алды Сал-Сал. Дивар күләгәләренә ышыкланып, ялгыз җайдак басып тора анда. Билендә кылычы, иңендә җәясе бар. Бик теләсә, әллә кайчан ук очына утырта алыр иде. Димәк, нык теләми. Сал-Сал батыр кирәк әле аңа. Айзирәкнең керсез-гөнаһсыз данына караганда, җайдак өчен сәрдәр кадерлерәк.

50

Сал-Сал далада яңа нөгәр белән күнегүләр үткәреп азаплана иде, төш җиткәндә, Ибраһим аны үзенең сараена чакырттырды. Кайтып керсә, дөя йоннынан суккан ап-ак киез, аллы-гөлле хәтфә келәмнәр өстенә корылган әмир табыны янына алты-җиде ир-ат тезелешкән. Йөзләре талчыккан, киемнәре керле. Сорашып торасы юк, ерак юл газаплары кичкән сәйяхчылар болар. Сал-Сал өчен һәммәсе дә чит-ят, шуны истә тотып, әмир таныштырды:

— Болгардан тагын яңа кунаклар килеп төште, сәрдәр. Барысы да ил терәге булырдай күренекле ирләр. Менә моныcы — Кашан каласының олугбәге Шуран. Янәшәдә — Тәмте олысына хуҗа тиеш Балтач. Болары — Сабакүлдән, Нур-Сувардан, Ашлы каласыннан илче итеп озатылган морза-байчуралар. Һәммәсе дә гозер белән килгән. Алар ми-

нем Болгар тәхетенә кайтуымны сорый. Моңа без әзерме? Син бит сәрдәр кеше. Тыңлап, үлчәп кара.

Карабаш кызлар, көмеш тәпсиләргә тезеп, кымыз, әче бал, хөрмә-йөзем, кунакларга таянып утыру өчен вак мендәрләр кертте. Табынга токмачлы аш, булар бөркеп торган ит күсәгәләре өелгән көмеш табаклар чыгарып куйган чакта илче булып килгән ирләрнең төп зарлары-максатлары ачыкланып беткән иде инде.

— Тимер-Мөэмин соңгы вакытларда аеруча чирмеш, ар, мукшы олысларын талый. Әлеге олысларда ислам динен кабул итәргә теләмәгән бәгъзе авылларга икеләтә-өчләтә салым җиткерелде. Мукшы ирләре, Сура елгасын кичеп, Растуф кенәзе ышыгына кача башладылар.

— Тимер-Мөэмин җәзасыннан исән-имин котылган тимерчеләр, пайтәхетне ташлап, башка калаларга чыгып качты. Болгарда бүген көбәләргә генә түгел, хәнҗәр-кылычларга тикле олы кытлык. Әмир Ибраһим кайтса, пайтәхетне яклардай көч табылмый.

— Пайтәхеттән гайре барча калаларда имам-хатыйблар, бәк-морзалар, һөнәр осталары, сәүдәгәрләр Ибраһим әмир яклы. Кара гавам да Ибраһим кайтса гына җиңел сулый башларга өметләнә...

Шушы хәбәрләрне барлап чыкканнан соң, һәркем өчен байтак тараф ачыкланды сыман. Тик шулай да Ибраһим әмир үз фикерен белдерергә ашыкмады әле. Әүвәл ул Сал-Салга төбәлеп сорау бирде:

— Һәммә сүзне энәсеннән җебенә тикле тыңлап утырдың. Ни әйтерсең, сәрдәр?

— Бер зур кимчелек бар, — дип, егет сәер сүзләр белән авыз ачкач, ашауларын ташлап, барчасы да аңа текәлделәр. Сал-Сал бала йоннарын да селкетми дәвам итте: — Сезнең арада менә олугбәкләр бар, морзалар, сәүдәгәрләр бар, хәрби сыбайлар юк. Әгәр Болгардагы барча гаскәр Тимер-Мөэминне яклап чыга икән, пайтәхетнең имән диварларын да, ханның таш кирмәнен дә бездәге көч белән генә яулап булмаячак. Гади халыкның урамнар буенча коры кулын болгап, бугазын ярып йөрүеннән безгә файда килми.

— Ә син ни пычагыма сәрдәр булып йөрисең?.. Гади халык та көч! — дип, кунакларның бер-икесе ризасызлык күрсәтә башлаган иде, хуҗа кеше кул күтәреп кенә тиз туктатты.

— Шартың, киңәшең нинди? Син кунакларга шуларын да җиткер.

— Хан чирүендәге меңбашларны, йөзбашларны, бигрәк тә курсыбайдагы түрәләрне үзебезнең якка аударырга ки-

рәк. Кайбер сыбайлар белән башта ук сүз куешып кую да артык булмас иде.

Сал-Сал шул рәвешчә Болгардагы хәрби түрәләрне Янкалага китереп күрештерү хакында киная ташлап алгач, Ибраһим әмир дә йөзен ачып салды.

— Әзерлексез-нисез көе кайтып, үз илемдә кан коясым килми. Башка калалар мине колач җәеп каршыларга әзер, анысын күреп торам. Иллә мәгәр менә сезнең арагызда пайтәхетнең үзеннән бер генә вәкил дә юк. Аеруча яңа сәет булып алган Әшрәф хәзрәт безне яклый микән, мин аны да белмим. Сал-Сал сәрдәр хаклы. Болгар диварлары эргәсенә кайта-нитә калсак, капка ачып безне каршыларга әзер торучы сыбайлар да күренмиләр әле. Борча белән кандаланы гына ут капкандай ашыга-кабалана куалар ул. Артка ут капмаган, без ашыкмыйк…

Кунакларның кайсыберләре, йөзләрен чытып, табынны ташлап китте. Үпкә-зарлары, рәнҗүләре яңгырап ишетелде.

— Йөз фәрсах юл үттек, бер ай буе килдек, ә ул безне битебезгә төкереп озатмакчы. И-и-и, игелексез бүкән!

Олугбәк Шуран гына тузынмады, ләкин үзенең шарт-киңәшен барыбер иреште рде.

— Син бездән генә таләп итеп ятма. Тәхеткә әзергә бәзер кайтып керергә кем дә оста. Әнә Сура аръягында бәҗәнәк, угыз, кыпчак көтүләре утлап йөри. Хуҗалары ерак түгел, димәк. Шулар аша бәҗәнәк, угыз ханнары белән солых төзесәң йә аларның алайларын ялласаң да була. Ачуым килмәгәе, шуларның кызларын дүртенче-бишенче хатының итеп ал, мәгәр ханнарын үз ягыңа аудар. Сиңа бот күтәреп яту аеры килешеп бетмәс…

Сәйяхларны төн кунарга озаткач, әмир Ибраһим Сал-Салны читкә чакырып дәште.

— Син, чыннан да, Болгардагы сыбайлар монда килер дип өмет итәсеңме? Әллә… әллә төнлә Ана сөте чишмәсен сакларга сәбәпме бу?

— Чишмәнең катнашы юк, — дип көлемсерәп җавап кайтарырга мәҗбүр булды Сал-Сал. — Ә сыбайларга килсәк, асылда да алар белән сүз беркетү хәер. Болгар диварлары каршына барып җиңелсәк, йә син үзең, йә Тимер-Мөэмин мине дарга асасыз бит. Аннан соң ул чишмәләр миңа нигә кирәк?

Ибраһим, канәгать көлә-көлә, сараена таба китеп барды…

Болгар иленнән яңа олы кәрван ярты елдан соң гына килеп җитте. Ләкин бу юлы аны инде йөзәрләгән җайдаклар озатып йөри, илчеләр төркеме сәет Әшрәфнең үзеннән, курсыбайдагы ике йөзбаштан, Болгардагы кәрвансарай түрәләреннән хасил иде. Кочаклашып күрешкәннән соң, барысы исеменнән сәет Әшрәф кенә гозер сүзен әйтте:

— Түземлек мичкәләребез коргаксыды. Болгар сине көтә. Илеңә кайтырга вакыт, Ибраһим… хан…

Өч көн үтүгә юлга кузгалдылар. Яугирләр, сәүдәгәрләр, һөнәрчеләр, Кызылком сәхрәләре артыннан монда килеп юлыккан дала җайдаклары, әллә каян гына хасил булган җыен сукбай, иң азакта туктаусыз мөгрәп йә бәэлдәп ияргән мал көтүе — барча җан иясе кала капкаларыннан озын дәрья булып сузыла-сузыла чыкты. Дивар-манаралар өстендә санаулы гына сугышчылар, үзләре каккан тәүге казыкларын ташлап китәргә кызганган ташчылар белән балта осталары, хатын-кыз, бала-чага, карт-корылар гына күз яшьләрен сөртә-сөртә тезелешеп калды. Манара очлары күздән югала башлагач кына, Ибраһим кулын болгый-болгый саубуллашты:

— Хуш, бәхил бул, газиз Янкала!*

51

Сал-Сал «әй, юл үтү ул яу йөрү түгел, мәшәкате булмас» дип бик һаваланып-көпрәеп кенә сәфәр чыккан иде, ай-һай, аю өненә таба аягына гер таккан аучы сыман сөйрәлә-сөйрәлә бару борчу-хәвефләрсез, ансат түгел икән. Язгы ташкындай киңәйгән-сузылган кәрванның бер очыннан икенчесенә чаба-чаба, егет тузанга, тиргә батып бетте. Табын янына утырып, тын да алганы юк. Кәрван колын, бозау, бәрән китергән мал көтүе сыман тукталыш саен тулылана, ишәя, үсә бара. Әүвәл Ибраһим яллаган ике мең бәҗәнәк җайдагы килеп кушылган иде, хәзер көн-таң атса арлар, чирмешләр өстәлеп кенә тора. Әлбәттә инде, әмир шат, канәгать, әмма барча күрсәтмәләр, гаепләү-әрепләүләр Сал-Сал башына имән чикләвеге кебек явып кына тора:

— Чирмешләр кичә ач калганнар. Аларга тирмә кормагансың, казан асмагансың.

— Бәҗәнәк ирләрен иң койрыкка калдырмыйча булмас. Алар беркөн төнлә ар кызларын көчләп чыккан икән.

— Ашлы каласына җитәргә ара күп калмады, иравыл йөзләрен көчәйтергә кирәк…

Сал-Сал, кылны кырыкка ярырдай булып, тәгәрмәч уртасына эләккән тиен шикелле әрле-бирле чаба. Айзирәк утырган бөркәвечле арба янына тукталып, сөйгәненә җылы сүз кушарга, тал бөреседәй йомшак кулларын сыйпап бушанырга бер ара юк. Өстәвенә табигать тә ук-җәясен нәкъ аңа каршы корып куйган сыман.

---

* 1221 елдан соң ул рус халкы нигезләгән Нижний Новгород дип атала башлаячак. Мәгълүм ки, тарихны һәрчак җиңүчеләр яза.

Җиһанга җәй сулышы якынлашып килә, ә язның чигенергә исәбе юк шикелле, мәхлук кәҗә төсле һаман киреләнә. Әмма аның буыннары камырланган, сыегайган инде. Күк йөзе хәзер ятим бала кебек еларга гына тора. Әле адашып килеп чыккан бер болыт пыскак яңгыры белән үкчәгә тибеп ала, әле сыргак буран юлчыларның яңакларын көнче хатын сыман чәбәкли. Чокыр-ерымнарда, уйсулыкта саңгырау шикелле кымшанмыйча яткан кар катламы ярлы кеше юрганы кебек һаман сәрпәләнә, һаман ертыла бара. Калдык кар астыннан килеп чыккан барча агач-куак, койма-читән күкрәк тутырып сулыш алган сыман бер карышка үсеп, биегәеп куя. Якын-тирәдәге елгаинешләрдә боз катламнарының сырхау карт-коры шикелле уфылдап йә сукранып ыңгырашкан авазы ишетелгәли. Тик ул боз-карткайлар кыяр урлашырга әзерләнгән малай-шалай сыман төрле яклап килгән ерганакларга каршы тора алмый. Карак малай-шалай — карак ерганаклар — картны барыбер талап китәчәкләр...

Аяк асты сагыз кебек баткак. Олы кәрван гармун күреге шикелле әле сузыла, әле җыерыла. Баш астына бет-борчалы ястык салганнармыни, Ибраһимның бөтенләй йокысы качты. Ул Сал-Сал янына әрсез чебен урынына һаман әйләнә дә килә, әйләнә дә килә. Җайлап-майлап сөйләшүне белми, теле әрем суыдай әче.

— Итәк-чабуларны җыярга иде бит, Сал-Сал сәрдәр. Һәр көн — җан бәһасе. Болай урык-сурык килеп барсак, сарык көтүе төсле таралып бетү дә ерак йөрмәс. Аннан кил дә чүке...

Аеруча тау төшүләр җыкны, сүлне ала. Арбаларның барча тәгәрмәчләрен әле тау очында ук бәйләп куйган булалар, ә түбәнгә таба төшә башладыңмы, алар боз өстенә куып керткән сыер сыман тайгаклый да йә якындагы бер ерым эченә мәтәлә, йә алдагы олау өстенә барып менә. Һәр олауны мең газаплар белән янә юлга сөйрәп чыгаралар, вакыт әрәм була.

Әле ярый, арада җор телле шаяннар, борын салындыра белмәс тапкырлар бар. Ямантау дигән сәер кушаматлы гаҗәп текә үр өстенә җиткәч, юл йөреп шомарган карт сәүдәгәр гыйбрәтле бер хикәят бәян итте.

— Әнә, күрәсезме, тау астында элек бер авыл бар иде, — дип, түбән таба бармак төртә-төртә башлап җибәрде ул.

Тау башына җыелышкан ирләр аста янган бүрәнәләр, күмер өемнәре күреп шаккаттылар. Карт сәүдәгәр янә дәвам итте:

— Җыелыштык та без яндырдык аны. Түзәр әмәлебез бетте чөнки. Ни хәл итик? Ничә генә олау маллар төяп

килмик, бөртегенә хәтле талап шәрә калдыралар. Ничек итеп дисезме? Болар оста! Шушы тау башында ел әйләнәсенә ике-өч ирләре каравылда тора. Мал төягән олау чылбыры килеп чыкты исә, юхалана-юхалана ярдәмгә ташланалар. Берсе алдан ук әзерләп куйган бастырыкларны тартып чыгара да үрәчәләр арасына китереп тыга. Калганнары тәгәрмәчләргә аркан урашалар йә өркүдән янга сикермәсен өчен ат күзенә каеш тырыс көйләп куя болар. Янып-көеп йөгерешкән мондый булышчыларны күреп, син, әлбәттә, сөенәсең инде…

Карт сәүдәгәр юлчыларны авызына каратып тоткан арада, тау башына дистәләгән яңа олаулар килеп туктады, күпләре кузладан төшеп сүгенә башладылар. Ләкин салмак хикәят тавышын ишетеп алуга, колак сагайтып, һәммәсе дә тынды.

— …Боларның ыргак яисә кармак сымак әләктереп ала торган хәйләләре шунда, бөтен эшне бетергәч, дилбегәне олаучының үз кулына тоттырып куя теге соран йөзләр. Аннары атыңның сыртына чыбыркы белән ике-өч тапкыр сыдырып алалар да, әйдә, әллү-үр-үр аска! Күз бәбәкләре акайган атыңны тыюлап, түбән таба атлый-сикерә йөгерәсең инде. Дилбегәләреңә кулда, күзең атта. Бөтен кайгың — атың гына әрәм була күрмәсен дә, атың өркеп читкә сикермәсен. Ир канаты — ат канаты, ансыз калсаң, беттең…

— Йә-йә, ә аннары, ә аннары, — дип, бер-берсенең өстенә өелешеп, юлчылар карт сәүдәгәрне тыкырдатырга ук тотындылар, ә тегесе үз җаена тезде:

— …Ә теге эт җаннар ул арада арткы яклап синең олау өстенә сикереп менә. Арба төбендә ни бар, ни табалар, барысын да читкә очыралар. Хәтта бау аламасы да, иске, тишек кәвешең дә калмый. Үр астына төшеп егылгач арбаңа әйләнеп карасаң, бозау ялагандай тап-такыр, салам төге дә юк. Син, бичара, җан ачысы белән ыргылып, тау өстенә йөгерергә мәҗбүр. Иллә мәгәр, фи-и-ю-уйт, анда төшеп калган малкайларыңнан да җилләр искән…

— Бәреп үтерәсе калган ул караклар көтүен, ботарлыйсы калган! — дип ярсуын чыгарып түгәргә ашыкты тыңлап торган ирләр.

Карт сәүдәгәр нәкъ үзенчә итеп, ашыкмый очлап куйды:

— …Бәреп үтерергә… тоттырмый шул алар. Бар байлыкны җыеп алалар да, җен алгандай, шундук юк булалар. Шуңа күрә без бүтәнчә хәл кылдык. Елан оясы корысын, юкка чыксын дип, менә шушы авылларын төрле яктан ут төртеп көлгә калдырдык без. Ләгънәт төшкән бу урынны башка юлчылар да онытмасын өчен, әнә без әле тау башына ике янган казык та утыртып, көйләп куйдык.

Тау очында, чыннан да, күмерләнгән ике казык күргәч, юлчылар үз олаулары янына ашыктылар. Әйтерсең лә һәркем әлеге урындагы яман данның үз чабуына ябышуыннан чиркана, шүрли иде…

Бара-бара, мондый гыйбрәтле, сәер риваятьләрнең тагын берсен Сал-Салга әле сөйгәне Айзирәк авызыннан да ишетергә, тыңларга туры килде.

Кәрван, Идел яры буйлап төшә-төшә, Ашлы каласына җитеп килә иде инде. Көн чалт аяз, ара-тирә генә ак болытлар бөкрәеп беткән карт чал сакалын өстерәгәндәй җиргә ятып үтә. Озын муенсаны хәтерләтеп сузылган олаулар чылбырындагы ат пошкырулар, арба шыгырдаулар, җайдакларның умарта күче сыман гөжелдәп сөйләшкән авазлары — барысы да Сал-Сал өчен йокы мендәредәй таныш иде. Мондый хәвефсез минутларның кадерен белеп калырга ашыгып, ул кача-поса гына Айзирәк янына килеп җитте. Ә тегесе, иркәләнергә-көйләтергә җай табылгач, шундук иреннәрен бүлтәйтеп каршылады.

— Аякка тараканнар көтүе төштемени, кымшана да алмыйм. Дала буйлап уратып та кайтмыйсың бит, ичмаса.

— Беткән баш беткән. Әйдә соң, алайса, — диде дә Сал-Сал Айзирәкне үзенең ияренә утыртып, читкә алып китте.

Исеме дә билгесез инеш ярында чалма рәвешендәге түмтүгәрәк, биек йомрытау янына җиткәч, Айзирәк сагышлы, боек тавыш белән эндәшеп туктатты аны:

— Әйдә, иярдән төшик тә тезләник без бу тау каршына. Башны иеп аңа сәлам бирик. Бәхетсез яр тавы дип олылыйлар аны кайберәүләр. Икенчеләр Ялгыз балдак диләр. Икесе дә урынлы, икесе дә дөрес… Әнә, күрәсеңме, тауның билен саргылт ком ураган. Сөйгән ярлар бер-берсенең бармакларына кидерергә өлгермәгән алтын балдак бит ул. Кавыша алмаган бәхетсезләр балдагы. Андый бәла-казалардан аралый күр безне, йа Ходаем!

Сал-Сал тирә-якта җәйрәп яткан тип-тигез дала уртасында олы печән кибәне шикелле калкып торган яңа-ялгыз тауга текәлде дә әсәренеп, җитдиләнеп калды. Йомрытауның нәкъ урта бер төшен һарьяктан да яңгыр, җил ашаган. Яшел үләннәрсез калган буынтыкта гәрәбәдәй сап-сары төстәге ком катламы ачылып тора. Тау — биленә алтын кушак, йә булмаса, алтын бөжра киеп баскан кебек. Ялгыз тауны алтын балдак кигән ялгыз, бәхетсез яр белән чагыштыру, и-и, бу чаклы да туры килер, дөрес булыр икән!..

Айзирәк элеккечә моңсу тавыш белән тезеп китте:

— Менә шушы инеш буендагы бер авылда Гөлйөзем атлы бик тә сылу бер кыз яшәгән, ди. Бик күп егетләр гашыйк булган аңа. Күрше авыллардан килеп тә кабат-кабат

кулын сораганнар. Ә ул беркемне дә үзенә якын җибәрмәгән, бер яучыны да кабул итмәгән, ди. Чөнки боларның авылында Зиннәт атлы егет булган икән. Алар сабый чактан ук бергә уйнап үскәннәр, тора-бара бер-берсенә үлеп-үлеп гашыйк булышканнар. Берзаманны болар инде өйләнешергә вәгъдәләр беркетеп, үзара балдаклар да алмашып өлгергәннәр. Ләкин Гөлйөзем болай итеп кисәткән, ди, үз егетен. «Гади балдак кына түгел, йөрәк ачкычым бу. Сансызлама, югалтасы булма. Әгәр бүтән егет күтәреп килә икән, ул чагында йөрәгемне аңа ачачакмын». Зиннәт моңа игътибар итеп тә маташмаган, балдакны шундук атсыз бармагына киеп куйган. Шулай да башка егетләр көнләшеп сорашканда, Зиннәт балдак хуҗасының исемен әйтми икән. Тик барыбер белгәннәр, аңлаганнар инде. Шуннан болар, әлеге балдакны кулга төшерергә дип, мәкерле уй корганнар…

Сал-Сал батыр җәя кереше кебек киерелде. Хәзер ул инде тын алырга да куркып тыңлый иде.

— …Теге көндәш егетләр бәхетеннән җиде кат болытлар өстендә йөзгән Зиннәтне үзләре белән ауга чакырганнар. Урманга баргач, егетне аю чокырына сугып төшергәннәр. «Күрше аланнарда, күрше урманнарда синең туганнарың, балаларың бардыр, алар янына ашык. Мине дә авылда сөйгән ярым көтә. Мин кайтмасам, ул нык сагыныр, елар. Ашама, тимә миңа, җибәр, аюкаем?» — дип, күз яшьләре белән ялварган, ди, Зиннәт. Аю ашамаган. Ләкин егет чокыр өстенә менгәч, көнче юлдашлары суеп үтергәннәр. Балдагын бармагыннан салдырып алганнар да Гөлйөзем янына кайтып кергән болар. «Син, кем балдакны кире алып килә, мин шуңа гына кияүгә чыгачакмын, дип вәгъдә биргән идең, йә, сүзеңне үтә, беребезне сайла», — дип, өстенә басып талымлыйлар икән. Гөлйөзем боларның сүзенә, әлбәттә, ышанмаган. Шул вакытны боларның авылына аю килеп кергән. Ул Зиннәтне биленә салып алып кайткан икән. Егетне Гөлйөзем каршына төшереп калдырган да кире борылып киткән. Җинаятьләре фаш булгач, җәза алудан куркып, катыйль җаннар авылдан чыгып качкан. Ә Гөлйөзем Зиннәтне күтәргән дә менә шушы урынга китереп җиргә иңдергән, ди. Өстенә бәләкәй генә таучык өеп куйган. Шуның очына хуҗасыз калган балдакны кидергән. Ә үзе кияүгә чыкмаган, көн-таң атса, шушы кабер янына килеп, кан-яшь түгә икән. Гөлйөземнең ачы яшьләренә чыланып үсеп чыккан тау бу. Бәхетсез яр тавы, Алтын балдак тавы…

Сал-Сал әлеге ялгыз тау яныннан газиз энекәшен җирләп калдыргандай көч-хәл белән генә атлап китте. Ә Айзирәк авызыннан мондый бәхетсез ярлар хакындагы хикәятләрне тагын-тагын ишетәсе калган икән әле.

Кәрван Кабан күлләре янына җитәрәк, ике-өч фәрсах кына ара калгач, Болгар каласыннан чапкын килеп төште.

— Тимер-Мөэмин, пайтәхетне калдырып, Чулман буйлап килә. Аның кул астында төмән ярым гаскәр. Сине мәмләкәтнең үзәгенә аяк бастырмыйм, ди. Иделнең уңъяк ярында ук турап ташламакчы…

Ибраһимның алдан уйлап куйган нияте булган икән, шундук әмер бирде:

— Сал-Сал сәрдәр! Булган бөтен көчне җый да артыңа ут капкан шикелле алга сыптыр! Өч Кабан күле янында кыядай Елантау бар. Шуны Тимер-Мөэминнән алда эләктерергә кирәк.

Сал-Сал, Айзирәк утырган бөркәвечле арба ягына күз ташлап, кыяр-кыймас кына авыз ачты:

— Ә карт-корыны, бала-чагаларны, э-э… мал-туарны нишләтәбез соң? Аларны дала уртасында каравылсыз көе ташлау ару түгел…

— Нинди карт-коры ди? Нинди мал-туар кайгысы ул тагын? — дип, үз-үзен белештермичә, яшелле-зәңгәрле тавышлар белән кычкырып җибәрде әмир. — Өскә Тимер-Мөэмин ябырылып килә. Аңлыйсыңмы, унбиш меңлек гаскәр! Әгәр Елантауны үз кулыбызга төшереп өлгермәсәк, Тимер-Мөэмин безне йон төргәге урынына тетеп ата. Ә без оттырсак, ул карт-корылар, ул мал кемгә кала?

Ибраһим иң беренче булып ияргә сикереп менде. Кәрван шул мизгелдә үк таяк тыгып болгатылган дәү кырмыска оясына охшап калды. Берничә минуттан соң инде барча җайдак җан-фәрман Кабан күлләре ягына оча иде.

Иң әүвәл, бүре өереннән өркеп качкан мал көтүе сыман, барысы да бер булып, Елантау өстенә менеп тезелделәр. Сал-Сал сәрдәр шул чагында гына тирә-юньне күзләп, бәяләп чыкты. Ибраһим дөрес сайлаган, урын искитмәле отышлы һәм уңайлы икән. Елантау — кыр уртасына бастырып куйган печән кибәне шикелле биек, озынча, текә. Бер ягыннан — Идел, икенче яклап — исеме юк елга, өченче яктан эрелеваклы күлләр муенсасы каплап тора. Тау, кыйблага табынган диндар шикелле, көньяк тарафына гына йөзен ачып, туры төбәп баскан. Ләкин әле ул яклап та Елантау сөяркәсен күкрәк-итәкләрен ачып каршылаучы фахишә хатын кебек көтеп тормый. Аста шактый текә булып сузылган тау итәге, аның алдында гына тигез, зур мәйдан бар. Тик аны да бер очтан сазлык китереп кыскан, икенче очта гаҗәеп зур тирән чокыр ята.

Ибраһим өчен күптән таныш, якын урын булгач, ул инде

йөзләрне-меңнәрне үзе тау өстенә урнаштырып йөри. Әнә җор-канәгать дәшкән әмер авазлары яңгырап ишетелә:

— Әй, меңбаш Бәхтегәрәй! Елантауны ул Мунчала күлләр ягыннан саклауның кирәге юк. Алапа хакына ялланган аймык вә угызлар ул черек күлләргә Тимер-Мөэмин арттан камчы илә куса да барып кермәячәк.

— Меңбаш Сәүбан! Тимер-Мөэмин колларының әнә теге казан эченнән күтәрелеп яисә сазлык аша килеп һөҗүм ясавыннан сакланырга кирәк!..

Тавышлар тынган кебек булган бер арада, Сал-Сал үзе Ибраһим янына барып җитте.

— Сигез меңгә якын җайдакны бердәнбер тау түбәсенә туплап яту бик отышлы түгел. Өстәвенә көрванда калган сугымчыларның, малчы-торгакларның янә бирегә килеп җитүе бар. Тимер-Мөэмин олы чирү белән һөҗүм итә алырдай җир берәү генә. Әнә теге казандай чокыр белән сазлык арасында яткан сукмак. Ул сукмакка бүген үк яшерен тозак корып калдырырга мөмкин.

Ибраһимның күз алмаларында утлы очкын биеп-биеп алды.

— Ничек итеп? Нинди яшерен тозак?

— Ике-өч мең җайдакны аерып алып, әнә теге Идел буендагы таллыклар, өрәңгеләр арасына яшереп куеп була, — дип, Сал-Сал бик җиңел генә бәян итә башлаган иде. Әмма Ибраһим карашындагы очкыннарның шайтан уты сыман шашына башлавын, уртларының яман кысылуын күргәч, телен тешләгәндәй туктап калды. Аның каравы Ибраһим үзе усал ысылдады:

— Миндә әле Тимер-Мөэминдәге хәтле ярты гаскәр дә юк. Ә син инде аны да Мөэминнең авызына калҗа-калҗа итеп бүлгәләп тыкмакчымы?

Сал-Сал, соңгы шартка барып, үз фикерен якларга мәҗбүр булды.

— Ярар соң, алайса, ярар! Синең кул астында йөргән җайдакларны алмыйм! Әнә үзем белән алып килгән бер мең яугирем бар, шуны бир дә чыгар. Ә нинди тозак корырбыз, ул үзен аклармы-юкмы, яуда күрсәтербез.

Ибраһимның әле һаман ныклы бер карарга килә алмый интегүен күргәч, янә дәште:

— Сайлаган корбаныңны кирәк чакта ике яклап кысып та аулыйлар ул. Берәү аягыннан килеп тешли, корбан абынып егылса яисә кирегә борылса, икенчесе күкрәгенә йә сыртына кадый.

— Мин бит ауга чыккан сунарчы түгел. Мин тәхет өчен яуга чыккан әмир. Алда бугазга-бугаз килеп җан кыешу көтә. Миңа һәрбер тешнең кадерле булуы бар.

Ибраһим шул рәвешчә тартышты-тартышты да ахырда барыбер кул изәде.

— Ярар, бер мең җайдагыңны ал да далага чык. Арткы яктан һөҗүм итеп, бәлки, чыннан да, аны тоткарларсың.

Сал-Сал үзенең карлукъ ларылары, мангытлары белән кичекмәстән Идел буендагы таллыкка күченде, шул кичтә үк күнекмәләр ясый башладылар. Дала ирләренең бер өлеше тал чыбыгыннан каз оясы йә читәннәр үрде, икенчесе яр астындагы балчыкта казынып көн үткәрде. Болгарныкылар белән бәҗәнәкләр Елантау өстенә баскан килеш тә, таллык янына килеп-килеп тә кат-кат күзәтеләр, тик бер сергә дә төшенә алмадылар...

Тимер-Мөэмин чирүе Кабан күлләре янында дүртенче көнне, инде төш вакыты үтеп киткәннән соң гына пәйда булды. Әлеге гаскәрнең килеш-килбәтен, кыйланышын күзәтеп яту үзе үк бер әкәмәт, олы сабак иде.

Хан чатырын биш үрәчә кушып ясагандай галәмәт озын арба өстенә көйләп утыртканнар. Аның артында тагын зур-зур тирмәләр корылган унлап арба, бөркәвечләр япкан утыз-кырыклап олау. Кайбер тирмәләрдән чыр-чу килгән кыз-кыркын тавышлары, кайсыларыннан чәң яисә кубыз авазлары яңгырап ишетелә. Ике якта озын дилбегә булып тезелгән җайдаклар шул ваемсыз аһәң тәэсирендә ияр өстендә килеш оеганнар. Хан кәрваны үзенең яу кәрваны икәнлеген бөтенләй онытканнар, ахры. Ул йә яшь килен алып кайтучы, йә яңа кодалар төшерүче моң-хәсрәтсез олауны хәтерләтә. Сан ягыннан күплек сукырайтканмы соң боларны, әллә җиргә хуҗа булып басып йөрү тойгысы шулай исерткәнме? — бернәни аңламассың.

Казандай зур чокыр белән сазлык арасында яткан мәйдан уртасына килеп керүгә үк олаулар, бер-берсенең өстенә өелешеп, капылт тыгылдылар. Арттан килгән ташкын басымына түзмичә, бер яклап сузылган дилбегә сазлык эченә барып керде, икенчесе тирән чокыр төбенә шуышып төште. Ике-өч минут эчендә Елантау итәген туфан сыман тавыш күмеп китте:

— Ханның иравыл алайлары юкмыни ул? Безне нинди тәмуг сазлыгына кертеп батырдылар?

— Җаек хәтле Җаек аръягыннан шушы казан эчендә сытылып үләргә дип килдек микәнни соң?!

Тимер-Мөэминнең курсыбай җайдаклары хан кәрванын ике яклап кысрыклый-кысрыклый, дөмбәсли-дөмбәсли ипкә-сапка кертә генә башлаганнар иде, Идел буендагы таллыклар эченнән шайтан туен хәтерләткән ташкын килеп чыкты. Нинди җанварлар өстенә менеп алганнар да кайсы төрдәге корал белән коралланган болар? Дию пәрие, гыйф-

рит шикелле җир астыннан калыккан нинди коточкыч дәһшәтле көч бу?

Тип-тигез диварны хәтерләткән тере ташкын юлда очраган һәрнәрсәне сытып үтәрдәй булып болгарлар өстенә килә. Дивар талдан үреп ясалган, арба зурлыгындагы калканчитәннәрдән хасил. Ул калканнар артыннан җайдаклар үзләре дә юньләп күренмиләр, өстәвенә чаптар-аргамаклар да тезләренә тикле капланганнар. Хан сакчылары сафындагы берничә мәргәннең сәрпи уклар очырып каравы да файда китермәде, алар шул читәннәрдәге талчыбыклар арасына кереп ябышты да калды.

Ә Сал-Сал җайдаклары берзаманны капылт туктады да тоташ дивар корды. Икенче мизгелдә инде читәннәр артыннар аймыклар, угызлар өстенә ук яңгыры очты. Бер көтү йомран-әрләп сыман сызгырып, селәүсен кебек чинап килгән укларны күргәч ук хан гаскәрендәге йөзәрләгән җайдак ияреннән җиргә сикереп төште, хуҗасыз калган аргамаклар дулый-дулый әле дала якка, әле кеше өстенә чапты. Сазлык арасына исән-имин килеп төшкән укларның очында балчыктан ясалган тишек башаклар күреп алгач кына беркадәр төшенделәр, ләкин саксыз кычкырган яңалыклары хан җайдакларына хәвеф кенә өстәгәндәй булды.

— Сызгыра торган уклар! Безнең өнне алу өчен ясалган махсус уклар!

Дала яугирләре, Тимер-Мөэмин гаскәре өстенә ук яңгыры яудырып бетерүгә, җиде-сигез кисәккә бүленделәр. Аралыкларда кулларына сагызланып беткән тал каз оялары белән ут кисәве тоткан өр-яңа җайдаклар төркеме пәйда булды. Бераздан соң инде хан гаскәренә таба дала яктан тоташ ут көлтәсеннән хасил тәгәрмәчләр чылбыры сызгырып оча башлады. Бу дәһшәттән өннәре алынган аймык, угыз аргамаклары җан ачысы белән кешнәп бер-берсенең өстенә сикерделәр. Җайдаклар арасында да кылыч белән тураш, суеш купты.

Ул арада Ибраһим әмир дә Елантауга тезелгән ике мең бәҗәнәк яугирен Тимер-Мөэмин гаскәре өстенә ташлаган иде инде. Текә тау башыннан чүл бүреседәй улап, карчыгадай канат җәеп төшкән өр-яңа ташкынны күргәч, хан ялчылары чокыр-сазлыкларны аралап тормыйча як-якка сибелделәр. Ә берничә минуттан соң курсыбай йөзбашлары кичәге ханнарын Ибраһим әмирнең аргамак аяклары астына китереп атты.

— Ул тәхеткә, әтисен үтереп, хыянәт белән менде. Шул нисбәттән ул беркайчан да безнең өчен хак хан, лаеклы хан булып саналмады, — дип, Тимер-Мөэминнең сыртына аягын куйган килеш сөйләп китте араларыннан берсе — йөзбаш Атлаш.

Ибраһим аны әле Янкалага килгән чагында ук ятлап калган иде, хәзер инде, әлбәттә, бүлдермәде. Йөзбаш дәвам итте:

— Безнең өчен, бөтен Болгар өчен бер генә инсан — хак хан. Ул син, Ибраһим... хан! Без сиңа гомер буе бил бөгәргә әзер!

Ибраһим янә йөзбашның кыяфәтенә өстән генә, бөркет сыман итеп күз ташлады. «Мине хан итеп күтәрү синең генә кодрәтеңнән килми». Ләкин Ибраһимның бәхет белән мөлдерәмә тулы күңеле бу минутта яңа гына күкәй салган тавык шикелле кытаклап тора иде, ул йөзбашның ялагайлануына каршы елмаймый булдыра алмады. Атлаш исә тагын батырланды.

— Ә моны хәзер нишләтәбез инде, Ибраһим... хан? — диде ул, корбанының сыртына аягы белән төртеп.

Тузанга, күз яшенә баткан Тимер-Мөэминнең йөзе җирдән күтәрелде. Тик бер үтенече генә сыкрап ишетелде:

— Бу көе калдырма, үтер мине, эн-не-к-кәш?

Ибраһим аннан каһкаһә белән кычкырып көлде:

— Чокырга егылып төшкәч, бер бүре баласы да кәҗә тәкәсенә «җизнәкәй» дип назлап эндәшкән, ди. Син дә минем энең икәнлегемне җиде ел үткәчтен искә төшерденме?

Аннары әтисенең «дөньяда таянырга әле дә син бар, улым» дигән сүзләре, Ука елгасы буенда үткән еллар, ажаган шикелле уйнап, Ибраһимның хәтереннән үтте. Йөрәк әрнүләренә түзмичә, ул, тешләрен, уртларын шыгырдатып, нәфрәт белән дәште:

— Юк, сине мин хөкем итмим. Әле Болгарга чаклы исәнсау көенчә алып кайтачакбыз. Анда син зинданга ташлаттырган вәзир, меңбашлар бар. Анда син кулларын чабып өздергән тимерчеләр, көмешчеләр исән. Ул гарипләрнең мескен хатыннары, балалары да, бәлки, ачка кыркылып, үлеп бетмәгәндер. Менә шуларның күзләренә кайтып кара әле. Шул мескеннәр сине хөкем итсен.

Җан ачысы белән Атлаш өстәп куйды:

— Минем әткәй белән ике абыем кулларына кашык та тота алмыйча, кеше күзләренә текәлеп, мөлдерәп яши. Канга — кан! Тимер-Мөэминне дә шулар көненә калдырырга кирәк.

— Шулай итсәң, бәлки, дөресрәктер, — дип, ваемсыз гына җавап кайтарды да Ибраһим, аргамагының касыгына типте. Ярым борылып Атлашка кычкырган сүзләре яндагы ботакяфракларга сарылып-йотылып калды:

— Мәгәр кайткач, Болгарга әйләнеп кайткач!

Ибраһим инде Елантау итәгенең яртысына менеп җиткән иде, Атлаш аның сүзләрен төгәл ишетмәде. Аның һавада яшен кебек ялтырап алган кылычы икенче минутта Тимер-Мөэминнең ике кулын да терсәктән тиң өзеп аткан иде.

Елантау өстенә менеп җиткәч тә, Сал-Сал сәрдәрне, якыннарын җыеп, Ибраһим сабан тургае сыман очына-очына әйтте:

— Мин бу урынга әле Янкалага чыгып киткәнче үк үлеп гашыйк идем. Бүген ул минем өчен инде иң истәлекле, иң кадерле җиргә әверелде. Без монда бүген җиңү яуладык, Болгар тәхетенең иминлеген, бәхетен саклап калдык. Мондый урынны мәңгеләштерми булмый. Кичекмәстән яңа кирмән корып куярга кирәк монда, яңа кирмән кирәк! Кем белә, бәлки, әле пайтәхет үзе дә тора-бара монда күчеп килер...

Ибраһим яраннары табын корып күңел ача, бөек җиңүне билгели башладылар. Янә сөеклесе белән кушылудан учак кебек кабынган, дәртләнгән Айзирәк, Сал-Салны җитәкләп, сикергәли-сикергәли, Елантау итәгеннән аска алып төште. Монда, исемсез елгага таба сузылган киң ерымнар эчендә, әллә ничә мәгарә бар икән. Мәгарәләргә йөзәрләгән җайдак белән кереп югалырга була; аларның ахыры, елан койрыгыдай боргаланып, Елантауга кереп югала. Шул мәгарәләрнең берсендә сабый күз яшедәй чиста чишмә челтерәп ята. Чишмә ерактан, Елантау астыннан ук тибеп чыккан бугай, мәгарә авызына килеп җиткән урында ул гөжелдәп, гөрләп ага. Чишмәнең нәни генә күл хасил итеп җыелган урынында матур җиз улаклар, кечкенә тирмәләр дә ясап куйганнар. Димәк, Елантау үзе дә, әлеге чишмә дә болгарлылар өчен чит-ят түгел, бирегә кемнәрдер бик еш килеп йөри икән.

— Нургали чишмәсе бу, — дип таныштырды Айзирәк, аның кәүсәр суын учларына алып. — Нургали дигән бәхетсез яугир хөрмәтенә шулай атаганнар. Күрше-тирәдә көн күрүче чирмеш авыллары да, узгынчы болгарлар да бу чишмәне һаман изге саный.

Ашъяулык чаклы гына нәни күл янына тезләнеп, Сал-Сал сорап куйды:

— Нургали бәһадир булганмы соң? Вәзир-мазармы, берәр хан туганымы?

Моңсу, талгын тавыш белән Айзирәк тезеп китте:

— Юк, аны кеп-кечкенә болгар авылыннан чыккан гапгадәти егет булган, диләр. Туган, үскән, егет булып җиткән. Җаек елгасы ягыннан дошман бәреп кергәч, аны Болгар мәмләкәтенең данын якларга дип яуга чакырганнар. Бер орыш барышында дошман пәһлеваны моның баш түбәсенә гөрзи белән китереп орган да, Нургали, аңын югалтып, менә шушы исеме дә юк елга ярына ауган. Иптәшләре, яудашлары аны инде вафат булган шәһиткә санаганнар, шушы елга ярында

япа-ялгыз көе ташлап калдырганнар. Егет аңына килсә, аның ике күзе дә сукырайган булган. Ул хәзер инде үзен беркемгә дә кирәксезгә санап, шушы яр буенда япа-ялгыз көе яшәп калган…

— Бәрәкалла, бәрәч! Әллә аның исәнлеген тикшерүче кеше дә булмаганмы? Теге егетләр нишләп алны-артны карап тормыйча да качкан? — дип ярсып купты Сал-Сал.

Айзирәк аңа игътибар да биреп маташмады.

— …Ә Нургалинең авылда Сөмбел атлы бик тә сылу сөйгән яры торып калган икән. Юлдашлары егетнең вафаты хакында кайтып әйткәч, Сөмбел ачыргаланып, өзелеп елаган, ди. Башка яугирләр «үлгән артыннан үлеп булмый, болай бетеренмә» дип үгетләп караганнар, чынлап гашыйк булып кызның кулын да сораганнар. Беркемне дә якын җибәрмәгән Сөмбел, барча яучыларны кире куган. Аннары менә шушы елганың чишмә башын эзләп тапкан да, якындагы тугайлыкта үскән аллы-гөлле чәчәкләрдән такыялар үреп, аларны елый-елый агымсу буенча озатып кала икән. «Такыялар гади генә түгел. Мин аларга йөрәгемне, сөюемне куштым. Бер дә туктамыйча, сөйгәнемне эзләп тапканчы агыгыз, такыялар. Егетем сезне танымыйча калмас», — дип, бәгырен телә-телә озаткан, ди, Сөмбел аларны. Такыяларның берсе нәкъ менә шушы урынга, Нургали яраланып ауган яр читенә агып килеп җиткән. Көтмәгәндә такыяга җан иңгән, ди. «Сөйгәнеңнән сәлам алып килдек, ә син безне таныйсыңмы, егет?» — дип, кеше кебек назлап эндәшкән ул. Дөм сукыр булса да, Нургали яр буена йөгереп төшеп җиткән, такыяны кулларына алган. Ул такыяны үбәргә дип иреннәрен тидерүе булган, ике күзе дә шундук ачылган, ди. Мондый бәхет белән канатланган егет аргамагына сикереп атланган да, сөйгәнен күрергә ашкынып, авылына очкан…

Сал-Сал, учларын бер-берсенә ышкып, очынгандай итте. Авызы ерык иде.

— Һе! Болай булгач, кавышканнар инде ул бәхетле ярлар.

Айзирәк егетнең хыялларын бик тиз җимереп атты:

— Ю-у-ук шу-ул, батыр, кавыша алмаганнар:

Иреннәрен әрем капкан төсле бөрештергән Сал-Салның күзләрендә ялкын сүнгәч кенә Айзирәк дәвам итте:

— …Сөмбел аны бик-би-и-ик озак итеп, атналар вә айлар буе көткән. Ә аннары инде кыздагы түземлек тә язгы кар шикелле барыбер эреп беткән. Көннәрдән бер көнне ул ирләр киеменә киенеп алган да, чаптар атка атланып, сөйгән ярын эзләргә чыгып киткән. Язмыш шаяртуы димичә, тагын ни әйтәсең? Нәкъ менә шушы урында үзенең такыялары җыелып торганны күреп тукталган ул.

Сукыр Нургали яшеренеп яткан шушы мәгарәне дә эзләп тапкан. Ләкин көтмәгәндә бер дошман мәргәне килеп чыккан да, ир-ат кешегә санап, бичара кызны ук очына алган. Мондый бәхетсезлек илә мондый гаделсезлекне күреп, өстәвенә әле гөнаһ та күтәрә алмыйча, Елантауның хуҗасы ярсыган, ди. Кинәт кенә бөтен тау өстендә кот чыкмалы гарасат, туфан купкан. Ә менә шушы мәгарә эчендә, Сөмбел егылган төштә, Җир-ананың күз яшьләре булып чишмә бәреп чыккан...

Айзирәк үзе дә хискә чумган иде. Күз яшьләрен Сал-Салга күрсәтмәс өчен ул яңагын бармак очлары белән сөртеп-сыйпап алды.

— ...Нургали Сөмбелнең гәүдәсен шушында эзләп тапкан. Каядыр мәгарә эченә алып кереп, сөеклесен яшереп җирләгән, ди. Кабер янында Сөмбел хөрмәтенә Елантау өстенә менеп яңа кирмән, яңа кала төзиячәге турында нәзер әйткән егет. Тик Нургалинең гыйсъяндай тәкәббер сүзләре Елантау хуҗасына бер дә ошамаган. Ул егетне шул минутта ук янә сукырайткан. Ахырда бичара егет шушы урынга әйләнеп кайтырга мәҗбүр булган. Әнә теге улак куелган урынга башын бәрә-бәрә өзгәләнгән. Сөеклесенең җырларын, күз яшьләрен, гыйшкын хәтерләткән бу чишмәне соңыннан да ташлап китмәгән ул. Менә шушы тирмә эчендә яшәгән, шунда җан биргән, ди. Чишмәне хәзер Сөмбел күз яшьләре дип телгә алучылар сирәгәйде. Аны күбесенчә йә Елантау җаны, йә Нургали чишмәсе дип искә төшерәләр...

Айзирәк сөйләүдән туктагач, Сал-Сал батыр басынкы, боек тавыш белән йомгак ясап куйды:

— Синең хикәятләреңнең һәрчак ахырлары сәер. Йә ике яр да берьюлы һәлак була, йә бер яры ялгыз торып кала. Табышып кавышкан бәхетле ярлар турында син бер хикәят тә сөйләмәдең әле... Нигә шулай? Әллә безгә дә аерылу юрыйсыңмы?

— Авызыңнан җил алсын! — дип ярсып кычкырды да Айзирәк, Сал-Салның муенына килеп сарылды. Нәни йодрыклары белән батырның күкрәген дөп-дөп төя-төя, тагын кабатлады:

— Юк, юк! Без аерылмыйбыз, җаным, аерылмыйбыз! Әткәй Болгар каласына гына кайтып җитсен, әткәй тәхеткә менсен. Аннары, аннары без синең белән мәңге-мәңге бергә булачакбыз...

Болгарга кайтып керүгә, Айзирәкнең әнисе яман сырхаулап түшәк өстенә ауды. Яңа яз борынлаган чакта, аны җирләделәр. Аннан соң да атналар, айлар узды, бәхетле йомгак очы һаман табылмады.

— Ука елгасы ягыннан дошман якынлаша! — дигән уттай хәбәр Болгарга язгы карлар тәмам эреп беткәч кенә килеп җитте.

Янкала — урыс кенәзлекләренең борын төбенә китереп торгызылган кирмән, дошман өчен аның бөергә утырган таш шикелле тәэсир итүе болгарларга ят сер түгел иде. Беренче хәвефне нәкъ шул кала тарафыннан көтеп яшәделәр. Кайгылы, шомлы хәбәрне атна-ун көннән соң ак күбеккә баткан чапкын алып кайтты:

— Янкала урыслар кулында. Һәрбер каралтыны тишек комганнарга хәтле талап бетерделәр.

Эскәк белән җыйган төсле төкләп-бөртекләп тупланган башка төр мәгълүматны Ибраһим хан алдында вәзир булып алган Насыйр бәян итте:

— Дошман чирүендә егерме биш мең яугир. Яу сәфәрен Кияү каласының олугбәге Владимир үзе җитәкләгән. Ул элегрәк безнең өскә килгән Святославның уйнаштан туган бер малае икән. Кияү каласындагы боярлардан шикләнгәнгә күрә, үзенә сәрдәр итеп әнисенең энекәше Добрыняны алган. Әтисе белән әнисеннән йоккан чир калгандыр инде, эссесен басар өчен Владимир үзе белән бергә өч йөз җариясен иярткән йөри икән.

— Һе, уйнашлыкта әтисен уздырган бу, — дип, әүвәл Ибраһим да каһкаһәләп көлде, әмма икенче минутта ук кискен җитдиләнде. — Хәер, уйнашлыкта гына түгел икән. Святослав безгә унбиш меңлек чирү белән килеп кергән иде, монысы егерме биш меңне җыйган. Димәк, тегеләрнең өнен тыгар өчен күбрәк калаларны кулга төшерергә, күбрәк байлык таларга өметләнә. Теге чакта әтисенең арт сабагын укытып озата белмәдек, шуңа күрә комсыз, азгын болар.

Ибраһим, тешләре сызлаган шикелле йөзен сытып, ярсый-ярсый кабынып ук китте:

— Әй-яй, ачыгавызлар без, әх, үшәннәр! Моннан өч ел элек үк Елантау өстенә яңа кирмән төзеп куярга ният иткән идек. Бүгенгәчә кыл да селкеткән юк. Авызга су тулмыйча торып, йөзәргә дә өйрәнә белмибез бит! Нигә дошман килеп артка типкәнче болай йоклап яттык? Әгәр Елантау өстендә хәзер ныклы кирмән, яңа кала балкып утырса, дошман Болгар иленең йөрәгенә таба аяк та атлый алмас иде бит, атлый алмас иде! Әй, үшән без!

Шул рәвешчә берникадәр бушангандай булгач, вакытны озакка сузмый-нитмичә, Ибраһим тәүге әмерләрен дә әйтеп ирештерде:

— Барча олысларга, калаларга иртә таңнан мөнадиләр вә

чапкыннар китсен. Калаларның һәркайсыннан өчәр меңлек чирү. Һәрбер олыстагы авыллардан берәр меңлек нөгәр тупласыннар. Күңелемә хуш килгән урын сиңа яхшы мәгълүм. Алайларның һәммәсен дә Елантау өстенә илтеп тупласыннар.

Тәхет залыннан вәзир Насыйр чыгып югалуга, Ибраһим хан шыгавыллар башлыгы Гаянны чакырып алды:

— Миңа курсыбайдагы йөзбашы Атлашны табып китер. Кара аны, кеше шәйләмәсен.

Караңгы зал ишегендә кап-кара башлыкка төренгән Атлаш пәйда булгач, теш арасыннан сытып сүз ыргытты:

— Тимер-Мөэминнең кулларын өзгән өчен мин сине инде әллә кайчан йә дар агачына астыра, йә кисәкләргә чаптырып ташлый ала идем. Син ханнар каны бәһасе торырдай алтын тавы түгел. Әмма теге чакта кисәкләргә өзгәләтеп ташламаганмын икән, димәк, кирәк чакта сиңа таянырдай исәпләрем булган. Менә сиңа да гөнаһларыңны юу өчен уңай форсат чыкты. Безнең өскә олы дошман килә. Иң ышаныч-лы биш-алты гына иптәш сайлап ал да шуңа каршы юнәл. Владимир кенәзнең ыстанына үтеп керми калма. Кенәз нинди адым кыла, ниләр ният итә — энәсеннән җебенә чаклы миңа җиткерерсең...

Атлаш төркеме таң аткач та юлга чыккан иде, унбиш-егерме көннән соң гына Шәһитләр убасы дигән йомрытау янында дошман гаскәренә килеп кушылдылар. Бу тирәдә яр читендәге бакакайлар кебек сирәк-мирәк кенә сибелгәләп ар йә чирмеш авыллары яшәп ята иде. Шул авылларның берсеннән чачаклы-чуклы киемнәргә төренеп, билләренә дөмбер һәм кыңгырау асып чыккан җиде-сигез ир-атка юньле-рәтле игътибар биреп торучы да табылмады. Арадан берсен — бил каешына көмеш аел эләктергән Атлашны гына ике сакчы ыстан үзәгендәге зур чатырга таба җилтерәтеп-йолкып алып китте.

— Нинди кыргый исемнәр бу сезнең якта? Каян килгән Шәһитләр убасы бу? — дип, өстән яңгыраган ят тавышны ишеткәч, тоткын юлчы сынып төшкән иде, тылмач тәрҗемәсеннән соң гына аңа җан кергәндәй булды.

Күтәрелеп караса, алмачуар ат өстендә иңнәренә җете-кызыл төстәге озын җилән япкан мәһабәт ир утыра. Олугбәк Владимир дигәннәре шушы була икән. Әче бал яисә хәмер капкан бугай, авызы ерык, аскы ирене иягенә чаклы салынып төшкән. Атлаш тилемсә кеше сыман башын чайкый-чайкый шундук тезеп китте:

— Каян килгән диеп, гомер буе шушында утыра инде бу йомрытау. Ни өчен исеме Шәһитләр убасымы? Чөнки монда яу кырында башын салган шәһитләрне, ягъни илен, халкын яклап вафат булганнарны җыеп җирләгән-

нәр. Исеме дә шуннан торып калган. Ә «уба» дигәне сезнеңчә «курган» була.

Атлаш аңлатмасын тыңлап бетерүгә үк, Владимир кенәз кулларын үз астындагы алмачуар атны да күккә алып менеп китәрдәй булып болгый-болгый тузынды, котырынды:

— Япа-ялан дала уртасында нинди ил булсын ди? Каян килгән дәүләт, нинди дәүләт? Барысы да уйдырма, һәммәсе дә ялган! Бу — әле төрән йөзе дә күрмәгән, кызлыгы да алынмаган дала, хуҗасыз җир! Монда бернинди дә шәһитләр була алмый. Әлеге тау астына сихерчеләрне, кыргыйларны җыеп җирләгәннәр. Аның изге курган булып саналырга хокукы юк. Хәзер үк, күз ачып йомганчы җимереп бетерегез!

Ялгыз бәрән тапкан ач бүреләр сыман барысы да йомрытауга барып ябырылды. Кич җиткәндә, аның урынында яшел кәс калдыклары, кызыл балчык өемнәре генә сибелеп ята иде…

Владимир кенәздәге чит-ят гадәтләрне, аның җансыз потларга табынуын да күргәч, Атлаш торган саен ныграк сәерсенде. Кенәз яу сәфәре, юл михнәте дип тормаган, зур-зур чытыр арбаларга утыртып, кайсысы балчыктан, кайсысы агачтан юнып ясалган әллә нинди сыннар алып чыккан. Берсе маллар алласы Волос икән боларның, икенчесе уңыш алласы Ярило, ди. Тагын җиләк-җимешләр алласы Купала үзе аеры көе бар, уйнаганда-биегәндә Колядага табыналар икән. Гыйшык тотучылар Ладо дигән потны үбеп-кочып яши, гөнаһлары өчен гадел хөкем өмет итүчеләр Прове атлы сын каршына барып тезләнәләр. Аннары бер-бер артлы тезелешеп киткән эреле-ваклы потларның ияләре — Подага, Живаго, Хорс, Дажебог, Припекала, Мокош, Стрибог, Похвист, Яр, Пик, Давор... Боларның исемнәрен дә ятлап бетереп булмый, ә алар тормыш итү, бала табу, уйнаш, тимер кою, кояшлы көн, җил… тагын кырыкмаса кырык төр буенча илаһи көч иясе дип саналалар икән. Ерып чыккысыз чытырманлык, куып таратып булмас шайтан туе белән бер бит бу, валлаһи!

Әле ярый, кенәз чатыры корылган арба янәшәсендә боларның Перун атлы төп алласын сурәтләгән пот ияреп йөри. Гәүдәсе агачтан ясалган, йөзен — көмеш, иягенә төшкән мыекларын алтын калай белән каплаганнар. Ул элегрәк яшен, ут алласы булып исәпләнгән, хәзер вак-төяк потлар арасында баш хуҗа, ди. Владимир аны бастырык шикелле озын, биек итеп ясаттырган, үз чатырыннан бер адым да читкә калдырмыйча, гел иярткән йөри. Кара сугышчылар: «Кенәзнең бу агач түмәрен түшәккә салып ятасы гына калды инде», —дип чыш-пыш килеп көләргә генә тора. Ләкин Владимирның күләгәсе пәйда булуга, шундук сагаялар. Кенәз әлеге потка тел тидергәннәрен бер дә сөйми икән. Озакламый Атлаш моңа үзе шаһит булды.

Җилем шикелле тартыла-сузыла бара торгач, Өрәкләр үзәнлеге дип аталган уйсулыкка да килеп җитте алар. Үзәнлекнең сәер кушаматын ишетүгә үк, һаман да шул Атлашны чакырып алды кенәз.

— Каян килгән исем? Нинди уйдырма? — дип, күк күкрәгәндәй акыруын белә.

Атлаш тавышын басып кына аңлатырга маташкандай итте:

— Бу үзәнлектә кычкырып сөйләшергә һич ярамый, кенәз. Элек бу урында бик олы яу булган. Меңәрләгән ирләр кырылышкан. Атлап йөрерлек тә урын беткәч, исән калган ирләр яңа далага күчеп орышканнар. Ә шәһит булганнарны соңыннан бер кеше дә килеп җирләмәгән. Менә шушында, ачык далада череп кенә юкка чыкканнар, ди. Кайсын ач бүреләр килеп ботарлаган, кайсын карга-козгын. Адәм балаларындагы мондый гамьсезлекне, кансызлыкны күреп, Ходай Тәгалә үтә рәнҗегән дә әлеге үзәнлекне бик нык каргаган, ди. Хәзер монда юлаучылар килеп керә калса, атлары һич тыңламый. Чыбыркы шартлатсаң, козгын-карга көтүе җыелыша. Сызгырып йә сүгенеп куйсаң, барча арба үрәчәләренә тикле кереп бата. Юлаучылар мал бүлешә йә сугыша башлады исә, җир убыла. Менә шундый, бик тә хәвефле, сихерле һәм яман үзәнлек бу. Аны хәзер күпчелек кешеләр урап кына үтә. Ә төннәрен монда фәкать өрәкләр генә чыгып йөри икән.

Тылмач хикәятне бәян итеп чыккач, якын-тирәгә җыелышкан барча ирләр утка пешкән мал тиресе кебек куырылып, кечерәеп калды. Владимир гына авызын күккә чөеп, буш чиләк шикелле даң-доң килеп шаркылдавын белде:

— Ниткән өрәкләр ди? Нинди яман үзән? Уйдырма, әкият, тоташы белән ялган! Бернинди дә сихер-михерләр юк. Бу урынга чаклы ни рәвешле килеп җиткән булсак, шул көенчә алга атлыйбыз да эһ тә итми үтеп китәчәкбез!..

Юкка гына һаваланды кенәз. Беренче меңдәге атлар үзәнлек эченә аяк басуга ук шабыр тиргә батты. Кайберләре авызлыкларын зеңгелдәтә-зеңгелдәтә, усал пошкыра-пошкыра алга таба атлаудан бөтенләй баш тартты. Җайдаклары аңлап һәм бәяләп җиткермәде. Дуамаллар малкайларның касыгына типте, камчы белән ярды. Өннәре алынган атлар, чарасызлыктан-көчсезлектән ярсып дулый-дулый, үзәнлекнең читенә сибелделәр. Дистәләгән җайдак әллә каян гына хасил булган сазлыклар эченә кереп батты, дистәләгән атның сыйраклары, умырткасы сынды. Ирләрнең аякларына киелгән катлы-катлы чабаталар сазлык эчендә җәфаланучы хуҗаларын таш аскандай аска өстерәде. Бичаралар өстенә арттан килгән ташкын килеп өелеште. Үзәнлекне ачыргаланып кычкырган ирләр белән атлар тавышы күмеп китте.

Ахырда, уйсулыкны урап узгач кына, санап карадылар. Өрәкләр үзәнлеге төп-төгәл бер мең атны, йөзәрләгән җайдакларны үзенә йоткан иде.

Владимир кенәзгә каршы иң беренче булып аталы-уллы Федор белән Иван гау куптарды. Боларның аякларында хәтта чабаталары да юк, алар карап торышка ук алла мескеннәре иде.

— Икебезгә бер чаптарсыз калдык. Хәзер Болгарны таларга да барып булмый, кайтып китик дисәк тә, бер терәк юк. Синең әнә йөзәрләгән чаптарларың балчык потлар, агач сыннар төялгән олауларны тартып йөри. Ул җансыз потларны сөйрәп бушка тыгынганчы, ике атны безгә кайтарып бир һәм вәссәлам, кенәз!

Владимирга әле генә кылган гөнаһларын юар өчен корбан кирәк иде. Шулар табылган сөенечтән, ләгънәт ора-ора, алга чәчрәп чыкты:

— Ah, безнең изге аллаларга тел тидерәсезме әле, ике бәдбәхет җан?! Алар җансыз агач сын да, яу сәфәренә чыккан кешеләргә җиңү сорап табынырга потлар кирәкмиме? Йөзләренә ялган битлек киеп алган дошман икән болар! Безгә җиңелү һәм хурлык теләп йөрүче кабих җаннар! Тураклап ташлагыз бу имансызларны, тураклагыз!

Өрәкләр үзәнлегендә зур югалту кичереп исәңгерәгән ирләр кенәзнең шашынулы әмеренә каршы тора алмады. Бер төркем җәяүле ир үзләренең гыйсъян юлдашларын күз ачып йомган арада өзгәләп тә атты[1].

55

Урыс гаскәренең икегә бүленеп килүен төгәл белә иде, Ибраһим да аларны болгар көчләреннән ике җәтмә корып каршылады. Елантау өстенә алданрак килеп җитешкән алайларның берсе дә тик ятмаган, дилбегә чаклы озын бүрәнәләрдән урыны-урыны белән ерым читләрендә, итәкләрдә тоташ койма-дивар бастырып куярга да өлгергәннәр икән. Ибраһим төп чирүне, әлбәттә, шул диварлар артына яшереп туплап куйды. Сал-Сал сәрдәр өчен дә фәрман-бурыч күптән әзер иде.

— Син мөгез чыгаруны бик тә яратасың. Әйдә инде, бу юлы да Идел буендагы таллыклар ышыгында посып утыр. Саллар, каеклар өстендә агып килүче сигез мең урысны Владимирның агасы Добрыня үзе җитәкләгән, диләр. Менә ике

---

[1] Аталы-уллы Федор белән Иван — мәҗүси Киев Русендә бер генә аллалыкны яклап чыккан өчен кенәз Владимир корбан иткән һәм соңыннан чиркәү тарафыннан изгеләштерелгән җаннар.

сәрдәр ике кәҗә тәкәсе шикелле маңгайга-маңгай килеп орышырсыз. Кайсыгыз остарак икән, сынап карыйк әле…

Канлы яулар, зур сынаулар үткәреп торырга насыйп булмаган шул. Авызларына камыш сабагы, көпшә капкан карлукъ, мангыт ирләре, тәүге саллар Кабан күлләре турысына килеп җиткәнче үк, су астыннан гына чумып барып, барча арканнарны кисеп бетерделәр. Бүрәнәләр елга буйлап таралды, йоклап баручылар су төбенә китте, уянганнарын аякларындагы чүлмәк кадәрле чабаталары аска өстерәде, Идел өстен тоташ мәхшәр, тәшвиш каплап алды. Елгырраклар янда аккан каекларга ташланганнар иде, өстәгеләр, сөңге-кылыч кадап, ишкәк белән сугып, аларны янә Идел дулкыннары эченә чумдырдылар. Дистәләгән каекларның асты өскә килде, елга суы яңадан-яңа корбан белән тулды. Җил тузгытткан салам сабаклары кебек таралышып яткан бүрәнәләр, үле балык сыман йөзтүбән яки яны белән йөзгән каеклар өстенә арттарак сузылган яңа саллар, күбесенчә ризык, малтуар һәм җәрияләр төягән олырак көймә-баркаслар килеп менде. Мондый башбаштаклык тагын күз күрмәгән, колак ишетмәгән гарасат китереп чыгарды. Бер-берсенең өсләренә яткан көймә-саллар язгы ташкын вакытында тар бугазга яисә биек бусага алдына килеп тыгылган боз катламнары сыман ухылдады. Өнсез калган кәҗә-сарыклар, тимер көбә белән ук-җәясен дә эләктерергә өлгермәгән ирләр күз-башларын тондырып суга сикереште. Йөзә белгәннәр Кабан күлләре ягына якынайса, алар өстенә таллык, әрәмәләр эченнән ук яңгыры очты. Каек-салларга төялгән урыс ирләренең күпчелеге, ахыр чиктә чабаталарына хәтле салып ташлап, Иделнең икенче як ярына чыгып ауды.

Добрыня үзе егерме ишкәкле зур корабта су кәрваны уртасында йөзеп бара иде. Яңагына китереп суккан сыман искә-аңга килеп, дилбегәне үз кулына эләктерергә бик соңарып кына өлгерде ул. Идел өстен аның җиз торба чыңы шикелле усал, мәгърур тавышы каплап китте:

— Саллар, каеклар читенә калкан күтәрегез! Смоленск белән Галич укчылары, алга, кәрван борынына! Радимичлар, вятичлар, кривичлар! Яр өстенә чыгып ябышу өчен каплан алайлары әзерләгез!

Барча кәрван астына ут ягылган олы казан сыман айкалды, гөбердәде. Сал-каекларның як-ягын агач яки тимер калканнар дивары төреп алды. Калканнар арасыннан дәһшәт бөркеп сузылган ук һәм сөңге очлары энәләрен усал тырпайткан мәһабәт керпеләрне хәтерләтте. Әле Галич, әле вятич укчыларыннан торган йөзлекләр, кәлтә еланнар кебек тавыш-тынсыз гына шуып төшеп, Кабан күлләренә таба йөзеп китте. Үгез тиреләреннән катлы-катлы итеп һәм сумала белән катырып

ясалган җиңел калканнар астына ышыкланган укчылар төркеменең һәркайсы, чыннан да, посып кына корбанын ауларга баручы кара капланнар шикелле дәһшәт бөркы иде.

Тора-бара яр өстенә чыгып ныгыдылар. Идел белән Кабан күлләре арасында яткан иңкүлектә өч меңнән артык сөңгесен як-якка тырпайткан беренче урыс гаскәре хасил булды. Яр өстеннән килүче төп көч белән ике арадагы элемтә өзелгән иде инде, Добрыня итәгенә ут капкандай ашыгып бер дистә чапкын куды.

— Кенәзгә җиткерегез! Болгар ханының төп гаскәре безне әнә теге тау башында көтә. Даладагы иң отышлы, иң шәп биеклекне мин эләктердем дип, шунда посып яту, дивар артына кереп качкан көе шәрә йодрык селтәп кәпрәю-һавалану — ул әле безне ярык тагарак тоттырып калдырдым дигән сүз түгел. Ибраһим ханның печән кибәненә менеп яткан эт шикелле үз-үзенә кабер казуы бар. Бәлки, ул кибәнне без дә озак вакыт буе кимерә һәм йолыккалый алмабыз. (Әгәр инде төрле яктан килеп ут төртмәсәк.) Ә иң мөһиме — ханның әнә шул кибән түбәсендә, печән ашый алмаган эт хәленә калып, ачтан үлүе бар. Монысы инде фәкать безнең нинди камалыш божрасы төзеп куюыбызга гына бәйле. Шуңа күрә олуг кенәз үзенең җайдакларын әнә теге, олы казан шикелле, чокыр буйлап тезеп куйсын иде.

Баскын җайдаклар гаскәре берәр сәгать чамасы вакыт үткәннән соң пәйда булды. Владимир Елантау буендагы хәлне үзе өчен тагын да отышлырак, хәвефсезрәк дип бәяләде, ахрысы, ул җайдакларын янә кыл урталай бүлде.

Владимир үзе белән бергә яу сәфәренә ике яшь хатынын, әтиләренең җиңүләренең күреп горурланырдый зуррак балаларын, шулар арасында ундүрт яшьлек Святополкны да алып чыккан иде. Святополк — кенәз Владимир ятагына көмәнле килеш кәнизәк сыйфатында килеп эләккән киленкәе Ангелина тапкан-баккан бала. Аның әтисе мәкерле Ярополкны Киев тәхете өчен суеш барышында Владимир үзе үтерттерде. Дөрес, Ярополктан соң тол калган юнан сылуын хатын итеп алды ул алуын. Святополкны да какмый-сукмый үстергәндәй итте. Ләкин картлар, «ятим бала асрасаң, авызың-борының кан булыр» дип, юкка-барга гына кисәтмидер. Бишектәге бала кырыкка төрләнә, ди. Святополк үсеп җитсә ни булыр бит әле? Әтисенең үлеме өчен үчкә сусамасмы? Андый хәвефләрдән котылыйм дисәң, көндәшеңне янган учак янында йөртү хәерлерәк. Хәтта син төртеп төшермәсәң дә, аның үзенең ачыгавызланып утка пешүе бар. Менә шушы уйлар аны үги улы Святополк белән юлдаш, яудаш итте…

Әтисе ым каккач та, хуҗасы мәрхәмәт күрсәтеп ыргыткан сөякне тугрылык һәм рәхмәт хисе белән эләктерергә таш-

ланган эт баласы кебек, канатланып килеп җитте егет. Авызын колакларына тикле ерган, йөзендә үч-мәкер чалымы юк, әмма... әмма ул барыбер сөзешергә әзерләнгән усал үгез кебек, каш астыннан текәп, сынап карый. «Ятим бала һәрчак үчле була» дигәннәре хакмы соң ул әллә?

— Бер нөгәрне синең кулга бирәм, — дип башлады Владимир, хәерче сукбайларга икмәк сыныгы өләшкән байчуралардагы шикелле вәкарь тавыш белән. — Әнә теге инеш буена бар да Ибраһим хан оялаган тауны шул тарафтан биклә. Мине җыен юк-бар мәшәкать өчен дә чапкын куып бимазалыйсы булма. Үзең баш, үзең түш. Һәммәсен ялгыз көе хәл итәргә өйрән.

— Итәм, итәм, әткәй! Үзем, үзем! — дип, учак кебек дөрләп кабынды япь-яшь егет.

Икенче мизгелдә җайдаклар өстенә күрше тавыкларын тапап чыккан яшь әтәч шикелле гайрәтләнеп кычкырган әмер яңгырады:

— Киевлылар, осколлылар, алга! Куркак хан менеп качкан тауны кече инеш яклап өчәр катлы чылбырга утыртабыз!..

Юк, тагын ашыкты, хаталанды кенәз. Яшүсмер Святополк үзенең алайларын Нургали чишмәсе тирәли тезеп тә өлгермәде, ә Елантау түбәсеннән баскыннар өстенә туфан куптарып улаган, дөбердәгән бүрәнәләр очты. Гади бүрәнәләр генә булса бер хәл, андыйлары урыс җайдаклары өчен зур яңалык түгел. Мәгәр болар! Һәрберсе җиде башлы дию, гыйфрит, аждаһа, буар елан!

Елантау өстеннән алдан ук сагызланып куелган һәм хәзер инде ут элеп очырган юан-юан бүрәнәләр тәгәри. Һәркайсы да озын, колач җитмәслек юан. Чүл бүресе сыман улап, яман ут көлтәләре бөркеп тәгәриләр. Алар килеп төртелгән һәр урыннан чүлмәк-чүлмәк кәс кантарлары, олы-олы ташлар кубарылып оча. Бүрәнәләр атларны-җайдакларны йә тау урынына сыта, йә мәһабәт кылыч айкап үткән кебек дистәсе-дистәсе белән кыеп сала. Тау белән инеш арасында тасма рәвешендә сузылган тар, ачык җир ята. Анда ышыкланып калырдай бер түмгәк, бер чокыр юк. Аждаһадай ажгырып һәм дулап төшкән бүрәнәләр җайдакларны инеш суына кадәр алып очыралар. Аяклары чабаталы, ияр-ләре өзәңгесез булгач, җайдаклар атларын хәвефсезрәк якка борып та кача алмый. Тау астында чуалыш, үлем, җан ачысы белән кычкырган хушлашу авазлары, өннәре алынган ат кешнәве, тәшвиш, өметсезлек, гарасат һәм мәхшәр!..

Баскын җайдаклар исемсез елга суына ташланып, вак-вак төркемнәргә бүленеп кача-кача, чак-чак котылдылар. Тау астында, инеш ярларында чабаталарына чаклы изелеп һәм сыты-

лып беткән йөзәрләгән мәет аунап калды. Святополк үзе инеш аша чыгып качкан иде. Җайдакларны кабат җыеп, аларны яңа яуга күтәрү аның кодрәтеннән киләчәк эш түгел. Шуны уйлап, Святополк алайларны туплау өчен ымсыну да ясап карамады. Кызган кул астына элөгүдән шүрләп, әтисе янына кайтырга ашыкмады. Качаклар кич белән, караңгы төшкәч кенә, койрыклары көйгән бүре көтүе сыман шыпан-шыпан кайтып, янә кенәз казаны янына тупландылар.

56

Төнлә Владимир кенәз ыстанына Добрыня үзе килде. Чатыр ишеген ачып эчкә иңүгә, башын җиргә орды.

— Салда килгән җәяүле укчыларны тоташ тәшвиш, бердәм курку басты. Аларны өр-яңадан яуга ташлау өчен дәртләндерми булмый. Болгар ханыннан батырлар алышын таләп ит. Әйдә, теге чакта болгар баһадирының җанын кыйган Алешаны чыгар…

Батырлар орышын үткәрү турында тәкъдим килеп җиткәч, Сал-Сал әле керфек тә селкетеп карамаган иде. «Аның ни даны бар? Сәрдәр чаклы сәрдәр башың белән юеш борынлы малай-шалай кебек сугышып йөреп булмас», — дип кенә кул селтәде ул. Ләкин берзаманны Олы Кабан күле ягыннан бик тә таныш, әмма аның өчен дөньядагы иң җирәнгеч исем ишетелгәч, куырылып калды.

— Алеша? Алеша дигән пәһлеванны янә алышка чыгаралар? Тукта, бу минем атайның гомерен кыйган җанвар түгелме соң? Әнкәй миңа аның исемен юкка гына ятлатмады бугай. Бәлки… бәлки, миңа атай өчен үч кайтарырга җай чыгадыр?..

Ибраһим хан янына атылып барып җиткәч, тегесе әүвәл өрәк күргән сыман аптырап торды.

— Нинди Алеша ул? Каян килгән нәүбәт? Нинди үч кайтару?

Тынычрак тавышка күчкәч җиңел аңлаштылар.

— Ә-ә, синең элегрәк тә әйткәнең бар иде бит инде, мин бөтенләй онытканмын, — дип, йокыдан айныгандай тезде Ибраһим хан. — Ә югыйсә синең әтиеңнең орышына мин үзем дә шаһит булган кеше. Әйе, моннан утыз-кырык фәрсах чамасы арада утырган Кашкатау янында әрәм булды атаң. Хәрәмләшеп җиңде аны урыс пәһлеваны, күзенә ком сипте. Теге имгәк шулай хәрәмләшмәсә, мөгаен дә, орышта синең әтиең җиңгән булыр иде. Язмыштан узмыш юк шул, юк шул. Мин ул алышка үзем чыгарга да ният иткән идем. Син кысылма, диделәр, ирек бирмәделәр…

Ибраһимның һаман урап-кырыйлатып сөйләнүенә түзмичә, Сал-Сал янә каен тузы сыман кабынып китте:

— Атай өчен үч алырга бу юлы үзем чыгам. Минем нәүбәт! Мондый форсатны кулдан ычкындырсам, үз-үземне гафу итәсем юк!

Сүз мең сарыклы көтүдән аерылып калган сыңар бәрән турында бара диярсең, Ибраһим чебен куган кебек итеп кул селтәде:

— Ярар, кулың бик кыҗрап тора икән, чыгарсың алайса...

Гаскәрләрне моннан егерме ел элек, Кашкатау янындагы шикелле, капма-каршы тезеп бастыру насыйп булмады. Елантау тирәсендә мәйдан чикле, йә чокыр, йә сазлык, өстәвенә борчак төсле чәчелгән күлләр сибелеп ята. Ибраһим хан үзенең җайдакларын Елантау итәгенә бастырып куйды, Владимир кенәз яртылаш төстә яланаяк калган укчыларын Кабан күлләре буендагы куе таллык ышыгына тезде. Рәвешен китереп, сорнай-дөмберләрне уйнатканнан соң гына, ике арадагы үзәнлеккә Алеша белән Сал-Салны чыгардылар.

Урыс баһадирына күз салгач та ошатмады Сал-Сал. Ит йә балык тозлау өчен әзерләп куелган агач мичкәдән дә юанрак гәүдә. Очы күкрәгенә салынып төшкән җирән, куе сакал. Кашлары алагаем аска бөтәрләнгән. Яңаклары әле яңа гына табадан сикереп төшкән беленмени? Борыны бәрәңгедәй. Йодрыклары саллы. Ирнең тәнендәге тазалыкны челтәр көбә дә каплап бетерә алмый. Беләкләре дәһшәт бөркеп тора. Ләкин шактый олыгайган шул инде бу баһадир. Ул бия-тай күрмичә, кап-караңгы аранда япа-ялгыз көе тотылган хиссез айгыр сыман. Үзең качсаң йә аны куалый башласаң, төрәнгә җигелгән ат шикелле тиргә батачак бу. Аннан кил дә чүке...

— Атың кем синең, әй, селәгәй егет? — дип, көтмәгәндә аваз салды урыс пәһлеваны. — Ичмаса, тукмак белән сугып җиргә индергәнче шуны белеп калыйм. Аннары соң була.

Сал-Сал котырудан күмер төсле кара янып чыкты. Аңкавына без белән кадаган шикелле ябышып калган телен көчкә әйләндереп, җавап сүзен әйтте:

— Байдар минем атым. Ишеттеңме, көзән?!

Алеша шундук куырылып калды, күзе акаеп чыкты.

— Нинди Байдар тагын? Мин сезнең андый исемдәге бер мәхлук батырыгызны моннан егерме ел элек үк дөмектергән идем. Нәрсә, әллә сездә Байдардан тыш бүтән исем юкмы?

— Синең өчен юк, мәкерле көзән. Син шушы исемне генә кабатлап үләчәксең!..

Аргамакларының касыгына тибеп, икесе дә берьюлы урыннан кузгалдылар. Алеша уң кулына сыер боты чаклы гөрзи

тоткан иде, бер сугуда чәрдәкләрдәй булып, үкереп якынайды. Сал-Сал качышлы уйнаган бала ары качты аннан, бире качты. Урыс баһадиры ярсудан, шашынудан тиргә батып бетте, түземлеген җуйды.

— Качма, куркак чебеш! Барыбер тураклыйм мин сине, барыбер он итәм!

Сал-Сал торган саен аны ныграк үчекләде:

— Мин бит мәрхәмәтле. Әйдә, әйдә, йөгереп кал, сыер! Телеңне аркылы тешләгәч кенә чалып ташлыйм сине…

Гөрзиен ажгыртып төшергән бер вакытта Алеша иярендә утырып кала алмады. Баскын пәһлеван җир өстенә капланып төште дә утын түмәре кебек тәгәрәп китте. Ул аягына басарга ымсынган бер минутта Сал-Сал аны кисәкләргә өзгәләп аткан иде инде.

Елантау өстенә тезелгән болгарлар күк капусын күтәрердәй итеп дәррәү кычкырдылар:

— Безнең сәрдәр җиңде! Сал-Сал җиңде!

— Урысларга безнең каршыга килеп тезләнергә вакыт!

Сал-Сал баскын укчылар ягына күз ташлады. Һәммәсе дә яңгыр астында калып шәбәргән тавык-чебеш кебек сөмсерләрен коеп тезелгәннәр. Күзләрендә өметсезлек, кайгы, тоташ тәшвиш. Сал-Сал ыргыткан үчекле, өр-яңа шарт бөтенесен тораташтай итте.

— Сезнең һәрбер батырыгыз белән аеры-аеры көе орышып булмас. Сәрдәрегез чыксын!

Болгар батырының шушы шарты баскыннарның бар гаскәрен әйтерсең лә пычаксыз-нисез суеп салды. Һәммәсе дә тере елан йоткандай тын тордылар. Фәкать кенәз чатыры ягыннан гына чышан-пышан килгән тавыш ишетелде:

— Чыгара күрмә мине, туганкаем, и-и, чыгара күрмә. Мин газиз анаңның бертуган энесе бит. Бар гомерен эт типкесендә, читкә кагылып үткәргән Малушаның хатирәсе хакына ялыныплар сорыйм, мине харап итмә. Мин картайдым бит инде, мин гайрәтсез. Син болгар сәрдәренең безнең Алешаны ничек өзгәләвен үзең карап тордың. Алеша хәтле Алешаны җиңгәч, мине бетле чебеш урынына ботарлап атачак бу. Юк, мин чыкмыйм! Солых сора, кенәз…

Ниһаять, гаскәр алдында Владимир үзе пәйда булды.

— Ханыңа җиткер, батыр, — дип, әле һаман элеккечә вәкарьләнеп, Сал-Салга эндәште ул. — Безгә уйлау, үлчәү, әзерләнү өчен бер төн вакыт кирәк. Кичкә караганда иртәнге эш, калдык ашка караганда яңа пешеп чыккан ризык хәерлерәк, диләр. Үз карарыбызны сезгә иртәгә таң аткач җиткерербез…

Ике як гаскәр дә күк йөзеннән убылып төшкән, көтелмәгән ялга таралышты.

Бу төнне ике ыстанда да яубашлары керфек какмадылар. Бер яктагы хәлне дә өметле, хәвефсез дип бәяләрлек түгел, шулай да Владимир кенәз чатыры эссе салмый да мунча керерлек булып кызып җиткән иде. Аеруча иртәгә үзенә үлем афәте янаган сәрдәр өзгәләнде. Аның яңагында көндез үк ялтырый башлаган күз яшьләре кипмәде дә сыман. Кортлы агач эзләп тапкан тукран шикелле, ул бер үк сүзне тукуын гына белде:

— Болай да шушы тау янында алты меңгә якын ир югалттык. Өрәкләр үзәнлегендә юкка чыкканнарны, юлларда егылып әрәм булганнарны да кушып исәпләсәк, җиде меңнән арта. Әгәр дә иртәгә мине орышка чыгарсаң, тагын бер корбан килеп өстәләчәк, моны бик белеп тор. Ярар, синең анаң белән минем төсле ятимнәрнең башы алтын бәһасе дә тормасын, ди. Ләкин чатыр тышында мондагы болгар капкынына килеп эләккән тагын унсигез меңгә якын ир-ат бар бит әле. Алар болай да аю чокырына егылып төшкән бичаралар хәлендә. Алар болай да чиле-пешле йомыркалар кебек дер калтырап тора. Ә иртәгә болгар сәрдәре мине дә турап аткач, син аларны яңа орышларга ничек күтәрерсең?

Владимир авызына ямау салган сыман әүвәл бер сүз эндәшмәде. Аның йөзе бердәнбер малаен җирләп кайткан атаныкы төсле катып калган иде. Кайчакларда гына кенәз кышкы салкында шартлап ярылган өй бүрәнәсе шикелле ухылдап йә дерт иттереп куйды. Уянгандай итсә, тишек оекбаш очыннан ялтыраган бармак кебек, бер генә зары ишетелеп торды:

— Ибраһим безгә ясак түләргә риза булмасмы икән?

Добрыня яңа яктан килеп үгетләргә ашыкты:

— Мин чамалыйм, син Киевка бер көтү тилемсә әптәрләп ташлаган кыз хәлендә әйләнеп кайтудан хурланасың инде. Шуңа күрә һаман «ясак, ясак» дисең. Тик син төшендә дә тары күргән тавык кебек алданасың, туган. Ибраһим үзенең җайдакларын тезеп куйган чакта шәйләмәдеңмени? Болгар гаскәрендәге һәрбер ир-ат аягына йә күн итек, йә күн читекләр кигән. Без тоташы белән диярлек тишек чабатадан. Чабатадан, кенәз, ча-ба-та-дан! Ә итекле-читекле ил безнең сыман чабаталы һәм яланаяклы мескенгә ясак түлимени! Кит лә, булмаганны! Шулай икән, юк инде, туганкай, болардан ясак талап китү турында хыялланма. Башны исән-сау көенчә алып качу хакында уйлау хәерлерәк.

Ниһаять, түземлеген җуеп, Владимир катгый сорау бирде:

— Нәрсә, хәзер инде үзебез ясак түләп яисә коллар калдырып кайтып китикмени?

— Нигә ясак түләп? Нигә коллар бирәп? — дип кабатлый-кабатлый җанланып куйды сәрдәр. — Бернинди мескенлеккә дә төшмичә, көчләре-дәрәҗәләре тип-тигез агай-эне сыйфатында да аерылышып була.

Владимирның күзләре җилдә уйнаклаган очкын сыман ялт-йолт килде.

— Ничек инде, ничек? Ибраһим капкыныннан кан коймыйча да котылу мөмкинмени?

— Мөмкин, мөмкин, туганкаем! Ибраһимга ике ил арасында солых төзү турында тәкъдим ясарга кирәк. Ике туган, ике дус үзара сугышмаска, кан коймаска сүз беркеткән кебек.

Владимир янә аптырашка калды.

— Соң, соң, Киев тәхетендә миңа хәтле утырган бер генә кенәзнең дә моның ише солых төзегәне юк иде бит әле.

— Ике ил арасында дуслык солыхы төзегән беренче кенәз менә син булырсың! Аның каравы атың һәм гамәлең тарихларга керер!

Мондый мәртәбәле, шөһрәтле сүзләрне ишетүгә, Владимир бер карышка үскән кебек булды, ул хәтта иңбашларын калкытып күркә сыман кабарынып алды. Моны күреп батырайган сәрдәр борчак сипкән кебек бертуктамый тезде:

— Безгә дуслык солыхы әле тагын яңа калкан кору, өстәмә терәк булдыру өчен дә кирәк, туганкаем. Бәла дигәннәре ялгыз гына йөрми. Болгарлардан җиңелгәннән соң ук хәзәр каганына коллыкка төшүебез бар. Болгарларны аркадашлар итеп, дуслар итеп, алар белән бергә каганга каршы яу күтәрү күпкә отышлырак. Болгарлар белән яу кырына кереп, дошман артыннан дошман җыеп йөрмик. Йөз дус та аз, бер дошман да күп, дигән бабайлар. Безне елан сыман сагалап торучы һәм тычкан яки бака урынына кабып йотарга әзер көндәшләр болай да күп. Бәҗәнәкләрне күз алдыңа китер әнә яисә мадьярларны. Үз кардәшебез сыман кыланып күзгә төтен җибәреп яткан Ростовныкыларны, Смоленск, Новгородны да шул ук сафка бастыр. Ә иң беренче дошманыбыз — хәзәр каганы безнең. Ул безнең вятич, радимич кабиләләреннән талап ясак җыя. Нәкъ менә шул хәзәр каганы безнең сылу кызларыбызны, япь-яшь егетләрне үзенең хәрамханәсенә алып китә. Аманат итә, имеш, шулай алдый. Ә чынлыкта җария итә бит аларны, сөяркәләр ясый. Менә, менә ни өчен болгарлар белән дуслык солыхы төзергә тиешле без.

— Тик ул солых хакында Ибраһимның үзенә ни рәвешле тәкъдим итәргә соң? Ялынып барсаң, мескенлек. Байлык белән сатып алыр идең, төяп алып килгән хәзинә юк. Мондый чакта «коры кашык авызны ерта» диләр. Нинди генә ысул, сукмак уйлап табыйк? — дип, Владимир баш чүмечен кашырга керешкәч, Добрыня, әлбәттә, чәчрәп алга чыкты:

— Ибраһим хан янына үзем барам, кенәз, үзем барам! Сәрдәр хәтле сәрдәрне кулга төшерү хәтәр ымсындыргыч булып тоелса да, алар миңа барыбер тимәячәк. Уен-муен түгел, аларның сәрдәре мине орышка чакырды. Миңа кул тидерсәләр, бик тә изге йола бозыла, алар үзләренә гөнаһ алмаячак. Ә Ибраһим янына барып кергәч, үлсәм үләм, әмма солых турында аның ризалыгын алмыйча кире кайтмыйм!

58

Ибраһим хан чатырындагы иминлек бизмәнен дөм караңгы төн уртасында Сал-Сал сәрдәр генә әйләндереп атты. Бер минутта алар чатыр эчендә тик икесе генә торып калган иде.

— Мин сиңа өч елдан артык гомер хезмәт итәм, — дип башлады ул, һич тә көтелмәгән, әрнүле һәм ярсу аһәң белән. — Өч ел буена бернинди мал да, алтын-көмеш таулары да сораганым булмады. Әрсезлеккә барсам, мин инде әллә кайчан синнән берәр кала йә олыс та таләп итә алган булыр идем. Без чит-ят кешеләр түгел, яшереп торасы юк бит. Әле Янкалада чагында ук мин сиңа канат бирдем. Менә шушы тау буена кайткач, Тимер-Мөэмин гаскәрен мин җимердем. Чынлап баксаң, сине тәхеткә утыртып куючы кеше дә асылда мин. Шулай түгелме, хан?..

Ибраһим баш түбәсенә күсәк белән китереп орган шикелле гел миңгерәп калды. Юк, ике арада кайчан да булса йә мунча ташыдай кайнар, йә кылыч очыдай кискен һәм хәлиткеч әңгәмә килеп туачагын ул чамалый, көтеп йөри иде. Әмма нәкъ менә бүген, ил язмышы хәл ителгән көндә, сәрдәр кеше ханны бугазыннан эләктереп алыр дип кем уйлаган?..

Ибраһим көч-хәл белән телен әйләндереп сорау бирде:

— Ниләр таләп итмәкче буласың? Әйдә, сана.

Сал-Сал элеккечә, үзен-үзе тыя алмыйча, ярсып дәвам итте:

— Кызың Айзирәккә гыйшык тотып йөрүем сиңа яхшы мәгълүм. Инде өч ел буе, Янкаладагы Ана сөте чишмәсеннән бирле гыйшык тотышабыз. Мин синнән Айзирәкнең кулын сорыйм.

Ибраһим бу сорауны да күптән көткән иде. Хәзер уенга борып җибәрмәкче булды.

— Кызның кулын әтисеннән түгел, үзеннән сорыйлар бит.

— Айзирәк риза, без аның белән әллә ничә тапкыр вәгъдәләштек инде, — дип җавап кайтарырга ашыкты Сал-Сал яна-пешә.

— Ә ни өчен нәкъ менә бүген сорыйсың син? Чатыр тышында дошман басып тора, иртәгә безне янә дә яу көтә. Кәләш сорау өчен һич кенә дә кулай вакыт түгел.

Сал-Салның карашында янә усал ут кабынды.

— Яу бетсә йә дошман кайтып китсә, синең мине тишек кәвеш төсле чыгарып атуың бар. Мин чамалыйм моны.

— Ә бүген хан беркая чигенә алмый, чөнки ул сәрдәреннән башка беркем түгел дигән нәтиҗә ясадыңмы? Әй-яй! Ашыгасың, Сал-Сал.

— Нигә, ник ашыгам? Миңа калса, иң-иң кулай вакыт.

Ибраһим хан инде көлемсерәп кенә йомгак ясап куйды:

— Айзирәк минем өчен берәү генә, Сал-Сал. Ә сәрдәрләрне мин көн саен да алыштыра алам. Монысы бер. Аннан икенчесе. Сине таңда канлы орыш көтә. Менә шул орыштан исән-сау чык башта.

— Исән чыксам, Айзирәкне миңа бирәсеңме?..

Ибраһим авыз ачарга да өлгермәде, чатыр ишеген дөбер-шатыр китереп, каравылбаш Көбәк килеп керде. Артыннан юлбарыс йә бүре куганмыни, сулышы-тыны капкан. Күз кабаклары шырпы кыстырып куйгандай акайганнар.

— Ибраһим хан! Көтелмәгән кунак... олуг түрә...

Чатыр почмагында кыя читенә китереп бастыргандай шик-шөбһәгә калган Сал-Салны күрүгә, каравылбаш авызына шундук йозак элде. Әмма Ибраһим хан колагына иелеп чыш-пыш килгән чакта, бер-ике җөмләсе барыбер дә ишетелеп калды:

— Ханның үзе белән генә сөйләшәм, беркем булмасын, ди.

Мизгел эчендә җитдиләнеп калган Ибраһим хан Сал-Сал ягына борылып әмер бирде:

— Арадашчы килгән, берүземне калдыр. Чамалыйм, иртәгә сиңа орышырга язганмы икән, юкмы — менә хәзер булачак сөйләшүдән тора...

Добрыня сәрдәр берьялгызы булып чыкмады, ул эт кебек иснәнеп юл күрсәтердәй кешене күптән тапкан икән. Чатыр эчендә элек курсыбайда йөзбашы булып йөргән Атлашны да күргәч, Ибраһим шактый тирән аптырашка калды. Әллә бу шымчы-йөзбашы ике якка да ярый, ике якны да имә белә торган йомшак иренле, юха еланмы соң?

Атлаш Добрыня өчен эзтабар гына түгел, әле тылмач та икән. Беренче җөмләләрне тәрҗемә кылуга ук, идәнгә төбәлеп утырган көенчә, ул гел үзенчә тезде:

— Алар синнән дуслык солыхы төзеп, үзләрен кыйнамыйча җибәрүне үтенәләр, хуҗам. Боларның сине сатып алырдай юньле байлыгы юк. Алар йорты-каралтысы янып беткәч хәер эстәп чыккан сукбайга тиң. Иллә мәгәр боларның бик тә йомшак, элпә сыман юка бер ягы бар. Бу хакта мин сиңа элек тә хәбәр иткән идем. Болар мәҗүсиләр, Аллаһы Тәгаләне бөтенләй танымыйлар. Алар кырыкмаса кырык төрле потларга табыналар. Солых төзисе булсаң, син

кенәзгә шарт куй. Әйдә, изге ислам диненә күч, шәригать йолаларына өйрәтү өчен мин сезгә имам-хатыйблар да тагып җибәрәм, диген. Менә шушы җиңү иң зур җиңү булыр. Безнең дингә күндерүгә ирешсәк, болар бер чакта да яу белән Болгар өстенә килмәс...

Иртәнгә чаклы сузылачак бәхәс-килешүләр шулай канат ярды.

59

Елантауның өстен бүген һич танырлык түгел. Тауның түбәсенә, куна тактасыдай тигез булып яткан мәйдан уртасына, акшардай пакь киезләрдән генә корылган өр-яңа чатыр күтәреп өлгергәннәр. Бер як читтә, уйсурак урында, иң чиста киемнәргә төренгән сугымчылар сарык бәрәннәрен, япьяшь колыннарны корбан итеп чала, кулларына комган-сөлге тоткан ак яулыклы кызлар тыз-быз килеп ярдәмләшеп йөри, янда гына дистәләгән олы казан кайный. Учаклардан күтәрелгән сыек-зәңгәр төтен өрфиядәй җиңел, нәни болыт ясап, өскә күтәрелә. Күк йөзе чалт аяз. Анда җир өстендә әле азгынлык, хыянәт барлыгын да белмичә су коенган гөнаһсыз кызларны күзәтергә чыккан шук егет шикелле туктаусыз елмаеп, эчкерсез һәм мәңге уяу кояш сакта тора. Җиһанның шау-шу, гөнаһ, хыянәт, яу кабул итмәс чагы.

Ибраһим хан әлегә үзе күренми, ул һаман да иске чатырында. Яңа кәләш янына кереп зөфаф төне уздырачак кияү егете диярсең, аны япь-яшь кызлар, олы-олы ләгәннәрдә коендырып, сакал-мыекларын пөхтәләп, зәйтүн мае, гөләп-җәсмин төнәтмәләре белән хушландырып, изге очрашуга әзерлиләр. Шушында ук ялтырап торган аел, садак тоткан һәм тычкан койрыгыдай нечкә мыекларын туктаусыз бөдрәләүче курсыбай йөзбашлары бөтерелеп йөри.

Бай кодалар көткән табын төсле бизәлгән зур мәйданга әлегә вәзир Насыйр хуҗа. Итек эченә ут салганнармыни, ул бер урында басып тора алмый. Тәрәзәдән яучы күзәтүче сазаган кыз сыман, вәзир әле пешекче-сугымчыларга килеп бәйләнә, әле меңбашлар белән олугбәкләр эшеннән гаеп эзли:

— Әмир Шуран, Мөслим! Чәңчеләр белән танбурчыларны чакырдыгызмы соң сез?

— Имам Мәрдән, Локман хәзрәт! Бүген Мөхәммәт галәйһиссәлам рухына багышлап шәриф догалар кыласы да бар бит. Нигә инде вакытлыча мәчет манарасы күтәреп куймадыгыз?

— Сәркатипләр белән битекчеләргә эндәшергә онытгызмыни, эх, Алла коллары!..

Тау өстенә, төрле яклап, өсләренә өр-яңа көбәләр, баш түгә-

бәләренә җиз самавыр сыман ялтырап торучы очлым элеп алган, көмеш җепләр белән бизәлгән кынлы кылыч һәм садаклар таккан яугирләрнең, укчыларның унлыклары, йөзлекләре күтәрелә тора. Су эчеп күбенгәннән соң тоз яларга атлыккан маллармыни, берән-сәрән булып аларга төнлә белән ат саклаучы торгаклар, әмир-бәк шикелле аксөякләрнең колчуралары, тимерчеләр, салчылар ияргәннәр. Һәркем җиңү тантанасына шаһит булырга ашкына, һәрбер Алла бәндәсе бүген үзен ил алдында эш күрсәткән фидакарьгә саный...

Тау итәге астыннан алтын каурыйлы кош тоткандай тантаналы, рисвай аваз ишетелде:

— Киләләр, ки-лә-ләр! Балтимер кенәз белән Дәүборын сәрдәр икесе дә килә!

Мәйдан өстендәге ирләрнең күпчелеге әүвәл май сибелгән учактай кабынып дәррәү көлештеләр:

— Урыс түрәләренә вәт шәп кушаматлар чәпәп куйды бу, чукынмыш!

— Балтимер, Дәүборын! Менә сезгә ике яңа исем!..

Аннары Елантау читенә тезелеп бастылар да кибет киштәләрен күзәтүче ярлыдай тын калдылар. Юк, тар-мар ителгән йә тез чүгәргә килгән йолкыш гаскәр башлыклары кебек борын салындырып, сугым малы сыман күндәм кыяфәттә атламыйлар болар. Кенәзләре алтын-көмеш җепләр белән нәкышләнгән кызыл җилән кигән. Алтын аеллы киң каешы астында озын хәнҗәр, очы җиргә чак-чак тими калган саллы кылыч. Добрыня сәрдәр өстендә уч төбе чаклы шакмаклардан ясалган тирән көбә, биленда көрәк киңлегедәй, ике йөзле корыч кылычы бар. Аларга иярген боярлар-меңбашлар да көбә-кылычтан, шайман-коралсыз атлаучы бер кеше юк. Шулай да мал төге шикелле чит-ят күзгә ияреп китәрдәй кимчелекләре бар боларның. Берсенең дә сакал-мыеклары ипләп таралмаган-кырылмаган икән, сөңге-калкан тотып атлаучы сакчылар арасында чабатадан гына килгән ярлылар бар.

Болгар ирләре өчен иң тансыгы һәм үтә кыйммәтлесе, балбалдай таш иткәне — иң азакта аккош чылбыры сыман тип-тигез сафларга тезелешкән чит хатыннар, сөлектәй сузылган зифа буйлы кызлар. Үләннәргә тиеп баручы озын итәкле ап-ак күлмәкләр-җиләннәр кигәнгәдер, ахры, аларның аяк атлаулары да күренми. Кызлар күл өстендәге казүрдәкләр шикелле тавыш-тынсыз, ымсыз-хәрәкәтсез генә йөзеп килә. Маңгай өсләренә асылташлар белән бизәлгән кәктүшләр[1] кигәннәр, иңнәрендә аллы-гөлле чәчәкләр төшерелгән чаклы-чуклы матур башъяулыклар. Күбесенең түшләрендә, кул яңакларында муенсалар, беләзекләр ялтыр-йолтыр килә.

[1] К ә к т ү ш — кокошник; биек, текә калфак.

Чибәркәйләрнең һәммәсе дә керфекләренә сөрмә тарткан, битләренә иннек ябынган, ә чәйнек чаклы булып тулган мул һәм тыгыз күкрәкләре өстендәге саргылт толымнары кызлар атлаган саен, елан сыман уйнап, егетләрне ымсындырып тора. Болгар яугирләре җансыз түгел, авыз суларын корытып үзара сөйләшәләр:

— Әнә тегесен, зәңгәр калфак кигәнен кара, Хәмзә. Бер кашык су белән кабып йотарлык бит, малайкаем!

— Ә тегесенә, сары муенса такканына күз сал. Моның белән бер мәртәбә булса да мунча керү бәхетенә ирешсәң иде ул! Аннары үлсәң дә үкенерлек түгел.

— Болар Алланы танымый, болар мәҗүси бит. Аларның кызлары алга юмарт, диләр…

Урыс яубашлары Елантауга менә башлагач та, Ибраһим ханга хәбәр иңдерделәр. Урысларның коралланган хәлдә килүен ишетүгә, Болгар ханы кылычын болгап атты.

— Кылычны кул таягы итеп солых төземиләр. Елантау өстенә менгән угланнарга, газиләргә, укчыларга фәрман җиткерегез. Һәммә яугир садак-кылычларын яшереп куйсын! Баскынлык белән генә көн күрергә ният иткән халык Болгар иленнән ачы гыйбрәт алып китсен әле.

Ибраһим хан бәйге көткән ярсу чаптар кебек чатырыннан тышка ашкына иде. Каравылбаш Көбәк кереп кенә, ил хакимендәге көрпәлек укасын бераз коя алды.

— Син сыеры кысыр калгач капкасын шар ачып, теләсә нинди узгынчы үгезне дә ихатасына кертергә әзер торган җүнсез хуҗа түгел лә инде, таждар. Җәбегән кенәз, солых төзегән булып, синең кармагыңнан исән-имин ычкынырга ниятлиме? Шулай икән, әүвәл үзе маэмай сыман мүкәләп каршыңа килеп җитсен. Ә син ияреңнән соңрак, болыт өстендәге алиһәләр кебек итеп кенә төшсәң дә бик килешә. Табынга көттеребрәк китерелгән ризык һәрчак тәмле була…

Ниһаять, вәзир Насыйр үзе кереп җитте.

— Килделәр, Ибраһим хан. Кенәз үзе дә, яраннары да монда. Кояш кебек чыгып күрен, әйдә.

Ибраһим, чатырның ишек төбендә кылыч-хәнҗәр аскан Сал-Салны күргәч, елан чаккан төсле агарынып калды.

— Мин һәр болгар яугиренә коралларын яшерергә дигән әмер бирдем. Ә син фәрманны ишетмәдеңмени? — дип, теш арасыннан сытып чыгарды ул сүзләрен, ата каз шикелле ысылдап.

Сал-Салның йөзе-кыяфәте болай да кыйналган кешенеке сыман кара янган иде. Сүзләрен бизмәндә үлчәгән шикелле тартып-сузып кына җавап бирде:

— Андый фәрман сәрдәр кешегә кагылмый дип беләм. Бер аягы белән элмәккә утыртылган булса да, лачын кош-

лар һәрчак чукышырга әзер булып тора. Мин дә үз ихтыяры белән читлеккә барып кергән юлбарыс сыман хәлдә.

Ибраһим янә яшен чатырдаган төсле коры тавыш белән дәшәргә мәҗбүр булды:

— Син, урыс сәрдәре белән орышка чыгарга насыйп булмады дип, ялан-кырда җил куалап йөрмә. Алатауда үскән качак булсаң да, сиңа Болгар иминлеге турында кайгыртырга өйрәнергә вакыт. Ә хәзер, бар, Елантау астына төш тә, Олы Кабан күле белән ике араны биклә. Юньсез кешене ипкә-сапка кертү — көкрәйгән кадакны төзәтү генә түгел. Баскын кенәз әнә тагын корал тагып килгән. Солых, дуслык, дигән булып көянтәдәй итеп бил бөгү дә яман хәвеф яный. Иелгән башка төкерүләре дә, аны хәтта кыеп төшерүләре дә мөмкин. Сәрдәр икәнсең, син сакта тор…

Сал-Сал кар астына чумган ерганак шикелле тавыш-тынсыз гына эреп юкка чыккач, һәммәсе дә яңа чатыр янына юнәлделәр. Чатырны тирәләп, яланда йөреп аргач, капка төбенә кайткан йорт казлары сыман, алтын-көмеш җепле ак яулыклар япкан, мәрҗән ташлы калфак, көмеш тәңкәле хәситәләр, аллы-гөлле бизәкле ак йә кызыл читекләр кигән кызлар тезелешкән. Шуларның нәкъ уртасына, йөзек кашы сыман булып, җиләктәй пешеп җиткән Айзирәк чыгып баскан. И-и, озын көн буена керфек тә какмый кыздырган кояш шикелле эчкерсез, самими нур бөркегән карашлары аның! И-и, куе яфраклар арасыннан масаеп сузылган чияләрдәй кызарып янулары! И-и, аның тәти курчак көткән сабый кебек нәүмиз елмаюы! Ибраһим хан Айзирәкне күреп шулай сокланды да, бар зар-хәсрәте җил себереп алгандай шундук юкка чыкты.

Кылыч-сөңге тотып керпедәй кабарса да, урыс илчелеге барыбер дә Елантауның читенә, сөзәк итәк тирәсенәрәк тезелешеп баскан. Владимир кенәз, әлбәттә, уртада, җансакчылар ышыгында тора. Добрыня сәрдәр әнә сугыш әтәче шикелле, кем якынайса, шуның өстенә очып кунарга әзер. Башкалар да бер кулларын кын өстенә салган. Карашлары авыл уртасындагы ихатага барып кергән бүренекедәй уяу. Боларның хәтта борын яфракларына тикле киерелгән.

Ибраһим хан арткы рәттә торган бер укчы ир кулында кечерәк кенә казан шәйләп өлгерде дә мизгел эчендә шабыр тиргә батты. Әстәгъфирулла! Ибраһим хан үзе урысларның яу башлыгы булган Святославка бүләк итеп биргән алтын казан бит бу! Моннан егерме ел элек, Ашлы каласында. Ибраһим ул вакытта урыс кенәзенә бу казанны «бу безнең уртак дуслык чагылышы булсын, безнең өскә яу йөрүне туктат» дип тәкрарлый-тәкрарлый әйтеп биргән иде. Нигә Ибраһим хан гозерен тыңламаган кенәз? Бу гозерне нишләп үз балаларына

нәзер итеп әйтеп калдырмаган? Кыркымыш сарык йонындай нинди кыска, сай хәтерле кавемнән соң болар?..

Шулай да Владимир кенәз батыр кеше икән. Яраннарына ым гына какты да Ибраһим ханга каршы япа-ялгыз китте. Кул сузымы ара калуга ук, кан дошманын иң беренче булып кочагына алды. Сүз башлаганчы әллә ничә тапкыр тамак кырды. Ул учак өстенә куелган казан кебек, чыннан да, дулкынланып-кызып чыккан иде бугай.

— Кулга кылыч күтәреп орышучы пәһлеваннарга караганда да куәтлерәк җаннар бар икән бу дөньяда, — дип, ниһаять, бар мәйданга ишетелерлек куәт белән сөйли башлады ул. — Кирәк чакта ярсуын авызлыклап, яу кылычын кабат үз кынына тыгып куя белгән илтабарлар да бар икән җир өстендә. Без Болгар җиренә килгәч, менә шундый кешене эзләп таптык. Андый олы җаннар, ил мәнфәгатен уйлап һәм дан-шөһрәткә күмеп яшәүчеләр кылыч тотып баскан мең яугиргә караганда да куәтлерәк икән. Болгар туфрагында әнә шундый көчле, туганнардан да якынрак булырдай дусны очраттык без. Ул син, Ибраһим хан! Ул сез, болгар дуслар! Менә шуңа күрә орышны-яуны туктатып, дуслык солыхы төзергә карар кылдык та без. Моннан ары Киев белән Болгар арасында һичбер дошманлык юк! Бер-беребез өстенә яуга йөрешмибез! Ике олуг дәүләт арасында сәүдә кәрваннары гына йөреп торсын. Бер-беребезне талауранжетү юк. Без мәңгелек дуслар!

Мәйдан читендә, алдан котыртып куйган шикелле, Добрыня сәрдәр дә капылт элөктереп алды:

— Дуслык солыхы төзибез, дуслык солыхы! Урыс белән болгар моннан ары мәңге-мәңге дуслар!

Артта, көттереп кенә, боярлар да дәррәү кычкырдылар:

— Дуслык кына насыйп булсын безгә! Дуслык, дуслык!

Күзләренә яшь бөртеге бәреп чыккан Ибраһим хан үз колакларына үзе ышанмагандай кат-кат сорау бирде:

— Ә безнең бу солых без икенче мәртәбә очрашканчы гына булмасмы соң, кенәз? Кабат кырда-далаларда бер-беребезгә тап булырга туры килгән чакта без янә юньсез тәкәләр шикелле сөзешмәбез микән?

Владимир кайнар мунчадан соң саф һавага чыккан яшь кияүләр сыман изүләрен ачып җавап тотты:

— Юк, без солыхны гомерлек, мәңгелек итеп ныгытабыз, туган. Без төзегән солых гасырлардан гасырларга, оныклардан оныкларга күчеп барырдай булсын! Киләсе буыннар үрнәк итеп, ядкарь итеп искә алсын аны.

Ибраһим ханга да тулысынча җан кергәндәй булды, учактагы ялкын сыман кабынып, кайнар хисләр сипте:

— Алайса, безнең халыкта мондый очракларда әйтелә тор-

ган бик тә матур сүз бар. Таш су өстенә калкып йөзә башласа яисә колмак үләне таш шикелле су төбенә китсә генә бозылыр безнең дуслык.

Таждар авызыннан ишетелгән хикмәтле сүзләрне янга килеп тезелешкән олугбәкләр, меңбашлар һәм тылмачлар сокланып кабатлады:

— Ah, ничек маҗ китереп, шәп әйтелгән сүзләр!

— Ah, никадәр тирән мәгънәле фикер бу әйтемдә!

Тылмачларның катлы-катлы, бормалы-сырмалы аңлатмаларыннан соң Владимир кенәз дә шаккатып баш чайкады:

— Таш суда йөзә башласа йә колмак су төбенә китсә генә бозыла, диген. Мәзәк, сәер. Таш бервакытта да су өстендә йөзеп йөрми бит инде ул. Колмак үләне дә су төбенә китми. Вәт, әкәмәт!

Ибраһим хан каурыйларын кабарткан тавис кошы кебек борын чөйде:

— Менә шуңа күрә әйтелгән дә инде. Таш су өстендә йөзә алмаган кебек, безнең солых та бозылу-сызылуны мәңге-мәңге белергә тиеш түгел. Төзесәң, фәкать шундый солых кына төзергә кирәк тә ул. Аңладыңмы, кенәз?

Язгы тургай төсле очына башлаган хан ак чатыр янында уклау йотып торган битекчеләргә карап әмер бирде:

— Әй, кәгазь кортлары, җыен әрәмтамак! Сәркатипләр белән бергә уйлагыз да тантаналы шартнамә тудырыгыз. Мондый солых, андый шартнамәләр бездән соң киләчәк яңа буыннарга үрнәк булып калсын! Болгар тарихында мондый хәлнең әле булганы юк. Моннан ары урыслар белән мәңгелек дуслар, якын туганнар без!*

Тантана шаукымы исерткеч шәраб сыман, һәр кешегә бик тиз канат куя. Владимир кенәз дә тышауларын өзде:

— Юк, без ике дәүләт тарихындагы беренче солых төзүне болай гына очламыйбыз әле, Ибраһим хан. Дуслык, туганлык дигән сүзләр, буш вәгъдәләр булып, кәгазьләргә язылып кына калмасын ул. Тарихи солых төзү бәхетенә ирешкәнбез икән, бер-берсенә ярдәмгә ашкынып торырдай һәм мәңге өзелмәстәй чын туганлык җепләре белән беркетик без аны. Әйдә, мин сиңа үземнең кызым Василисаны хатынлыкка бирәм!

Болгарлылар күк йөзеннән итәкләренә утлы шар тәгәрәп төшкән сыман үрә катып калды, урыс укчылары капкын-тозакка таба җанвар куа килгән сунарчылар төсле дәррәү кычкырдылар:

— Әй, Василиса чибәркәй, Василиса! Хан хатыны булачаксың, уртага чык!

Владимир кенәз ап-ак күлмәк, зәңгәр кәктүш кигән, сар-

---

* 985 елда булып узган мәгълүм вакыйгалар.

гылт чәчле, зәңгәр күзле, тыгыз тәнле сылуны бармак очларыннан тотып кына мәйдан уртасына чыгарып бастыргач, Ибраһим хан фәрештәнең үзен күргән сыман бөтенләй коелып төште.

— К-һм, ни, эһем-эһем, ни бит, — дип, авыз эченнән генә ботка пешерде ул. — Инде ничә айлар буе хатын-кызга якын барган юк бит. Мин, ни, Айзирәкнең әнисен бик ярата идем. Шуны оныта алмыйм. Иллә мәгәр бу кыз... эх-ма, ничек каршы торыйм!

Ибраһим хан батырая башлап яшь кәләшнең билләреннән алгач, болгарлылар оясыннан куркытылган кош шикелле пырхылдап көлештеләр:

— Безнең хания күрше ихатадагы танага ияргән яшь үгез шикелле сырпалана, әттәгенәсе лә!

— Чыбыркысы шәп шартлыйдыр әле, шундыйга охшаган бу!..

Бераздан Ибраһим хан акылына килде. Бармак белән изәп кенә вакыт сорады да, чибәр кызлар уртасында гөләп чәчәге кебек балкып-аерылып торган Айзирәк каршына китте. Дөрес, үзенең үк төсе-кыяфәте көне буе җилкәсенә капчык-капчык таш күтәреп ташыган йөкченеке кебек нык талчыккан иде.

— Кунак ашы кара-каршы булырга тиеш, кызым, — дип, талгын, ипле тавыш белән сүзен башлады ул, Айзирәкне кочагына алып. — Без ике ил арасында зур солых төзедек, урыс кенәзе үзенең кызын миңа хатынлыкка бирде. Синең башка чараң юк, кызым. Син туган илеңнең иминлеге хакына менә шушы кенәзгә хатынлыкка чыгарга тиеш булачаксың.

— Минем Сал-Салым бар бит, без бит аның белән үзара вәгъдәләшкән ярлар, — дип, күз яшьләре аша калтыранды, өзгәләнде бала.

Ибраһим элеккечә ипле, әмма инде торган саен корычлана барган җитди тавыш белән үгетләвен белде:

— Ярлы-ябагай кызлары, әле хәтта олугбәк кызлары да әллә кемнәр белән гыйшык уйнап, миңа димәгәе, дию пәриенең үзенә дә кияүгә чыгарга хаклы, балакаем. Әмма синдәй ханәкәләр түгел. Син илең хакына, әтиең сайлаган отышлы гамәл хакына үз җаныңны, гыйшык утларыңны корбан итү өчен яралгансың, кызым. Синең хәлдә алдына салган иске солыны өнәмәгән карт алаша кебек пошкырынып булмый. Менә шуны аңла да күз яшеңне сөрт. Авызың тулы кан булса да, чит кешеләр алдында төкерергә ярамый шул безгә, ярамый. Түз, ризалаш, балам.

Айзирәкнең дә язгы ерганак челтерәве шикелле генә тонык, зәгыйфь тавышы ишетелде:

— Әле булса Сал-Салны күрмәдем бит. Ичмаса, аның күзенә бер багасы иде.

— Кирәкми, балакаем, — дип ашыга-кабалана янә тезде ата. — Сал-Сал батырны мин кисәткән идем. Ул ризалашты, шуңа моннан сине калдырып китте.

Айзирәкнең куллары кыйнап ташланган аккош канатларыдай салынып төште, ул күз яшьләрен йотып үз карарын әйтте:

— Мин аңладым, әти. Ил хакына шулай кирәк икән, мин карышмыйм. Син кушканга күрә генә мин кенәзгә чыгам. Сал-Сал да баш тарткач, миңа барыбер инде.

— Син акыллы, балакаем, рәхмәт, рәхмәт, — дия-дия, кызын мәйдан уртасына таба этте ата. — Сине анда булачак ирең көтә, әйдә, горур атла.

Әле Ибраһим хан белән Айзирәк мәйдан уртасына килеп җиткәнче үк, Владимир кенәз күзләрендә шайтан уты яна иде инде.

— Бездә дә чит-ят дәүләтләргә, хәтта каган илә кайсарларның үзенә дә хатынлыкка бирердәй кызлар юк түгел ул, Владимир кенәз! Менә сиңа бүләккә минем кызыкаем, Айзирәгем, — дип, яшь кәләшнең кулларын да тоттыргач, баскын кенәз тәмам эреп китте.

— Новгородка, Ростов, Галичларга барып чыкканым бар. Мадьярлар, бәҗәнәкләр янына да кат-кат эләккәләдем. Инде мин лаек кәләш сорап юнан кайсары янына барырга йөри идем. Бактың исә, кайсар кызларының йөзен, меңен бирүзе алыштыра алырдай чибәркәйләр сездә үсә икән. Рәхмәт сиңа, рәхмәт, Ибраһим хан!

Владимир кенәз, күзләрен мут уйнатып, Айзирәкнең билләрен дә кымтырыклый башлагач, мәйдан читендә янә Добрыня шәрран ярды:

— Һе! Сез бер-берегез белән үзара кияүләр дә булыштыгыз инде. Ә моның туй дигәннәрен кайчан, ничек билгеләп үтәбез соң? Туйсыз гына кәләш алышмыйлар ла инде ул, кит, әкәмәт!

Владимир кенәз хуҗа сыман кыйланып сүз ыргытты:

— Калган эшкә кар ява, ди, сузу-соңарту юк. Хәзер үк туй итәбез! Урыны шәп. Олауларда байлык, нигъмәт җитәрлек. Туйны менә шушы төштә үткәрәбез.

Кулыннан дилбегә ычкына башлавын сизеп алып, Ибраһим хан гаярь аваз салды:

— Кунакларның, дусларның сый-ризыгы әле кайтыр юлда үзләренә бик күп кирәк булыр. Сез минем кызымны юлда ачлыктан интектерергә ниятләмисездер лә инде? — Андасанда көлешү авазлары яңгырап алды, хаким дәвам итте: — Ә кунакларны сыйлар-көйләр өчен безнең үзебездә дә ризык олы күл кадәрле. Әнә, күрәсезме?

Урыс укчылары зәңгәр төтен бөркеп утырган дистәләгән

учакларга таба борылып авыз суларын корытты, ә Ибраһим хан дилбегәне янә каккалады:

— Урынын шәп, дидең, Владимир кенәз. Менә шушы Елантау өстендә туй итәбез. Хәзер үк туй!

Йөзәрләгән ир-ат шундук эләктереп алды:

— Туй, туй! Ике кияү, ике хаким туе!

Күк күкрәвенә тиң тавыш басылуга, Ибраһим хан яңа тәкъдиме белән һәммәсен шаккатырды:

— Әле моның белән генә эш бетмәде. Безнең бабаларыбыз элек заманда ук изге гамәл кылган урыннарында яңа нигез кора торган булганнар. Мин дә шушы олуг җиңү, мәңгелек солых хөрмәтенә ошбу тау башында өр-яңа бер кала кордыртам. Без инде элек үк монда яңа кирмән корырга кыжрап йөргән идек, кул җитмәде. Менә син булса да чеметеп уяттың безне. Калган эшкә кар ява, ди. Яңа каланың беренче казыкларын бүген үк кагып куям! Еллар, гасырлар үткәч, синең оныкларың да, бәлки, шушы солых хөрмәтенә нигезләнгән бу каланы яндырып юк итмәсләр.

— Ну инде, ну инде! Солых төзедек лә, нинди яндыру ди? — дип сөйләнә-сөйләнә Владимир кенәз борча талагандай бөтерелде.

Курсыбай газиләре «ә» дигәнче тап-таза имән казык табып китерделәр. Ибраһим хан аны кулларына алды.

— Аллага тапшырдык, — дип, уч төпләренә төкерен гәләп куйды.

— Кая, мин дә кагышыйм, — дип, Владимир кенәз дә имән казык янынарак елыша башлаган иде, Ибраһим хан терсәге белән төртеп читкә арындырды.

— Һәрбер яңа кала — яңа бала сыман. Ә җир йөзендә бер генә баланың да атасы икәү-өчәү булганы юк әле. Бу безнең җир, казыгын да ялгызым кагачакмын!

Ниһаять, гайрәтле кизәнеп, Ибраһим хан казык башына чукмар белән орды.

— Меңьяшәр кала булырга язсын инде берүк!

— Уртак кала булсын! — дип, чак-чак кына ишетелерлек итеп пышылдады бер як читтә турсаеп торган кенәз.

Имам Мәрдән белән Локман хәзрәт читкә китеп кенә дога багышлады. Гади яугир белән ярлы-ябагайлар кыйбла якка карап намаз укыдылар. Беренче йолалар шул рәвешчә үткән генә иде, яңа сорау белән кенәз аваз салды:

— Җиһан бездән оныкларга кала. Бу җирләргә дә, бәлки, тора-бара яңа хуҗалар табылыр, каланың туган елы да әллә ничә тапкыр үзгәрер әле... Ә исемен, исемен ничек дип кушасың, Ибраһим хан? Җир йөзендә кушаматсыз мал да сирәк ләса.

— Исеменме? Исемен... — дип кабатлап торды таждар,

аннары һичкем көтмәгәнчә капылт әйтеп салды: — Ә исеме Казан булыр, кенәз. Әйе, Казан! Бөтен ил белән бергә килеп аскан күмәк казан. Ахыр чиктә, егерме ел үткәч үз иленә әйләнеп кайткан әнә теге казан. Алтын казан!

Ибраһим хан куллары белән төртеп күрсәткәч кенә, читтә янтаеп утырган ялгыз казанны шәйләп, һәммәсе аһ иттеләр. Хуҗа хаким тиз-тиз генә аңлатмалар бирде:

— Моннан егерме ел элек безнең өскә килгәч, атаң Святославка нәкъ мин бүләк итеп биргән идем аны. Моннан бер йөз чакрым чамасы ераклыкта, Ашлы каласында. Бу безнең уртак казаныбыз булсын, яңа яулар белән безнең өскә килмә, дип, олы, изге хисләр кушып биргән идем. Атаң кабат килмәде килүен, ә менә син барыбер дә килдең. Димәк, атаң сабак бирмәгән бит сиңа, нәзер калдырмаган. Менә бүләк ителгән казанны да кулыннан ычкындырган. Ул казанны өстерәп монда син килгәнсең. Яман фал бу. Мондый савыт юлда йөри башласа, сез үзегезнең аерым кала-олысыгызда аңа салырдай ризык таба алмыйсыз, ул ризыкны күршеләргә кереп кенә юнәтергә җыенасыз икән дигән шик уяна. Ә кулдан-кулга күчеп йөргән казан гел уртак мал җыя…

Мондый юраудан соң ирләр арасында моңсу-сагышлырак тынлык сарган иде, каравылбаш Көбәк аны йомры сүзе белән төтен сыман куып таратты да куйды:

— Кенәз, кенәз! Сез үзегез белмисез дә әле, ә безнекеләр сәрдәр белән сезнең икегезгә өр-яңа исемнәр уйлап тапканнар бит.

— Нинди исем тагын? — дип, кенәз күз акайткач, Көбәк ярты ялан ишетерлек итеп шәрран ярды:

— Син Владимир түгел, Балтимерсең хәзер. Ә сәрдәреңнең яңа аты-наме төп-төгәл Дәүборындыр.

Сүзләрнең мәгънәсен тылмачлар аңлатып бетергәч, Владимир кенәз эченә кату төшкәнче туктаусыз шаркылдады:

— Балтимер, Балтимер, минеке ярый әле. Ну менә синекен, туган агайкаем, ай-яй, туры китергәннәр дә инде. Дәүборын! Суйган да каплаган бит, бигрәк килешеп тора…

Йөзбашлар һәм вак түрәләр генә түгел, хәтта олугбәкләр дә казаннар белән ак чатыр арасында инде күптән тыз-быз килеп йөгерешә башлаганнар иде. Ниһаять, вәзир Насыйрның тантаналы, дәртле чакыру авазлары яңгырады:

— Туйга рәхим итегез, дустанә яшәргә ант беркеткән дәүләт таҗдарлары! Туй табыны сезне көтә, яшь кияүләр белән яшь кәләшләр!

Чәнчеләр һәм танбурчыларның дәртле аһәңенә кушылып, Елантау өстен янә йөзәрләгән яугирләрнең шатланып кычкырган тавышлары күмде:

— Туй итәбез, туй! Ике туган туе!

Кабан күлләре тирәли урнашкан баскыннар ыстанында җанланыш, хәрәкәт чаткылары өч көн үткәннән соң, әче таңда ук тоемланган иде. Бу хактагы хәбәрне ишетүгә, Ибраһим хан кияү чатырыннан шундук чәчрәп чыкты.

— Хәзер үк аргамакны китерегез миңа! — дип, каравылбаш Көбәк тарафына әмер ыргытты ул. — Бөтен гаскәр яу хәленә килсен! Аннан... аннан Сал-Сал сәрдәрне дә табып китерегез!

Көбәк кыяр урлап тотылган шук малай шикелле авызборынын салындырып кына җавап бирде:

— Сал-Сал юк, Ибраһим хан. Сәрдәрне инде ике көн буе эзләп тә таба алмыйбыз.

Ибраһим шөпшә тешләгән шикелле боргаланып, ярсып җикеренде:

— Кайда соң ул, кайда? Ике көн буе да табылмагач, нинди сәрдәр ди ул?

— Берни белүче, күрүче кешеләр юк, — дип, Көбәк элеккечә гаепле аһәң белән аклануын белде. — Качып китмәгән булса ярый инде тагын.

Ибраһим хан янә котырынды:

— Качкан икән качкан. Төкерәм мин аңа! Болгар илендә сәрдәр итеп куярдай ирләр беткәнмени? Менә син булырсың!

— Әй-яй, Ибраһим хан! Сәрдәр — кәнизәк тә, сөяркә дә түгел. Чәчбиләрне ятакта көн саен да алыштырып була, әмма язгы боз шикелле ышанычсыз яки тимерче мичендәге булат хәленә китереп сыналмаган, чүкелмәгән сәрдәр белән тәхет тоту кыен. Син әмер бирәсең икән, сәрдәр булырмын мин анысы. Тик хәзер үк кисәтеп куям, мин Сал-Салны алыштыра алмыйм!

— Син алыштыра алмасаң, яңасын куярбыз! — дип, элеккечә җикерде Ибраһим хан. — Түрә урынына кызыкмаган кеше буламыни? Майлы калҗа һәрчак ымсындыра.

— Анысы шулайдыр да, әмма ул калҗаның зәһәр капкын эченә көйләп куелган булуы да мөмкин...

Тагын да дәгъвалашырга ирек бирмәделәр. Елантау өстенә янып пешкән яңа чапкын егет менеп җитте.

— Кенәз белән сәрдәр бу тарафка килә. Бик җитдиләр. Олы гозерләре бар, ахрысы...

Бу юлы инде коралсыз гына килгән яубашларның сүзе асылда да җитди булып чыкты.

— Миңа Киевка коры кул белән әйләнеп кайтырга ярамый, моны аңлыйсыңдыр, — диде Владимир. — Аннары ил-

дәгеләр миннән бот чабып көләчәкләр. Мин атай юлы буйлап китәргә карар кылдым.

— Һаман бер үк балык башы, тагын Йосыф каган өстенә барырга җыенасыңмыни? — дип, Ибраһим хан сүз кыстырып куярга мәҗбүр булды.

Владимир кырт кистереп, катгый җавап тотты:

— Барам, Ибраһим хан! Хәзәр каганы безнең икебезне дә нык имде, күп сауды. Аны кан белән костырырга вакыт. Син каганга каршы кылыч күтәрергә җөрьәт итмисең икән, мин аның йортына япа-ялгыз көе бәреп керәм! Сукыр тычкан кебек качып-посып кына җан асраудан, кәрван-кәрван ясак озатып ятулардан менә болай гарык! Йә кырылып бетәбез, йә җиңәбез! Башка юл юк!

Мин-минлегенә балта чабылган Ибраһим хан йөзен чытып аның сүзен бүлде:

— Ә син мине кай нисбәттән куркаклыкта гаеплисең әле? Каган каршында көянтә шикелле бөгелеп яшәүдән мин дә туйдым. Йосыф каганны тәхетеннән чәнчелдереп төшерү Болгар иленә дә хөрлек, мөстәкыйльлек алып килә. Шуңа күрә мин дә синең яу сәфәреңә кушылырга риза! Бар нечкәлек фәкать санда гына. Сиңа ничә мең яугирлек гаскәр бүлеп бирим?

Бу юлы кенәз урынына Добрыня сүз тотты:

— Җиде мең, Ибраһим хан, төп-төгәл җиде мең баш җайдак. Без, синең иленә сәфәр чыгып, шулчаклы ир югалттык.

— Ярар, һичбер төрле тоткарлык та булмас, — диде Болгар ханы, бик тә ансат күнеп. Әмма яңа җөмләсе белән баскын яубашларны кайнар суга салды. — Иллә мәгәр олы бер шартым бар. Сез Елантау эргәсенә килеп урнашканнан бирле гажәпләнеп йөрдек. Сезнең һаман һичбер аллагыз юк, сез чирмеш, ар һәм мукшы кабиләләре сыман кырыкмаса кырык төрле потларга, җансыз сыннарга табынып көн күрәсез икән. Сезгә дә фәкать бер аллага гына табынырга, изге дин юлына күчәргә вакыт. Мин бүген үк, кичекмәстән безнең дингә күчегез, дип әйтмим. Динне кабул итү өчен аңа җаныңтәнең белән инанырга, аның бар канун-йолаларын, гореф-гадәтләрен өйрәнергә кирәк. Менә шуңа күрә синең даирәңә безнең муллабызны, ислам диненең барча нечкәлеген белгән имам-хатыйбны кушып җибәрәм мин.

Ибраһим хан мәйдан уртасында хасил булган тагын бер яңа чатыр ягына борылып оран салды:

— Әһ-һәй, имам Якуб Ногман! Монда чыгып күрен!

Чатыр ишегендә борын астына тычкан койрыгыдай нечкә мыек җибәрсә дә, япь-яшь кыяфәтле егет пәйда булды. Кенәз белән сәрдәрнең гажәпләнеп текәлүен күргәч, Ибраһим хан үзе аңлатмалар бирде:

— Яшь икәнлегенә карамагыз. Ул Коръәни-Кәримне су

урынына эчә. Андыйларны бездә Коръән-хафиз диләр. Юлда чагында да, сараеңа кайтып җиткәч тә сиңа аның үгет-нәсихәтләрен, вәгазьләрен тыңлау комачауламас, кенәз. Мин ышанам, син үзең дә, урыс милләте дә без сайлаган изге динне якын итәчәксез. Ә дәүләтең белән ислам диненә күчсәң, без бер ана балаларыдай газиз туганнар булып та көн күрербез әле.

Владимир кенәз Ибраһим ханның һәммә мәшәкатен уен сыман кабул итте бугай, кулын селтәп кенә җавап бирде:

— Киев, чыннан да, бер асыл дин сайларга тиеш инде. Бу яшь егет безне ислам ягына борып куя алса, әйдә, сихерләсен. Үзенең кыйбласына инандыра икән, без сезнең динне кабул итәргә риза…

Елантау өстендә инде икенче көн буе балта тавышлары яңгырап ишетелә иде, Владимир тирә-юньгә күз ташлады. Чыннан да, гаҗәеп хәл хөкем сөрә икән. Әнә дистәләгән ирләр җилән-күлмәкләрен салып ташлаганнар да, икешәр дилбегә буе бүрәнәләрне яланның бер башыннан икенчесенә мамык каурый шудырган шикелле генә итеп сөйрәп күчерәләр. Бүрәнәләрнең күбесе инде каезланган, алар ап-ак сөяктәй ялтырап, күзләрне камаштырып тора. Һәр агачның баш-башларында матур уемтыклар, буеннан-буена тигез итеп алынган улакчыклар. Оста куллар һәркем көнләшерлек итеп башкарган бу эшләрне. Бүрәнәләрнең бер-берсенә сумаладай берегеп ятасына шикләнерлек түгел. Балта осталары үзләре дә канәгать, күрәсең, ара-тирә тел шартлатып дәшкән авазлары ишетелеп куя.

— Их, бүрәнәсе дә бүрәнәсе! Валлаһи, җан кебек! Менә мондый бүрәнәләрдән салынган сарайларда яшәсәң дә була!

Җор теллеләр һәр җирдә табыла, өстәп-төрттереп куючылар бик аз түгел.

— Йортың моннан кайтыш агачлардан салынган булса да ярый ла ул. Иң мөһиме, култыгыңда кайнар җанаш булсын!

— Арты белән иелгән саен ирлегеңне искә төшереп торырдай җанашың янда булмаса, алтын сарайларда яшәүдән ни хикмәт?

Ирләр нәсел айгырлары сыман кубып дәррәү көлешәләр, хәтта күк капусы киңәйгәндәй була. Шулай, дәрт белән, килешеп һәм көлешеп үткәргән өмәләрдән дә татлырак мизгелләр юк инде ул ир-атка. Мондый чаклар бик аз тәти шул ул.

— Көнләшәм мин сездән, — дип куйды Владимир кенәз чын күңелдән. — Без Киев җирендә бер-беребезнең калаларын үзара яу йөреп яндырабыз, ә сез кирмән артыннан кирмән тергезәсез. Безгә менә мондый тәртип кайчан керер инде?

Ибраһимның: «Яу йөрүдән туктагыз», — дип төрттерәсе килеп китте. Теле бик тә кычытып тора иде, дәшми калды.

Владимир кенәз белән Ибраһим хан бер-берсен кочакларына алып саубуллашты.

— Кунакның гомере өч көн, юл кешесенең юлда булуы хәерле, ди, без кузгалыйк, — дип хушлашты кенәз. — Инде шушы Елантау өстендә, өр-яңа кала нигезендә төзегән солыхыбыз җимерелмәсен дә яу сәфәрләребезнең юллары кисешмәсә генә ярар иде.

Яубашларны түгәрәкләп алган болгарлылар бердәм кабатлады:

— Шулай була күрсен, кенәз, амин, амин!

61

Болгарлар белән урысларның күмәк гаскәр төзеп сәфәр чыгуына бер атналап вакыт үтте инде, ә Ибраһим хан һаман яшь кәләше белән кереп бикләнгән чатырыннан ерак китә алмый. Дөрес, кияү чатырын Елантау өстеннән төшереп, исемсез елга буена, нәкъ Нургали чишмәсе каршына күчереп кордыртты ул. Чөнки табигать соңгы көннәрдә акылы керәлечыгалырак булган яшь киленнәр төсле көйсезләнә, иртәгә кайсы яклап терсәк күрсәтәсен һич тә аңламассың. Әле озын кара итәкләрен Елантауның түбәсенә сөйрәп авыр болыт уза, әле тауны йөз кисәккә бүлгәләп һәм тетеп ташларга җыенгандай яшен кылычы чытырдап-айкап ала. Күк йөзеннән фәрештәдәй иңгән Василисаны әнә шул яшен утлары куркытты да инде.

— Тау түбәсе түгел, утлы таба бит бу. Ирем куенында онытылып үбешә дә алмыйм. Чытырдаган һәрбер яшен кылычы астында дер калтырап бишкә бөгелгәнче, әйдә, тизрәк тау астына төшик. Ичмаса, шунда рәхәтләнеп назга күмелербез.

Яшь хатын сүзе олыгая башлаган һәр ир өчен тайпылышсыз канун. Монда хан яки әмир булуның аермасы һич юк. Ибраһим да, муенчакка утыртылган көчек кебек уйнаклап, шундук Нургали чишмәсе янына төшеп җитте. Юкка түгел, каһәр! Василиса хәзер аны куеныннан бер дә ычкындырмый. Ул әле үзе Ибраһимның өстенә менеп атлана да ими башларын аның мыекларына тидереп уйната-сикертә рәхәтләнә, әле юрган астына чума да яшь кияүне оҗмах бакчасына кертеп адаштыра. Ибраһим шәраб эчеп исергән сәрхуш сыман тәүлек буе иләсләнеп ята. Ул мескен дә элек үзен иркәлек-наз татыган ир урынына санап яшәгән икән бит, и-и, томана!..

Менә шуңа күрә әледән-әле кереп, үзен бимазалап йөргән вәзир белән олугбәкләрнең сүзенә бик үк ыжламый ул. Тик шулай да, ил хуҗасы булгач, колак салмыйча да мөмкин түгел. Ә тегеләр, сукбай тәненнән бет эзләгән шикелле, җыен

вак-төякне табып кына тора. «Яшь кәләшең безнең дингә иңдерелмәгән бит, никах укыту фарыз булыр», — диделәр, таҗдар шундук күнде. Менә биш көн буе аның яшь хатыны Вәсиләкәй хәзер, Василиса түгел. Аңа карап кына кәләшнең иреннәре-тәне суынмады, ул утлы күмер шикелле элекке чә кайнар.

Аннары якындагы бер авылдан тапкан чирмеш камын тотып китерделәр. Чәче мич пумаласы шикелле тузгып, катып беткән. Биленә һәм муенына аскан кыл бауларга кипкән чуртан башлары, бүре һәм аю тешләре, тавык тәпиләре тезеп чыккан. Өстенә аллы-гөлле төскә манылган, катлы-катлы киндер күлмәк кигән, ләкин һәммәсе дә эт талагандай кылка. Әлеге кам аламасының хәтта зәһәр исенә чыдамалы түгел, әмма аның сәер хорафатын барыбер тешләрне кысып тыңларга туры килде.

— Син яңа кала урыны итеп сайлаган бу тауның олуг хуҗасы бар. Ул ярканат шикелле итеп канатларын җәйгән зур аждаһа. Ул монда көн дә кунмый, сирәк кенә килә. Аждаһа юк чагында тауга хуҗа булып вак еланнар кала. Вак дисәң дә, алар арасында дилбегәдәй озыннары да, бүрәнәдәй юаннары да ысылдап-ыжлап йөри. Алар синең монда аждаһа рөхсәтеннән башка килеп утыруыңа бик нык рәнҗегәннәр. Ул еланнарның көтмәгәндә килеп сине чагуы бар. Мондый бәладән исән калыйм дисәң, иң әүвәле, Елантау түбәсенә меңәрләгән учак кабызып, аның хуҗасы булган аждаһаны да, вак-төяк еланнарны да куып җибәрергә, ә аннары аларны бәхилләтер өчен корбанын да китерергә кирәк. Аждаһаны күп очракта менә шушы Нургали чишмәсе агып чыккан мәгарә авызына килеп куна, диләр. Корбанны да, мөгаен, шуннан эзләр.

— Әллә нинди сәер һәм бормалы бу синең хорафат-юраулары ң, — дип, Ибраһим хан кул селтәмәкче булган иде дә, чирмеш камы усаллана барып таләп итте:

— Юк, берничек тә сәер йә бормалы түгел, хан. Син асылын аңламадыңмыни? Әлеге тауга тик бер генә җан иясе — аждаһа гына хуҗа. Тау түбәсе — вәкарь чаптар сыман, ул үзен дистәләгән кеше иярләүне сөйми. Икенең берсе: йә аждаһа хуҗа булып кала тау башына, йә син булачаксың. Йөзәрләгән учак тергезеп, тоташ ут кабызып, мөгаен, син ялгыз аждаһаны куып та җибәрерсең. Мәгәр үзең аның өстендә гомер буена, гасырлар буена бердәнбер һәм азат хуҗа булып тора алырсыңмы? Елантау кулдан-кулга күчеп йөрүләргә лаек түгел. Башкалар аңа хуҗа булырга ымсынмасын өчен Елантау буена чит-ятларны китермәскә кирәк. Әгәр читләр камалышка алып ут төртсәләр, сиңа да нәкъ аждаһа шикелле чыгып качу юлы гына кала... Тизрәк корбан китер!..

Чирмеш камы китте, ләкин аның хикәяте белән тәэсирләнгән таждар Елантау өстенә тоташ ут ягарга барыбер әмер бирде. Тау башында йөзәрләгән учак дөрли башлауга ук, хан чатыры тышында әллә ничә ирнең саташулы тавышы яңгырап ишетелде:

— Әнә, әнә кыйбла якка кара! Ике канатын җилпеп аждаһа күтәрелде. Әнә инешнең икенче ярына таба очып бара!

— Китче, китче! Пыскый-пыскый очкан салам көлтәләре генә түгелме соң?

— Юк ла инде, юк ла, үзем күреп тордым. Канатларын җилпи-җилпи аждаһа очып китте. Без Елантауга хуҗа булып калдык!..

Икенче таңда имам Мәрдән белән Локман хәзрәт килде. Үзләре сөенеч китергән төсле, үзләре калтырыйлар. Чатыр тышына күлмәкчән генә чыккан Ибраһим хан аларның гозерен көчкә аңлый алды.

— Нургали чишмәсе янында бер-бер хәл булмасмы дип сакка төшкән идек. Мәгарә эчендә әүвәл ниндидер карачкы шәүләсе ялтырап алды да капылт гаип булды, аннан коры сөяккә калган карт эт чыкты. Ипи сыныгы ыргытып мөритләр теге этне кулга элэктерделәр. Әллә... яңа кала астына корбан итеп... шул хуҗасыз этне суйыйкмы соң әллә?

Ибраһим хан, үкчәләре белән җиргә тибеп, давыл сыман дулап җикеренде:

— Нинди эт сую ди?! Кая сездә гакыл? Корбан итеп эт чаласың икән, димәк, бездән соң этләр кулына калачак бит Казан! Чирмеш камы бик тә хак сүз ычкындырды. Казан каласы гомер буе, мәңге-мәңге тик безнеке генә булырга тиеш! Аны эт каны белән буяу, аңа эт аягы бастыру да хәрам!..

Имам Мәрдән белән Локман хәзрәт, капкын авызыннан чак качып котылган бүреләр шикелле койрыкларын кысып, тавыш-тынсыз гына китсәләр дә, өйлә намазыннан соң янә иске табак сыман тәгәрәп килеп тә җиттеләр. Бу юлы инде үзләре генә түгел, яннарында сукыр бер сукбай бар. Сәләмә киемнәреннән, тоташ җыерчыктан хасил төс-кыяфәтеннән үк сизелеп тора: урау, озын юллар үткән дәрвиштер бу.

— Җаек аръягыннан, Җидесу иленнән үк килгән, — дип таныштырды имам Мәрдән. — Үзе чичән, үзе күрәзәче. Яңа кала язмышы хакында берәр гыйбрәт ачып салмас микән? Бергә-бергә сорап карыйк әле.

— Казан каласын нинди язмыш көтә? — дип эндәшкән хан ягына таба йөзен дә бормады бу сукбай чичән. Яңа кирмән нигезләнү хакында әле юлда ук ишеткәндер инде, солы биштәренә төртелгән ат шикелле, иреннәрен чапыр-чопыр ялмап тезеп китте:

— Озын гомерле булачак бу кала. Мең кат егылып, мең

кат тереләчәк. Кай елларда ут-янгын да ялмап алыр аны, әмма даладагы кылган төсле янә уяныр, янә күтәрелер. Көтү-көтү булып әллә ничә дошман килер аның өстенә, әмма күп гасырлар буе бер гаскәр дә аны тез астына егып сала алмас. Тик берзаманны каланың үз эчендә үләтләрдән хәтәр яман бер чир котырып кузгалыр да ошбу кирмән дошман кулына төшәр. Аннан ары Казан шул дошманнар каласы булып исәпләнер, аңа шөһрәт һәм дан китерер...

— Нишләп дошман кулына төшәр соң ул? — дип, хәзрәтләр бердәм чәчрәп купканнар иде дә, сукыр чичән һаман үз җаена, салмак дәвам итте:

— Дошман умарта күче кебек өерелеп килсә, дәүләтләрнең язмышын ике юл хәл итәр. Берсе — каланы бирмибез, дип киребеткән, мүкләк кәҗә сыман үҗәтләнү. Бу очракта гаскәрең белән илбашыңны капчыкка салган бүре урынына кыйнап үтерәләр. Икенче юл — гаскәреңне һәм халкыңны саклап калу бәрабәренә кирмәнне ташлап чыгу.

— Соң, кирмәнне дошман кулына ташлап китү — ул җиңелү ләбаса! — дип, янә Ибраһим хан ярсый-ярсый чичәнне бүлгән иде, тегесе аның сүзен чебен куган кебек кире какты:

— Көя кисә, көя талый, дип, үз күлмәген баш астына салып йоклаган тилене күргәнең бармы, таждар? Яки нәкъ киресе. Умарта күче килеп ябырылса, бер бәндә дә үз күлмәгенең итәк астына качып котыла алмый. Мең кат сынаган бар: мондый чакта кеше күлмәген сала да аны селтәп-болгап кортлар талавыннан котылырга тели, ахыр чиктә, читкә-янга качып, якын тирәдәге күл эченә чума. Менә шушы ике мисалдан соң нинди нәтиҗә килеп чыга, таждар? Димәк, һәр ике очракта да адәм баласына күлмәгеннән бигрәк башы кадерлерәк. Күкрәк баласы гына әнисенең имчәгеннән башка берни белми, ә акылы бар илбашы камалышта калган кирмәнгә ябышып ятарга тиеш түгел. Буш калдырылган кирмәнгә барып кергән дошман үзе капкынга эләгә ул. Аннары аның үзен ничек кирәк шулай ябырыл да тала. Алай итсәң, дошман үзе күлмәк-ыштаннарын сала-сала чыгып йөгерәчәк. Менә шуны аңламыйча, тар маңгайлы булганга оттыралар ханнар...

Ибраһимның аркасы буйлап кайнар сумала йөгергәндәй булды, сукыр дәрвишкә каршы саллы дәлил китерә алмаганы өчен бөтен тәне янды, янә кәефе кырылды.

— Алып китегез моны, — дип ысылдады ул имам Мәрдәнгә, ишетелер-ишетелмәслек кенә итеп. — Җыен сукбайны минем янга ташып йөдәтмәгез.

Сукыр кеше колакка сак була. Дәрвишнең бик әрнеп үртәлеп мыгырдаган тавышы ишетелде:

— Шәп сандугачның башына аның шәп сайравы җитә, ди. Йөзгә бәреп әйтә торган хакыйкать — ул һәрчакта да артык кашык кебек. Андыйларны бер хуҗа да сөймәи...

Хәзрәтләр «баш өстә, хуҗабыз» дигән төсле иелә-бөгелә китеп барсалар да, ахшам намазы алдыннан икесе дә янә күренделәр. Икесенең тиң йөзе акшар сөрткән төсле агарынган иде.

— Мәгарә эчендә эт белән бергә йөргән карачкыны тагын күргәннәр бит. Чәче-башы ап-ак, сакалы биленә җиткән, теләсә нинди ертык-мыртык, кылка киемнәргә киенгән, ди. Иң сәере: аның ике кулы да терсәктән тиң кисеп ташланган, җиң эчләрендә ике зәгыйфь ботак кына тырпаеп тора икән. Болгарга теге чакта «йөзбаш Атлаш Тимер-Мөэминнең ике кулын чабып ташлаган» дигән имеш-мимеш хәбәр кайткан иде. Бәла табан астында йөри, ди. Бу карачкы Тимер-Мөэмин йә урыслар калдырып киткән катыйль-мазар булып чыкмагае! Илбашларны читтән килгән утыз меңле, илле меңле дошман гаскәреннән саклап калып була ул. Мәгәр бер хыянәтче соранның пычак йөзеннән аралап калу өчен бөтен халкыңның да, дәүләтнең дә көч-гайрәте җитми.

Ибраһим ихахайлап көлде:

— Куркак җанга урмандагы һәрбер агач төбе бүре башы булып күренә, ди. Мең кат әйттем инде, җыен юк-бар ташып, саруымны кайнатып йөрмәгез әле монда!

Хәзрәтләр шыпан-шыпан гына юкка чыкты. Елантау итәкләре өстенә ипләп кенә караңгылык ятты. Хан чатырыннан күгәрченнәр кебек гөрләшүче сөекле ярлар тавышы ишетелә иде, аны тыңлап торуны арусынмыйча, шыгавыллар читкә китеп басты. Томан төшкән кебек сиздермичә генә төн уртасы җитте, җиһан кышкы урман йокысына талды.

Нургали чишмәсе агып чыккан мәгарә ягыннан сыңар таш кисәге тәгәрәгән тавыш ишетелде, игътибар итмәделәр. Чатыр янына бикле ишекне тырмалаучы песи баласы шикелле кыштырдап шуышкан шәүлә якынлашты. Чатыр эчендә фәкать балавыз шәм яктысы гына җемелдәп тора иде. Менә шәүлә чатыр авызына килеп җитте, эчкә башын тыкты. Чәче-сакаллары яңа явып үткән ак кар сыман, авызына каен кайрыларыннан ясалган олы тырыс капкан. Шәүлә шул тырысны чатыр эченәрәк кертеп куйды, борыны белән төртеп аны бер янга аударды. Эчке якта йомран сызгырган кебегрәк тавыш яңгырауга, шәүлә чатыр авызыннан шундук юкка чыкты...

Икенче көнне өйлә вакыты җиткән чакта гына чатыр эченә аяк басарга җөрьәт иттеләр. Ибраһим хан белән Вәсилә-Василиса шәп-шәрә көенчә ике елан янәшәсендә җансыз ята иде.

62

Сал-Сал Елантауны ташлап киткән беренче тәүлектә генә көне буе чапты. Югыйсә артыннан куа чыкмасларын да, үзенең бер йөз аучыга тоттырмас җайдак икәнлеген дә аңлый, белә иде. Тик барыбер тәнендәге бар ярсуын, үчен, рәнҗүләрен дала өстенә каурый урынына коеп калдырырга җыенгандай, Акбуранны кызганып тормый-нитми алга куалады да алга куалады. Әйтерсең лә күк күкрәгән төсле дөбердәп, аны арттан үртәп-мыскыллап кычкырган ачы авазлар яңаклый-яңаклый куа, ә ул шулардан колакларын томалап котылырга ашыккандай һаман ераклаша, алга кача иде.

Каршында сазлыкка эләккән олау шикелле менә җимереләм, менә авам дип торган иске йорт аламасы урнашкан кеп-кечкенә бер аланлыкка килеп кергәч кенә сәерсенеп, сискәнеп туктады ул. Нинди таныш чалымнар бар соң монда, күңелгә якын нинди ызаннар бу? Хәтер сандыгында, чатнап беткән көзге кисәкләре кебек ялт-йолт килеп, дистәләгән мизгел ялтырап үтте. И-и, син икәнсең лә бу, кендек каным тамган газиз нигез! Очарга, талпынырга дип, әткәм-әнкәм канат биргән ызан! Яшәргә, аумаска тырышып синең камылларыңа ябышкан һәм беренче мәртәбә иңнәреңә таянып аягүрә баскан газиз туфраккаем! Ничәмә-ничә ил-далалар, утлар-сулар, канлы яулар үтеп, никадәрле хаким-түрәләр каршында бил бөгеп тә бер уч бакыр акча, яңа киндер күлмәк, ярты кабым икмәк тә юнәтә алмаган мескен, ятим улың гап-гади, ялангач кол хәлендә синең каршыңда башын иеп тора. Иленхалкын түгел, хәтта үз нигезен дә данлый алмаган игелексез сукбай улыңны кабул итәрсеңме? Бу җиһанда аның бер бәндәгә, сыңар байбәтчә түрә-хакимнәргә дә тишек кәвеш чаклы да кадере, кирәге юк. Дәрья дулкыннары гомер буе ялына-ялвара килеп сыенса да, коры җир хуҗасы алар назын бер мизгелгә дә кабул итмичә, һәрчак кире куа. Син дә шулай йөз чөереп кире какмассыңмы?..

Сал-Сал газиз бусага туфрагына ятып озак өзгәләнде. Ул кабат аягүрә күтәрелгән чакта, табигать үзе дә йорт нигезенә чыгып утырган ак сакаллы карт шикелле чүккән, юашланган һәм гаярь Сал-Салның да күңеле-җаны йоп-йомры, сапсары үрдәк бәбкәләрен зыян-зәүрәттән аралап калырга тырышкан күл өстедәй көзге төсле тигезләнеп, тынып калган иде.

— Ярар, яр-р-р-ар, — дип, саташкан кешедәй, үз-үзенә кычкырып эндәште ул. — Һавадагы иң гүзәл аккошны, күк йөзендәге иң якты йолдызны кулларыңа эләктермәкче идең. Битеңә лач иттереп төкерделәрме, туган? Шул-лай. Җир йөзендә һәркемнең үз урыны. Шайтан таягы икән, ул әрекмәннәр, алабута, кычыткан янәшәсендә. Күкчәчкәләр, лалә,

гөләпләрнең үз түтәле, кишәрлекләре бар. Алабута, саташып, канәферләр ышыгына барып борын төртсә, аны төбе-тамыры белән йолкып ыргыталар. Син күк йөзендәге иң матур, иң алсу йолдызны күрергә маташкан сукыр кеше кебек хыялланма. Атаң Байдар менә шушы яланлыкта Сания исемле бер ялгызны, үзенә язган лаек парны очраткан бит әле. Җиһан чиксез, тәкъдир дигәннәре йөгәнсез ат сыман. Үпкәсагышларыңа кул селтә дә үз тиңеңне көт син!.. Аннары... аннары тәхет хакына, ил хакына дип бил бөгеп һәм җан түгеп йөргәннәрең өчен мәрхәмәт һәм рәхмәт сүзләре дә көтеп азапланма. «Изгелек эшлә дә суга сал, халык күрмәсә, балык күрер» дигән аксакаллар сүзе тиктомалдан гына туар идемени? Шулай, изге гамәлләрне, корбан бирүләрне бәяли белердәй хакимнәр юк бездә. Халык яклы яисә ватан җанлы кешеләр бездә гомер буе ятим. Шул, ел-гасырлар үткәч, оныклар күреп бәяләсә генә. Кичәге мәшәкатьләреңне, йөрәк яраларыңны оныт, Сал-Сал. Иске бишмәт бүре талаганда булса да ярап тора, диләр. Бәлки, сине дә берәр кайчан иске бишмәт, иске балта төсле искә төшерерләр, сагынырлар әле...

Йорт яңарту, ризык, утын, савыт-саба табу кебек вак-төякләр белән мәшәкатьләнеп, бер ай чамасы вакыт үтеп китте. Төннәрен гел йорт түбәсендә, хәтфә печән кочагында аунап уздыра торган иде. Беркөн таңда Акбуранның ярсып, дулап пошкырган тавышына сискәнеп уянды ул. Түбә ярыгыннан сузылып аска бакса, арпа-солы сибелгән колаша янында ике аяклы бер карачкы бөтерелеп йөри. Ни адәм, ни җанвар түгел бу җан иясе. Иңнәреннән ике якка кисек күлтәпиләр чыгып тырпаешкан. Өстендә сагызланып каткан, кылка-ертык чүпрәк аламасы. Биленә чаклы җиткән чәчесакаллары ап-ак, алар елан күче сыман үзара укмашып, буталышып беткән. Телен иягенә салындырган йөзе котчыкмалы кыргый, шакшы һәм җирәнгеч. Акбуран булып Акбуран да укшый бугай, малкай. Ул бер тибүдә сытарга чамалап, шушы карачкыны агач колаша тирәли ду китереп куа.

Сал-Сал кылычын янына кыскан көенчә аска сикереп төште. Шашкын Акбураннан аралаучы кеше табылуга сөенгән шикелле, җанвар аламасы аның каршына мүкәләп килеп җитте. Ул инде аягүрә басу, бил турайту гадәтен дә гел онытканбугай. Күзләре белән Сал-Салга төбәлсә дә, тездә торган көе, бияләй чаклы теле белән сакал-мыекларын ялмый-ялмый, капылт сүз башлады:

— Ә мин Ибраһимнан барыбер үч алдым бит. Мине узып яши алмады ул җиһанда. Мин ташлаган еланнар чакты ул кабихне, буа-буа чакты! Аларны тиккә генә ике атна буе ач тотмадым ла мин. Шул еланнарга чактырдым, чактырдым Ибраһимны! Менә шулай кирәк аңа, шулай кирәк!

Ибраһим дигән имгәк хан юк хәзер җир йөзендә, Ибраһим юк! Мин җиңүче хәзер бу җиһанда, йа Аллаһ, мин җиңүче!..

Бу шакшы җанвар үзе дә Сал-Салга зәһәр елан булып күренә башлады, аркасы буйлап меңәрләгән кырмыскалар, тараканнар чабышып-биеп узды. Кылыч сабына салган кулын тыеп, тешләре арасыннан тик бер генә сорау сытып чыгарды ул:

— Ә, син эттән туган Тимер-Мөэмин атлы үләт чире инде, алай булгач?

Карачкы аягына күтәрелә башлап, ярсый-ярсый, котырына-котырына аваз салды:

— Үләт түгел, Тимер-Мөэмин хан мин! Хан мин!

Карачкы тураеп басарга өлгермәде, аның түмгәк сыман тырпаеп торган башы агач колаша астына таба тәгәрәп китте. Кылычын үләнгә сөрткәч, Акбуранның йөгәненә кулын салды Сал-Сал. Күңеле яман шештән, зәһәр чуаннан котылган кеше тәне кебек җиңеләеп, бушап калган иде. Рәхәтләнеп аргамакка дәште:

— Тәхет тирәсендә тагын мәхшәр башлангандыр инде, тугры дустым. Сарай эргәсендәге түрәләрнең күбесендә баш урынына җиде тишекле түмәр утырса да, аларның һәркайсы фәкать үзен генә алтын таҗ киргә лаек асыл зат дип саный. Айзирәккәй үзе безгә тәтемәде инде. Ичмаса, аның энекәше Хәсәнне булса да тәхеткә күтәрү өчен кире кайтыйк, туган.

63

Владимир кенәз юл буе Айзирәкне учыннан төшермәде. Иң тәмле ризыклар — аңа, татлы-төче сүзләр — аңа һәм, әлбәттә инде, яшь, кайнар тән сусау кичермәслек иркә-наз да — аңа. Айзирәк үзе генә бу хисләргә җавап кайтара алмыйча һаман-һаман тоташ ут эчендә барды. Беренче атналарда аңа хәтта иң якты көн дә караңгы төн булып күренде, кенәзнең кирәкмәс назыннан кереп качар урын эзләп, мең-мең изаланды. Чатыр тышында чит-ят ирләрнең аяк тавышлары ишетелсә дә, кылыч таккан каешлары яисә кытыршы куллары чагылып китсә дә, шул мизгелдә үк аның күз алдына Сал-Сал газизе килеп баса һәм әйтерсең лә адым саен тик бер сорауны гына кабатлап, бетмәс-төкәнмәс ут эченә сала да куя иде: «Табышып кавышкан бәхетле ярлар турында син бер хикәят тә сөйләмәдең әле... Әллә безгә дә аерылу юрыйсыңмы?»

Айзирәк хыялында аңа нәкъ Нургали чишмәсе янындагыча өзгәләнә-өзгәләнә җавап кайтарырга ашыга:«Юк, юк!

Без аерылмыйбыз, җаным, аерылмыйбыз!.. Без синең белән мәңге-мәңге бергә булачакбыз!»

Ләкин менә шушы хыялыннан аерылып, ул чынбарлыкка кайтып төшә дә никахлы иренең карашыннан-назыннан ничек котылырга белмичә, ялгыз калган аккош сыман һаман бәргәләнә, һаман җаны сыкрый. Кенәз-ире — яу сәфәренә чыккан сәрдәр, меңәрләгән кешеләр гомере өчен җаваплы кеше бит, аңа бик еш кына яшь кәләше яныннан юк булып торырга да туры килә. Бер уйласаң, сөйкемсез кочактан аерылып тору дәва булыр сыман. Ләкин ялгыз калуның да шифасы юк, мондый вакытларда Сал-Салының томан аша эндәшкән һаман да бер соравы эзәрлекли башлый һәм ул Айзирәкне икеләтә көйдерә, бәгырен телә икән. Сөйкемсез ир кочагына кереп назлануның ялгызлык газапларыннан мең мәртәбә өстен икәнлеген менә шушы чакта аңлады ул.

Владимир да аның ниндидер сәер хисләр өермәсе эчендә януын тоя-сизә бугай, ул яңадан-яңа юаткычлар табып, ике арадагы бозны эретмәкче була. Бер төнне, хәтфә печән түшәлгән зур арбада чалкан яткан көе иләсләнеп-хозурланып барган чакта, һавадагы Киек Каз Юлына төртеп, кенәз сәер риваять сөйләп бирде:

— Минем кебек бер кенәз синең төсле үк бик тә чибәр сылуны очратып, аны үзенә хатынлыкка алган. Чөкердәшә-чөкердәшә бер ай чамасы да яшәп өлгермәгәннәр, кенәз үзенең дружинасы белән байлык тупларга дип яуга чыгып киткән. Ә кәләше япа-ялгыз көе, әмма инде буйга узган хәлдә яшәп калган. Кенәз яуда йөри-йөри бик күп дошманнарын җиңгән, тау-тау байлык җыйган. Ләкин ерак-ерак илдә, җиде башлы бер гыйфриткә очрап, шуның кулына әсирлеккә төшкән. Бу вакытта инде аның туган нигезендә калган яшь хатыны игезәк балалар да табып өлгергән. Шул хакта ишетеп, гыйфрит кенәзгә мондый таләп куйган. «Йә шул балаларыңны үземә тартып алам, йә башыңны өзәм!» Уйлаган-үлчәгән дә, балаларын корбан итәргә ниятләгән кенәз. «Ярар, мин әле яшь, хатыным белән балаларым да соңгылары булмас», — дип, үзен юата икән. Ул арада гыйфритнең өчәр башлы әне-сеңелләре — аждаһалар очып килгәннәр дә, яшь ана кулындагы балаларны алып киткәннәр, ди. «Сабыйларыма тимәгез, мин алардан башка яши алмыйм», — дип ялварып та караган ул ана. Аждаһалар кычкырып көлгән генә. «Ирең риза булды бит, ә ирне узарга ярамый», — дип җавап кайтарганнар. «Алайса, мин иремне дә каргыйм!» — дип, бар йөрәге белән кычкырган, ди, ана. Аның өзгәләнүләрен, елауларын күк йөзендәге фәрештәләр күзәтеп торган, имеш. Шулар ялгыз ананы, канатларына утыртып, күккә алып менеп киткән. Ә ананың күкрәкләре югарырак менгән саен

ныграк тулылана, ныграк шешә икән. Чөнки балаларын имезә алмау сәбәпле һаман саен сөт җыела икән дә сөт җыела икән. Менә шушы төшкә менеп җиткәч, күкрәкләренең сызлавына-талавына түзмичә, бәхетсез ана күкрәк очларын тырнап җибәргән, ди. Ана имиеннән бәреп чыккан сөт тамчылары күк йөзенә әнә шулай, мең йолдызлар булып сибелгәннәр. Алар күктә ана сагышы да, хатын каргышы да булып һаман яналар, ди. Менә шулай хасил булган ул Киек Казлар Юлы.

— И-и, бигрәк сагышлы, аяныч икән бит сездәге хикәятләр, гел безнеңчә түгел, — дип, Айзирәк гаҗәпләнә-гаҗәпләнә баш чайкады. Ахырда барыбер тел очына килгән иң олы теләген әйтми түзә алмады.

— Андый язмышлардан минем балаларымны аралый күр, Ходам!..

Җидеколак дигән сай сулы елгачык ярында алар ап-ак чәчле, күзләре чокылган картка тап булдылар. Тирә-юньдә һичбер юлдашы юк, кулында сөяк сыман кибеп беткән шома таяк кына. Мондый диңгездәй зур дала уртасында ничек исән-сау килеш яши ала да, ничек адашмый бу?

Шул хакта үзенә киная ташлагач, сукыр сукбай болай да җеп шикелле булып калган иреннәрен усал кыса-кыса җавап тотты:

— Миңа бу килеш кенә үлеп китәргә һич тә ярамый бит. Җир йөзендә мине әҗәт йөртә. Иосиф каган дигән бер җәлладка әҗәтем кайтарылмаган. Шул вәхши җан ике күземне чокып алды минем. Үз күзләрем өчен әллә ни үкенмим мин. Аларны иртәрәк чокып алса, яхшырак булыр иде. Ә ул мине тоташ елга булып аккан туганнарымның канын карап торырга мәҗбүр итте. Минем күз алдымда бер мең юлдашымны, миңа ышанып чыккан бер мең урыс ирен суеп чыкты бит ул, эттән туган имгәк! Мине җир йөзендә әнә шул бер мең илдәшем алдындагы бурычларым йөртә. Мин аларның каны, алар гомере өчен үч алмыйча китәргә тиеш түгел.

Меңбашлар белән йөзбашлар яу сәфәрен Владимир кенәз җитәкләп баруы турында да әйтеп салгач, сукыр карт катгый кистереп дәште:

— Иң яшерен юллар белән каган өстенә мин сезне үзем алып барам. Савилий дөм сукыр, пычагым да күрми, дип, юкка кайгырмагыз. Ике күзле көе сукыр булып яшәгән туң йөрәкле, агач бүкәннәргә караганда, дөм сукыр көе уттай янып йөргән кешеләр күпкә кыйммәтрәк ул...

Каганат уртасында аерым утрау булып утырган Итил каласының тоткавыллары бу юлы да берни сизмәделәр. Болгар белән урыс угланнары бар урамны чәчәк түтәле урынына сытып-таптап узды. Капчык кебек юанайган Иосиф кы-

лычын болгый-болгый атылып чыккан чакта, болгар җайдаклары каган сараеның диварларын тулысынча чолгап алган иде. Тоташ көбәләргә төренгән болгарларны шәйләп өлгергүгә, утка пешкән төсле ачыргаланып һәм ярсый-ярсый, вәзир-бәкләренә үкерде яһүд каган:

— Болгар илен саклагыз, алар белән дуслыкны өзмәгез, аларга тимәгез, дип әйттем бит мин сезгә! Урыс кенәзләре Болгар илен аяк астына салса, аннан безнең чират, дидем. Менә күрдегезме? Болгар иле черек койма төсле урыс ягына ауган. Болгарларны калкан итеп алгач, бу кыргый баскыннар Хәзәр илен дә таптап үтәр инде…

Иосиф каганны үз сараеның баскычлары өстендә турап үтерделәр. Идел ярындагы иң биек кыя түбәсенә менеп баскан Владимир пайтәхетнең барча урамнарын күк күкрәгәндәй көчле, күркәнекедәй тәкәббер һәм масаюлы тавыш белән күмеп гөрелдәде:

— Хәзәр каганы юк ителде, Иосиф атлы юха яһүдине җир йөзеннән тәмуг төпкеленә себереп аттык! Моннан ары каган дигән шанлы дәрәҗәне мин үз өстемә алам! Белеп торыгыз, җиһанга хәзер Владимир каган атлы урыс хакиме башлык!..

Итил каласын тоташ талап чыккач, Владимир, шул ук кыя өстенә басып, яңа әмер бирде:

— Кибән төсле, төрле яклап ут төртегез моңа! Хәзәрләрнең пайтәхет урынында көл катламы гына ятып калсын! Каганат далалары өстендә хәзер урыс мәмләкәте канат җәяр!

64

Балаларын Айзирәк бик интегеп тапты. Түшәк өстендә ике тәүлек буе газап чиккәч, җиһанга мичтән чыккан күмәч кебек кып-кызыл, орчык чаклы гына бәп-бәләкәй сабый пәйда булган иде дә, михнәтләр бетмәгән, Айзирәккә игезәк бала яратырга насыйп иткән икән. Якты дөньяга анысы да чыгып аваз салгач, кенәзбикә янында бөтерелеп йөргән кендек карчыкларының һәм бояр хатыннарының барчасы да, тулган ай шикелле елмаеп, бердәм сөенделәр:

— И-и, әле ни юнан киленененең, ни варяг хатынының игез бала тапканы юк иде. Кенәз Идел буеннан иярткән кайткан болгар кызы бигрәк уңган икән!..

Бояр хатыннары аның көндәшләрен санаганда, Айзирәк, яргаланып беткән иреннәрен усал кысып, үрсәләнеп ятты. Ни хәл итмәк кирәк, урыс хакименең бердәнбер хатыны булып яшәү бәхете тәтемәгән аңа. Кенәзнең менә шушы сараенда түбә бүлешүче хатыннары гына да тугыз. Аларның һәркайсына «җанкисәгем» дип эндәшкән чагында, кенәз, чыннан да, үзенең

хатыннарын аның җанын һәм түшәген яңартып-кайнарлап торучы сөяркәләр генә итеп саный кебек. Кенәз туймас, дуамал, шашкын. Аның нәфесе көтүче чыбыркысы сыман озын бугай. Аңа тугыз хатын гына да җитми. Ул әле Аккалада, Өскалада, кул сузымында яткан Берестовта янә сигез йөз җария кыз тупланган хәрамханәләр тота. Сарайга ул атнага-айга бер генә, анда да кайнап торган казанга чумдырылган чөгендер төсле кызарып пешкән хәлдә кайтып керә. Үзен ел буена күрмичә тилмергән картрак хатыннары Владимирга чәнечкеле-төртмәле кушамат та тагып өлгерделәр.

— И-и, безнең кенәзебез болытлар арасыннан чыккан Кызыл Кояш кебек күзебезгә кайтып күренде бит!

— И-и, безнең Кызыл Кояшыбыз, Кояшыбыз кайткан!..

Айзирәк балалар тапкач та, кенәз аның бүлмәсенә кереп карамады. Яшь ананың ашъяулыктай керсез, пакь күңеле ачыну-гарьләнүдән көзге болыт сыман тулып ташкан иде. Биләүләрен тибеп елаган сабыйларына кушылып, түшәк-ястыкларны төя-төя әллә ничә төннәр буе яшь түкте ул. Теле белән нинди генә сүзләр әйтеп бетермәде?!

— Синең сөюләреңдә шул, өй кыегындагы язгы боз сөңгесе белән бер икән бит. Башка сөяркәләр бераз гына елмаеп карадымы, синең миңа булган мәхәббәтең шундук эреп бетә, юкка чыга икән. Далада яндырып калдырган учак кебек онытырлык булгач, нигә, нигә дип кенә алып килдең соң син мине шушы чит-ят җиргә? Табаны ике яклап кыздырган чагында гына андагы ризык тәмле-татлы булып пешеп өлгерә ул. Ә мин сабыйларыма күчерерлек ут-җылыны берьялгызым гына каян табыйм?..

Әле ярый, аның күңелендәге болытларны куып таратырдай бер кеше бар. Үзе аунап үскән урам чирәмедәй газиз һәм тансык ул Айзирәккә. Һәрбер таңда чәчәк тажы сыман елмаеп һәм ачылып каршылый ул аны. Тик бусаганы атлап керүгә үк Якуб Ногман барын да күреп ала, һич ялгышмый. Аның сүзләрен тыңлап утыру да ләйсән яңгыр астында йөргән кебек рәхәт.

— Картайган кәккүк шикелле моңаеп утырма әле. Аллага шөкер, яныңда балаларың бар, син кәккүкләр шикелле япа-ялгыз түгел. Кенәзнең сирәк күренгәне өчен дә чәч агартма. Хакимнәрнең гыйшыклары кышкы учак сыман. Терәлеп утырган чакта җылысы бәреп тора, бер-ике адым ара калды исә, туңдыра ук башлый. Андый бәндәләрнең мәрткә киткән намусы — йокыга чумган авыл гына түгел. Аны тәрәзәгә шакып кына уятып булмый, наный...

Айзирәк сабыйлар белән юанган беренче көннәрдә дә кояш кебек иртә таңнан килеп елмайды ул. Балаларга исем кушарга кирәклеге хакында да нәкъ шул Якуб башлап сүз кузгатты.

— Кенәз күргә керми, дип, йөгән-дилбегәсез көе елап ятып булмас. Беткә үч итеп тунны утка ягу — таза акыллы кешеләр эше түгел. Кенәз үз ярына таба йөзә тормыш дәрьясында, ә безнең үз кыйблабыз бар. Аталары килеп эт кушаматлары такканчы, сабыйларны мөселман исемнәре белән тәгаенләү күпкә хәерлерәк.

— Соң, ни, килешеп бетәр микән? — дип, Айзирәк әүвәл каушабрак, йолкыбрак сузып караса да, тора-бара язгы урман төсле уянып китте. — Уйлап куйган исемнәр бар инде ул. Беренче сабыйны мин Киевка килгәч, дүрт дивар уртасына бикләнеп калганга күрә, «иптәш китер миңа, сердәш җибәр миңа» дип ялына-ялвара көтеп йөргән идем. Ходай Тәгаләгә барып җитте зарым. Шуңа күрә беренче сабыйга Аллазар дигән исем кую урынлы булыр сыман. Ә икенчесен көтми идем дә, белми идем дә бит. Анысы Ходай Тәгалә хозурына үзе аяк басты. Аңа Аллахозур дигән исем кушсак, игезәк туганы белән пардан булыр иде.

Якуб хәзрәт авыз ера-ера шундук эләктереп алды:

— Бик әйбәт, бик урынлы. Йә, килештек, наный. Берсен Аллазар дип тәгаенләп куйыйк. Икенчесе, әйдә, Алхозур гына булсын. Шулай ипле, алай килешлерәк. Аллазар, Алхозур! Икесе дә безнеңчә, мөселманча! Икесе дә озын гомерле була гына күрсен!..

Ни үкеneч, Якуб Ногманның яңгыравык, дәртле тавышы Айзирәк бүлмәсендә бик аз гына вакыт яңгырап ала да шундук юкка чыга. Айзирәк өчен Якуб Ногман төнге даладагы ялгыз учак сыман. Хәзрәт Киев каласын бөтенләй ташлап китсә, Айзирәк караңгы һәм салкын базга кереп чумар төсле. Менә ни өчен һәр көн саен газиз дә, тансык та ул.

Тик хәзрәтнең йөзен соңгы араларда гүя болыт каплап китте. Якуб үз эченә йомылып, йомарланып калды. Авызыннан бер сүз алып булмый. Сораштыра башласаң, керпе төсле кабара да кадый:

— Син кенәз хатыны, уңны-сулны барыбер аермыйсың. Синең кенәзеңә дә мин тукыган сүзләр ташка баш белән орган кебек кенә. Минем сүзне санга сукмый киреләнеп кенә торса бер хәл иде әле. Ю-у-ук, кысла сыман гел кирегә сукалый бит, каһәр! Бу җиһанда фәкать бер генә Аллаһ бар, дип аңлата-аңлата телем сынып бетте. Ә ул әнә Саескан тавы өстенә һаман үзенең агач сыннарын мендерә дә тезә, мендерә дә тезә. Ачуым килмәгәе, шунда унбиш-егермеләп потның зиратын корып куйды инде…

Ниһаять, беркөнне учак кебек балкып керде хәзрәт. Авызы — колагында! Сүзләрен дә сәйләп урынына челтерәтеп сибә:

— Аллага шөкер, Румнан[1] килгән христиан епископы, Коры үзәндә качып йөргән раввин, Балтыйк дәрьясы буенда яшәгән алманнар аббаты белән дүртебезне берьюлы кабул итә синең ирең, Владимир каган. Әй-яй, шәп туры килде бит әле бу! Үз динебезнең өстенлекләрен ачып салу, тегеләрне дә үз ягыбызга аудару өчен менә дигән форсат, әйбәт форсат! Җиңми кайтаммы соң! Кайтаммы соң!..

65

Владимир кенәз руханиларның барысын да үзенең тәхет залында, аягүрә басып каршылады. Иосиф каганга карата булган үч һәм нәфрәт хисе әле һаман хәтерендә күмер булып пыскый иде бугай, урыс хакиме яһүдине юньле-рәтле тыңлап та бетермәде.

— Әле сез, Ходай тарафыннан каргалып, үз иленнән сөрелгән һәм корыган агач яфраклары шикелле бөтен дөнья буйлап себерелеп йөргән яһүдиләр дә безне өйрәтергә, остазлар булырга маташасызмыни? Юк, сезнең сымак илсез-җирсез калырга исәп тотмыйбыз без! — дип, Владимир аны сараеннан себеркеләп куды.

Алман аббаты кереш сүзен үк урыс потларын, аеруча Перунны нәҗескә батырудан башлап китте. Владимир аның белән дә дилбегәне үтә кыска тотты:

— Минем бабаларым, сезнең атагыз каршына барып, дин ялынып йөрмәгән. Моннан ары да сездән аеры яшәп саргаймабыз әле...

Юнан побы сөйли башлагач кына, Владимир кенәз уяngандай булды. Аеруча тарих борынында булган су басулар, Адәм белән Хаваның яралышы, Тәүрат кануннары, чиркәүләрдәге чаңнарның шанлы тантанасы, адәм балаларының гөнаһларын юу, мәңгелек дөньяда көтеп торган җәннәт яки гөнаһлары өчен ләгънәт укыганнан соң гомерлек җәзага тарган мескен җаннар турында тыңлаганда, кенәзнең күзләре җил кабарткан учаклар шикелле кабынып-янып торды. Юнан илчесе хәйлә кушудан да тартынмады.

— Син җәннәткә эләккәч тә иң беренче җан булып йөриячәксең, син анда да бөек булып калачаксың, тизрәк чукын, кенәз, — дип, юха үгетләүләр белән тәмамлады ул үз сүзен.

Кулы белән ишарәләп, Владимир аны чүктергәндәй итте.

— Мөселман имамын да тыңлап карыйк. Син мине теге дөньяга озатырга бик ашыкма әле.

---

[1] Рум — безнең бабайлар телендә Византия, Константинополь.

Якуб Ногман бик тәфсилләп Коръән сүрәләре, шәригать кануннары, болгарлар арасында тамыр җәйгән гореф-йолалар хакында сөйләп чыкты. Хәзрәттән саркыган хис һәм ялкын вакыты-вакыты белән кенәзгә дә йога, ул да тал ботагына кунып сайрарга җыенган сандугач шикелле канатларын җилпеп, талпынып ала иде. Ни үкенеч, кенәздәге комар һәм дәрт хисләре яңгыр астында калган учак сыман әкрен генә сүнде, сүрәнләнде. Тамакларын кырып үзе сүз алганда аның йөзе инде тау башына куелган Перун потныкыдай җансыз, салкын иде:

— Мөхәммәт атлы пәйгамбәрегез бик тә акыллы, төпле кеше булган. Хәтта ул индергән Коръән синең белән минем ише карабашларның мактау сүзләренә бөтенләй мохтаҗ түгел. Тик шулай да сезнең динегезгә минем күңелем ятып бетми әле. Әллә нинди, мал өчен корып куелган агач аран төсле тар, кысан ул. Аллаһ алдында баш иям дип, тәүлегенә биш мәртәбә тот та тезлән, тот та тезлән. Алай еллар буе тезгә чүгә торгач, телисеңме-теләмисеңме, адәм баласында мескенлек, үзен түбән санау, коллык чире ярала, үсә башлый. Җитмәсә, ул тезләнүчеләрне аксөякләргә, карачураларга аерып тору да юк. Мин — хаким, ә мәчеткә кереп минем янәшәмә тезләнгән кеше — ертык киемнәрдән мәңге арынмаган шакшы карачура. Йә, мин ни өчен шул карабаш белән рәттән торыйм да, Аллаһ каршында булмаса, һич югы, руханилар каршында, үземнең илдәшләрем алдында сансыз бәндә булып калыйм инде? Юк, миңа бу һич килешми. Христианнарда әнә кайсарларны, кенәзләрне, аксөякне алтарь янынарак, башкалардан аерып, өскә бастыралар. Аларның побы-епископы сине шәхси чукындыра, сиңа гына багышлап аерым мәдхия җырлый…

— Ходай Тәгаләгә, Коръәни-Кәримгә тел тидерү гөнаһ, — дип, Якуб Ногман кат-кат авыз ачып караса да, Владимир кенәз Перун шикелле хәрәкәтсез утыруын белде.

— …Сезнең ул Аллаһ йортлары булып исәпләнгән мәчетләрегездә бөеклек, тантана, гауга-шау юк. Ниндидер бер бәндә генә манарага кәҗә тәкәсе сыман менеп азан кычкыра да, башка диндарларыгыз шуның янына сарык көтүе төсле йөгереп килеп җитәргә тиеш. Ә христианнарда әнә җиз чаңнар бар, катлы-катлы итеп төзелгән мәһабәт соборлар бар. Андый йортка керү, чаң шаулату — ул үзе үк һәр кешене күркә сыман кабарта, үсендерә, сиңа үзеңне бөек, гаярь тоярга ярдәм итә…

Владимир кенәз юнан побына караш ташлау өчен генә туктап-туктап торды, әмма күкрәк тутырып сулыш алуга ук янә тезеп китте:

— …Инде килеп, гөнаһ мәсьәләсе. Сездә гомер буе гө-

нah кылудан сакланырга кирәк. Гөнаһларың фәрештәләр канатына язылып бара, ул кара таплар өчен сине алда сират күпере, тәмуг, җәза көтә. Син кылган гөнаһларыңнан котыла алмыйсың, теге дөньяга күчкәч син барыбер газраилләр кулына барып эләгәчәксең. Ләкин дүрт аяклы ат та абына бит. Ә адәм баласы үзенең гөнаһларын гомер буе җилкәсенә олауолау итеп төяп йөрсенмени? Юк, мин менә шунысы белән дә катгый риза түгел. Христианнарда әнә рухани каршында тезләнеп гафу үтендеңме, үкенү күрсәттеңме — кичәге гөнаһларың юыла да бетә, иртәгә яңасын кыл, янә гафу үтен. Ичмаса, менә бу тормыштагы сыман...

Үзенең тайгак яшәү рәвешенә шәп аклану-калкан табуына сөенүдән Владимир кенәз очынып-очынып куйды.

— ...Ә инде гөнаһларны санап чыгуга күчсәк, ай-һай, бөтенләй чүп-чарны да гаеп саныйсыз сез. Дуңгыз ите ашама, чит хатынга нәфесеңне сузма, зина кылма, сугышма, урлашма, кеше җанын кыйма, ахыр чиктә килеп, хәтта аракы да эчмә. Кит инде, әкәмәт! Ул рәвешчә, Мөхәммәт пәйгамбәрнең үзенә тиң булып яшәп буламыни? Ул чагында нигә кирәк миңа андый тормыш? Күрше тавыгын басарга кызыкмаган әтәч — ул сау-сәламәт түгел. Урлашуны телгә алабыз икән, безнең халык ул һөнәрдән башка мәңге яши алмый, шундук аяк суза. Сугышмыйча, кан коймыйча, ә тулаем алганда күндәм һәм карусыз кол шикелле яшәргә җыенсаң, сине күрше халык, көндәш дин яулары изеп китә. Гомумән, үзен-үзе якларга әзер тормаган дин озак яши алмый. Андый дин — ул коллар, җебегәннәр һәм куркаклар дине...

Владимир кенәз алда әйтәсе сүзен уйлап куйды, ахры, тәхетендә башын артка ташлап, туарылып көлде:

— ...Ә шәраб, аракы, хәмер тыю хакында Мөхәммәт пәйгамбәр Коръәненә юкка гына язган. Кит, әкәмәт! Урыс халкы эчемлектән башка ничек яши алсын? Ул өч мәртәбә сөннәткә утыртуга риза булса булыр, әмма аракы белән хәмерне мәңге кире какмас!..

Якуб Ногман инде тамырына балта чабылган тал чыбыгы кебек бөгелеп төшкән иде, Владимир кенәз яңа канат куйды.

— Динегездәге кимчелекләр хисапсыз күп булса да, бөтенләй баш тартыйм. Бизмәнгә салып үлчәтү, илегездәге гореф-гадәтләрне капшап карау өчен Болгар җиренә ун кешелек илчелек җибәрәм мин. Ләкин христиан диненең асылын белер өчен ул яралган җиргә, юнаннар иленә үзем барып кайтам. Менә шуннан соң җыелып янә бер үлчәрбез, әмма хәл итәрбез. Урыс дәүләте бөек динсез яшәргә тиеш түгел!

Владимир юнаннар иленә бару хакында юкка гына киная ташламады. Кайсаркала белән Киев арасында элемтә җепләренең өзелеп торганы юк, ә соңгы хәбәрләр кенәз күңеленә аеруча хуш килә иде.

— Юнаннарның Цимисхий атлы кайсарлары кисәк үлеп киткән. Ул бернинди дә нәзер-әманәт язып калдырмаган. Кайсаркалада хәзер мәхшәр хөкем сөрә. Пайтәхетне Фока исемле фетнәче сәрдәр чолганышка алган, ә Цимисхийның туганнары Василий белән Константин сарайда бикләнеп ни кылырга белми утыралар икән...

Владимир шундук утыз меңнән артык җайдакны ияргә атландырды. Аңлатмасы шома, ипле килеп чыкты:

— Менә төшәм, менә төшәм дип, үзләре синең авызыңа кереп барган җимешләрне өзеп капмас өчен ахмак булу кирәк. Юнаннарда йорт хуҗасы да калмаган, аларның ихаталарын саклаучы этләре дә бәйдән качкан икән. Атам Святославны кол урынына хур итеп куганнары өчен үч алырга иң-иң кулай вакыт. Таламыйча яткан кулга буар елан чире кагыла да ул үз атасының бугазына килеп урала, ди. Елан түгел, ә очар козгын йә бөркетләр булсак, бай юнаннар утарын барып талыйк...

Үзи елгасы тамагында утырган Иске Херсон дүрт-биш гасыр буе Юнан дәүләтенең төньяктагы терәк-кирмәне булып исәпләнә иде. Шуңа юл тоттылар. Сәүдә кәрваннарын озатып йөрү бәхетен татыган берничә сәйяхчы ир авыз суларын корытып тасвирлады:

— Херсонлылар бөтен диңгез яры буйлап сәүдә итә. Боларга алтын-көмеш таулары кораб-кораб булып кайтып тора. Бәҗәнәк йә урыс кыргыйларының талаулары мөмкин, безгә үзебезнең каланы ныгытырга кирәк дигән сылтау белән юнан кайсарына ясак та түләмиләр. Болар күккә төкереп, балда-майда йөзеп кенә яши. Утта яндырылган балчык торбаларны ялгый-ялгый, һәр урамга, һәр тыкрыкка суүткәргечләр дә көйләгәннәр инде...

Херсонны тоташ камалышка алып, озын ай буена һөҗүм, янгын, тәшвиш оештырып караулар бернинди уңышка да китермәде.

— Өч ел торсам торам, әмма калагызны тезләндерми китмим! — дип куркытты Владимир кенәз, дивар янына килеп, чарасызлыктан тагын ни кылырга белми.

Каладагылар ыжлап та карамады. Кенәз, үҗәтләнеп-ярсып, даладан дивар буена олау-олау туфрак ташытырга тотынды. Херсонлылар: «Бу кыргый ни кыйлана?» — дип баш ватты, берни аңламады. Владимир «сер»не үзе ачып салды.

— Тышқы якта олы тау төзим дә калагызга өстән бәреп керәм! Йә үзегез биреләсез, йә җимереп бетерәм, башка юл юк!

Мондый дуамаллыктан херсонлылар да өнсез калды бугай. Каладан тышка җир асты юлы казып, урыслар көндез әзерләп куйган туфрак өемен төнлә белән кирмән эченә ташый башладылар. Владимир кич белән чатырына юнәлгән чагында кала тышында кибән-кибән балчык өелеп кала, тик иртән торып чыксa, ул таулардан инде җилләр искән. Янә шашына-котырына яңа меңнәрне дала ягына чыбыркылап куа кансыз кенәз.

Әмма, ни үкенеч, һәр өйнең дә бер гарибе, сатлыкҗаны, имгәге табыла шул. Беркөн таңда Владимир кенәз аяклары янына каен кайрысы уралган ук атылып төште. Кайрыдагы язуны белемлерәк боярлар кычкырып укыдылар:

— Сезнең артта, сулдагы тауның итәкләрендә ургыл чишмәләр бар. Су безнең калага торбалар буйлап шуннан агып килә. Шуларны җимерсәгез, шәһәрдә су бетәчәк... Каланы алгач мине үтермәссез. Сезне көтеп торучы Анастасий...

Атна-ун көн чамасы сусыз интеккәч, шәһәр капкаларын херсонлылар ачты. Кала башлыгы булып алган сатлык Анастасий инде кайсарлар сараендагы серне дә чишеп салды:

— Тәхетне ничек бүлешергә белмичә интеккән Василий белән Константинның Анна исемле сеңелкәшләре бар. Әле кияүгә чыкмаган, бик чибәр кыз. Юнан патшабикәсен үз хатының итү синең эчне төртеп тишмәс иде...

Владимир кенәз Херсон хакимнәрен шундук Кайсаркалага илче итеп куды.

— Кайсарларга илтеп тапшырыгыз. Мин — каган, Анна — патшабикә, бик кулай пар. Аннаны миңа кияүгә бирәләр икән, Фока дигән сатлык сәрдәрләрен үзем сытып ташлыйм. Ну әгәр дә инде... битемә төкерсәләр... Херсон урынында да көл генә калдырам, Фокага да ун мең җайдак бирәм...

«Озынколаклар» аша әүвәл патшабикә Аннаның «ризалыгы-бәясе» турында җавап кайтып төште:

— Ул кыргый җәлладка кияүгә чыкканчы, мин чиркәү манарасы өстеннән сикереп үземә кул салам! Башкача кабатлап тормагыз, исемен дә ишетәсем килми!..

Алда кояш сыман үзенә тартып-ымсындырып торган тәхет, ә кала тышында пычак кайрап көткән хәвеф бар бит әле. Игәү сыман туктаусыз үгетли торгач, горур патшабикәне дә сындырганнар. Херсонга зур корабта кәләш Анна белән бергә Василий атлы кайсар үзе килеп җитте. Патшаби-

кә Анна асылда да күз явыңны алырдай сирәк чибәр, әмма боларның да шарты катгый, кырыс икән.

— Йә хәзер үк чукынасың да христианлыкка күчәсең, йә корабтан төшеп тә тормыйча кире борылабыз!

Кайсар Василий беркадәр көттергәннән соң гына өстәп куйды:

— Христианлыкка күчсәң, Дим-тарханны[1] да сиңа туенырга бирәм.

Владимир таш диварга сөңгеләр терәп кысрыкланган ялгыз сугышчы хәлендә, чигенерлек бер ара юк иде. Карашын патшабикә Аннадан аера алмыйча, камыш сабагыдай капылт сынып төште.

— Мин риза, христианлыкка күчәм.

Шул сәгатьтә үк яр өстенә махсус корылган чатырлар эченә алып керделәр дә Владимир белән Аннага христиан-нарча никах укыдылар. Алар артыннан ук яубашлары белән урыс укчылары да Үзи елгасына куып төшерелде…*

Киевка кайтып кергәч, иң элек Владимир кенәз Саескан тавындагы барча потларны кылыч белән үзе турап атты. Нарат агачыдай биек, дәһшәтле Перунны, ат койрыгына бәйләп, тау өстеннән Үзи суына сөйрәп төшерделәр. Аннары Киев халкы өчен бердәм фәрман ишетелде:

— Барлык кешеләр дә Үзи суына кертеп чукындырылачак. Имчәк балалары өчен дә ташлама ясау, кызганулар булмый…

Айзирәк айга-елга бер мәртәбә генә күренә торган ире Владимир каршына барып, әүвәл ялынып, елап та карады:

— Аллазар белән Алхозур тәпиләренә әле яңа гына баса башладылар. Бер карынны урталай бүлешү җиңел түгел икән, алар болай да тумыштан ук чирләшкә һәм йончу булып үсә. Алар җилдән туган үксез-ятим түгел, үз балаларыңны кызган!

— Нинди Аллазар да, ниткән Алхозур ул? — дип үкереп җибәрде тормыш мәсләге бөтенләй алышынып беткән дилбегәсез кенәз. — Попны чакырып, бүген кич үк мин малайларыма Борис белән Глеб атын кушам. Ә хәзер әнә аларны кочагыңа ал да, бөтен кеше белән бергә шәрә калып Үзигә чум! Юкса мин аларны, синнән каерып алып, монастырьга бирәм!..

Аллазар белән Алхозур икесе дә кичен, ут кебек кызышып, түшәккә егылдылар.

---

[1] Дим-тархан — Тмутаракань.

* 988 елда булган вакыйгалар.

Еллар үтә тора, ә Айзирәкнең пыскып яткан ялгыз учагы янына килеп бер әрдәнә утын да өстәүче юк. Кичен ятса — ялгыз, иртән торса — ялгыз. Игез бала үсеп килү, әлбәттә, зур куаныч. Ләкин әллә нигә үги бала, ятим бала төсле уңмаганнар, бәхетсезләр алар. Айзирәк инде ничә еллар буе сынап яши. Уенга-мазар чыгып киттеләрме, йә Аллазар тип-тигез җирдә аягын сындырып кайта, йә Алхозурның адым саен авыз-борыны каный. Владимир кенәзнең йөгерешеп йөргән малайлары гына да уннан артык хәзер. Ялагай тиуннар, боярлар алар өчен сирәк-мирәк ау да оештыра. Аллазар белән Алхозур анда чыгып китсәләр дә, нәкъ шул ук хәл. Кирәк чакта гына йә берсенең җәя кереше шартлап өзелә икән, йә икенчесенең борын төбеннән җәнлек качып китә. Өлкәнрәк агалар ару гына тәпәлиләр, ахры, игезәкләр сарайга бик еш кына күгәргән йә елаудан шешенгән күз төпләре белән кайтып керә. Айзирәкнең малайлар сөйләшкәнне колак чите белән генә ишетеп калганы бар.

— Изяслав белән Чонтык Ярослав[1] юри алдан кисеп куйганнар ул минем җәя бавын. Бер карабаш тиште.

— Святополк баш күтәрергә ирек бирми безгә. Теге чакта төлкене тик шул гына сызгырып куркытты бит...

Айзирәк кенәзнең балаларын хәтердән барлап чыга. Святополк — Ярополк атлы кенәз үтерелгәч, аның хатыны Ангелина табып баккан бала. Владимир ул баланы үзенеке дип игълан иткән итүен, ләкин Святополк егерме яшен күптән тутырса да, кенәз аңа бер кала да бирми. Изяслав — әтисе белән ике абыйсы суеп үтерелгәч, Владимирга кияүгә чыгарга көчләп мәҗбүр ителгән варяг хатыны Рогнеда тапкан бала. Изяслав та байтак яшькә җитеп килә инде, ә Владимир аны да үз янында буш ояга утыртылган ана каздай тота. Аксак Ярослав та шул ук Рогнедадан туган бала бугай. Айзирәк аларны әле һаман ятлап бетерә алмый. Тик һәммәсенең дә Владимирга үчле булып яшәүләрен белә. Үзләре ныклап аякка баса алмаганга күрә, алар үч-ярсуны Айзирәк балалары өстенә чыгарып түгәләр, җай табылган саен типкәлиләр инде.

Шулар арасыннан аерып алу өчен Айзирәк Аллазар белән Алхозурга гел Коръәнне укый. Әлбәттә инде, ныкышереп кенә. Сабыйлар бусаганы атлап чыгуга ук Борис белән Глебка әйләнәләр, алар бүлмәдә бикләнеп утырган

[1] Чонтык — бер аягы кыскарак, гарип кеше. Ярослав балачактан бирле шул кимчелек белән иза чиккән.

чакта гына күндәм мөселманнар. Икесе дә инде күптән укырга-язарга өйрәнделәр, йөзәрләгән сүрәләрне ятлап бетерделәр, алар өчен сөенерлек кенә. Ләкин Айзирәк бүлмәсендәге учак җылысыннан көнләшүче юха еланнар табылдылар бугай, Аллазар белән Алхозурны әледән-әле монастырьга илтеп бикли башладылар. Әниләре салган белем оеткысы шифалы чиргә әверелгән, ахры, игезәкләр Иске Инҗил, Яңа Инҗил китапларын да ярты лаш-ярты лаш ятлап өлгергәннәр. Белем бөкрене чыгармый, аны дөя өркәче урынына сыртка күтәреп йөрисе дә түгел, әйдә, ятласыннар. Көнче агалары боларга зыян-зәүрәт кенә салмасыннар берүк...

Беркөн сарайда ачы гауга чыкты. Владимир үзенең иң карт хатыны булган Рогнеданы сараеннан куып, кала читендәге утарына күчерергә ният иткән икән. Газиз әтисен, ике абыйсын суюны кичергән Рогнеда гаилә түшәгендәге хыянәтне гафу итә алмаган, аннан йөз чөергән ире янына пычак күтәреп кергән. Инде кадап үтерәсе дә булган, имеш, Владимир кенәз соңгы мизгелдә аңа беләген каршы куеп өлгергән, ди. Барча кенәзбикәләрне, балаларны да Рогнедага хөкем карары чыгарганны тыңларга чакырдылар.

Залга аяк басуга ук игътибар итте Айзирәк: кенәзнең сул кулы, чыннан да, канга баткан иде. Уң кулына барыбер кылыч тоткан. Йөзендә нур юк, кыяфәте шашкын. Рогнедага таба төбәлгән дә тамак төбе белән генә, нәфрәт кушып сөйли:

— Менә монда җыелган килендәшләреңә карар чыгарсыннар, аннары мин сине үз кулларым белән суячакмын. Гафу итү, чигенү булмаячак!

Һәммә хатын, барча бала-чага кайнар казанга чумдырганда кебек куырылып, тын алырга да куркып утыра иде, Рогнеданың өлкән улы Изяслав чәчрәп чыкты:

— Кая, кылычыңны китер миңа, әткәй! Мондый хыянәтче хатынны үзем тотып турыйм!

Владимирның күзләре акаюдан маңгаена менде.

— Син нәрсә, имгәк! Бу бит синең анаң! — дип яралган арыслан шикелле үкереп җибәрде ул. — Ул сине шушы җир йөзенә табып үстергән бит!

Изяславның йөзендә бер төк тә селкенмәде.

— Ә ни пычагыма дип алайса кулыңа кылыч алдың? Кизәнгәнсең икән, чаба да бел! Йә гел күтәрмә, коткы салма!

— Ну, юха җан! — дип, читкә төкерде дә, кылычын идәнгә зеңгелдәтеп ташлап, Владимир ишектән йөгереп чыгып китте...

Икенче көнне Рогнеда белән Изяславны Витебск дигән калага озаттылар.

Идел буен яшендәй көйдереп коточкыч хәбәр үтте:

— Суздаль дигән калачыкта урыслар ачлыктан балаларын ашый башлаганнар!..

Кыргый афәт сукыр кеше кулындагы зәһәр кылыч сыман уңны-сулны белмичә, бар җиһанны айкап килә иде. Беренче булып, Ука елгасы тамагында утырган Янкала сугым малы кебек тавыш-тынсыз ауды.

— Ач урыслар һәрбер ихатаны нигезенә тикле талаганнар, кирмән хәзер пеләш баш шикелле шыр ялангач калган...

Мул карлы кыштан соң кузгалган язгы ташкын вакытында тар елгалардагы йөзәрләгән-меңәрләгән боз кантарлары, утарга ябылган ярсу үгезләр шикелле, бер-берсенең өстенә өелешеп, сөзешә-сөзешә, тибешә-тибешә, ыңгырашып-үкереп, кайный-кайный ага. Суздальдан күтәрелеп чыккан ач әрвахлар чирүе дә нәкъ менә шул язгы ташкын, йә булмаса, челләдәге коточкыч янгын сыман, Иделнең ике як ярын да сытып-ялмап, Болгар уртасына якынайды.

Казан кирмәненең диварлары әле һаман яртылаш та төзелмәгән иде. Ушкуйлар хакындагы көенечле хәбәр Янкаладан яшендәй тиз килеп ирешсә дә, дивар араларындагы өзек-ярыкларны имән бүрәнәләр, ком-таш белән аннан-моннан гына ныгытып өлгерделәр.

Сал-Сал баскыннарны Корыган елга буена чыгып каршы алды. Ач әрвахлар чирүен һәммәсе дә өрәкләр өеренә тап булгандай акаеп күзәттеләр. Тимер мичкәгә ябып ыслаган балык төсле, корсаклары аркаларына ябышкан арык карачкылар. Күзләре агач түмәрендәге тишекләр шикелле эчкә батып калган. Корыган нарат ботагыдай кипшенгән куллары тартып озынайткан сыман, тезләренә җиткән. Яңак сөякләре терсәк очы кебек тырпайган, борын яфраклары әрекмән яфрагы шикелле юп-юка, арба тәгәрмәчендәге тырнаклардай сирәгәеп калган тешләре шак-шок килеп тора. Киемнәрен адәм теле белән аңлатмалы түгел, эт өере талагандай иске, ертык, кылка. Аның каравы коралларны байтак эләктергәннәр. Яртысында — хәнҗәр, кылыч, җәя. Калганнары икешәр аршынлы сапка утыртылган сөңге, сәнәк, чалгы тотып баскан. Сизелеп тора: бугазга ябышсалар, болар кан эчеп туймыйча җибәрәчәк түгел.

— Сугыш арбаларын алга чыгарыгыз! — дип үкерде Сал-Сал. — Боларны башка ысул белән өркетүе читен.

Ике гаскәр арасында яткан үзәнлеккә пар атларга җигелгән уннан артык олау атылып килеп чыкты. Хәзер инде баскыннар аһ иттеләр. Олау дигәннәре ике генә тәгәрмәчле

җиңел арбалардан хасил. Арбалары тоташ калканнарга, аргамаклар тимер көбәләргә бөркәнгәннәр. Тәртә башларына өчәр япьле сөңге, үрәчәләргә беләк буе булып чыгып торган кылычлар беркетелгән. Тимер калканнардан корылган тирмәләр эченә икешәр-өчәр яугир баскан бугай. Берсе дилбегәләр тартып ат куалый, калганнары калканнар арасындагы ярыклардан ук яңгыры коя.

Сугыш арбалары баскыннар гаскәрен утлы кылычлар, дәү сөңгеләр төсле алты-җиде кисәккә телеп-ярып узды. Әллә калканнар астына качкан яугирләр угыннан, әллә үрәчә-тәртәләргә көйләнгән кылыч-сөңге йөзеннән дистәләгән баскын авып калды. Баскыннар җавап итеп очырган ук яңгырыннан файда күренмәде. Йә уклар аргамакларга бернинди дә зыян-зәүрат салмый, йә, инде аргамаклар абынып егылса да, болгарлар аларны бик тиз генә яңалары белән алыштыра иде.

Баскыннар бозлы яңгыр астында чебеш көтүе сыман төрле якка сибелеп кача башладылар. Арада ис-акылын җуеп бетермәгән атаманнары калган икән әле, кылыч-сөңгеләрен җиргә ташлап, шулар аваз салды:

— Биреләбез, яуны туктатыгыз! Без сезнең белән үзара солых төзеп куйган кардәшләр бит. Дуслык, дуслык!

— Ә-ә, артыгызга ут капкач, шәрә икәнегез исегезгә килеп төштемени? Капкынга көйләнгән майлы калҗаны бушлай гына йотарга исәп тотсаң, шулай эләсең ул! — дип кәпрәеп сөйләнсә дә, Сал-Сал яуны туктатырга әмер бирде.

Баскыннар чирүенең башлыклары белән Казансу ярында очрашып сөйләшкәндә болай килештеләр:

— Без ун корабка төяп ашлык җибәрәбез, ә сез Янкаланы яңадан торгызасыз...

Солых Киевтагы Владимир кенәз күңеленә хуш килмәгән. Суздаль тирәсендәге авыллардан җыелган бер чирү ач ирләр Смоленск ягына да барган һәм байтак биләмәне талап кайткан икән. Якун атлы сыңар күзле варяг сәрдәр ышыгына басып, Владимир Суздаль өстенә үч алырга килгән һәм меңәрләгән ач әрвахны тураклатып аткан. Туймас кенәзнең «әмер-үтенече» Болгар иленә дә килеп ишетелде:

— Суздаль янында меңнәрчә туганыгыз ачка кыркылып ята. Аларга янә бер көрван ашлык белән ярдәм кулы сузу артык булмас иде. Казаныгызда төзелгән дуслык солыхын яңартырга вакыт...

Хәсән хан җәдәләшеп-карышып вакланмады, әмма яңа көрван башлыгына катгый таләп куйды:

— Нәфес белмәс ул кенәзгә тапшыр. «Болгарларның сәүдә көрваннары урыс иленә аяк басарга дер калтырап яши.

Сезнекеләр талап кына туймый, безнең сәүдәгәрләрне суеп бетерәләр. Йорты-ихатасы рәттән туры килгән ике күрше кунакка йөрешеп көн күргә тиеш. Шулай булмаса, алар үзара талаша йә урлаша башлый. Бүләк-күчтәнәчне чын күңелдән күтәреп кергән бер күршедән икенчесе капка-ишек ачкан өчен түләү-фәләп дә, аяк ялы да алмый. Әгәр дустанә күрше булып яшисең килә икән, ике ызан арасында сәүдә юлын булдыр. Синең канат астында яшәгән вак-төяк кенәзләреңә, аяк ялы, тамга дигән булып, болгар кәрваннарын талаудан туктасыннар...»

Ике-өч айдан соң Болгар дәүләтенә сөенечле хәбәр кайтып төште:

— Владимир кенәз болгарларның сәүдә кәрваннарын урыс җирендә түләүсез йөртү турындагы солыхка кул куйган*.

69

Владимир кенәз сараеның нигезенә әйтерсең лә янә янгын капты. Ләһ[1] кайсарының кызына өйләндергән һәм үзенең улы дип иглан иткән Святополк көннәрдән бер көнне табын артында энә белән кадагандай астан чагып алды:

— Атай миңа туенырга бер биләмә бүлеп бирә белмәде инде. Аеры өстәл сорап, бабай янына качасы булыр, ахры.

Владимирның хәтерендә үз туганын суйган кансыз Ярополк калкып чыкты бугай, ул Святополкны шул кичтә үк зинданга ташлаттырды. Әмма яман үрнәк үләт чире кебек бик тиз йога, диләр. Хәзер инде аның тирәсендә сарайдан сөрелгән Рогнеданың улы Чонтык Ярослав шөпшә сыман бертуктамый гөжелдәргә тотынды:

— Ата кеше буе ишек ниргәсе чаклы булган һәр малаен башка чыгарырга тиеш инде ул, тиеш инде. Юкса түбәләре белән ниргәгә бәрелә башлый бит ул малайлар, башлый, башлый...

Куенында зәһәр елан асрап ятасы килмичә, ул Чонтык Ярославны Балтыйк буендагы Новгород каласына үк олактырган иде. Тегесе данлы шәһәр нигезенә әле сыңар казык та кагып өлгермәде, ә кәҗәләнеп кычкырган тавышы бик тиз килеп җитте:

— Моннан ары Новгород кенәзлеге аерым дәүләт булып яши башлаячак. Мин Киевка ясак түләүдән бөтенләй баш тартам!..

---

* Киев дәүләте белән Болгар иле арасындагы мондый беренче солыхның 1006 елда төзелүе мәгълүм.

[1] Ләһ — поляк.

Бу чаклы әрсезлектән коелып төшкән ата әүвәл бот чабачаба көлгән генә булды:

— Ну баш бар да соң монда! Атасының җиләненнән итәк кисеп алып, аерым чатыр кормакчы, баштанаяк ябынмакчы була. Ай-яй, зиһенле бу!*

Ләкин ике-өч ай буе ясак кәрваннарын көтеп яшәү бернинди нәтиҗәгә дә китермәгәч, шашкын карар кылды:

— Киевтагы барча ирне иярге күтәрегез! Аксак тәренең ыштанын салдырып, бөтен Новгород каршында артын ярып кайтам!

Гаилә колагына гына ишеттерәчәк сүзе башка иде:

— Чукынган хатыннар үстергән малайларга ышанычым тәмам коргаксыды. Без сәфәрдә йөргән чакта, олугбәк урынына болгар хатыныннан туган улым Борис кала!..

Юк, Айзирәк балаларына тәхет биеклеген тәтеп карарга насыйп булмаган шул. Владимир кенәз биленә кылычын да тагып өлгермәде, аны Берестов хәрамханәсендәге бер җария ятагыннан җансыз калган көе алып кайттылар. Ә аннары инде кенәз сараенда канлы туфан купты.

Атасы үлгән кайгыдан дип, Святополкны зиндан чокырыннан чыгарганнар иде. Кай арада табып, нинди хакка яллап өлгергәндер инде, ул сарайга йөзәр-йөзәр юлбасарлар озатуында кайтып керде. Бер кулында кылыч, икенчесендә хәнҗәр, сүзләрне ут шикелле чәчеп кенә тора:

— Аның өчен үги булсам да, мин кенәзнең иң-иң өлкән улы. Тәхет миңа тиеш. Мин үземне үзем бүгеннән үк олугбәк дип игълан итеп куям!..

Шәһәр читендә качып йөргән Борис янына берничә бояр килеп, егетне баш күтәрергә димләп карадылар:

— Атаң сине булачак олугбәк дип билгеләп куйган иде. Йола буенча тәхет сиңа тиеш. Безнең бер сызгыруга ун мең кешелек гаскәр җыела. Әйдә, атаң урынына сине утыртабыз.

Борис кырт кистереп кенә каршы төште:

— Юк, Святополк минем әтием урынына калган кеше. Аңа каршы кул күтәрә алмыйм.

Гәрчә Борисның һәр сүзе түкми-чәчми барып ишетелсә дә, Святополк үзе яллаган катыйльләргә кансыз әмер бирде:

— Болгар хатыныннан туган Борис белән Глеб үтә зиһенлеләр. Аларны боярлар гына түгел, чиркәүләр дә яклый. Бер көтүдә алты-җиде тәкәне башлык итеп йөртсәң, тәртип бетә. Миңа энекәш булып саналган кенәзләрнең һәммәсен дә суеп бетерегез!

---

* Рәсәй тарихында беренче булып әтисенә каршы кылыч күтәргән шушы бәндәгә Мудрый дигән кушамат тагылып йөри.

70

Киевтан көч-хәл белән качып котылган Якуб Ногманның тәүге сүзләре үк болгар түрәләренең ис-акылын алды.

— Святополк, эт җан, Аллазарга чатыр япмалары аша сөңге кадаттырган. Ул әле исән калган булган, бәгырь. Тик катыйльләр кулыннан котылып буламыни? Чатырдан шуышып чыгуга, кылыч белән чабып өзгәннәр балакайның башын. Ә Алхозурны аның үз пешекчесе үк, катыйльләр акчасына сатылган Горясер атлы бәдбәхет, сарык бәрәне урынына тез астына салып, пычак белән суйган. Менә шулай әрәм булды безнең газиз улларыбыз*.

Болгарлылар күз яшьләре түгеп елаштылар:

— И-и, чит ояга барып күкәй салган кәккүк хәленә калган икән безнең Айзирәккәй. Мондый ачы кайгыларга япалгыз көе ничек түзә микән? Нигә үзең белән бергә алып кайтмадың ул мескен балакайны?

— Күпме үгетләп карадым, тыңламый бит. Чит-ят җирдә япа-ялгыз хәлдә ятып калмасыннар, үзем саклармын, ди. Аның бу җиһанда таянырдай кешесе юк бит инде, аны нишләтәсең?

Сакал-мыеклары чаларып чыккан Сал-Салның җаны болай да пыялага кунган күбәләк шикелле бәргәләнә иде, соңгы сүзләрне ишеткәч бигрәк бетеренде.

— Юк, Айзирәкне урыслар кулына ташлап калдырмыйбыз, — дип өзеп салды ул кинәт. — Миңа күпме гомер буйдак көе интегергә була? Үлсәм үләм инде, әмма Айзирәкне Туган иленә барыбер алып кайтам!..

* * *

Казансу аръягында беркөнне бәп-бәләкәй генә җайдаклар төркеме пәйда булды. Юл йөреп азау тешен чыгарган кешеләр җитез абайларлык: меңәр чакрым араларны мең михнәтләр аша кичкән сәйяхчылар болар. Атлары ябыккан, җайдакларның киемнәре тузган, ләкин йөзләрендә сөенеч, җиңү тантанасы учактагы ялкын шикелле янып-балкып тора. Һәммәсе дә, иярләреннән күтәрелә төшеп, елга аръягындагы тау башында мәчет манаралары, сарай гөмбәзләре белән әтәчтәй кукраеп утырган калага төбәлгәннәр.

— Син киткәндә бу урында сыңар казык кына калган иде. Ә хәзер, күрәсеңме, нинди матур кала калкып чыкты. Байтак еллар элек син Казансу буена утырып бер аяныч хикәят сөйләгән идең миңа, хәтереңдә микән? Имеш, Нурга-

* Киевта 1015 елда булган канлы вакыйгалар турында сүз бара.

ли атлы батырны Елантау өстендә кала корырга ният иткән өчен бу тауның хуҗасы — канатлы аждаһа сукырайткан булган. Ул аждаһаны да, дошманнарны да куып җибәрдек без. Аллага шөкер, бу тауга без хуҗа. Нургали батырга язмаган өр-яңа каланы синең белән мин дә, икәүләп төзешербез. Кемнәр белә, бәлки, бу Казан каласы киләчәктә пайтәхет тә булыр. Ни генә язмасын, үз бәхете белән, сау-сәламәт сабыйдай үссен иде. Син туган җиреңә кабат әйләнеп кайттың, аякларың төкле була күрсен, Айзирәгем минем, җанашкаем! — дип, янындагы юлдашын күкрәгенә кысты пәһлеван ир.

Кечкенә гәүдәле җайдак та назлы аваз салды:

— Амин, амин, шулай була күрсен, Сал-Сал батыр. Минем кебек кол хәленә төшү, туган халкыннан аерылып япаялгыз көю газапларын күрмәсен бу шәһәр. Берүк озын гомерле бул, азат һәм хөр яшә, газиз Казан калам!

2004 ел, Чаллы.

Литературно-художественное издание

Вахит Имамов
(Имамов Вахит Шаихович)

КАЗАНСКАЯ КРЕПОСТЬ

Исторический роман

(на татарском языке)

Мөхәррире *Ф.М.Хафизов*
Рәссамы *В.Е.Булатов*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Ї.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *В.А.Савельева*
Корректорлары *Г.Х.Сундукова, Л.З.Шиһапова, Г.М.Хәбибуллина*

Нәшриятка 04184 нче номерлы лицензия 2001 елның
6 мартында бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 15.06.2005. Форматы 84×108 $^{1}/_{32}$.
Офсет кәгазе. «Kudriashov» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма
табагы 12,60. Шартлы буяу-оттиск 13,02. Нәшер-хисап табагы 14,17.
Тиражы 5000 экз. Заказ А-439.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул. Баумана, 19.
http://tatkniga.ru
e-mail: tki@tatkniga.ru

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

ААҖ «Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.